ISSN 0206—478

# Казан утлары

8. 1992



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ НИГЕЗЕНДӘ

ТАТАР МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЕН ҮСТЕРҮДӘГЕ
КАЗАНЫШЛАРЫ ӨЧЕН

**„КАЗАН УТЛАРЫ“ ЖУРНАЛЫ
РЕДАКЦИЯСЕ КОЛЛЕКТИВЫ**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАКТАУ ГРАМОТАСЫ

БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНӘ

**Татарстан Республикасы Президенты** М. Ш. ШӘЙМИЕВ

**Казан, Кремль**
**18 июнь, 1992 ел**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**8**

**(838)**

**1992**

КАЗАН

## *Бу санда*

Ниятебез пакь, юлыбыз туры (Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевнең 1992 елның 19 июнендә Бөтендөнья татар конгрессындагы нотыгы) ........ 3

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ж. РӘХИМОВ. Батырша. *Роман* ........ 14
Г. МОРАТ. Ачлык. *Поэма* ........ 53
Г. ГОМӘР. Юлбарыс тырнагы. *Мажаралы чытырлык* ........ 61
ЗОЛФӘТ. Матур бабай. *Шигырьләр* ........ 89
Р. ХАФИЗОВА. Аккошлар сере. *Парчалар* ........ 94

ПУБЛИЦИСТИКА

И. СӘЛАХОВ. Кара көннәр. *Истәлек* ........ 96

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

М. ГАЙНЕТДИНОВ. XVIII йөздә татар яңарыш хәрәкәте ........ 102

СҮЗЛӘР ТАРИХЫННАН

Н. ФӘТТАХ. Башкорт һәм башкырт ........ 116

ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

М. ЮНЫС. Мал буләбезме? ........ 125

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

В. БУЛАТОВ. Гореф-гадәт, йолаларыбыз ........ 129

БЕЛОРУС ТАТАРЛАРЫ АВЫЗ ИҖАТЫННАН

Тапкыр егет. *Әкият* ........ 151

ӘДӘБИ МИРАС

Балта әкияте ........ 157

Л. КАРАН. Сөембикә һәм татар бәйсезлеге ........ 158
Йөрәктәге тынгысызлык. *(Язучы Газиз Кашапның тууына — 50 ел)* ........ 160

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Рөстәм Мингалимов**

**Фәрвәз Миңнуллин**

**Минтаһир Минһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**

***(баш мөхәррир урынбасары)***

**Индус Таһиров**

**Марс Шабаев**

***(җаваплы сәркатип)***

**Тәүфикъ Әйди**

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

СӘНГАТЬ

Г. ЗӘЙНАШЕВА. Сагынулары биниһая ........ 166

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Үр артында үрләр ........ 174

ЮМОР-САТИРА

М. СӘЛИМОВ. Бигрәк шәп илебез! *Сатирик хикәя* ........ 177

ГЫЙБРӘТЛЕ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Тарихыбыз хатирәләре ........ 181
Рәсәй империясе тарихыннан ........ 182

Күченүләрдә үзгәреш ........ 182

Котлыйбыз! ........ 184
Уймак уйлар ........ 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 187
Тышлыктагы сурәтләр ........ 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Наши помыслы чисты, путь — справедливый (доклад Президента Республики Татарстан М. Ш. ШАЙМИЕВА на Всемирном конгрессе татар 19 июня 1992 г.)
«Проза и поэзия»: продолжение романа ДЖ. РАХИМОВА «Батырша», приключенческая быль Г. ГУМЕРОВА «Когти тигра», рассказы Р. ХАФИЗОВОЙ, поэма Г. МУРАТОВА «Голод», стихи ЗУЛЬФАТА.
«Публицистика»: статья И. САЛАХОВА «Черные дни».
«К истории татарского народа»: статья М. ГАЙНУТДИНОВА «Движение национального возрождения в XVIII веке».
«Актуальная проблема»: статья Н. Фаттаха о происхождении слова «башкорт», статья М. ЮНУСА «Что мы делим?»
«К истории культуры»: В. БУЛАТОВ. «Наши обычаи, обряды».
«Из фольклора белорусских татар»: сказка «Находчивый джигит» (перевод Ф. Фаизова).
«Литературное наследие»: сказка, статья Л. Карапа «Сююмбикэ и независимость татар».
«Неугомонность» (К 50-летию писателя Г. Кашапова).
«Искусство»: статья Г. ЗАЙНАШЕВОЙ о творчестве певца Р. Ильясова.
«Книжное обозрение»: статья Ф. Галимуллина о творчестве писателя З. Зайнуллина.
«Юмор и сатира»: сатирический рассказ М. САЛИМОВА «Как хороша наша страна!»
«Поучительные сведения»: «Страницы нашей истории», «Завоевания Российской империи», «Демографическая таблица на 1991 г.»
К 50-летию писателя Р. Валиева.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: праздник Сабантуя (Березовая роща). Татарский курэш. Портрет известного писателя, лауреата премии им. Г. Исхаки Рабит Батуллы. Фото М. Козловского.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.

Производствога бирелде 02.07.92 ел. Басарга кул куелды 06.08.92 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 24382. Заказ В-301. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

# НИЯТЕБЕЗ ПАКЬ, ЮЛЫБЫЗ ТУРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ
## МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВНЕҢ
## 1992 ЕЛНЫҢ 19 ИЮНЕНДӘ
## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНДАГЫ

## НОТЫГЫ



Кадерле кунаклар, ватандашлар — татар халкының газиз уллары һәм кызлары!

Без бирегә, үзебезнең тарихи Ватаныбызга, үз дәүләтебез Татарстанга төрле тарафлардан, төрле илләрдән жыелдык. Без — бүген Җир шарында көн күрүче татарларны берләштерүче, барлык татарлар исеменнән рәсми сүз әйтә алучы олы һәм вәкаләтле мәҗлес. Ата-бабаларыбыздан калган, тарихның иң кырыс җилләрендә дә тузмаган-таушалмаган гадәт буенча сезгә: «Исән-имин килеп җиттегезме? Өстәлләребез түгәрәк, мәҗлесебез мөбарәк булсын!» — дип әйтергә рөхсәт итегез...

Ә тарих җиле, язмыш җиле татарларны континентлар, илләр буйлап сипкән дә сипкән — ата-аналар улларыннан-кызларыннан, туганнар берберсеннән, дуслар дусларыннан аерылган. Без бүгенгә кадәр:

*Себелә чәчәк җилләр искәндә,*
*Өзелә үзәк исемә төшкәндә,*

— дип бер-беребезне сагынышып, сулыгып-сулыгып җырлыйбыз.

Бүген Казаныбызга Башкортстанда, Үзбәкстанда, Казагыстанда, Түмән өлкәсендә, Уралда, Идел буенда, Мәскәүдә һәм Санкт-Петербургта, Себердә, күрше республикаларда һәм өлкәләрдә, Бердәмлек дәүләтләрендә яшәүче ватандашларыбыз килде. Татарлар көн итмәгән республиканы яки өлкәне табуы кыен һәм алар барысы да дәүләтебезнең башкаласы Казанга үзләренең вәкилләрен җибәргәннәр.

Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез хакында аерым әйтергә телим. Озак еллар буе без алар белән әйбәтләп аралаша алмадык. Монда безнең гаеп юк. Тарих, ачы язмыш шулайрак булды. Үзгәртеп корулар белән бу бәйләнешләр юлга салына башлады. Татарлар Татарстанга

килеп мәдәни, фәнни һәм экономик элемтәләр урнаштырдылар, сабантуйларда булдылар, үзләренең туган-тумачаларын, ата-бабаларының каберләрен эзләп таптылар, яңа дуслар булдырдылар. Ә безнең гражданнар туганнары, дуслары, коллегалары янына башка илләргә бардылар. Без моңа чын күңелдән шатланабыз. Һәм, ниһаять, безгә АКШтан, Төркиядән, Финляндиядән, Германиядән, Польшадан, Япониядән, Австралиядән, Кытайдан, Швециядән, Норвегиядән, Румыниядән абруйлы делегацияләр килгән күркәм көн дә җитте. Татарстан Республикасы аларның барысына да: «Уртак Ватаныбызга рәхим итегез, кардәшләр, милләттәшләр!» — дия ала. Кайда гына яшәсәләр дә, татарлар Татарстанның чын патриотлары булдылар. Һәм моның өчен мин аларның барысына да олы рәхмәтемне белдерәм!

Минем Указым нигезендә чакырылган бу Конгресс татарлар яши торган төбәкләрдә халыклар арасындагы дуслыкны тагын да ныгытуга юнәлдерелгән фактор булып хезмәт итәр дип өметләнәм һәм моңа иманым камил. Безнең ниятләребез ак, алар беркемнең мәнфәгатенә дә аяк чалмый. Һәм без бу хакта бөтен дөнья каршында ачыктан-ачык әйтәбез.

Халкыбыз өлешенә михнәтле язмыш туры килде. Анда горурланып сөйләрлек сәхифәләр булган кебек, үтә авыр түбәнсету еллары да булды... Бүген узганнарны искә төшереп яраларга тоз саласы да килми, ләкин дәреслекләрдә, фәнни һәм матур әдәбиятта тарихыбызның гаять дәрәҗәдә бозып күрсәтелүе йөрәкне әрнетә. Татарлар турында ялган-уйдырмалар бихисап күп җыелды шул. Кайбер халыкларда татар сүзе үзе үк курку һәм ышанмаучылык тудырды. Татар халкы мондый гаделсезлеккә лаек түгел. Ул гомер-гомергә тыныч хезмәт белән шөгыльләнде, икмәк үстерде, сәүдә итте, китаплар бастырып таратты, татар балаларына гына түгел, Шәрык халыкларының күпчелек ул-кызларына мәгърифәт нуры чәчте, укытты, сугышырга туры килгәндә дә, фәкать үзенең газиз җирен яклады. Без дөнья җәмәгатьчелеге аңында «явыз» татарлар, татар-монгол изүе хакында уйдырмаларны юк итәргә, безнең халкыбызга һәм республикабызга карата ялган карашларны бетерергә тиеш.

Без гасырлар буена кешеләрнең аңына сеңдерелгән таушалып беткән фикерләрдән арынуның гаять кыен эш икәнен аңлыйбыз, татарлар турында чын дөресен генә бәян итүнең каһарманлыкка тиң икәнен беләбез, шуңа күрә безнең халкыбызны ачыктан-ачык яклаучы Лев Николаевич Гумилев кебек тарихчыларга чиксез рәхмәтлебез. Тик, кызганычка каршы, мондый галимнәрне бармак белән генә санарлык шул әле.

Татар халкы үзенең үсешендә Төрки каганлыгы, Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларын узды. Аның артында мең еллык дәүләтчелек тарихы тора. Заманында бездә Алтын Урда яки Казан ханлыгы чорларына караган хәлләр турында бөтенләй сөйләнмәде һәм язылмады. Бүген без турыдан-туры әйтергә тиешбез: бик борынгы заманнардан башлап хәзерге көннәргә кадәр татарларның тарихы тулысынча, дөрес һәм бернинди бозуларсыз күрсәтелергә тиеш. Бу — безнең ата-бабаларыбызның изге мирасы һәм без бер генә тарихи гамәлебездән дә баш тартырга җыенмыйбыз.

Татар милләтенең тарихы гаять катлаулы һәм фаҗигале. Гөрләп чәчәк атып утырган Болгар дәүләте һәлакәте — югалтуларның иң әрнүлесе һәм зурысы. Фәкать үзенең түземлеге, мәгърифәтле һәм зирәк булуы аркасында гына халкыбыз исән калды, аякка басты һәм Алтын Урта дәүләтендә лаек урын алды. Алтын Урда җимерелеп, Казан, Себер, Әстерхан, Кырым ханлыклары оешкач, үсәр өчен халык яңадан үзендә көч тапты.

Тарихта күбрәк хәрби походлар һәм «дошманнарны» җиңү бәян ителә. Күрәсең, моңардан котылып булмыйдыр. Ләкин тарихта халыклар арасындагы сәүдә һәм мәдәни бәйләнешләр зуррак әһәмияткә ия. Тарих гаять авыр ач елларда татарлар һәм русларның бер-берсенә ярдәм

итүләре, безнең төбәктән чыккан осталарның рус шәһәрләрен төзүдә катнашулары, һөнәрчелек әйберләре, мехлар, бизәнү әйберләре алышулары хакында күп кенә гыйбрәтле фактларны саклаган. Тарихчы М. Худяков: «Руслар дәүләтчелек культурасы нигезләре белән татарлар аша танышканнар»,— дип яза. Татарлар һәрвакыт үзгә диннәргә тигез карадылар, башка халыкларның мәдәниятләрен ихтирам иттеләр. Безгә бүген тарихыбызны дөрес бәян иткән тарих дәреслекләре генә түгел, изгелеккә һәм түземлелеккә өйрәткән китаплар да кирәк. Дошман эзләү беркайчан да яхшыга илтмәде һәм илтмәячәк.

Татарлар турында нәрсә генә сөйләсәләр дә, милләтебез бернинди гамәле белән дә үз йөзенә тап төшермәде. Безнең оялыр урыныбыз юк. Халыкның иң күркәм сыйфатлары буыннан-буынга күчеп барды, алар камилләштеләр, кайберләре вакытлар узу белән төшеп калдылар, ә кайберләре алдагы буыннарга тапшырылды. Менә шул сыйфатларның берсенә — аң-белемгә омтылышка — аерым тукталасым килә.

Күп кенә галимнәр татарларның бу асыл сыйфатын гаҗәпсенеп, басым ясап күрсәтәләр. Татарларның көнкүрешен һәм холык-фигылен озак еллар өйрәнгән Казан университеты профессоры Карл Фукс сокланып: «Читтән килгән һәр кешегә, гомумән алганда, Казан татарларының башкалар белән, хәтта Европа халыклары белән чагыштырганда да, белемлерәк булуы, һичшиксез, сәер тоелырга мөмкин. Укый һәм яза белмәгән татарны якташлары кешегә санамыйлар һәм ул, гражданин буларак, башкалар арасында абруйсыз»,— дип язып калдыра. Хәзерге шартларда мондый сыйфат гаять мөһим, чөнки, ахыр чиктә, нәкъ менә белемле булу безне дөньяның алдынгы милләтләре рәтенә бастырырга мөмкин.

Тагын бер нәрсә хакында да әйтәсе килә. Безнең халкыбыз беркайчан да үзен кол итеп тоймады һәм нәкъ менә шуңа күрә Степан Разин, Емельян Пугачев һәм башка крестьян күтәрелешләрендә татарлар күпләп катнаштылар да. Муса Җәлил кебек каһарман шәхес тә шушы җирлектә туды. Татарлар иң кыен елларда да хакыйкатьнең тантанасына ышандылар. Мәгълүм миссионер Ильминскийның әйтүенә караганда, татарлар үзләрен дәүләтле халык итеп тойганнар. Һәм, чыннан да, дәүләтчелекне торгызу иҗтимагый аңда беркайчан да үлмәде. Ул әкиятләрдә, риваятьләрдә, җырларда яшәде, аның хакында шагыйрьләр, политиклар сөйләде һәм язды. Монда мин Рәшит Ибраһимов, Муса Бигиев, Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими һәм Садрый Максуди кебек мәшһүр исемнәрне исегезгә төшерәм. Бу шәхесләр дәүләтчелекне торгызуның бердәнбер дөрес юлын күрсәттеләр дип әйтеп булмый, билгеле. Ләкин алар азатлык көрәшенә шактый зур өлеш керттеләр. Бу мәсьәләне хәл кылуда Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Фуат Туктаров, Мирсәет Солтангалиев кебек социал-демократлар да үз юлларын тәкъдим иттеләр.

Октябрь революциясеннән соң үз дәүләтебезне төзүнең берничә варианты булдырылды. Берәүләре Идел-Урал штаты төзергә чакырдылар, икенчеләре милли-мәдәни автономия белән чикләнергә кирәк дип чыктылар. Совет власте исеменнән Мулланур Вахитов Татар-Башкорт Республикасы проектын тәкъдим итте. Мәгълүм булганча, бу идея дә тормышка ашырылмады. Аның урынына берничә вариантта, шул исәптән бүген дә яшәп килә торган хәлендә, Татарстан Республикасы төзү планы пәйда булды.

Без Татарстан автономияле республикасы төзелү фактына бүген ничек кенә карасак та, аны шулай да уңай күренеш дип бәяләргә кирәктер. Автономиягә таянып тулы хокуклы дәүләтчелек өчен көрәшне дәвам итәргә мөмкин иде. Монда баштарак республикаларның союздашларга һәм автономияләргә бүленмәвен дә искәртеп китәргә кирәк. Татарстанның хокукларын кысу 1922 елда, республикалар сортларга бүленгәч, башланды. Милләтләр эшләре буенча халык комиссары Сталинның уры-

нбасары Мирсәет Солтангалиев моңа кискен каршы чыкты. Аның чыгышы өерелеп килә торган диктатура турында беренче кисәтү булды һәм бу фаразлар тулысынча акландылар. Солтангалиевнең дөньяда сәяси процессларның үсүе, колониаль системаның җимерелүе, Россиядә милли дәүләт төзелеше турында фикерләрен вакыт үзе раслады. Хәзер аның исеме һәркемгә мәгълүм һәм бу көннәрдә без аның тууына 100 ел тулуны тантаналы рәвештә билгеләп үттек. Ул үз халкының азатлыгы, тигез хокуклы булуы өчен генә түгел, Казагыстан, Төркстан, Әзәрбәйҗан, Әрмәнстан, Грузиянең хокуклары хакына да көрәште. Сталин моңа түзеп тора алмады.

Солтангалиев һәлак булды, ләкин аның идеяләре яши һәм алар өченче дөнья тарафыннан байрак итеп күтәреп алынды. Бүген Франциядә, Японииядә, Англиядә, АКШта, Төркиядә, Алжирда һәм башка илләрдә аның турында хезмәтләр дөнья күрде. Бу аның өчен генә түгел, ә бөтен татар халкы өчен дә зур мәртәбә.

1936 елда, СССР Конституциясе кабул ителгәндә, Татарстан үзенең хокуклары турында мәсьәләне кабат күтәрде. СССРның соңгы Конституциясен кабул иткәндә дә республиканың хокуклары мәсьәләсе яңадан кузгатылды һәм ул элеккечә үк калды.

Ниһаять, хәбәрдарлык һәм демократия чоры халыкның башка союздаш республикалар белән тигез хокуклы булырга омтылышына яңа куәт бирде.

Без, Яңа Огарево процессында катнашып, Союз яңа принципларда үзгәртеп корылсын өчен шактый күп көч түктек һәм үзебезнең позицияләребезнең дөрес булуына күпләрне инандыра алдык. Ләкин Союз таркалды һәм Татарстан Республикасына яңа сәясәт булдырырга туры килде.

1990 елның 30 августында дәүләт суверенитеты турында Декларация игълан ителде. Ул Татарстанны суверен дәүләт итеп билгеләде, үз территориясендә Республика законнарының өстенлеген таныды, җирне, җир асты байлыкларын, табигать хәзинәләрен һәм башка ресурсларны республиканың күпмилләтле халкы мөлкәте итеп беркетте. Сәяси-хокукый планда бу хокукый дәүләт нормаларына туры килә. Ул татар һәм рус халкының да, Татарстанда яшәүче башка милләтләрнең дә мәнфәгатьләренә җавап бирә. Декларация республикада милләтара мөнәсәбәтләрне нығытуга хезмәт итә һәм мин аның бөтен татар милләтенең демократик омтылышларына туры килүенә чын күңелдән ышанам. Шуңа күрә дә бу көн бездә, хаклы рәвештә, Республика көне, олы бәйрәм көне.

1992 елның 21 мартында уздырылган референдум Татарстанны Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән үзенең мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы килешүләр нигезендә билгеләүче суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты дип игълан итүче сәяси курсны раслады. Шик-шөбһәләр алып ташланды. Без үз юлыбызны сайладык.

Күпләр референдумның нинди катлаулы шартларда узуын, республика халкының нинди тупас сәяси басымга дучар булуын беләләр. Ләкин берсенә дә карамастан, без сайлаган юлыбызга тугры калдык һәм референдумны тиешле югарылыкта уздырдык,чит илләрдән, күрше дәүләтләрдән, төрле партияләрдән, иҗтимагый оешмалардан һәм хәрәкәтләрдән килгән күпсанлы күзәтүчеләр безнең сәяси ныклыгыбызны һәм демократик принципларда эш итүебезне үз күзләре белән күреп ышандылар. Референдумга әзерләнгән көннәрдә без АКШта, Германиядә, Польшада, Австралиядә, Бердәмлек илләрендә, Россиянең күп өлкәләрендә яшәүче милләттәшләребездән бик күп хатлар һәм телеграммалар алдык. Бүгенге мөмкинлектән файдаланып мин аларның барысына да чын күңелдән рәхмәт әйтәм. Хөрмәтле дуслар, сезнең ихлас теләкләрегез безгә һәрвакыт көч һәм ышаныч биреп тора.

Республиканың бөтенхалык тавыш бирү юлы белән билгеләнгән статусы Татарстан Республикасының яңа Конституциясе проектына ни-

гез итеп алынды. Без халыкара стандартларга туры килә торган Конституция әзерләргә тырыштык. Халыкара хокук нормалары республиканың эчке законнарыннан өстен йөргәндә генә безне башка дәүләтләрнең таныячагын яхшы беләбез. Шушы югары мөнбәрдән торып мин сезне һәм халыкара җәмәгатьчелекне Татарстанның кеше хокукларын, халыкларның хокукларын саклауда халыкара нормаларга хилафлык китермәячәгенә ышандырам. Бу — безнең сәясәтебезнең нигез ташы!

Без Татарстанның борылыш чорына аяк басуын яхшы аңларга һәм яңа чынбарлыкка туры килерлек сәяси фикерләү булдырырга тиешбез. Республика дәүләтара һәм халыкара мөнәсәбәтләр субъекты, халыкара хокук субъектына әверелә бара. Аның җилкәсенә дәүләтара договорлар һәм килешүләр төзү һәм аларны үтәү җаваплылыгы төшә, ул халыкара оешмаларда катнашу хокукы ала. Нәкъ менә шуңа күрә Татарстан халыкара нормаларның, шул исәптән Берләшкән Милләтләр Оешмасы Уставы принципларының үтәлүен гарантияли. Шунысын да әйтергә кирәк, Татарстанның позициясе торган саен дөньяда аңлау таба һәм хөрмәт казана бара.

Татарстанда безнең республиканы әүвәлгечә Россия составындагы гап-гади бер «автономия» сыйфатында сакларга тырышучылар да, Россия Федерациясе белән элемтәләрне тулысынча өзәргә чакыручы сәяси көчләр дә бар әле. Карашларның тегесе дә, бусы да кабул ителерлек түгел. Без сәясәтебезнең һәм экономикабызның нигезен тәшкил итүче үз суверенлыгыбызны корбан итә дә һәм шул ук вакытта Россия белән озак еллар яшәп килгән экономик һәм мәдәни элемтәләрне өзә дә алмыйбыз. Без үзара мөнәсәбәтләрдә иң кулай һәм җайлы юлларны табарга тиеш. Экономикабыз да, геополитик хәлебез дә, Россиядә миллионлаган милләттәшләребезнең яшәве дә моны эшебездә исәпкә алырга мәҗбүр итә. Без тулаем татар халкы турында уйларга бурычлы. Мин Татарстан бөтен татар диаспорасын берләштерүче булырга һәм Россиянең милли сәясәтенә җитәрлек дәрәҗәдә йогынты ясарга тиеш дип исәплим.

Бу өлкәдә хәл итәсе мәсьәләләр бик күбәйде. Әйтик, татар халкының ихтыяҗлары өчен Россия информация чыганакларыннан файдалану мәсьәләсе. Без Россия радиосы һәм телевидениесе Россия Федерациясенең барлык халыкларына, шул исәптән сан ягыннан икенче урында торган татар милләтенә дә, эзлекле рәвештә эфирда күпмедер вакыт бирергә тиеш дип саныйбыз. Бу мәсьәлә безнең тарафтан Россия җитәкчелеге алдында да куелды һәм аның уңай хәл ителәсенә вәгъдә алынды.

Кызганычка каршы, Россиянең гомуми информация чаралары милли мөнәсәбәтләрдәге кискенлекне йомшартуга ярдәм итәсе урында еш кына моның нәкъ киресен эшлиләр. Татарстан турында дөрес булмаган хәбәрләр, бездәге тормышны фәкать берьяклы гына яктырту халыклар арасында бер-берсенә ышанмау тудыра.

Татарстанда сәяси процессларның үсеше күп очракта Россия белән мөнәсәбәтләргә бәйле. Дәүләт суверенлыгы хакында Декларациябезгә һәм референдум йомгакларына каршы килгәнгә, Федератив Килешүгә Татарстан кул куймады. Безнең фикеребезчә, Россия Федерациясенең дәүләт төзелеше принциплары тиешле дәрәҗәдә демократия һәм федерализм таләпләренә җавап бирми. Теләсә кайсы федератив дәүләттә вәкаләтләр астан (субъекттан) өскә — федераль органнарга тапшырыла, һәм бу җәмгыятьнең ныклыгына, демократиклыгына нигез булып тора. Ә менә Россия белән Федератив Килешүгә килгәндә, барысы да киресенчә килеп чыга. Әгәр республика Федератив Килешүгә кул куйса, ул тәмам үзенең йөзен югалтыр һәм булган хокукларыннан да колак кагар иде. Референдум йомгаклары һәм Югары Советның соңыннанрак чыгарылган карарларына таянып, Татарстан Россия белән ике яклы мөнәсәбәтләрне Договорлар нигезендә төзүгә юл тота һәм шул ук вакытта аның бөтенлеген дә бозмый.

Татарстан һәм Россия арасында дүрт тапкыр сөйләшүләр узды. Позицияләрдә күпмедер аерма булуы ачыкланды. Ләкин шул ук вакытта үзара аңлашу өчен реаль юлларның калуы күренде. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы делегацияләре арасында 1992 елның 30 марты — 2 апрелендә узган консультация йомгаклары теркәлгән беркетмәдә «Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе арасында аерым мөнәсәбәтләр урнаштыру кирәклеге турында» язылган. Бу хәл безнең — Россия Федерациясе белән үз иреге белән ассоциациягә керергә омтылган суверен дәүләтнең — сәяси статусын ныгытыр дип ышанабыз. Агымдагы елның 11 июнендә мин Б. Н. Ельцин белән очраштым, без анда әлеге Килешүнең текстын эшләү буенча сөйләшүләрне дәвам итүнең кирәклеген тагын бер кат расладык. Очрашу үзара аңлашу рухында узды.

Безнең республикада татарлардан кала руслар, чувашлар, мордвалар, удмуртлар, марилар һәм башка милләтләр яши. Татарстанның суверенлыгы республикада көн күрүче барлык күпмилләтле халыклар исеменнән игълан ителде. Без ике телне — татар һәм рус телләрен — дәүләт телләре итеп беркеттек. Боларның барысы да безнең өчен бик мөһим нәрсәләр. Геополитик хәлебез һәм демографиянең торышы бездән тарихыбызны да, бүгенге чынбарлыгыбызны да исәпкә алган үз сәясәтебезне булдыруны, дөнья бердәмлегенә керүдә аерым юллар эзләүне таләп итә.

18 майда узган Татарстан халыклары съезды безнең адымнарның дөрес булуын раслады. Дәүләт суверенлыгы турында Декларация, чыннан да, милли мәнфәгатьләрне дәүләтнеке белән яраклаштырып республикабыз халыкларын берләштерә, барысына да үзләренең мәдәниятләрен, телләрен, мәгариф системасын үстерергә мөмкинлек бирә. Татарстанның чын дәүләтчелеген урнаштыруда аның экономикасының бөтендөнья экономикасына үтеп керү, халыкара хезмәт бүленешендә үз урынын таба алу сәләте мөһим шартларның берсе. Моның өчен Татарстанда көч-куәт һәм егәр аз түгел.

Барлыгы 3,7 миллион кеше яшәгән Татарстан төп экономик күрсәткечләр буенча элеккеге Союздагы иң үскән ун республика рәтенә керә. Ул күп тармаклы экономикага ия. Республикада югары технология таләп итүче производстволар тупланган. Бездә йөк автомобильләре, кораблар, самолетлар һәм вертолетлар, компрессорлар, радиоэлектроника әйберләре, электротехник приборлар, медицина җиһазлары һәм кораллары, сәгатьләр һәм башка бик күп нәрсәләр җитештерелә. Бу әйберләрнең шактый өлеше теләсә кайсы фирманыкы белән ярышырлык һәм 80 нән артык чит илләрдә мәгълүм. Татарстан 34 миллиард киловатт-сәгать электр энергиясе җитештерә һәм аның бер өлешен башка төбәкләргә җибәрә.

Республикада нефть химиясе тармаклары да яхшы үсеш алган. Алардан полиэтилен, шиннар, ашламалар, көнкүреш химиясе һәм башка кирәкле товарларны җитештерүне атап китәргә була.

Татарстан нефть чыгара торган дәүләт. Аның еллык күләме 28 миллион тонна тәшкил итә, ә чыгарырга мөмкин булган запаслар якынча 2 миллиард тонна дәрәҗәсендә бәяләнә. Битумлы нефть запасларыбыз бар, аның күләме 7 дән алып 12 миллиард тонна чамасы булыр дип фараз итәләр. Бу киләчәккә зур өмет уята торган күркәм саннар. Хәзерге вакытта республикада нефтьнең яңа, перспективалы чыганаклары ачыла.

Тегүчелек, мех әйберләр, аяк киемнәре, мебель җитештерү тармаклары да яхшы гына үскән. Экономиканың аграр секторында 300 меңләп кеше эшли. Республика ел саен якынча 3,2 миллион тонна ашлык, 800 мең тонна шикәр чөгендере, 270 мең тонналап ит, 1,6 миллион тонна сөт, 1,3 миллиард данә йомырка, җитәрлек күләмдә бәрәңге һәм яшелчә, шулай ук башка күп кенә авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерә. Республика үз халкын башлыча үзендә үскән азык-төлек белән туендыра.

Татарстанда Фәннәр академиясе төзелде, фундаменталь фәннәргә, гамәли юнәлешләргә бәйле проблемаларны, технологияләрне хәл итү буенча йөзгә якын фәнни-тикшеренү институты эшли. Аларның интеллектуаль продукциясе чит илләрдәге партнерларда да кызыксыну уятырга мөмкин. Әле күптән түгел генә эшләнмәләрнең һәм продукциянең шактый өлеше оборона хаҗәтләренә карый иде һәм киң кулланучылар өчен ябык булды. Хәзер аларның күбесеннән «яшерен» тамгасы алынды. Бүген хәрби промышленность предприятиеләренә аеруча кыен, ләкин Татарстан халкына гаять зур табыш китерерлек куәтләрнең иң күп өлеше нәкъ менә шунда тупланган. Конверсияләнә торган предприятиеләрдә дәүләтнеке булмаган структуралар белән берләшеп эшләү өчен хезмәттәшлекнең яңа ысулларын эзлиләр. Күп кенә кызыклы эшләнмәләр күренә дә башлады инде.

Дистәләгән еллар дәвамында экономиканың үсеше үзәк диктаты астында барды һәм аның структурасы республика мәнфәгатьләренә җавап бирмәде. Никадәр генә гаҗәп тоелмасын, 45 ел буена нефть чыгарып, Татарстан бүген ягулык-майлау материалларының аерым төрләренә зур кытлык кичерә.

Республика күп еллар дәвамында ике үзәк (Союз һәм Россия) өчен савым сыеры булды, аларның икесенә дә буйсынып, ул үз халкының иң мөһим ихтыяҗларын да хәл итәргә җай тапмады. Республиканың яңа статусы үсү өчен киң мөмкинлекләр ача. Без экономик суверенлыкны гамәлгә кертү өчен барысын да эшләргә әзер торабыз. Бу юнәлештә беренче адымнар ясалды инде. Бүген табигый ресурслар халыкныкы. Татарстан Республикасы үзенең табигать ресурсларын, беренче чиратта нефтьне һәм нефть-газ химиясе продуктларын чыгаруны һәм сатуны мөстәкыйль башкара. Промышленность предприятиеләренең күпчелеге безнең карамакка күчте. Экспортка китә торган продукциягә лицензияне үзебез бирәбез. Россия белән исәп-хисапны бер каналлы бюджет принцибы буенча башкарабыз.

Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә керүче барлык илләр кебек үк, Татарстан да базар мөнәсәбәтләренә күчә. Ләкин без базарга керүнең «йомшак» формасын сайладык. Шуңа күрә халыкның аз тәэмин ителгән өлешен яклау системасын төзергә, халыкның сатып алу сәләтен сакларга, кешеләрнең хәерчеләнүенә юл куймаска тырышабыз.

Авылга ярдәм итү, фермерлыкны үстерүне һәм шушы нигездә халыкның үзен-үзе азык-төлек белән тәэмин итүенә күчүне экономик сәясәтебезнең иң мөһим сыйфатларыннан берсе итеп карыйбыз.

Һәммә җирдәге кебек үк, бездә дә житештерү кими, ләкин соңгы вакытта без аның төшү темпын киметә алдык. Без хәрби промышленность комплексын конверсияләүнең программасын эшләдек һәм югары квалификацияле кадрларны, бар булган техниканы тормыш өчен кирәкле продукция җитештерүдә файдаланырга ниятлибез. Шул ук вакытта промышленностька инвестицияләрне киңәйтергә уйлыйбыз.

Бездә хосусыйлаштыру программасы бар. Ул чынлап торып базар мөнәсәбәтләренә күчүне тизләтер дигән өмет яши.

Татарстан экономик яктан торган саен халыкара хокук субъектына әверелә бара. Бердәмлек илләре белән турыдан-туры килешүләр төзелә, дөньяның күп кенә дәүләтләре белән элемтәләр активлаша. Дәүләтчелекнең аякка басуында хокук юлыннан барып, без иң якын араларда чит ил капиталын тарту өчен ныклы закон нигезләре булдырырга ниятлибез.

Без Венгрия, АКШ, Төркия, Англия, Канада, Австрия, Япония һәм башка күп кенә илләрнең фирмалары һәм концерннары белән шактый әйбәт экономик элемтәләр урнаштыруга ирештек. Файдалы байтак килешүләр төзелде. Чит ил партнерлары Татарстан белән нык кызыксыналар. Аларны безнең чимал, промышленность һәм фәнни куәтләребез, һава, су, тимер һәм шоссе юллар кисешкән уңайлы урында урнашкан булуыбыз, түләү сәләтебез һәм төбәктәге сәяси тотрыклылык үзенә тарта. Без чит

илләрдәге инвесторларга закон нигезендә гарантияләр бирү, тиешле инфраструктура төзү өчен кулдан килгәннең барысын да эшләячәкбез. Июльдән җирнең ясалма иярчене аша телефон элемтәсе эшли башлаячак, банкларыбыз халыкара банклар белән исәп-хисап ясарга керештеләр, без халыкара хезмәт бүленеше шартларында эшләү өчен кадрлар әзерләргә керештек һәм башка күп кенә планнарны тормышка ашыра башладык.

Теләсә кайсы милләт турында чыгарылган нефть тонналары, үстерелгән ашлык яки башка продукциягә карап кына түгел, ә аның мәдәниятенә, фән һәм техника өлкәсендәге казанышларына, атаклы, шәхесләренә, сәяси эшлеклеләренә, язучыларына, шагыйрьләренә, галимнәренә карап фикер йөртәләр. Бу җәһәттән без бәхетле милләт.

Татарлар дөнья мәдәниятен үстерүгә шактый зур өлеш керттеләр. Монда барлык атаклы кешеләрнең исемнәрен китерү кыенрак булса да, кайберләрен әйтеп үтүне кирәк саныйм. Кол Галинең XIII гасырда язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы бөтен дөньяга билгеле. Халык дастаны «Идегәй», күп кенә киртәләрне җимереп, ниһаять, басылып чыкты һәм рус теленә тәрҗемә ителде. Халыкка мәгърифәт таратуда Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдинов, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, мөгаллим Хәлфиннәр династиясе һәм башка бик күп шәхесләр бәяләп бетергесез гаять зур роль уйнадылар.

Бу гасыр язучылары һәм шагыйрьләреннән беренче итеп бөек Тукай исемен атарга кирәктер. Татарда яңарышның башлануын билгеләп, ул гасыр алмашынган чорда калыкты. Ул чын мәгънәсендә милли шагыйрь иде, аның бөтен тормышы халык белән, аның киләчәге белән бәйле булды. Аның иҗатының асылы хакында: ул — халык өчен әрнү, татарны дөньяның бөек халыклары белән бер рәттә күрергә теләү,— дип әйтеп булыр иде. Шул ук вакытта Тукай киләчәккә илткән юлның үз-үзенә бикләнгән милли даирә аша түгел, ә тел-лөгать һәм белем алмашу аша узуын бик яхшы аңлаган. Ул юкка гына төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып Пушкин, Лермонтов, Некрасов шигырьләрен тәрҗемә итәргә алынмаган. Аның рус халкына мөнәсәбәтне чагылдырган юллары яхшы мәгълүм.

*Һич бетәрме тарихи бу бергәлек.*
*Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.*

Кайберәүләргә Тукайны яңадан, хәзерге чорда укып чыгу һич тә зарарлы булмас иде.

XX гасыр башында милли театр туа, татар китабы һәм вакытлы матбугат киң тарала. Шагыйрь Дәрдмәнд, язучы һәм сәяси эшлекле Гаяз Исхакый, татар прозасының классигы Галимҗан Ибраһимов, татар драматургиясенә нигез салучы Галиәсгар Камал, шигырьдә яңарыш ясаучы Сәгыйть Рәмиев, Һади Такташ һәм башка бик күп күренекле җәмәгать эшлеклеләренең гаять куәтле агымы бәреп чыга. Милли музыкантлар пәйда була. Алар арасында Салих Сәйдәшев аеруча сөекле композитор булып танылды. Татар опера, балет һәм симфоник музыка сәнгатен Ф. Яруллин, Н. Җиһанов яңа биеклеккә күтәрделәр. Һәм бүген без сәнгатебезне дөнья киңлекләренә алып чыккан композитор Софья Гобәйдуллина, биюче һәм режиссер Рудольф Нуриев, биюче Ирек Мөхәммәдов исемнәрен зур горурлык хисе белән телгә алабыз.

XX гасыр башында милли промышленностьның һәм сәүдәнең тиз үсеше күзәтелә һәм ул Россия экономикасында сизелерлек урын да ала. Татар эшмәкәрләренең мәдәниятне үстерүгә матди ярдәм күрсәтүләрен дә әйтеп китәргә кирәк. Аларның тырышлыгы аркасында Мөхәммәдия, Галия, Хөсәения, Иж-Буби кебек Шәрыкта абруй казанган мәдрәсәләр яшәгән һәм үскән. Аларда милли зыялыларыбыз тәрбияләнгән. Без татар мәдәнияте белән генә горурланып калмыйбыз, безгә Лобачевский, Бутлеров, Бехтерев исемнәре дә бердәй кадерле. Без нәкъ менә Казанда

Лев Толстойның, Аксаковның, Горькийның яшәүләре һәм укулары, Шаляпин һәм Качаловның иҗат юллары башланып китүе белән горурланабыз.

Татарстан төрле мәдәниятләр һәм халыклар кушылган җирдә урнашкан. Монда Шәрык һәм Көнбатыш тоташа, төрки һәм славян мәдәниятләре бер-берсен баета, ызгышмый-талашмый мөселман һәм христиан диннәре яшәп ята. Казан гомер-гомергә борынгы мәдәни үзәк булды. Ул бүген дә төрле мәдәниятләрнең үзара кушылып һәм үрелеп үсүенең кабатланмас үрнәге. Без моны кадерләп саклый, үзебезнең һәм башка халыкларның мәнфәгатендә файдалана белергә тиеш.

Безнең горурланырлык кешеләребез күп, ләкин шул ук вакытта үзебезне битәрләргә дә сәбәп юк түгел. Бүген Солтангалиевнең керсез исеме янадан торгызылды, ләкин без тегe яки бу сәбәп аркасында илдән китәргә мәҗбүр булган, эшчәнлекләре дөрес итеп чагылдырылмаган яисә бөтенләй онытылуга дучар ителгән шәхесләр каршында зур бурычлы әле. Гомумән, татар диаспорасының рухи тормышын (Бердәмлек илләрендәме, чит илләрдә булсынмы), аның дөнья мәдәниятенә керткән өлешен өйрәнү бүгенге көн бурычы.

Безнең мәдәниятебез, чыннан да, бик бай. Тик аның хакында, күренекле шәхесләребез хакында, башка халыклар димим инде, татарлар үзләре дә аз беләләр. Аларның һәркайсын искә төшерү һәм барысына да тиешле рәхмәтне әйтер вакыт җитте. Бүген кайсы сәяси эшлекле реакционер, ә кайсысы революционер, кайсы язучыны бастырырга һәм дәреслекләргә кертергә, ә кайсысын онытырга дип баш ватарга кирәкми. Аларның һәммәсе дә тормышыбызда үзенең урынын алды. Алар барысы да озак көткән азатлык көнен якынайтырга омтылган кешеләр. Алар тормыш юлын лаеклы уздылар.

Мин монда татар мәдәниятенең данлы традицияләрен дәвам иттерүче күп язучыларның, рәссамнарның, композиторларның, артистларның, галимнәрнең җәмәгать эшлеклеләренең исемнәрен һәм иҗат коллективларын атамыйм. Аларны сез үзегез дә яхшы беләсез. Аларның күбесе бүген шушы күркәм залда утыра. Республиканың симфоник оркестры, төрле континентларны татар моңы, татар биюе белән таныштырган Дәүләт җыр һәм бию ансамбле сәнгатебез күгендә якты йолдыз булып балкыйлар.

Татар музыка, сәхнә сәнгатен пропагандалаучы иҗат коллективлары элеккеге СССРның бик күп шәһәрләрендә дә бар. Аларның күбесе чын мәгънәсендә профессиональ биеклеккә күтәрелделәр. Самарадан «Ялкынлы яшьлек», Мәскәүдән «Хыял», Уфадан «Тальян», Алма-Атадан «Сарман», Ташкенттан «Дуслык», Омскидан «Яшьлек», Чиләбедән «Таң нуры», Оренбурдан «Чишмә», Төменнән Татар халык хоры, Магнитогорскидан «Айгөл», Новосибирскидан Бию театры әнә шундыйлар. Әлбәттә, бу исемлекне дәвам итеп булыр иде. Киләчәктә ул һичшиксез тагы да озынрак булыр.

Минем гомуминформация чараларыбыз — газеталар һәм журналлар, радио һәм телевидение турында да берничә сүз әйтеп узасым килә. Соңгы ярты гасырда алар өлешенә бик зур кыенлыклар туры килде, ләкин алар татар мәдәниятенең байрагын төшермәделәр. Татар халкын рухи һәм әхлакый тәрбияләүдә шушы көннәрдә генә үзенең 70 еллыгын билгеләп үткән «Казан утлары» журналының өлеше зур. Үзебездә генә түгел, Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләрендә дә популяр «Чаян», «Сөембикә», яшьләр журналы «Идел», «Ялкын», сабыйлар өчен матур рәсемле «Салават күпере» журналлары да халкыбызга тугры хезмәт итәләр. Газета-журналларны бармак белән генә санарлык булса да, бу басмалар һәр өйгә, һәр гаиләгә, һәр татарның бәгыренә үтеп керделәр. Алар аша без рухи бәйләнешләребезны исән-сау саклыйк һәм өзмәскә тырыштык.

Мәдәният — берботен күренеш. Аны фәкать иҗат берлекләре белән колачлап та, министрлыклар эшенә сыйдырып бетереп тә булмый. Мәдәният ул әдәбият һәм сәнгать, опера һәм балет, сынлы сәнгать һәм архитектура гына да түгел әле. Ул әхлак та, сәяси җитлеккәнлек тә, заманча белем һәм технология дә һәм, ниһаять, көнкүреш тә. Моңа кадәр яшәп киткән буыннар безгә мирас итеп күркәм сәнгать, бөек әдәбият калдырдылар. Аларны яңа биеклекләргә күтәрү безнең бурыч. Бабаларыбыз һәм бабаларыбызның бабалары белемгә сусауны гасырлар аша югалтмый алып чыктылар. Бу изге омтылышны тагын да үстерү безнең бурыч. Өлкән буыннар халыкта хезмәткә мәхәббәт, үз сүзенә һәм бурычыңа тугрылык, кешеләр белән аралашуда түземлелек тәрбияләделәр. Экономик, сәяси һәм мәдәни чәчәк ату хакына бу сыйфатларны файдалану — безнең бурыч.

Татарлар кайда гына яшәсәләр дә, безнең мәдәниятебез бер. XX гасыр башында татарларда милли тормышның берничә үзәге барлыкка килде. Уфа, Оренбург, Мәскәү, Петербург, Уральск, Троицк һәм башка шәһәрләр еш кына хәтта Казанның үзе белән көндәшлек итәргә сәләтле мәркәзләр иделәр. Кызганычка каршы, соңгы елларда аларның мәркәзлекләре бетерелде. Бу үзәкләрне яңадан торгызу өчен барысын да эшләргә кирәк.

Төрле республикаларда һәм өлкәләрдә яшәүче язучылар бер-берсе белән аралаша алмадылар. Без үзебезнең Үзбәкстанда, Казагыстанда, Петербургта һәм башка төбәкләрдә иҗат итүче рәссамнарыбызны фәкать ишетеп кенә белә идек. Күп кенә татар архитекторлары бөтен ил буйлап шәһәрләр төзеделәр, кинематографистлар барлык республикаларда фильмнар төшерделәр, ләкин үзләренең белемнәрен һәм хезмәтләрен Татарстанга бирүдән мәхрүм иделәр. Бүгенге көннән башлап татар язучылары, композиторлары, рәссамнары, архитекторлары, кинематографистлары, үзләрен, кайда гына яшәсәләр дә, безнең иҗат берлекләренең дә уртак гаиләсендә дип хис итсеннәр иде.

Мәктәп һәрвакыт милләтнең төп нигезе булып тора. Кеше мәктәптә тәрбияләнә, аның аңына белем, әхлак һәм шәхес нәкъ менә шунда салына. Заман таләпләренә җавап бирерлек мәгариф системасы төземәгән милләт азат була алмый. Кешенең хөрлеге аның аң-белеменнән башлана. Нинди генә кысуларга да карамастан, татар мәктәпләре Россиянең күп кенә төбәкләрендә сакланып калдылар. Милләтләрнең кушылуы турында теорияләр чыккан һәм милли мәктәпләр ябылган заманнарда безнең укытучыларыбыз искиткеч ныклык һәм фидакарьлек күрсәттеләр. Татар мәктәбен нәкъ менә алар алып калды. Аларга нинди генә рәхмәт әйтсәң дә аз булыр кебек. Хәзер Татарстаннан читтә дә татар халык мәгарифен торгызу бара. Ләкин бу гамәл югары таләпләр дә куя: яңа дәреслекләр кирәк, укытучылар кирәк, акча кирәк. Казанның, Татарстанның югары уку йортлары, галимнәре һичшиксез бу проблеманы чишүдә мәсьәләнең үтә җитдилеген исәпкә алып эшләрләр. Милләттәшләребез күмәкләшеп яшәгән төбәкләрдән килгән абитуриентларга, белемнәрен күтәрергә килгән белгечләргә, укытучыларга тиешле игътибар һәм ярдәм булыр. Моның өчен Президент каршында төзелгән яшь белгечләр әзерләү буенча халыкара фондны эшлеклерәк файдалану кирәк. Безнең Халык мәгарифе министрлыгы үзенең эшен шушы яңа бурычларны исәпкә алып оештырырга тиеш. Мәдәният министрлыгы да, Президент каршындагы мәдәният фонды да нәкъ шул рәвешле татарларның мәдәни үзәкләрен торгызуда ярдәм күрсәтергә бурычлы. Бу мөһим эштә Бөтентатар иҗтимагый үзәге һәм аның төрле төбәкләрдәге бүлекчәләре дә сизелерлек роль уйный лар. Сүз дә юк, татар мәгарифен һәм мәдәниятен үстерүдә Татарстанның рәсми органнары да, татарлар яшәгән дәүләтләр һәм өлкәләр дә хуплап күтәреп алырлык дәүләт программасы кирәк. Татарстан хөкүмәте бу юнәлештә кайбер республикалар һәм шулай ук Россиянең өлкәләре белән килешүләр төзи башлады инде.

Татар мәдәнияте үсешенә ярдәм итү өчен Татарстанның башка дәүләтләрдәге даими вәкиллекләрен мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга кирәк булачак. Алар экономик һәм илчелек вәкаләтләрен башкарып кына калмыйча, чын мәдәни үзәкләргә әверелергә тиешләр. Татарстан Президенты моны татар милләте каршында әхлак бурычы дип карый.

Бөек мәдәниятнең һәрвакытта да үзенең милли тамырлары була. Гомумкешелек кыйммәтләре мәгълүм милли шытымнардан үсеп киткәннәр. Икенче яктан, үз милләтенең мәнфәгатьләре белән яшәгәндә генә гомумкешелек үрләренә күтәрелеп була. Бәлки үзара ярышучы, берсен-берсе баетып торучы һәм шул ук вакытта яңа, кабатланмас төсмерләр алучы милли мәдәниятләр әлегә кадәр кешелек дөньясы тудырган иң зур байлыктыр!...

XIX гасырның ахыры, XX йөзнең башы татарлар өчен мәдәниятнең бик тиз үскән чоры булды. XXI гасыр чигендә торганда да татар милләтенең һәм аның мәдәниятенең үсешендә яңа күтәрелеш булыр дип ышанасы килә. Минем тарихи гаделлекнең тантана итүенә иманым камил.

Сүземнең ахырында Конгресска уңышлар, файдалы очрашулар һәм эшлекле фикер алышулар теләр идем. Мин Конгресста кабул ителгән карарлар татар милләте үсешендә мөһим этап булыр һәм киләчәктә Татарстан Республикасының барлык дәүләт структураларында һәм аның Президентында тулаем яклау табар, дип ышанам.

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт.

**Җәмит Рәхимов**

# БАТЫРША

РОМАН

## Алтынчы бүлек

Ирәндек тавының һәр ике ягына Нугай юлы авыллары сибелгән. Мәгәр һәркайсында тормыш-мәгыйшәт агышы бер төрле диярлек. Кар-бураннарына мохтаҗлык булмаган кышкы айларда нәсел-ырулары төпләнгән авылларда ничек кирәк алай җан саклаган башкортлар, җирләр кибеп, үләннәр мал авызына эләгерлек булуга, аяусыз салкыннардан сакланган өйләрен, каралты-кураларын калдырып, бала-чагаларын, мал-туарларын, урын-җирләрен, савыт-сабаларын төяп тау араларындагы җәйләүләргә кузгалалар. Шуннан инде авыллар кара күзгә хәтле ташландык мазарга охшап кала.

Алай да тома ятимләнеп, бөтенләй иясез калмый авыллар. Җәйнең теләсә кайсы вакытында морҗаларның берничәсеннән булса да сыек төтен күтәрелүен күрергә, кизәк янудан чыккан әчкелтем исне сизәргә, берән-сәрән калган этләр өрүен ишетергә була монда.

Шәрә маңгайлы Ягалча тавы итәгенә сыенган Ташавыл — әнә шундыйларның берсе. Ягалча тавы астындагы кизләү буеннан көнозын тимер чыңы ишетелә. Алачык татар-башкорт авылларына хәрәм нәрсә. Шуңа да мондагысы тирә-юньдәге халаекларга үтә тансык, тәҗел. Менә шуңа да Ташавылның урам-юлларын җәйләрен дә үлән басмый, килеп-китеп йөрүче өзелеп тормый монда.

Яшь булса да исеме бөтен Нугай юлына таралган, хәтта Иртешнең теге ягына — кыргыз-кайсак урдасына барып җиткән корыч куллы, киң күкрәкле, ару-талуны белми торган тимерче Әмин эшли биредә. Алачык — аңа моннан дүрт ел элек вафат булган атасыннан мирас...

Бәндәнең үз күңелендә булмаса, бер түгел ун останың аягы арасында уралып үссә дә, аңардан рәт чыкмый. Бөтен хикмәт — кешенең йөрәгендә, аның ата-баба һөнәренә ихласлыгында. Әмин исә нәкъ әнә шундый малай иде, атасының һәр хәрәкәтен, осталыгын үз итте. Балигъ булып җиткәндә ул инде тимерче осталарның мәңгелек сере булган булат кылычлар коя, алмас очлы дип даны чыккан ук башаклары ясый иде. Аның даны авылдан-авылга, иләүдән-иләүгә таралды.

Тимерлек шундый урын инде ул, авылда аңа йомышы төшмәгән кеше юк диярлек. Тимерчесе нинди генә булмасын, хаҗәте барлар шунда бара. Янә дә килеп, алачык бит әле ул адәм балаларының очрашу, тел кашып, күңел ачу, фикер алышу, дөнья хәлләрен ишетү урыны да. Ташавыл алачыгы да — тирә-күрше авылларның, ул гына да түгел, бөтен Бөрҗән иләүе халаекларының очрашу урыны.

Дәвамы. Башы 7 нче санда.

Узган ел исә алачыкка килеп-китеп йөрүчеләр бермә-бер артты. Тагы да гаҗәбе — бәндәләрнең йомышлары үзгәрде. Элегрәк килүчеләрнең хафасы — чиләк-көрәк, авызлык-ияр булса, хәзергеләрнең гозере — кылыч та сөңге, чукмар да ук. Мәгәр әле монысына да әллә ни исе китмәде Әминнең. Җәя-уксыз, кылыч-сөңгесез ир-егет була ди мени?! Ялгызы гына өлгерә алмагач, күрек басарга, тимер таптарга агасы Чурашны да чакырды. Инде икәүләп тә өлгерә алмый башладылар. Сизенде егет: Бөрҗән башкортлары яуга әзерләнәләр.

Язгы ташудан соң елгалар ярларына кайтып, юллар төшә башлаган чак иде. Ирәндек буенда әллә каян гына Брагин дигән түрә пәйда булды. Үзе генә дә түгел, утызлап солдаты, төрле яраннары, пешекчеләренә хәтле бар, имеш. Берәүләр аны Оренбурдан килгән дип сөйләсә, икенчеләре, Петербурдан ук, дип бәхәсләштеләр. Халык теленә кергән төрле имеш-мимешләргә караганда, таулардан асыл ташлар җыеп, аларны эшкәртмәкче-шомартмакчы, кальгалар салу өчен таш чыгармакчы, чынаяк заводы өчен ак балчык эзләмәкче икән бу түрә.

Мәгәр алачыгына көн саен ишелеп-ишелеп килеп торган шомлы хәбәрләр агалы-энеле тимерчеләрнең дә колакларын торгызырга мәҗбүр итте. Имеш, Брагин түрә, ниткәндер мәкерле язулар күрсәтеп, халаекларның кайсын куркытып, кайберсен юмалап, тирә-яктагы Тимәш, Куян, Анык вә башка авылларның күп кенә җирләрен үзләштергән.

Әмингә ни, аның җире юк — хәбәрләрнең болары бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. Тик үзләренең Ташавыл янындагы Ягалча тавына кемнәрдер килеп, борынгыдан калган таш базлары тирәсендә казынып йөрүләрен, анда кабат эш башларга җыенуларын үзе күргәч кенә, Брагин турындагы сүзләрне шигеп тыңлый башлады.

— Брагин түрә Елан-Этколның сакалын йолкып аткан!

— Теге явыз Буранголның дүрт атын талап алган!

— Килмешәк түрәнең солдатлары Атнаголның үгезен суеп ашаганнар!..

— Килмешәк Моратшаның күз алдында хатынын көчләгәннәр...

Монысы инде ата-баба күрмәгән кыргыйлык, мөселманнарның ишеткәне дә булмаган ерткычлык иде. Бөрҗән иле гөж килде. Әмин агасы Чурашның кулыннан эш төште. Ул, ашыга-кабалана, каяндыр табып алган богау йозагын төзәтте, тиз генә авылга кайтып, хатынын келәткә биклəп куйды. Әминнең хатыны юк. Әмма һич кенә дә башка сыймаслык хәбәр аны да гаҗиз итте. Егет, еш кына эшен ташлап, уйланып утыра торган булып китте. Алай да хәл кул кушырып утыра торган түгел. Йозак мәсьәләсе бер Чураш башына гына килмәгән икән. Шушы гомергә тиклем өй биклəүнең ни икәнен белмәгән башкортлар һәм татарлар, бер-бере белән ызгыша-ярыша, йозак ясатырга тотындылар.

Йозак шаукымы тына башлаган көннәрнең берендә, алачыкка Ходайбирде мулла килеп чыкты. Шушы җәйгә хәтле башкалар кебек үк мал асрап, кара эшне сөреп көн күргән озын буйлы, какча гәүдәле бу бәндә быел гына Ташавыл мәчетенең имамы булуга ирешкән иде.

— Бән ул шакшы бәндәне байтактан беләм,— дип башлады мулла, бераз тыңкышрак тавыш белән.— Йөрүзән буенда шул ташлары белән җентеклəп йөрде. Бер җәй таш ваттым бән аңарда. Шунда күргәннәремне ходай тәгалә берәүгә дә язмасын. Яшь хатыннарга вә кызларга кул сузып, халаекларны кан елатты явыз.

Пәһлеван гәүдәле Чураш, мулланың авызына керердәй булып, аның каршына килеп басты. Әмин дә алар янына тартылды. Ходайбирде исә, керфексез соры күзләрен учак янындагы күмер чуманына текәгән хәлдә, хикәятен дәвам итте:

— Ханкилде атлы берәүнең кәләше кызганыч булды бигрәк тә.

Егетнең өйләнәсен ишеткәч, Брагин аңа кәләшен өч көнгә үзенең тирмәсенә китерергә боерган. Билгеле инде, Ханкилде ризалашмаган, ул гынамы, түрәгә камчы белән янаган. Шуннан бөтенләй майлагандай булды түрә, яхшатланып, туйны укмаштырып йөрде, мәҗлеснең түрендә иде. Туйда ул, Ханкилденең мәңгелек дусты булырга ант эчеп, кияүне хәмер белән кыстады да кыстады. Тегесе исә, Брагинның үч алуыннан куркып, эчте дә эчте. Төн урталарында тәмам исереп егылды, бахыр.

Ходайбирде туктап калды, авызына җыелган суны лач иттереп җир идәнгә төкерде. Әмин белән Чураш икәү бердәм аңа тартылдылар:

— Соң, соң? Шуннан?

— Исерек кияүне келәткә кертеп салдылар. Мәҗлес таралды. Брагин исә, кияүнең вә киленнең ата-аналарын, карендәшләрен солдатлары белән куркытып, кәләшне үз тирмәсенә алып киткән...

Алачыкны авыр тынлык басты. Чураш, алпашма гәүдәсе белән алпан-талпан килеп, өенә торып чапты. Әмин исә тышка чыкты, кизләү янына килеп, чирәмгә утырды да тирән уйга талды. Әйе, ул әле тормышын хатын-кыз белән бәйләмәгән. Мәгәр ниндидер бер килмешәкнең төбәк назлыларын мыскыл итүе аның да намусын җәберли. Әле теге чакны, Моратша хатыны белән булган хәлне ишетүгә, егетнең күз алдына алтын чәчле Асылбикә килеп басты. Асылбикә һич кенә дә башкорт кызларына охшамаган: алтын-сары чәч ике калын толым булып биленә хәтле төшкән, күзләре — җитен чәчәге. Гәүдәсенең һич кенә дә килмәгән җире юк. Чишмә буеннан узып барганда, Асылбикә үзе күреп алды егетне. Күрде генә түгел, бер мизгелгә туктап калды, кояш балкыгандай елмайды һәм, атына кисәк селтәнеп, сикертеп чабып китте.

— Асылбикә! — дип кычкырып җибәрде Әмин һәм аның каршына атылды. — Сиңа сүзем бар, Асылбикә!

Кыз, тезгенен кисәк тартып, атын кинәт борды һәм тауга ыргылды: «Сүзең булса, куып җит!»

Әмин кызның бу кыланышын шаяртуга да юрады, үзен кимсетү дип тә сыкранды — анык кына ничек аңлатырга да белмәде. Шуннан инде Асылбикәнең чыркылдап көлүе тимер чыңы арасында да ишетелгәндәй тоела башлады. Ул Асылбикәне юксынды, төннәр буе, кайчак көннәрен дә шул чибәр хакында уйланды: Асылбикә — аның буе җитмәслек асыл зат!

Ул инде кызны күңеленнән бөтенләйгә чыгарып ташларга җиткән көннәрнең берендә, Асылбикә алачык янында тагы үзе күренде, шулай ук атыннан төшми генә эчкә кычкырды:

— Әй, егет, алтын балдак ясый беләсеңме??

Әмин аның каршына атылды:

— Беләм, Асылбикә!

— Беләзек тә коясыңмы?

— Коям. Синең өчен беләзеген дә, чулпысын да, йөзеген дә тау итеп өеп куярга әзер, Асылбикә!

— Яратасың алайса?!

— Яратам, Асылбикә!

Кыз, гадәтенчә, атын бер урында борып, атылган уктай чабып китте: «Яратсаң, яучы җибә-рр!»

Әмин, ярлы булса да, горур егет, шулай ук тимерне кызуында сугарга күнеккән. Озын-озын сузмый, Ходайбирде мулланы үгетләп, Исәнбай авылына, Байбул старшина өенә юллады.

Күңеле, җәрәхәтләнгән кош сыман, юкка сыкранмаган икән егетнең. «Авызын ачса, үпкәсе күренгән йолкышка бирердәй кыз юк миндә», — дигән җавап алып кайтты Ходайбирде. Могҗиза булмый калды.

Егет, бар тырышлыгын куеп, кызның исемен йөрәгеннән чыгарып атты. Мәгәр Моратша хатыны турындагы хәбәр эчен айкап алгандай

булды. Брагин Моратша хатынына түгел, нәкъ менә Асылбикәгә кулын суза сыман тоелды аңа.

Тик болай хатын-кызны биктә тотып яшәү, яисә аңа тагылып, гел саклап йөрү — тузга язмаган хәл бит инде. Ир-ат халкы, аулакта очрашып киңәш-коңаш итәргә тотынды. Яшерен сүз өчен иң кулай урын, әлбәттә, Әмин алачыгы иде. Башта Брагин түрәдән иң зур җәбер күргәннәрдән сакалы урынында кара кутыр йөрткән Елан-Эткол, хатыны мыскыллланудан кара шәүләгә калган Моратша һәм Атнагол килде: нишләргә, ничек котылырга бу ходай орган бәндәдән?

Бәрхеттәй йомшак, куе кара сакалыннан колак какканына ахыр чик хурланган Елан-Эткол сүзе бер булды:

— Җир йөзеннән юк итәргә кирәк ул бәдбәхетне!

Моратша урыныннан ук сикереп торды:

— Үзем дөмектерәм мин ул кабахәтне!

— Без болай итеп караек! — Ходайбирде мулла салмак сүзе белән барын үзенә каратты. — Котлымөхәммәт морзага шикаять язып, тамгалар җыяек, Оренбурга чапкыннар җибәрәек!

«Үз корсагы, үз мәнфәгате хакына иманын саткан Тәфтиләүдән игелек иңәр димсең?!» Ир-егетләрнең җыелып киңәшүләрен дәшмитынмый гына тыңлап йөргән, аннан инде жалу вакыйгасының ни белән бетәсен сүзсез генә көткән Әмин әнә шулайрак фикер йөртте.

Иләү халкы тәшвишләнеп һәм шомланып Тәфтиләү морзадан җавап көткән көннәрнең берендә, Әмин алачыгы янына өсләре елкылдап торган атларда биш җайдак килеп туктады. Тимерченең чираттагы кылычын киндер маенда чыныктырып маташкан чагы иде. Шөбһәләнеп, ишек ярыгыннан тавышлар килгән якка бакты. Килүчеләрнең берсе — тимеркүк айгырга атланганы — иярennән җәһәт кенә сикереп төште, тезгенен янәшәсендәге солдатка ыргытты да болайга таба атлады. Әмин аны, башкалар сөйләве буенча, чамалады — әлеге бәндә, һичшиксез, Брагин түрә иде. «Сизенгән, кабахәт, — дигән уй үтте егетнең башыннан һәм күңелен хәвеф басты, — халаекларның монда җыелып, киңәш-табыш итүләрен белгән. Димәк, мәрхәмәт көтәсе юк».

— Так-с, кылыч коябыз, корал чүкибез, ә, чибәр егет?! — диде ул, тыныч кына, тимерчегә карап. Аннан солдатларга борылып кычкырып җибәрде. — За-абра-ать!

Драгуннар алачык хуҗасына ташландылар. Әминне, ат сыртына салып, Сапсал ям станына таба алып киттеләр. Брагин түрәнең тирмәләре һәм солдатларның аннан-моннан корыштырган казармаларының шунда икәнен белә иде Әмин. Егетне караңгы, дымлы базга ябып куйдылар.

Асылбикәнең үзенә яр булмаячагын белгәннән бирле, дөньяда яшәсәм ни, яшәмәсәм ни, диебрәк йөргән егет, дөм-караңгы баз почмагына чүмәшеп, соңгы айларда беренче тапкыр чын-чынлап үз язмышы турында уйлана башлады. Бәтте, аны болачыларга теләктәш дип, калудник итеп озатачаклар. Биш елгамы, ун елгамы, әллә гомерлеккәме?

Салкын базда әлеге уе тәмам ачыкланып, бөтен чынлыгы белән каршына басты. Үләсе килми аның. Бу дөньяда кыз югалту бер нәрсә, башны югалту исә — бөтенләй башка. Ни аяныч, хәзер инде котылу өчен бер әмәл-чара да юк, хак язганны күрергә кала.

Иртәгесен аны баздан чакырып чыгардылар. Караңгыда ятып сизмәгән дә: көн инде тәмам кызып җиткән, шәүләләр шактый кыскарган икән.

Брагин ак күлмәк-ыштаннан гына тәбәнәк ятагында ниндидер хуш исле тәмәке пыскытып ята иде. Кереп килүчеләрне күргәч тә урыныннан кузгалмады, башын яктыга борып, саф татарча сорап куйды:

— Димәк, корал коям димсең?

— Мин — тимерче, галиҗәнап.

— Мөселманга тимер белән шөгыльләнергә ярамый!

Анысын гына белә Әмин — атасы мәрхүм гел әйтә килде: «Бу бик хәтәр эш, улым,— диде,— урыс патшасы чүкеч тотарга кушмый безгә». Алай да егет башын диванага салырга булды:

— Минем бабам да, атам да тимер чүкеп көн күргәннәр, галиҗәнап.

— Так-с, аңлашыла. Караңгы бер авылда рәхәтләнеп корал коеп яттыгыз алайса?! Моның өчен, егеткәем, мәңгелек каторга сиңа!

— Ни диим. Аллаһ тәгалә шулай язган икән...

— Болван! Алла түгел, патша хәзрәтләре шулай язган аны. Әй, солдатлар, кулына богау салыгыз!

Драгуннар, тыз-быз чабышып, Әминнең кулларын тышаулап куйдылар.

— Инде ни дисең? — Брагин ятагыннан торды. Аннан солдатларга кычкырды:

— Кулларын азат итегез!

Драгуннар, богау йозагын ачып, егетнең кулларын чиштеләр.

— Чыгыгыз! — дип боерды түрә, чылбыр чылтыратып маташкан гаскәриләргә.— Тимерчегә ашарга бирегез!

Солдатлар, күз ачып йомган арада, күздән югалдылар. Ул да түгел, берсе өстәл сыман нәрсәгә салкын ит белән ипи кертеп куйды, кружка белән су китерде дә үзе янә гаип булды.

— Ә син утыр, тартынма! — диде Брагин аңа.— Син иртәгәдән кәйләләр, зур чүкечләр, ломнар ясарсың...

Бу хәтлесен бөтенләй көтмәгән иде Әмин. Әлеге мизгелдә аңа дөньяда Брагиннан да яхшырак кеше юктыр сыман тоелды. Ул аның Моратша хатынын кочләвен дә, башка явызлыкларын да гафу итәргә, хәтта аягына егылырга әзер иде.

— Ясыйм, галиҗәнап! — дип кычкырып җибәрде егет.

Яз җитүгә, Бүрҗән иленә янә афәт килде — Брагин үзенең солдатлары һәм яраннары белән кабат әйләнеп кайтты. Бөтен җир өстеннән, елга-күлләрдән һәм ачык зәңгәр күк йөзеннән сафлык бөркелеп торган бу язгы мәлдә явызлык вә әшәкелек дигән нәрсәләр бәндәләрнең башына да килми иде. Брагин түрәнең дә быелгы сәфәрен яхшыга юрадылар, инде, шаять, акылына килгәндер, дип өметләнделәр. Чыннан да, хәзер аның гамәл-шөгыльләрендә начарлык юк кебек. Җирләр кибеп, аяк астына сукмак төшүгә, түрә Ягалча тавыннан таш чыгартырга тотынды. Шул тарафтагы олы-олы базлардан таш ваткан авазлар тәмам көчәеп җиткән көннәрнең берендә, Брагин, ике солдат ияртеп, Әмин янына килеп чыкты.

— Тырышлыгыңны мактыйм, егет,— диде ул, алачыкка керә-керешкә.— Коралларны күп ясыйсың, тик кәйләләрдән зарланалар.

— Минем кәйләләремме начар?! — Әмин җилтерәп алачыгының почмагына килде һәм агасы Чураш саплап куйган кәйләләрнең берсен өемнән тартып алды.

Брагин агарынып китте һәм солдатлары артына сыенды.

Мәгәр тимерчедә түрә кайгысы юк иде бу мизгелдә. Аның намусына төкерделәр һәм ул акланырга тиеш.

— Карап тор, түрә!

Ул, иләмсез кизәнеп, чуерланып торган ташка кәйләсе белән китереп орды — таш дүрт кисәккә аерылып китте. Тик анысын карап тормады Әмин, кәйләсен кочаклап диярлек, Брагин каршына йөгерде:

— Менә, күрең!

Брагин кәйләне кулына алды, янчелгән урын юк иде.

— Егет икәнсең! — диде.

Әминнең йөрәге тантана итте ул көнне. Тик юкка горурланган икән. Кичкә таба аңа кәйләләргә тел тидергән Таһир картның кыйнап ташлануын хәбәр иттеләр. Аһ, белгән булсамы? Белгән булса, камчы астына үзе ятар иде Әмин.

Бүрҗән иле «аһ!» итте бу хәлгә. Мәгәр бу хакта бер-бер киңәшкә

килергә өлгермәделәр, урыс атнасының икенче көнендә солдатлар тирә-як авыллардагы бар халыкны Сапсал ям станыннан ерак булмаган Талкыш күленә куып йөри башладылар. Агач чиләкләр күтәргән бәндәләр белән юллар тулды. Алачыгы янында басып торган Әмингә аларның сөйләшүләре килеп ирешә:

— Кичә, якшәмбе көн, сәрхуш хәлендә күлдә балык тотып, кәефсафа корып йөргәндә, Брагин түрә алтын балдагын суга төшереп җибәргән, ди. Ул балдакны аңа әби патша үз кулы белән биргән булган икән. Шуңа да бик кайгыра, имеш, Брагин. Халаекларга күлнең суын сосып алырга боерган.

Сүзләре дөрес булса да гаҗәбе юк. Көнозын, аннан соң төн буе эчеп чыккан түрә ни боермас?! Айныгач, акылына килеп, барын куып кайтарыр әле.

Юк, кайтмады халык. Гомер бакый кешеләрнең өннәрендә түгел, төшләрендә дә күрмәгән бу мәшәкатьтән читтә калса да, бер Әмин генә калгандыр. Тимерченең эшен өзәсе килмәде бугай түрәнең.

Ходайбирде мулла бар икән тагын. Кичке буйда, көн сүрелгәч, мулла үзе алачыкка килеп чыкты. Нидәндер куркынган, гаҗизләнгән сымак иде ул. Алачыкка керүгә, артыннан ишекнең келәсен элеп үк куйды, шыпыртлап кына:

— Менә,— диде ул, үзенә сәерсенеп карап торган егеткә,— тәзкирнамә. Абдулла Мәзгытдин, ягъни мөсәлән, мулла Батырша язган. Яшер. Халаеклар Талкыш күле буенда җил куып йөрүдән бушагач, ирләр белән бергәләп укырбыз!

Тагы ике көннән алачык янына бер төркем ир-ат җыелды. Егетҗилкенчәкләрдән икәвен Ягалча тавына менгезеп җибәрделәр, кешекара күренсә, өстән таш тәгәрәтергә куштылар. Монда калганнар алачык буендагы чирәмгә түгәрәкләнеп утырыуга, Ходайбирде җилән җиңеннән Батырша хатын чыгарды һәм, керешсез-нисез, бераз көйләп укырга тотынды. «Бән, Абдулла Мәзгытдин, бар вә бер алланың һәм пәйгамбәребезнең мәрхәмәтенә өмет итеп...»

Алачык янын кабер тынлыгы басты, кылган сабакларындагы камкаларның кыштырдаулары ишетелгәндәй булды хәтта. Ходайбирде хатның соңгы юлын укыгач та, тынлыкны бозарга җөрьәт итүче табылмады. Шулай байтак утыргач кына Моратша:

— Әйа, гайрәтле ирләр бетмәгән икән әле дөньяда,— дип куйды.

— Амин! — дип, аның сүзен куәтләп куйды Ходайбирде.

Тәзкирнамәне хуплап, бер дога кылып өйләренә таралдылар.

Иртәгесен исә Әмин алачыгына килеп, учагын кыздырып җибәрергә өлгермәде, тышта ат тоягы тавышлары ишетелде. Ул да түгел, ишек ачылып китте һәм бусагада Байбул старшинаның кызгылт сакал-мыек баскан борчулы чырае күренде. Егет тетрәнеп куйды, ләкин аны-моны сиздермәде. Ә башыннан яшен тизлегендә: «Чистый эт икән, кичен җыелганны белеп тә алган»,— дигән уй үтте. Йортавайның тавышында исә усаллык та, мыскыл да сизелми иде:

— Саумы, кияү,— диде ул, йөзен мөлаемлык белән тутырып.

Исәнләшүен исәнләште Әмин, мәгәр кунакның сүзенә игътибар биреп җиткермәде. Аның барлыгын Байбул старшина чыраендагы таныш чалымнар җәлеп иткән иде. Менә кемгә охшаган икән Асылбикә! Шул ук кызыл бакыр сыман чәч вә сакал-мыек, шундый ук зәңгәр күзләр. Ә чыраенда ниндидер нур һәм мөлаемлык. Байбулның «кияү» дип эндәшүе аның миенә соңрак ирешә һәм ул илөү агасының күк чәчәктәй күзләренә текәлде. Нәрсә, шаяртамы?! Мәгәр старшинаның сүзләре самими иде:

— Теге чактагы җавабым өчен кичер, кияү. Хата миндә. Әлеге дә баягы комсызлык боза бәндә баласын. Әйдә, әзерлән, берсекөнгә — туй!

Егет аңа, бу әллә чыннан да ычкына башлаганмы дигәндәй, сынаулы карап торды да көлеп җибәрде:

— Нинди туй, Байбул агай? Бәне үләндерергә җыенсаң... хәлем юк бәнем. Хода кушып, җәен Чураш агамның маллары ишәйсә, көзгә туй сыман нәрсә ясап та булыр иде. Хәзергә... ашарыбызга да такы-токы.

— Бән сәннән туй ясарлыгың бармы, дип сорамыйм, кияү,—дип кызды старшина.— Бар мәшәкать-чыгымны үзем күтәрәм. Югыйсә, Асылбикәгә кулын суза башлады теге битсез.

— Брагин сәнең дустың бугай, Байбул агай?

— Андыен дустлардан ходай сакласын!

— Соң бит, бәнем үз өем дә юк, Байбул агай. Чураш агам берлә киңәшми торып...

Старшина чынлап торып кызып китте, түбәтәен сандалга ташлады:

— Үзенең нә сүләгәнен колагы ишетмиме әллә Байбулның? Үземдә яшәрсез!

— Йортка кергәнче, утка кер, дигәннәр борынгылар. Өй өлгергәч, никахны яңа нигездә уздырырбыз, Байбул агай.

Йортавай ярсый ук башлады, тынычсызланып, баскан урынында таптанырга тотынды, тавышын шактый күтәреп әйтеп салды:

— Брагин түрәнең кул уйнатуы бүген генә түгел ләбаса. Бел: сайланып-сырланып тору юк. Йә берсекөнгә никах, йә мәсхәрәләнгән Асылбикә!

Байбулның тәкъдименә күнүдән башка чарасы калмады Әминнең. Ләкин никахны тынычлап уздыру язмаган икән аларга. Икенче көнне, икенде намазыннан соң, атын кара тиргә батырып, Байбул старшина янә алачыкка килеп җитте.

— Ишетеп тә өлгергән теге сасык,—дип кычкырды — Асылбикәне тирмәсенә китерергә кушып ике солдат җибәргән.

Егет катып калды. Бармаклары кысылудан чүкеченең сабы чытырдады кебек.

— Нишлибез соң, Байбул агай.

— Бән Асылбикәне келәткә биклән куйдым.

— Кораллы солдатлар йозакны ватмаслармы димсең?

— Бүген-иртәгә генә ватмаслар. Кызны дүшәмбе көн үзем китерәм, диеп әйтергә куштым бән солдатларга. Ә сән бүген кичкә үк ирләрне җый! Түрәләрдән Бикбулат вә Алкаш ыстаршиналарны, Исмай сотникны, башкаларны үзем дәшәрмен.

Яшерен оран авазы бөтен Бөрҗән иләүенә таралды. Кичке ахшам вакытына Әмин алачыгы янына ике йөзләп ир-егет җыелган иде инде. Күбесенең җилән-чапаннары астында — кораллар.

Шушы көч-куәттән тагы да гайрәтләнеп киткән Елан-Эткол алачык түбәсенә үк менеп басты һәм, һич куркып-өркеп тормастан, кычкырып сөйли башлады:

— Ирләр! Ишеткәнсездер, теге кабахәт иләүнең гүзәле Асылбикәне рисвай итмәкче. Шул хәлгә дә түзеп торабызмы, ирләр?!

Аның кыюлыгы башкаларга да күчте — барысы бер тавышка үкереп җибәрде:

— Үлем! Үлем!! Үлем!

Шулчак Моратша сикереп диярлек аягына торып басты:

— Фатиха бирсәгез, бән ул дуңгызны бүген үк...—дип кайнарланды һәм җиләне астыннан хәнҗәр тартып алды.— Әйтегез генә!

— Ашыкма, әүвәл бән аның сакалын йолкырга тиеш,—дип каршы төште Елан-Эткол.

Җыендагылар тәмам кызды, әле бер, әле икенче тарафтан нәфрәт авазлары ишетелеп кенә торды:

— Үзем суям бәдбәхетне!

— Терелэй тиресен туныйм!

— Бәңа тапшырыгыз, бәңа!

Салмак чайкалып, Байбул старшина торып басты:

— Бүген монда иң нык җәберләнүче кеше — минем кияү. Әмингә тапшыраек без бу әманәтне!

Эшләр болай ук тирәнгә киткәч, моңа кадәр аны-моны дәшми бер читтә утырган Бикбулат белән Алкаш старшиналар үзара чышын-пошын нидер сөйләшеп алдылар. Бикбулат, мәртәбәле булырга тырышып кына, мәҗлес уртасынарак узды, көмеш төсенә кергән сакал-мыегын сыпыргалап алды да вәкарь белән сүз башлады:

— Туктагыз әле, җәмәгать, кызмагыз! Аннан соңгысын кем җыеп алыр, әй?! Төягебезгә чирү килер: йорт-җирләребезне туздырыр, үзебезне дарга асар, хатыннарыбызны, бала-чагаларыбызны кол итәр... Йә, шул да булдымы егетлек?!

Елан-Эткол, аңа очып кунардай булып, каршысына килеп басты:

— Син халаекларны куркытма, Бикбулат!

— Патшаның чирүе кара болыттай,— дип карулашты Бикбулат.

— Анысыннан да шүрләгән юк,— дип Елан-Эткolга ярдәмгә чыкты Байбул.— Кыр казакълары белән быелтырдан бирле юкка гына мәслихәтләшәбезмени? Җаек аръягындагы канкардәшләр теләсә кайчан үз йөзләренә сыендырырга әзерләр безне.

— Ие шул, кысырыкка килә башласа, далага — әллүр!

— Бала-чага булмагыз, туган төяк...— дип Бикбулат нидер сөйли башлаган иде дә, аның авызын тиз томаладылар. Тегесе, кулын селтәп, урынына ук китеп барды. Мәгәр элек утырган җиренә туктамады, кизләү буендагы атлар өеменә таба атлады. Алкаш старшина, Исмай сотник һәм тагы байтак кеше аның артыннан кузгалды.

— Китсеннәр. Куркакларның кирәге юк безгә! — дип калды алар артыннан Елан-Эткол һәм, монда калганнарга аны-моны уйларга бирмичә, сүзен дәвам итте:— Димәк ки, менә болай, ирләр. Иртәгә — якшәмбе. Брагин түрә, гадәте буенча, Талкыш күле буена сәйранга төшәчәк. Монысы рас — бән белештем инде. Иртүк күлне камап алабыз да...

Җыен төн урталарында гына таралды. Мәгәр түшәккә ятучы булмады бу төндә, һәркайсы сөңге-кылычын, ук-җәясен барлый-карый иде. Итәгенә таман сырпаланып торган Ирәндек тавына таң яктысы төшкәндә, баштан-аяк коралланган йөз егерме ир күл буенда иделәр инде. Елан-Эткол кайсы тарафка күпме кеше яшеренәсен билгеләде, аларга камыш уйдыгының куерагын, кулайрагын үзе күрсәтеп йөрде. Брагинга иң зур үч саклаучылар төркемен түрә тукталырга тиешле урынга якынрак урнаштырды.

Бу вакыт исә Бикбулат яклылардан сигез дистәгә якын кеше, ашыгыч рәвештә, Исмай сотникның Сакмар буендагы җәйләвенә җыелды. Бикбулат старшина үзе сүз алды һәм, берәүгә дә бәхәсләшер урын калдырмыйча, сөйләргә тотынды:

— Барыгыз да ишеттегез булыр, ирләр, теге ахмаклар бүген кузгалмакчылар. Бикбулат ыстаршина әйтте диярсез: муеннарын сындырачаклар алар. Без яуга кушылмайбыз! Урыслар үзебезнең авыл-җәйләүләргә килеп, безнең бәндәләргә, йорт-җирләребезгә кул сузганда гына коралга тотынырбыз! — Кайсыдыр:

— Аерылганны аю ашар,— дип кычкырды.

Башка каршы килеп торучы булмады. Ул арада табынга кымыз чыкты, кай арада пешереп өлгерткәннәрдер, табагы-табагы белән ит килде — җәйләүдә шау-шулы, уен-көлкеле мәҗлес башланды.

Берзаман ям станы ягыннан дөңгер какканнары ишетелде, бер төркем җайдак Талкыш күленә таба килә иде. Бераздан алар сөзәк ярдагы чирәмлеккә тукталдылар да ат сыртларындагы йөкләрен бушата башладылар. Күл буе ыгы-зыгы белән тулды. Солдатлар тирмә куйдылар, аяк астыннан коры-сары җыеп, ут ягып җибәрделәр. Урта яшьләрдәге кыска чәчле, ялангач ботлы марҗа, су читенә үк килеп, савыт-сабалар белән әвәрә итәргә тотынды.

Ул арада солдатларның икесе каяндыр, камышлар арасыннан, зур гына көймә куып килделәр, аны ярга тереп үк куеп, түрәне көтә башладылар. Брагин исә көймәгә утырырга ашыкмый иде. Ул, гадәтенчә, тонозын эчеп чыккан бугай, күңеле — һаман да шул шайтан суында.

— Әй, Сидоркин, эчәргә китер! — дип кычкырды ул.

Иртәнге өлешен эчеп алгач, кәефе күтәрелеп китте бугай. Брагин, авызы эченнән генә нидер көйли-көйли көймә янына килде. Солдатларның икесе, кармак-ятьмәләрен алып, хуҗалары артыннан ташландылар. Болар кереп утыруга, көймәдәгеләре ишкәкләрен кулларына алдылар һәм җай гына кузгалып киттеләр.

Алардан ерак та түгел куе камышлыкта яшеренеп яткан Елан-Эткол йодрыгы белән Әминнең янбызына төртте:

— Вакыт, бик вакыт!

Әмин аягына басты, садагыннан үзе ясаган иң яхшы угын җәя керешенә кидерде. Озаклап төзәде. Атып җибәрде. Бер үк вакытта диярлек аның колак төбеннән генә, выжт-выжт итеп, тагы ике ук очып үтте. Борылып караса, Моратша белән Чураш, бушап калган җәяләрен иңнәренә салып, күл уртасына бакканнар.

Кайсының угы тигәндер, аркылы тактага утырган Брагин кисәк тартылып куйды, ни өчендер аягына басты, аркасында, нәкъ йөрәге турында, өч укның да «койрыклары» тырпаеп тора иде. Түрә... гөрселдәп ауды. Көймә капланды. Брагин белән бергә аның дүрт солдаты да суга чумды. Берсе йөзә белми иде, күрәсең, кире калкып чыкмады, калганнары җитез генә йөзеп киттеләр.

— Берсен дә ярга җиткермәгез! — дип боерды Елан-Эткол, үзе исә күл уртасына таба аллы-артлы ук яудыра башлады. Башка урыннарда яшеренеп ятучылар да йөзүче солдатлар өстенә ук атарга тотындылар. Аларның өчесе берьюлы диярлек юкка чыкты.

Укчылар, үзләренең гаярьлекләреннән канәгать булып, масаешып торган арада, Елан-Эткол: «Ур-р-а!» — дип үкереп җибәрде һәм үзе башлап түрәнең ярдагы станына ташланды.

Бичара солдатлар, түрәнең хәмер чүлмәге тирәсендә ялманып, хәтәрлекне бик соң сизеп алдылар. Бераздан инде бар да тынды — ярда канга баткан үле гәүдәләр генә аунап ята иде. Солдатлар белән әвәрә килгән арада, су читендәге кыска чәчле марҗаның авызына курай кабып күлгә чумганын берәү дә абайламый калды.

Тирә-юньнең тынып калуын ничек сизенгәндер, хатын, шашынган кабандай, атылып күлдән чыкты, хуҗасыз атларның берсенә атланды, һәм Оренбурга таба чабып китте.

Көткәннәренчә, солдатларның казармада калганнары изрәп йоклыйлар иде әле. Елан-Эткол канлы кылычын болгап алды һәм башлап казармага кереп китте. Калганнар аның артыннан ташландылар. Казарма акырышкан, ыңгырашкан тавышлар белән тулды, аяк астында кан пычтырдады.

Ул арада казарманы ялкын чолгап алды. Болачылар бәрелә-сугыла тышка чыктылар һәм, канлы өрәкләр сыман, Сапсал ям станы башлыгының өенә ташландылар. Башлык исә эшнең нәрсәдә икәнен сизеп алган икән — ишеген ачмады. Мәгәр аны ачтыруны кирәгүче дә булмады. Кулына кисәү тотып, Моратша килеп җитте, өйнең дранча кыегына ут салды.

Бу вакыт исә ярсыган кешеләрнең икенче төркеме өмәт ишеген каерып атты. Казарма сымаграк озын агач йорттагы ямчыларга тимәделәр, авылларына таралырга куштылар. Кояш төшлеккә җиткәндә, элек Сапсал ям станы дип, зурлап йөртелгән урында тау-тау булып күмер өемнәре генә калган, ә көчәеп киткән җил кайнар көл буранын дала буйлап куа иде.

Болачылар исә янгыннан шактый читтәге кылганлы түбәгә баскан-нар да үзләре майтарган эшнең нәтиҗәсенә карап катканнар. Һич кенә

дә сүз катучы юк, йөзләрендә газап һәм үкенү. Шул рәвешле күпме басып торганнардыр, ниһаять, Елан-Эткол телгә килде:

— Йә, инде нишлибез, ирләр?

Барысы берьюлы уянып киткәндәй булды, мәгәр җавап бирергә ашыгучы күренми иде. Үлем тынычлыгын Байбул старшина бозды:

— Бәңа кайтабыз. Никах мәҗлесен үткәрергә кирәк лөбаса!

## Җиденче бүлек

Кара кайгы Неплюевның түгәрәкләнеп, күркәмләнеп киткән тормышына майның уночендә бәреп керде. Әле иртәнге буйда гына шаугөр итеп уйнап, чыркылдап көлеп йөргән Коля төштән соң хәле бетеп караватына егылды.

Көнне-төнне, алны-ялны белми казна мөшәкате артыннан чапкан Неплюевның кулыннан эш төште, сөекле оныгы яныннан китмәс булды. Коляның хәле начарланганнан-начарлана барып, ул кичке эңгер-меңгердә җан бирде.

Бәла үзе генә йөрми, диюләре дөрес икән. Бердәнберенең үлүе кайгысыннан һушы китеп егылган Татьяна килен иртәгесен, таң аткач та, аягына баса алмады. Доктор һәм өйдә булган бар кеше аның янына ташланды.

Өсте-өстенә килгән казадан эченнән генә «ах-ух» килеп йөргән Иван Иванович кинәт кенә тәне кызышканны абайлап алды, шуның артыннан ук аны бизгәк тота башлады. Хәлен берәүгә дә сиздермәде губернатор, хинин сорап алды, шуны эчеп куйды — җиңеләеп, савыгып киткән сыман булды һәм, гадәтенчә, бөтен барлыгын биреп, оныгын күмү эшләрен оештырырга керешт.

Ниһаять, майның унбишендә нәни Коляны җирләп кайттылар. Малайның анасы да җиңеләеп киткәндәй булды. Инде Неплюевка да үзенүзе карар чак җитте. Ул, кәефе юкка сылтап, йокы бүлмәсенә кереп бикләнде. Мәгәр хәлен башкалардан яшереп кала алмады — кичке буйда куәтле бизгәк аны ятакка кадаклап куйды.

Ике тәүлек буе яныннан китми йөгергәләп йөргән доктор юкка гына тырышмаган икән, майның унсигезендә губернатор йокысыннан шактый кәефле уянды, яткан җиреннән генә бер стакан кофе эчте:

— Хәлем бүген әйбәт, доктор. Син, батенька, бераз ял итеп алыр идең ичмасам,— диде.

Врач чыгып киткәч, төрледән-төрле уйлары белән ялгызы ятып калды Иван Иванович. Аның бар игътибары үз халәтенә, сәламәтлегенә юнәлтелгән иде. Берәүне дә кабул итмәде, йомшак җылы урында назланып ята бирде. Янына кайгысыннан кара коелган Николай ике тапкыр кереп чыкты чыгуын. Тик улы аны түгел, ата үзе югатты хәсрәтле баласын. Ниһаять, дөньяның бар ыгы-зыгыларыннан, мәшәкатьләреннән, соңгы ике тәүлектә интектергән саташулардан арынып, тыныч һәм рәхәт йокы белән баһадирларча йоклап китте.

Сәгать көндезге икеләр булды микән, ишетелер-ишетелмәс кенә шыгырдап ишек ачылды, аягы очларына гына басып, бүлмәгә тагын Николай килеп керде.

— Ни бар, Коля?

Тегесе авыр гына көрсенде:

— Без башта сезгә белдереп тә тормаска идек тә, хәл бик җитди булгач...

Неплюев ятагыннан күтәрелеп, терсәгенә таянды:

— Сузма, Никола, сөйлә!

— Нугай юлында башкортлар кузгалган, атай. Экспедиция начальнигы Брагинны үтереп ташлаганнар. Сапсал ям станын тар-мар иткәннәр...

— Хәбәрне кем китерде? Хәзер үк бирегә чакырыгыз!

Ул да түгел, Николай чәче-башы тузган, күлмәге теткәләнеп беткән бер хатын ияртеп килеп керде.

— Сез кем буласыз? — диде Иван Иванович.

— Брагинның кухаркасы мин.

— Сөйләгез, ни бар анда сезнең?

— Ворлар Брагинны үтереп, күлгә салдылар...

— Рәте белән генә тәфсилләп сөйләгез!

Әлеге хәбәрне ишеткәннән соң, Неплюев беравык уйланып утырды, аннан, берни булмагандай, тыныч кына улына эндәште:

— Менә нәрсә, Никола! Бар, әйт: бу хатынны ашатсыннар, эчертсеннәр, адәм рәтле киемнәргә киендерсеннәр!

Николай хатынны ияртеп, ишеккә таба кузгалды, тик бусагага җитә алмады, артында губернаторның яшьләрчә саф тавышы яңгырады:

— Тукта! Комендант Бахметевка җиткер: хәрби совет җыйсын!

Бүлмәдә ялгызы калгач, Неплюев чайкала-чайкала аягына торып басты, мундирына үрелде. Башында исә уй ташкыны кайный иде: ялкын һәрчак чаткыдан кабына ич. Янып киттеме, ансат кына сүндерермен димә. Ай-һай, күп шул янар нәрсә бу якларда! Губернада ясаклы башкортлар гына да тугыз мең йорт чамасы. Типтәрләре алты меңгә якын. Мишәрләр ышанычлы ышанычлысын. Мәгәр алары — мең ярым тирәсе... Уһу, шул кадәрле халык бердәм кузгалсамы?!

Ул инде, чыкмакчы булып, тоткага үрелгән иде. Ишек үзеннән-үзе ачылып китте, һәм каршында купшы полковник Исаков пәйда булды.

— У-у-у! Сәламәтләнүегезгә шатмын, Иван Иванович! — дип төчеләнде ул,— һич кенә дә борчырга исәбем юк иде, галиҗәнап, тик...

— Нәрсә булды? — дип бүлдерде аны Неплюев.

— Ниткәндер коткы... Татарлар өметтә җыелышып укып утырган...

— Ярый, калдыр,— диде Иван Иванович, кәгазьне бөтереп кесәсенә тыкты...

Аллы-артлы кабинетына керүче хәрбиләрне барлап, үз алдына уйланып утырды Иван Иванович. Генераллар да полковниклар, подполковниклар да капитаннар. Хәрби осталыклары чамалы булганга, сугыш театры фараз ителгән урыннардан меңнәрчә чакрым ераклыктагы Оренбурга килеп бөялгәннәр алар. Нишлисең, башкача сайларлыгы юк губернаторның, шушы калай әтәчләр белән эш итәргә, киңәшкән булып «уйнарга» кала. Һәм шулай итте дә губернатор, офицерлар урыннарына урнашып бетүгә, мәсьәләне бөтен кискенлеге белән ачып салды:

— Бүрҗән волостенда, ягъни Нугай юлында — бунт, әфәнделәр!

Карашын янәшәсендәге акыллы, аек фикерле Тәвкилевкә төбәде Неплюев. Морза инде кибәк тутырган чыпта кабына охшап бара, аңардан нинди дә булса эш көтү — суга таяну белән бер. Алай да, Тәвкилев — үзенең канкардәшләре белән көрәштә акыл туплаган карт бүре.

— Уйланып утырыр вакыт түгел, әфәнделәр,— дип дәвам итте ул, җитди төстә.— Бунтны бастыру эшенә бүген үк керешергә кирәк. Подполковник Исаков!

Купшы Исаков сикереп торды, ни үле, ни тере хәлдә катып калды.

— Сез,— дип дәвам итте губернатор, аңа карап,— бүген, хәзер үк, махсус команда башында Сапсал ям станына чыгып китәсез. Максат: явызларны исләренә китерү, бунтка катышмый калганнарны куркыту. Ворларны эзләп табарга һәм аларның тамырларын корытырга. Явызларның үзләрен, аларга ярдәм итүчеләрне тотып, монда озатыгыз! Беркемне һәм бернәрсәне кызганып тормагыз: ватыгыз, җимерегез, сындырыгыз!

Подполковник, үлемгә хөкем ителгән әсирдәй, өметсез чырай белән чыгу юлына китте. Бүлмәдәгеләр иркен сулап куйдылар. Әмма губернатор киңәшмәне ябарга ашыкмый иде әле:

— Бригадир Бахметев! Үрге Җаек һәм шул тирәдәге башка крепостьларга чапкыннар җибәрегез, андагы мишәр, башкорт старшиналарына һәм регуляр командаларга минем фәрманны җиткерегез! Һөҗүмгә күчсеннәр! Сапсалга таба хәрәкәт итүче барлык хәрби көч белән җитәкчелек итү сезгә йөкләнә! Бүген үк Воздвиженск крепостена чыгып китегез!

— Баш өсте, галиҗәнап!

— Экспедицияне әйбәт башкарып чыгарсыз дип ышанам, бригадир! — дип сүзен дәвам итте Неплюев. — Шуңа да бунт бастырылганнан соң, старшиналарның яңаларын читтән китерегез! Икенчедән, баш күтәргән Бүрҗән волостеның урта бер җирендә яңа крепость салдыра башлагыз. Әйтик, Зилаер крепосте. Анда Казан драгун һәм пехота полкларының алты ротасын урнаштырырбыз. Уңышлар телим, комендант!

Кинәт барысының да теле ачылды. Тәвкилев тә урыныннан кузгалды.

— Син кал әле, Алексей Иванович,— диде аңа губернатор, бераз серле итеп. — Мә, укы һәм тәрҗемә ит! — Иван Иванович аптырабрак калган Тәвкилев алдына кәгазь төргәге чыгарып салды.

Морза шигәеп кенә кулына алып, күңеленнән исә ниндидер бер ләззәтле хис дулкыны узды. Шөкер, яшь, гайрәтле чагындагы һөнәре һаман да ярап куя бит әле.

«Я, Абдулла Мазгутдин, уповая на Бога и милость пророка, следуя стезям потомков его учеников, воспоминаю и вразумляю высшее повеление вам, в российском государстве живущим и от неверных россиян разными нападками и коварствами обидимым и пришедшим во изнеможение и не состояние и в том пребывающим следующим образом...»

Тәвкилев туктап калды. Әлеге кәфер сүзләрне, үзе язгандай, курkынып, губернаторның күзләренә карады, калтырана-калтырана әйтеп куйды:

— Бу бит... Бу бит... халыкка мөрәҗәгать бу, морза. Кем соң ул Абдулла?!

— Ниндидер бер мулла булса кирәк. Ялгышмасам, Себер юлыннан. Ибраһим хәзрәтнең аңа ахунлык рисаләсе әзерләп йөргәнен хәтерлим. Халыкта Батырша дип йөртәләр үзен...

Губернаторның иң зур ике түрәсе вакыт дигән нәрсәне оныттылар. Әйтерсең, ниндидер бер мулла язганны түгел, патша хәзрәтләренең гаять мөһим указын укыйлар. Неплюев мөрәҗәгать белән шулкадәр кызыксынган иде ки, хәтта донесение белән керергә теләүчеләрне дә кабул итмәде. Әнә шундый киеренкелектә ике сәгатьләп вакыт үтте. Ниһаять, Тәвкилев соңгы җөмләне тылмачлады:

— На сих днях и солтана турецкого из Турции войска на Астрахань пришли для воспротивления и умерщвления оных неверных россиян... — Морза кәгазьне өстәлдәге яшел постау өстенә ташлады да, пайтәхет театрындагы драма артисты сыман, хисләнеп кычкырып җибәрде. — Аһ, кабахәт, ах, явыз! Халаекларны яуга өнди бит, әшәке җан!

Неплюев та телгә килде һәм, гадәтенчә, сабыр гына:

— Дошманны ахмакка санарга ашыкма, морза! — диде. Неплюев урыныннан ук торып китте һәм бүлмәсен бер әйләнеп килде. — Әйе, әйе, алар, без уйлаганча, ахмак та, көчсез дә түгелләр.— Губернатор өстәл артына килеп басты һәм Тәвкилевнең күзе алдында канлы сугыш белән җитәкчелек итүче генералга әверелде. — Менә нәрсә, Алексей Иванович, бүген үк кыргыз-кайсакларның Кече йөз ханы Нуралигә, урта йөз ханы Аблайга хат языгыз: ырудашларын башкортларга ярдәм күрсәтүдән, аларны яннарына сыендырудан тыйсыннар! Сүз уңаенда ханнарның бездән алтышар йөз сум хак алып торуларын да исләренә төшерергә кирәк. Хәер, аларын үзем язам. Сез исә, улым Николай Иванович белән бергәләп, кыргыз-кайсакларның старшиналарына, батырларына, халыкка сүзләре үтәрдәй башка күренекле кешеләренә махсус мөрә-

җәгать әзерләгез! Бүләкләрне һич кызганмый вәгъдә итегез, ләкин сүз арасында куркытып, йөрәкләренә шом салырга да онытмагыз.

Никадәр генә ашыкмасын, подполковник Исаков, үзенең командасы белән, Талкыш күле буена майның егерме икесендә генә килеп житте. Беренче эше итеп ул, яраннарын иярттеп, Сапсал ям станын барып карады. Биредә, чыннан да, көл-күмер өемнәре генә утырып калган, тирә-юньдә им өчен бер җан иясе күренми. Этләр генә дә очрамый, ичмасам. Мондый хәл экспедиция эшен шактый катлауландырып җибәрсә дә, Исаков югалып калмады. Көл-күмер өемнәреннән читтәрәк тирмә куйдырды һәм офицерларның берсен ям станы башлыгы итеп билгеләде.

Күзәтүчеләр, бик озак йөреп, кичке буйда гына әйләнеп кайта башладылар. Хәбәрләре бер үк — билгеләнгән юнәлештә күпме генә бармасыннар, кеше-карага тап булмаганнар. Тик иң соңгысы булып кайткан төркемнекеләр генә күлгә таба шактый зур коралллы отряд якынлашып килүен әйттеләр.

Күл буенда әмер авазлары ишетелде. Солдатлар, мылтыкларын тотып, камышлыкка яшеренделәр. Ул да түгел, теге як ярда сөңгеләр, ян-җәяләр белән коралланган атлылар төркеме күренде. Исаков инде: «Пли!» — дип команда бирергә җыенган иде. Шул мизгелдә отряд алдында килүче кызыл сакаллы бәндәнең сөңгесендә ак чүпрәк күреп алды.

Ул арада җайдаклар тәмам якынлашты. Исаков тылмачы колагына иелде, шул арада күл буеның дәһшәтле тынлыгында саф татарча әмер яңгырады:

— Тукта, туктагыз! Коралларыгызны ташлагыз!

Алдан килүченең аты кадаклангандай туктап калды. Башкортлар башлыкларын урап алдылар, нидер киңәштеләр бугай. Аннан инде сөңге-җәяләрен, кылыч-укларын җиргә ташладылар.

Килүчеләрнең кара сакаллысы, яше, тазасы, Исаков каршына җитү белән, җиңел генә сикереп атыннан төште һәм, күптән күрмәгән туганын очраткандай, шатланып бил бөкте, сүзен әйтте:

— Бикбулат ыстаршина булабыз. Менә монысы — Алкаш ыстаршина.

Старшина үзләре белән таныштырган арада, башкалары да атларыннан төшеп, подполковник алдына килделәр һәм башларын игән хәлдә катып калдылар.

— Яхшы, — диде Исаков, коры гына. — Йомышыгыз ни?

— Әйттем ич, түрә әфәнде: без патша әгъзәм хәзрәтләренә вирнай кешеләр булабыз. Сезгә ярдәмгә дип килдек, ягъни мәсәлән, вурларны аулашырга.

— Шунысы кызык, ворлар кая соң? Гомумән, волостьның халкы кайда? — Подполковник янәшәсендәге капитанга күз кысты.

— Качтылар, урман-тау араларына качтылар. Җаекның теге ягына, кыр казаклары янына шылучылар да бар, диләр.

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, солдатлар, кинәт ташланып, сигезесен дә эләктереп алдылар. Исаков бәрелешнең нәтиҗәсен көтеп тормады, мәһабәт буйлы, ыспай ярдәмчесенә кычкырды:

— Капитан, ут!

Башкорт җайдакларының дистәләбе кан эчендә җирдә ятып калды, калганнары исә «ә» дигәнче атларына атланып, якындагы урманга таба чабып киттеләр. Драгуннарның зур төркеме артларыннан төште.

— Менә шулай, — дип зур канәгатьлек белән нәтиҗә ясап куйды Исаков һәм өлгер капитанга таба борылды. — Бу туземецларны таң белән Оренбурга озатырга кирәк.

Таң яктырганда, атын ак күбеккә батырып, губерна үзәгеннән чапкын килеп төште.

— О-о, киек сунарчының каршына үзе йөгереп килеп чыгар, имеш,— дип каршылады аны Исаков.— Бик вакытлы килдең. Миңа рапорт, Неплюев җәнапләреннән үз кулына тапшыр.

— Әлбәттә,— диде ерак юл килүдән тәмам талчыккан майор.— Тик алар бу көннәрдә генә укый алмаслардыр, мөгаен — Иван Ивановичның килене дөнья куйды бит...

— О-о, губернаторны белмисең икән әле син,— дип бүлдерде аны подполковник.— Килене түгел, үзе үлгәндә дә дәүләт мәнфәгатен кайгыртачак ул. Күрәм, син дә бер дә юкка чапмагансың, майор.

— Сез хаклы, подполковник. Мин, сезгә өстәмә инструкция китердем. Кул куеп алыгыз.

Исаков чапкын сузган кенәгәгә кул куйды да ашыгып пакетны ертты һәм андагы юлларга текәлде: «Качкын явызларның калганнарын — агай-энеләрен, хатыннарын, бала-чагаларын — кыскасы, бөтен токымнарын тотып, Оренбурга озатыгыз, мөлкәтләрен конфискацияләгез, мал-туарларын суеп, гаскәриләрне сыйлагыз!»

Агачлар арасында нидер шатырдады, дөпелдәгәндәй булды. Учак янындагылар, бердәм борылып, шул якка карадылар. Караңгыга күзләре ияләшергә өлгергән иде инде — аның Әмин икәнен тиз танып алдылар. Егетләр коралларын урталыктагы карт юкә төбенә ташладылар. Байбул старшина исә, чукмарын кулына тоткан килеш, учакка якынлашып килүче Әмингә каршы атлады.

— Шөкер, кияү, исән-аман икәнсең. Йә, ниләр бар анда?

— Яна, бөтен Бөрҗән иле яна,— диде Әмин авыр гына һәм атының тезгенен Асылбикәгә тоттырды.— Мәхшәр анда, бабай. Солдатлар урман-әрәмәләрне тарап йөриләр. Хатын-кыз дию юк, бала-чага дип тә тормыйлар, кулларына эләккән бер адәмнәрне богаулап Яман калага озаталар.

Аларны урап алырга өлгергән качаклар уфтанулы итеп көрсенеп куйдылар. Кемдер учак терелтеп җиберде — аланга кот кунды.

— Димәк ки, кыр-казаклар янына олагудан башка чара юк,— дип сөйләнә-сөйләнә, Байбул учак янындагы имән төбенә утырды.

— Сүзең хак, ыстаршина,— дип Байбул әйткәнне җөпләде Моратша,— күрәләтә кулны богаулатып булмый бит инде.

— Ие шул, ирекле көннән катыр китәргә димәгән.— Монысы Чураш күкрәгеннән сыгылып чыкты.

Инде шул ниятка килеп беттек дигәндә, старшинага каршы утыручы Елан-Эткол телгә килде:

— Күгәрченгә кайда да бодай, диләр диюен дә, ул казак сахраларына бер дә җан тартмый бит әле, җәмәгать. Әллә соң көзгә хәтле сабыр итәбезме? Бөрҗәнне мәңге саклап ятмаслар бит инде ул драгун дигәннәре!

— Уйлама да, Эткол агай,— дип аңа каршы төште Әмин,— тамырны корытмый торып, китәргә охшамаганнар. Зилаер суы буенда яңа кальга сугып яталар.

— Син, Эткол, халаекларның күңеленә вәсвәсә салма инде!

Старшина әйткәнне бердәм күтәреп алдылар:

— Ие шул, дөрест. Монда калу ярамас.

— Ихтыярыгыз алайса.— Елан-Эткол салкын кан белән тәкәббер генә барына каршы чыкты.— Бин илемдә калам! Барыбыз да посып бетсәк, ул явызларны Уралдан кем куар?!

Тынлыкта Әминнең кырыс тавышы аеруча куәтле яңгырады:

— Бин синең белән, Эткол агай!

Байбул старшина, итәгенә утлы күмер чәчрәгәндәй, өтәләнеп аягына басты, артында торган Әмингә таба борылды:

— Син шулай дисең дә, кияү, безне кем карар да, юлбасарлардан кем саклар. Ие, елкы көтүе ишле. Аннан да битәр, теләсә кайсы

фасикъның күзе төшәрдәй яшь хатының бар бит әле. Нәрсә, аны язмыш карамагына тапшырасыңмы?!

Монысы инде Әминнең иң авырткан җире, чи йөрәк ярасы. Чыннан да, Асылбикәдән башка мизгел дә тора алмый бит ул хәзер. Аның дәшмәвен ризалашуга юрады Байбул һәм җиңүче кыяфәтендә сүзен тукуда булды:

— Шулай, җәмәгать, иртән таң белән кузгалабыз. Көн яктысында Җаекка җитеп, бер-бер агачлыкта яшеренеп торырбыз да, төнен елганы кичәрбез. Аръяк ярда безне иркенлек вә хөрлек көтә!

Башкача старшина белән бәхәсләшүче табылмады. Бары бер Елан-Эткол гына:

— Бәнекеләрне ярдәмеңнән ташламассың, ыстаршина,— диде.

Иртәгесен кояш чыгып килгәндә тулы бер яу булып кузгалдылар.

Кояш кыр-казаклар ягына авышып түбәнәйгәндә, Җаек буена килеп чыктылар. Текә ярдан ике-өч чакрым гына үсеп утырган зур булмаган каенлык бар икән. Әмир кәрвандагыларга шунда җитеп туктарга һәм ял итәргә кушты.

Кояш казак даласына төшеп чумганнан соң, кичке эңгер-меңгердә кузгалдылар. Җаек буендагы тынлык шулкадәр ымсындыргыч иде ки, яр кырыйларын кабат карап-тикшереп чыгу башларына да килмәде. Тик барыбер Әмин һәм аның егетләре һаман да кәрван башында иделәр әле. Асылбикә исә иренә тагылган сыман. Гаиләсен Җаекка кадәр озатып баручы Елан-Эткол белән Байбул старшина да аларга кушылды.

Менә алар инде ярның сөзәкләнеберәк торган җиренә җиттеләр, су буендагы таллыкка таба төшә башладылар. Шулчак әллә каян гына, җир астыннан үсеп чыккандай, каршыларында дистә ярым чамасы ир-егет калыкты. Кулларында коралллары юк югын, мәгәр килеш-кыяфәтләренә караганда — Җаек казаклары. Ул арада берсе, мундирына караганда, офицеры Әмин атының тезгененнән тотып алды.

— Тукта! Туктагыз!! Мин рус каравыл отряды башлыгы капитан Лядомский. Сез кемнәр һәм болай төн уртасында кая барасыз?

Аны-моны хәйләләп, сүз куертып торыр ара юк иде. Әмин биләндәге чукмарын тартып алды һәм, әлеге офицер аңына килеп өлгергәнче, каты кизәнеп, аның башына сукты — тегесе «әһ» тә итми авып төште. Янәшәдә генә кылыч чыжлаганы ишетелде, ул да түгел капитан белән янәшәдә килгән капралның канлы башы әрекмәннәр арасына тәгәрәде. Беренче уңыштан кайнарланган Елан-Эткол канлы кылычы белән капралларның икенчесенә кизәнде. Мәгәр анысын чабарга өлгермәде, Асылбикәнең бәләкәй, җыйнак хәнҗәре тегенең җилкә тамырына батып кергән иде. Егетләр дә тик тормый: һавада кылычлар сызгырды, сөңгеләр айкалды — беравыкта аяк асты кан белән тулды. Казакларның барысы да диярлек җирдә аунап яталар иде инде. Тик берсе тал арасына чигенеп, яшеренде. Моннан чакрым ярым чамасы ераклыкта гына отрядның төп көче төнге ялга тукталган иде. Казак шунда ашыкты.

Качакларның исә уңга-сулга карап торыр вакытлары юк иде. Байбул старшина, атын камчылап, яр өстенә менеп китте һәм көтүчеләргә елкыларны елгага таба куарга кушты.

Алай да елганы тынычлап, исән-имин кичү насыйп булмаган икән. Баштарак кузгалганнар теге якка чыгып җитәргә өлгермәделәр, яр башында казаклар төркеме күренде, гөрселдәтеп мылтыктан аткан тавышлар ишетелде. Бәхеткә, алар тал куаклары баскан су читендә ни барын юньләп күрмиләр, болай куркыту өчен генә аталар иде. Аның каравы, яр өстендә торганлыктан, үзләре качакларга көндезге сыман ачык күренә. Уклар очканы ишетелде — текә ярдагылар берәм-берәм җиргә кадалдылар. Һөҗүм сөрлекте, казакларның калганнары борылып кирегә йөгерделәр.

Әмин чираттагы угын атмый тыелып калды, җәясен иңенә салып, елгага таба борылды. Бакса, каршында — Асылбикә.

— Син, син нишләп монда, Асылбикә?! — дип кычкырганын сизми дә калды Әмин.— Бар, бабайдан калма!

— Мин синнән башка суга кермим, Әмин!

Тагы да бәхәсләшеп торыр ара калмады. Казаклар судан килеп чыктылар бу юлы. Акылга да утырганнар бугай, баягыча алагаемга килмиләр, талларга ышыклана-ышыклана, ата-ата якынлашалар. Качаклар да җавапсыз тормыйлар билгеле, күренгән бер карачкыга төбәп ук яудыралар. Ләкин аларның аркаларына аскан садаклары бушап бара иде инде.

Әмин садагыннан соңгы угын суырып алды һәм, аны якынлашып килгән казакка төбәгән хәлдә, кычкырып җибәрде:

— Суга, суга сикер, Асылбикә!

Соңгы угын очырып җибәрде дә, кисәк борылып, Җаекка ыргылды егет. Тик йөгереп китә алмады — үзеннән өч адымда гына Асылбикә кан эчендә аунап ята иде. Ул сөйгәне янына ташланды.

— Колынкаем, нәмә булды сиңа?!

Җавап түгел, ыңгырашу авызы да ишетелмәде — Асылбикә җансыз иде. Әмин, хатынының җансыз гәүдәсен күтәреп алырга дип, җиргә иелде. Нәкъ шул мизгелдә таллар арасыннан әзмәвердәй казак килеп чыкты, Әмингә мылтыгын төби башлады. Егет сөйгәнен кулыннан ычкындырып җибәрде һәм, ярсып, дошманы өстенә сикерде, хәнҗәрен сабына кадәр аның күкрәгенә кадады.

Ул кабат Асылбикәсе янына йөгерде. Мәгәр бу юлы да хатынның гәүдәсен күтәреп ала алмады. Кырыеннан гына Елан-Эткол чабып үтте, кыргый тавыш белән Әмингә кычкырды:

— Үлеләр белән маташма, ахмак!

Чыннан да, Елан-Этколның үкчәсенә басып диярлек ат кебек дүрт казак йөгереп килә иде. Җан саклау теләге мәхәббәттән куәтлерәк икән. Әмин ике-өч сикерүдә су читенә җитте, елгага ташланды.

Ул теге як ярга чыкканда, исән калганнар бар да бер урынга — Коры чокырга җыелганнар иде инде. Шаулашмый гына мондагыларны барлап чыктылар. Асылбикәдән башка тагы өч кеше югалган икән. Байбул старшина, ике кулы белән башын тотып, шашынгандай һаман бер үк сүзләрне кабатлый иде:

— Елкыларым, аһ, елкыларым! Ярты көтүем харап булды!

Бу вакыт исә теге як ярдагылар да шулай ук күңелсез шөгыль белән мавыгалар иде: капитаннан кала, ике капрал, җиде казак үтерелгән, прапорщик һәм янә дә егерме тугыз казак авыр яраланган. Ашыгырга, бу җенле елгадан читкәрәк китәргә кирәк.

Кыргыз-кайсаклар ягындагы качаклар да кабаланалар иде, билгеле. Таң атканчы, Җаектан ераграк китеп, бер-бер җәйләүгә барып егылу фарыз.

Елан-Эткол исә хатыны, балалары белән саубуллашты да, бөтенләй башка якка — Җаекның үрге агымына таба кузгалды.

— Тукта, Эткол ага, бин дә аръякка бит. Асылбикәм көтә! — Әмин дала түренә таба кузгалган якташларына да, ялгызы чаукалыкка ашыккан Елан-Этколга да борылып карамады, кабаланып Җаекка таба китеп барды.

Елгада су салкыная башлаган иде инде. Ләкин Әмин моны сизмәде. Үзен аска сөйрәгән коралларын саклый-саклый, эт сыман тын гына йөзеп, Җаекны кичте. Агымны исәпкә алуы дөрес булган икән, нәкъ баягы кыргын урынына килеп чыкты. Атылып Асылбикә янына килде, хатынының кулларын, аякларын, битен капшап-капшап карады — аның өчен дөньядагы иң асыл затның гәүдәсендә кабер ташы салкынлыгы иде. Ул ярының баш очына утырып, тирән уйга чумды.

Шул хәлендә әллә онытылып киткән, әллә инде черем итеп алган, Әмин күзләрен ачканда, бөтен яр буен сөт күбеге сыман ак томан баскан иде. Егет каударланып Асылбикәне күтәреп алды. Бераздан кичә генә үзләре килгән эзгә төште. Бу мизгелдә ул кайгыра да, елый да алмый, бөтен җаны-тәне үч һәм нәфрәт белән тулып ташыган иде аның.

## Сигезенче бүлек

Батырша көнен дә, төнен дә Гәйнәдән хәбәр көтте. Мәгәр анысы башка яктан — Урал буеннан килеп ишетелде. Аның иртән йокысыннан торып, кулына комганын тоткан хәлдә, абзарлар ягыннан кереп килеше иде. Уйламаганда-көтмәгәндә каршында Яхъя пәйда булды. Егет, әйтерсең, әле генә чабыштан кайткан:

— Хәзрәт,— дип кычкырды ул, сәлам бирергә дә онытып,— Нугай юлында бөрҗәннәр кузгалган!

Мулла беравык дәшә алмый торды, аннан инде үзен-үзе кулга алды, тынычлыгын сакларга тырышып, әйтеп куйды:

— Белеп сөйләйсеңме, мелла Яхъя, әллә чүбек чәйнәүчеләр гайбәтен генә кабатлыймсың?

— Алдаса, теге бәндә алдыйдыр, хәзрәт. Бүген төн мәдрәсәдә Урал аръягында гыйлемлектә торып, Туруйскида бер сәүдәгәрдә хезмәт итүче шәкерт кунып чыкты. Ул әйтә: бөрҗәннәр купты, ди. Урыс түрәсен үлтереп күлгә салдылар вә үзләре посып беткәннәр, ди.

— Кая, үзен чакырың әле!

— Ул таң белән китеп барды шул, хәзрәт.

— Ал-лай.— Батырша телен тешләгәндәй тынып калды һәм шактый көттереп кенә сүзен әйтеп бетерде.— Хәбәреңнең чынын-ялганын белгән кеше юк. Шуңа да бу хакта авызыңны ачып бирәүгә дә дәшмә.

— Өлкәнрәк шәкертләр дә ишеттеләр бит, хәзрәт.

— Аларга да әйт: сүзләп йөрмәсеннәр.

Иртәнге чәе чәй булмады мулланың. Гомер булмаганны, тары чәчү хафасы турында сүз кузгаткан Зөлхәбирәсенә җикерде хәтта. Ярый әле әйтешүләре зурга китмәде, ишек шыгырдаганы һәм аның артыннан ук: «Хуҗалар үдәме?» — дигән тавыш ишетелде. Ул да түгел, өйгә сакалмыегын пөхтә итеп кыркыткан, аксыл чырайлы берәү килеп керде. Гәйнә илөүеннән мелла Исхак иде бу.

— Әссәламегаләйкем, хәзрәт. Исән-аман торамсыз?

Сәлам алынып, гореф-гадәт буенча хәл-әхвәл сорашкач, чәй янына утырдылар. Кунак беренче чынаягын эчте дә сүзенең асылына күчте:

— Безнең урман тарафлары, Гәйнә кешеләре — барчамыз әзермез. Бәне сез хәзрәтләргә хәбәр бирү өчен җибәрделәр.

— Хәердер,— дип куйды Батырша, бүген иртәдән бирле беренче тапкыр күңеле булып.— Әлхаль сабыр итеңез. Бән Оренбурга барып киләем, ул тарафларның хәлен беләем. Кабат хәбәрләшербез, иншалла тәгалә.

Оренбург сылтау өчен генә, төп йомышы аннан да арырак — Нугай юлында аның. Шул якларны урап, андагы камил бәндәләр, галимгөләмә белән киңәшми генә, хәзер инде ни дә булса майтару мөмкин түгел. Бөрҗәндәге хәлләр хак булса, алар киләпне тулысынча чуалта.

Андыен ук ерак сәфәргә чыгу өчен пашпурт кирәк. Анысын юллаганда, инде күп кенә бәндәләрнең теленә кереп өлгергән Нугай юлына барам, дип әйтеп булмый да. Оренбурга исә сылтавы бар — ахуннар янына барышы, янәсе.

Нияттән гамәлгә бер генә адым. Ул Кузьма писыр янына барып кайтырга булды.

Вакыйган, дусты аны бер сүздән аңлады. Иске паспортка язылганнарны пычак белән кырып ташлады да, шунда ук нидер язып, «яңа»сын

өмәлләп бирде. Йомышының болай һич көтелмәгәнчә ансат хәл ителүеннән куанган Батырша, кайтып китәргә дип, урыннан кузгалган иде инде. Әмма Кузьма авыз ачарга да бирмәде, өстәле янына утыртты, бәләкәй генә имән мичкә белән ачы бал китереп куйды.

Ихлас күңелдән кунак итүне кем бәһаламый? Батырша да чишелеп китте. Тәмен белеп кенә, ләззәтле сөйләшә-сөйләшә, сыйланырга тотындылар. Үзе мөселман булмаса да, Кузьма мондагы халаекларга хәерхаһ бәндә, аларны кызганып вә жәлләп берсеннән-берсе аянычхәлләр бәян итте. Аннан инде сер итеп кенә знакумына зур яңалык җиткерде:

— Урыс йортына хәвеф төште бит әле, Батыршаһ. Ислам даирәләреннән гаскәр килә, имеш, дигән сүзләр йөри. Кала-кальгалардагы чирү кешеләренә фәрман бар — дарыны коры тотарга, орышка әзер торырга дип...

Димәк, түрәләр инде нидер сизенгәннәр. Димәк, Нугай юлына баруны ашыктырырга кирәк. Шушы мизгелдә сәфәренә чыгардай булып, өенә ашыкты мулла. Юл ерак, заманалар аман түгел — иптәшкә берәр ышанычлы юлдаш булса икән, дип уйланды ул. Бердәнбер таяныр кешесе Яхъя аның. Мәгәр аны алып китсәң, Зөлхәбирә ике кулсыз калачак. Мостафа углы Борһан ризалашса әллә?

Соңгы вакытта, төгәлрәк әйткәндә, Батыршаның тәзкирнамәсе халаеклар арасында мәгълүм булгач, Карышбашның урта тормышлы кешесе Мостафа углы — буйга шәп кенә шәкерт, мулласы тирәсендә еш чуала башлады. Бервакыт хәтта җомгадан соң мәчет ишеге төбендә остазы белән мәҗлес корып утырды. Егет Батыршаның чакыруын бәйнә-бәйнә укыган һәм аны чын йөрәктән кабул иткән. Бүгеннән яуга чыгарга, халаекларга җәбер-золым китерүчеләрне җир йөзеннән юк итәргә әзер. Ие, юлдашка шул егеттән дә кулае булмас, дигән нәтиҗәгә килде Батырша кайта торгач һәм юл уңаена ук Мостафаның тәрәзәсен шакыды. Сүз кыска булды. Егет үзе дә, атасы да мулланың ниятен хупладылар.

Атларны Сөләйман старшинадан алды Батырша. Карышбаш белән Оренбург арасы йөрмәгән юл түгел, сәфәргә кинәнеп кузгалдылар. Өстәвенә, юлларның ныгып җиткән, доньяның гөлгә күмелгән чагы. Мондый мәлдә ил-җир күреп йөрү — үзе бер гомер. Алай да юл азабы — гүр газабы. Син никадәр генә ашыксаң да, ул үзенекен итә. Яман калага атна дигәндә генә барып җиттеләр. Өмәткә урнашып, тәмләп кенә кайнар аш ашап, чәй эчеп алуга, Батырша тагы каударлана башлады. Борһанга иркенләп ял итәргә кушты да, үзе Ибраһим ахун янына кузгалды. Сәфәрнең сылтавын чынга ашырырга, эзен югалтырга кирәк иде аңа. Монысына җае да бар — ахунлык рисаләсе хакында сүз кузгатыр.

— Әйа, Баһадиршаһ, бик көттереп, зарыктырып кына йөрисең,— дип каршылады аны ахун һәм, өстәле артыннан чыгып, аңа ике кулын сузды.— Әссәламегаләйкем, узың, мелла, менә моннан утыр! Без монда, синең хакыңда ахунлык рисаләсе төзеп куйганыек. Себер юлына ахунлыкка...

— Бәңа мәгълүм, вәлинигъмәт. Фәтвагызга тәшәккермен.

— Афәрин, Баһадиршаһ, афәрин. Ул рисаләне төзеп, мөһеребезне басып вә кул куеп, Габделсәлам ахунга бирдек, сезгә тәслим кылыр өчен. Аны кабул итеп алгайсыз!

— Без кемнәрне дин мәртәбәсе илә зурлаганыгыз өчен, хак тәгалә сезләрне йөзен ачып хөрмәтләсен. Вә ләкин кабул итмәде дип рәнҗү тапмагайсыз, бу хәлдә теләмәйбез.

— Анысы нә диюең тагы, мелла Баһадиршаһ?

— Күрәсез, доньялар буталып тора, вәлинигъмәт. Рас булса, бәрҗәннәр купкан, диләр әнә.

— Хәбәрең хак хагын. Вә ләкин Бәрҗән иләүендәге хәлләрнең сезләргә нә катнашы булыр икән?

Сүз белән мавыгып, теленнән ычкынганын сизми дә калды Батырша:

— Нугай юлындагы ялкын Себер даругасына да үрләмәс дип кем әйтер? Ие, янгынның безне дә ялмап алуы бар бит. Йортына ут капканда, кем генә кул кушырып утырыр икән?!

Ибраһим сискәнде, алдындагы кәгазьләрен караган булып, берадык дәшми торды. Аннан инде, Батыршаның сүзенә куангандай, әйтеп куйды:

— Бирсен ходай! Әйткәнең фәрештәнең амин дигәненә туры килсен!

Батырша артыгын сөйләп ташлавын абайлап, телен тешләде, кашлары астыннан гына Ибраһимга бакты. Үз булып, телне чишәргә маташуы түгелме? Алла сакласын, үз мәнфәгатен яклап, башыңны катыр җибәртүе бар. Андыйлар янында саграк булуың яхшы. Һәм ул сүзне башка юнәлешкә борырга ашыкты:

— Гәбделсәлам ахун хәзрәтләре ни хәлдә торалар, вәлинигъмәт? Исән-аманнармы, сезнең катка килгәлиләрме?

Ибраһим ахун да аның хәйләсен аңлады һәм уенга кушылып китте. Әңгәмә сузылды, ул инде Батыршаны туйдыра башлады. Тагы ни дип утырмак кирәк?

— Китим, вәлинигъмәт.

— Әйа, чөй эчми торыпмы?

— Кыстамагыз, вәлинигъмәт, губерна кәнсәсендә йомышларым бар.

— Мәйлең алайса,— диде Ибраһим, килешеп һәм сүзен кабат ахунлык мәсьәләсенә борды.— Рисаләне алып китмәйбез дисез икән, соңырак үземез җибәрермез.

— Иншалла тәгалә, хәер улыр,— диде Батырша, чыга-чыга.

Хәзер инде аны монда бер генә нәрсә дә тотмый иде. Борһан белән икәүләп өмәттә тамакларын туйдырдылар да, Гәбделсәлам ахун янына киттеләр.

Каргалыда алар теге чакны үзендә кунып чыккан Гәбделсаттар шәкерт янына фатир төштеләр. Якташы белән очрашу бигрәк тә ярап куйды Батыршага, егеттән күңеленә хуш сүзләр ишетте. Чәйдән соң алар икәүләп, Гәбделсәлам ахун мәдрәсәсен карарга барган булып, урамга чыгып киттеләр. Мәчет янындагы аулакка җитүгә, сабырсызланып сорады Батырша:

— Ни хәбәрең бар?

Егет як-ягына каранып алды, икәүдән-икәү икәнлекләренә инангач, сөйләп китте:

— Каргалы татарларын, үгетләп-үгетләп, Бөрҗән иленә пахутка җибәрделәр. Без анлар белән сүзләштек: башкорт җәмәгатьләре гаярьрәк вә куәтлерәк булса, анларга кушылыгыз, кырыла башласалар, анларның котылмагына вә һәм һәлак булмакына сәбәпче улыгыз, дип.

— Хәердер. Тагын ни хәл вә ни хәбәр?

— Кичә өмәттә ике шәкертне очраттым. Хәер, тиз үк үзләрен алып киләм.— Гәбделсаттар өмәт ягына китеп барды.

— Кая барасыз?— дип сорады алардан Батырша.

— Урал аръягында гыйлемлектә торып, Казан ягына өемезгә кайтып барамыз,— диде шәкертләрнең мөлаем чырайлысы.— Туруйскида тора торган чирү кешеләре — мишәрләр һәм башкортлар хәбәр җибәрделәр: бик саклык белән торыгыз, халык бик тиз күтәрелер, диделәр.

Ишеткәннәре ымсындыргыч өметле дә, хәвефле дә иде. Әмма бу яклардагы чын хәлне Гәбделсәлам ахун гына төшендереп бирә алыр, мөгаен. Батырша, ашкынып, остазы белән күрешү сәгатен көтте.

Очрашу урыны итеп мәдрәсә тәгаенләнгән иде. Монда да кала рухы кагылган икән, Гәбделсәлам аны иркен генә якты бүлмәдә каршылады. Әллә Каргалы килешкән, әллә инде замана җилләре кагылган, Гәбдел-

сәлам тәмам мөһабәтләнеп, олпатланып киткән. Өстендәге бәрхет казакие, затлы җөббәсе, олуг тантаналарда гына урала торган ак ефәк чалмасы һәм бик пөхтә итеп түгәрәкләп кыркылган көмеш сакалы аны чын кала зыялысы итеп күрсәтә. Элеккеге Ташкичү мөдәррисеннән якты чырай да үткер күзләр калган.

— Хуш килдең, кем мелла Баһадиршаһ, түрдән узың,— диде ул, кенәфидән урын күрсәтеп.— Бән, дөресрәге, без сәне күптән көтәбез!

Бераз серле итеп әйтелгән шул сүздән соң Гәбделсәлам туктап калды, почмакта торган калай тышлы сандыгы янына килеп, аны ачты һәм кулына кәгазьләр алды. Батырша исә сүзнең ахунлык рисаләсе хакында барачагын чамалап, тыйнаклык күрсәтергә тырышты, дәшмитынмый гына көтте. Мәгәр ахун һич уйламаганны әйтеп куйды:

— Әллә соң безнең хат сезләргә барып ирешмәдеме, мелла Баһадиршаһ!

— Көлчәр иләүенең Исмагул дигән бәндәгә тапшырылганы булса, алдым бән аны, хәзрәт, укыдым.

Гәбделсәлам янә ишек янына узды, туктап, байтак кына нидер тыңлап торды. Аннан кабат өстәле янына килеп, кәгазьләрен җәеп салды.

— Алар да шикләнәләр шул, мелла. Баһадиршаһ халаекларны кузгата кузгатуын да, үзе яу башлыгы булырга разый микән, диләр.

— Алар дигәнегез кемнәр инде, хәзрәт?

— Һай, Урал буенда бик күп алар: галим-голәмә, корьән-хафиз, ыстаршина вә башка камил кешеләр. Хак тәгалә кушып, тәвәккәлләсәгез, әлеге олуг җөрьәт итсәгез, үзләре белән күрешерсез, боерган булса.

— Һаман да шикләнеп-шөбһәләнеп торам шул, вәлинигъмәт. Бәннән яу башы чыгар микән?

— Безнеңчә, мелла Баһадиршаһ, узаманлыкка иң кулае — сән.

— Шулай димсез дә, вәлинигъмәт... бик тә олуг вә җаваплы эш бит.

Ахун акрын гына урыныннан торды, шәкерте каршына килеп, аның күзләренә текәлде һәм, көйли төшеп, җыру әйтте:

Карчыга карап очар — тауны күрсә,
Ир-егет кылыч алыр — йауны күрсә!

Бу мизгелдә остазы, дин әһеле булудан элек, шагыйрь иде. Димәк ки, фатыйхасын шагыйрь буларак бирә. Шагыйрь сүзе — халык сүзе инде ул! Мулла үзен кинәт кенә тагы бер баш биеклеге үсеп киткәндәй тойды, аягына калкып, Гәбделсәламне кочаклап алды.

— Җыруыгыздан бихуш вә тәшәккермен, вәлинигъмәт!

Гәбделсәлам аның кочагыннан арынды һәм, кулларын шәкерте җилкәсенә салган хәлдә, әйтте:

— Сүзем улдыр: бездән фатыйха, Баһадиршаһ! — Кинәт шыгырдап ишек ачылды, бүлмәгә хәлфәләрнең кайсыдыр килеп керде. Гәбделсәлам борылып карамады, берни булмагандай үрелеп, кәгазьләре арасыннан берсен кулына алды һәм аны Батыршага сузды.— Ахунлык рисаләсен кабул итеп алгайсыз! Амин!

Дога кылдылар. Ул арада теге хәлфә шкафтагы калын китапларның берсен алды да кабат чыгып китте. Ишек ябылгач, Гәбделсәлам шыпыртлап өстәп куйды:

— Күргәйсез, монда серләшеп утыра торган урын түгел.Кичкә бәнем өемә чәйгә рәхим итәсез!..

Аларга кичен дә җәелеп серләшү насыйп булмады. Чәйгә галим-голәмә, мулла-мунтагайдан ике дистә чамасы кеше килгән иде.

Табындагы нигъмәтләрдән җиләр исеп, чәй эчелгәч, тарала башладылар. Гәбделсәлам, җаен чыгарып, Батыршага ым какты — калырга кушты. Соңгы кунагын озатуга, сүз башлады:

— Тагы ике-өч көн сабыр итәргә туры килер, мелла Баһадиршаһ! Безнекеләр узаманнарның сүзен алырга киттеләр.

Каргалы авылында ике-өч көн буена ничек тик ятармын,ничек итеп сәгатьләрне үткәрермен, дип борчылган иде Батырша. Вакыт дигәнең җитми дә калды. Аның килүен каян ишетеп,ничек белеп бетергәннәрдер — һич күрмәгән-белмәгән бәндәләргә кадәр ашка чакырып йөдәттеләр аны. Әлеге мәҗлесләргә күбрәк сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр вә тагы әллә кемнәр җыела. Болар инде мулла-мунтагай сыман бер-береннән тел яшереп утырмыйлар. Аларның сүзләрен тыңлый-тыңлый, байтак нәрсәне фараз итте, аннан да битәр төпле бер фикергә килде. Әйе, таш кызып җиткән, шуннан да соңга калырга ярамый, халаекларны күтәрергә кирәк, дип уй йөртте гыйсьянчы мулла.

Ул шулай өзгәләнеп сый-хөрмәт эчендә уздырган икенче көннең кичендә, аны Гәбделсаттар шәкерт болдырда ук каршы алды һәм ахунның мәдрәсәдә көтеп торуын хәбәр итте.

Көндезен шактый зур булып күренгән мәдрәсә кичке караңгыда кечерәеп, ятимләнеп калган сыман. Бары тик бер тәрәзәдә — әлеге дә баягы хәлфәләр бүлмәсендә генә ут яна. Батырша шунда юнәлде. Гәбделсәлам бернинди керешсез-нисез сүз башлады.

— Агыйделнең аръягында, Бөрҗән иләүендәге беренче ям станыннан ерак түгел, Чаршау каен янында мул сулы чишмә булыр. Күрешү урыны улдыр. Кем алдан килсә, ул намаз укып ултырмыш. Әлхасыйл, сезгә иртә таңнан кузгалырга кирәк. Баһадиршаһ! Хәерле сәфәр!

Дәшмәс юлдашы Борһан белән билгеләнгән ям станына өченче көнне төш вакытында гына барып җиттеләр. Атларын урнаштырып, өмәттә үзләренә урын-җир көйләүгә, Батырша бер тустаган су эчте дә, тамак та ялгап тормастан, ишегалдына чыкты, бер тарафка өеп куелган каен агачлары өстенә күтәрелде. Гәбделсәлам әйткән якка — дала киңлегенә текәлде. Күз күреме җирдә, вакыйган, чаршау сыман булып торган каенлык шәйләнә. Аннан астарак, биредән караганда, яшел билбау булып күренгән чишмә бормалана. Чакрым чамасы җир булыр. Ул иярендәге капчыгыннан намазлыгын гына алды да чаршау каенга ашыкты. Якын-тирәдә җан иясе барлыгын белдергән бернинди билге күренми. «Нишлисең, көтәргә кала»,— дип уйланды ул. Аннан, намазлыгын ачыклыктагы калкуырак урынга җәйде дә, намазга оеды.

Беренче рәкагәтен укып бетермәде, җир астыннан чыккандай, әллә кайдан гына дүрт җайдак күренде. Алар сөйләшми-нитми генә чишмә янына килеп туктадылар да ашык-пошык тәһарәт алдылар, намазлыкларын Батырша янәшәсенә үк җәеп, гыйбадәткә тезләнделәр.

Аллага согынулары чын күңелдән түгел иде бугай, Батырша соңгы тапкыр «Аллаһе әкбар»ен әйтүгә, арадагы өлкәнрәге, мөгәр таза бәдәнлесе сәлам бирде, саф мөселманча күреште вә сорап куйды.

— Әй мөсафир, кем буласың вә кай тарафларга юл тотасың?

Батырша башын күтәреп, аның йөзенә бакты. Бу бәндәне һәм аның юлдашларын танымый иде ул. Аларның нишләп йөрүләре хакында да хәбәре юк. Шуңа да чишелеп китмәде, сүзенең очын яшеребрәк җавап кайтарды:

— Ил кыдырып йөрүче булырмын.

— Кайсы галимнең мәдрәсәсендә торып укыдың?

— Карышбаш мәдрәсәсендә сабак алдым.

— Әйа, мулла Баһадиршаһ хуш торамы?

Монысы инде ачыктан-ачык сөйләшүгә ишарә сыман иде.

— Бик хуш тора, үзегез күргәнчә,— диде Батырша.

Әллә аңламадылар, әллә чишелеп китәсе итмәделәр:

— Безнең аны күргәнебез юк шул,— диделәр.

Сүз киселеп калды. Башкортлар бу сәер мөсафирның Батырша хәзрәт булуыннан әле һаман да шикләнәләр иде бугай, тапталмаган кылган өстенә ашъяулык җәйделәр, төен-капчыкларын алып килделәр.

ашарга утырдылар. Юлаучыны да табынга чакырдылар. Сүзне ялгау Батыршага калды:

— Үзегез кайсы иләүләрсез? Ни йомыш белән йөрисез?

Җавапны өлкәнрәкләренең карчыга борынлы, тәвәккәл чырайлысы бирде:

— Бөрҗән халкы буламыз, ыстаршиналык эше белән йөримез.

Монысы инде тегеләрнең чаршау ачулары иде.

— Сезнең Бөрҗән халаеклары посып беткәннәр, дип ишетәмез. Инде сезләр дә качып барасызмы?

— Ие, вурлар посып китделәр, берчә халык калдык.

Инде Батырша да кемнәр белән эш йөртүен төшенеп алды һәм, тегеләргә акланырга бирми, һөҗүмгә күчте:

— Ник «вурлар» дисез? Нәрсәләрегезне угрлап киттеләр?

Барысы исеменнән дә һаман да бер шул табак битле адәм сөйләшә иде:

— Һич нәрсәмезне угрламадылар. Падишаһ әмереннән баш тартып китделәр.

— Падишаһның кайсы әмереннән баш тарттылар?

— Завут башлыгын юлдашлары иле үлтерделәр.

— Ул завут башлыгы бик усал вә залим бәндә иде,— диде икенчесе.— Куркытып вә талап, малларыбызны алды, җиремездән-суымыздан ирексез итте. Хәтта кем хатыннарымыз вә кызларымызны күзебез алдында көчләп зина кылды.

— Падишаһ ул завут башлыгына шундый эшләр эшләргә әмер иткәнме? Халаекларыгыз падишаһның шул әмереннән баш тартырлармы?..

Чишмә буенда бер ялгызы аллага сәҗдә итеп утыручы бу бәндәнең гади бер мөсафир түгеллегенә инандылар бугай, ашауларын да онытып, җиргә төбәлделәр — дәшмәс булдылар. Батырша исә, туры сүзе белән аларны һаман саен бөгә баруын күреп, урыныннан купты:

— Сакалларыгыз агарган, сурәтләрегез хуш. Әмма гакылларыгыз һәнүз агармаган. Чын сүзегезне яшерәсез. Мөселман — мөселманның ярдәмчеседер. Әлхасыйл, бәне үзегез дип белегез. Бән — мелла Баһадиршаһ! — диде.

Кинәт өермә китереп бәрдемени?! Башкортлар җиргә капландылар.

— Торыгыз, әй, соекле бәндәләр,— дип боерды Батырша.

Башкортлар берәм-берәм башларын калкытып, кайсы намазлыгына, кайсы кылган япмасына тезләнде. Мәгәр сүзне әлеге дә баягы узаманнары дәвам итте:

— Әй, вәлинигъмәт, рас әйтәсең: сүзләргә базмый торабыз. Безнең тарафларымыз шикләнәдер, дүрт даруга халкы берьюлы хәрәкәтләнәек дип... Ничә мәртәбә халкымыз Котлымбәт морзага барды. Ниплүй янаралга да ялварып карады. Һич файда табылмады. Ата-бабаларыбыз били торган җирләремезне, суларымызны ташлап китәр хәлгә җиттек.

— Ташларга түгел, якларга кирәк, кем?..

— Бән Бөрҗән иләүеннән Елан-Эткол буламын, — дип сүзенең башына кайтып төште узаман.— Теге хәсис түрәне олактыруда башлап йөрүчеләрнең берсемен. Кыр-казаклар даласына посып баргач җирдән кире туган төягемә кайттым менә. Сән вәлинигъмәт сүзләгәнчә, илемҗиремне яклау вә саклау өчен...

Моңа чаклы утырган егет тә аягына калыкты:

— Алар бәнем бәхетемә балта чаптылар, яп-яшь бикәчемне үлтерделәр. Соңгы кяфернең җанын җәһәннәмгә җибәргәнче сугышырга ант эчтем. Бән — тимерче Әмин!

Егетләрнең ыспай гына сакал-мыеклы чибәре телгә килде:

— Посып киткән Байбул йортавай урынына тәгаенләнгән яңа ыстаршина — мишәр Абдул Ваһап, кяферләрдән гайре, залим булып чыкты.

Кыргыз-кайсак йөзенә качып киткәннәрне аклап сүз каткан атаемның чыраена камчы сукты. Канга — кан! Җир йөзеннән юк итәчәкмен бөн ул кабахәтне! Шуны эшләмәсәм, Яубасар Аздуров исеме хәрәм булсын!

— Сүзләрегез хакдыр вә мактаулыдыр,— дип куйды Батырша.— Хуш, инде, тәкъсир, сәне кем дип белик? — диде ул, дүртенче юлаучыга карап.

Горур бәндә җавап бирергә ашыкмады, һич селкенми таш сын сыман утырган җиреннән ачулы төкереп җибәрде:

— Кыпчак иләүеннән Көчекбай атлы булабыз,— диде. Ул янә туктап калды һәм байтак кына дәшми утырды. Аннан янә төкереп куйды, күкрәген киерә төште һәм вәкарь белән сүзен дәвам итте.— Сән, ахун, шуны бел: тау халкы — яу халкы. Нугай даругасыныкылар орышка атлыгып торалар. Бөрҗән вә Кыпчакныкылар гына да түгел, Тамьян, Үсергән, Тангавыр вә башка иләүләр... Атларымыз дагаланган, кылычларымыз кайралган, сөңгеләремез очланган, ян керешләре тартылган. Без инде Себер даругасыннан Юлай вә башкалар белән дә сүз беркеттек. Әй буена, янә дә килеп, кояш баешындагы Уран, Гәрәй, Ирәкте вә Гайне вулысларына да атчабарлар җибәрдек. Әлхасыйл, дүрт даруганыкылар дәррәү кубарга дип торабыз. Алай да, хәзрәт...

— Без әз, дип шикләнәсең инде, кем, Көчекбай?! — дип бүлде аны Батырша.— Хафаланма! Нугай юлы кузгалу белән, дала вә урман тарафындагы бар халаеклар күтәреләчәк, Гәйнә ягында биш йөз мишәр вә мең типтәр атларга менәргә әмер көтә. Чуваш-мукшылар вә чирмешарлар да форсатны кулдан ычкындырмаслар. Казан татарлары һәм дә кыр-казаклар безне яклап яу чыгачак! Боларны бән белеп вә ышанып әйтәмен, Көчекбай! — Ул хыялындагы якты өметләрен дә эшкә кушты.— Шунысын да исегездән чыгармагыз, узаманнар: Кырымның куәтле вә кодрәтле ханы да безнең якта, күп меңле чирүе Хуҗитарханга килеп төшкән, дигән хәбәр бар. Әлхасыйл, көч-куәт җитәрлек безем.

— Әнә шунысы тормышка ашмас дип, куркам да инде бән, хәзрәт!

— Андый шигең нидән?

— Анысы үзеңә дә мәгълүм түгелме, хәзрәт? Халаекларга язган кыздырмак хатында бөтен урысларга каршы ябырылырга котыртасың, диләр. Анау завутлардагы кол урысларны да кыйратыйкмы инде, йә?

— Әйа, кем, Көчекбай, ниткәндер хата бу! Эш урысларын рәнҗетергә чакырганым юк. Киресенчә, аларны үз ягыбызга аударасые, дим. Вә әй хәсрәт, тәгъризнамәне ялгыш шәрехләгәннәр микәнни?!

Көчекбай да урыныннан кузгалды:

— Аңлаучылар гына түгел,— диде ул.— Шуны әләм итеп, Батырша хәзрәт урысларны кайратып бетерергә чакыра, дип, оран салып йөрүчеләр дә җитәрлек. Ыстаршина Сатлык Йәүкәев, аның тарафдарлары Йомахуҗа Бирдегол углы, Аптырак вә Ишалы Көлембәтовларны әйтәмен бән. «Баһадиршаһ дигән әүлия пәйда булган: завутларны җимерергә, урысларның җәмгысын чабарга әнди»,— диеп халаекларны котырталар. Исәпләре — яу кубу белән, завут-кальгаларны вәйран итеп, анда яшәүчеләрнең малларын талау.

— Алла сакласын, диң, Көчекбай! Андыен эшкә бүгеннән чик куярга кирәк. Кайда ул Сатлык ыстаршина? Торган җире еракмы?

— Анысы кыен эш түгел, вәлинигъмәт,— дип сүзгә янә Елан-Эткол кушылып китте.— Хаҗәт бар икән, бүген кич үк очрашырга була Сатлык белән. Әнә, егетләр озатып куяр.

— Үзем барам! — дип кычкырып җибәрде Әмин.

— Сәнең гайрәтле егет икәнеңне беләбез,— диде Көчекбай, егетнең салпы ягына салам кыстырып.— Вә ләкин никадәр genә гаярь булсаң да, ялгызың гына саклый алмассың яу башын. Бәнем егетләрем белән бергә иртә таңнан кузгалырсыз...

Ихтилал башлыгын, Борһан белән Әминнән тыш, Көчекбайның өч дистә егете озата барды. Сатлык старшинаның ике тау арасындагы

җәйләвенә килеп җиткәч, бу чараның һич кенә дә артык булмавы ачыкланды. Мул сулы инеш ярына сыенып утырган тирмәләр янында көтүче ише ябай башкортларга караганда ян-сөңгеле егетләр күбрәк иде. Алай да сер бирәсе итмәде Сатлык старшина, кунакның каршына килеп, аны ияреннән күтәреп алды:

— Төкле аякларың белән, вәлинигъмәт, хуш киләсең! — дип, ак тирмәсенә җитәкләп алып китте.

Сатлыкның озын колаклары әйбәт эшлиләр, күрәсең, җәйләүдә инде олы кунакны каршылау өчен бар да әзер: казан-казан ит пешкән, саба-саба кымыз тирмәгә үк кертеп куелган. Аннан да гаҗәбе шул: бирегә хәйләкәр йортавыйның бөтен тарафдарлары җыелган.

Хуҗа аксакалларны табынга утыртты, җамаякларга үтә төҗел очраклар өчен саклап тоткан каты балны салдырды һәм сүз башлап:

— Ниһаять, узманнар, без дә куәт алган яшь шоңкардай аягыбызга ныгытып бастык,— диде.— Канатыбызны бик тә ышанычлы җәйдек. Безнең хәзер әүлиягә тиң гакыллы, гайрәтле башлыгыбыз Баһадиршаһ хәзрәтебез бар! — Әйдәгез, яу башлыгының исәнлеге хөрмәтенә!

Ул чем-кара сакал-мыегын кул аркасы белән генә сөрткәләп алды да нотыгын сөйләвендә булды:

— Йә, күптән көткән көнебез килде. Югыйсә, кылыч-хәнҗәрләребез тутыга, ян-җәяләребез языла башлаган иде инде. Кодрәтле яу башы өмерен биргә, туган төбәгебезгә сөлек күк ябышкан завутларны кайрата, чакырылмаенча килгән урысларны чаба башлыйбыз. Яздырган җирләребезне вә югалткан малларыбызны кайтарып алыр сәгать сукты, узаманнар!

Табынның төрле ягыннан дистәләгән тавыш аңа куәт биреп куйды:

— Хак әйтәсең, Сатлык, афәрин! Балыкны куе суда тоткан яхшы!

Батырша аларның йоннарын уңайгарак сыпырырга тырышты:

— Олы яуга әзер торуыгыз да, гайрәтегез вә дошманга нәфрәтегез дә — әйбәт! Тик бер-беребезне аңлап җиткермәү дә бар икән бит әле. Завутлардагы кол урыслар вә кара халыклар рәнҗетелмәсеннәр иде, азаматлар!

Ул әйтәсен әйтеп бетермәде, тавыш купты:

— Аңлашылмай: каферләрне кыйратырга үзең оран салдың лаба-са!

— Динемезнең иң авыз дошманы — шул урыслар бит инде!

Батырша кулын күтәрде — табын тынып калды. Ихтимал башлыгы һаман да шул тыныч тавышы белән яуның мәслегән шәрехләргә тотынды. Әмма Сатлык яклылар һич кенә дә аны аңларга теләмиләр иде. Мулла тагы һәм тагы сөйләде — халык кузгалышын олы максатка бору зарурлыгын тәкрарлады. Менә Сатлык үз янындагы фикердәшләренә күз кысты һәм буйсынулы тавыш белән сөйләп китте:

— Ярый, хәзрәт, ярый. Сән вәлинигъмәт әйткәннәргә разый без. Түрәләрне вә мортәтләрне генә кыйратырбыз, ил-җирне дәҗҗал кавеменнән тазартырбыз. Тик боланың көнен-сәгатен генә әйт!

— Анысын инде, узаманнар, бән ялгызым хәл итмәем,— диде Батырша, чыраена канәгатьлек чыгарып.— Якын арада күп халаеклар катнашында корылтай җыярбыз, шунда барын хәл итәрбез.

Мулла Сатлык старшина җәйләвендә куна калырга булды. Үзлегеннән аның җансакчысы булып киткән Әмин, Батыршаның карарын хупламаса да, кайтарып сүз әйтмәде, алай да Көчекбай егетләрен әлегә ак тирмә тирәли урнаштыруны кирәк тапты.

Уйланып ята торгач, таң беленде. Мулла җәһәт кенә тирмәдән чыкты һәм пыскып янган учак янында утыручы Әмингә атларны иярләргә кушты. Тояк һәм әзеңге тавышына хуҗа да торып чыкты, хәлне аңлап алуга, үпкә-рәнҗү сүзләре яудыра башлады. Мәгәр Батыршаның карары ныклы иде.

Сатлык старшина җәйләвеннән дүрт-биш чакрым җир китүгә, җай-

даклар икегә аерылды. Көчекбай егетләре үз юллары белән китеп бардылар, Батырша исә, икесе ике канатына әверелгән Борһан һәм Әмин озатуында, күптән тансыкланган Мөслим авылына борылды.

Кечә генә аерылышкандай, тыйнак вә ыгы-зыгысыз күрештеләр.

— Хәлләр ничек монда?— диде Батырша, атыннан төшүгә.

— Һаман да шул бер балык башы инде, хәзрәт,— диде Мөслим старшина, кичен өзелгән сүзне дәвам иткәндәй.— Күп кенә мишәрләребезне, Салчугыт вулысыннан ун башкорт йортын көчләп чукындырдылар. Тун угырлап тотылган берәүне Тубыл әрхәрәенә илтеп биргәннәр дә муенына «тавык тәпие» асканнар, чыдар хәлләр калмады, хәзрәт.

— Күбенә түзгәнне, азына чыдарсыз. Тиздән кузгалабыз!

Ерактан килгән кунакны каршыларга, яннарына күрше-күлән, йөзбашлары вә башка куштаннар җыела башлады. Сүз үзеннән-үзе Батыршаның бәләкәй адашы Апушның булачак туена, мәһәр вә бирнә ише дөнья мәшәкатьләренә күчте.

Кайчандыр адашына биргән сүзендә торды Батырша. Егетнең яшь бикәче белән никахын үзе укыды. Мәгәр теге чактагыча Мөслим якларында туарылып ял итә алмады, туй мәҗлесе тәмамлануга, Мөслим старшинаның ерак урмандагы чолыклыгына китеп барды.

Монда аулак һәм тыныч иде. Ниһаять, көннәрнең берендә аулак чолыклык чал Уралның әллә кай төбәкләреннән килгән гайрәтле ир-егетләр, иярле атлар белән тулды. Кемнәр генә юк иде монда! Инде Батыршаны танып белгән Елан-Эткол белән Көчекбай да, кызу канлы Яубасар да, Юрматыдан Моталлап Көлчекәев, Үсергәннән Куәт Кинҗәголов, Тамьяннан Качкын Самаров, Ямансары Җаббаров та, Сатлык һәм аның тарафдарлары янә бик күп аксакаллар...

Мөслим старшина, гадәтенчә, сер бирмәде — тулы бер яу хәтле кунакларга ашны мул әзерләтте. Әмма корылмайга җыелганнарның хафасы ашау-эчүдә түгел иде.

Киңәш-табыш соңарганнар килеп җиткәнче үк башланды. Сөйләүчеләрнең телләрендә бер генә сүз — кичекмәстән кузгалу. Бигрәк тә Елан-Эткол белән Көчекбайның тавышлары таләпчән:

— Иртәгәдән калмый кузгалабыз! — диләр.

Мәгәр бу олы җыенда алар сыман кайнар башлар гына түгел, салкын акыл белән эш итүче дөнья күргән аксакаллар да байтак иде. Ярты төн буе бәхәсләшкәч кенә, әсәднең июльнең унында атларга атланырга булдылар. Мәҗлес халкы аксакаллар сүзен бердәм кабул итте, кайберләре инде китә дә башлады. Шулчак кыпчаклы Көчекбай оран салды:

— Тагы бер киңәш бар бит әле, узаманнар. Ниплүй янарал кыр-казаклар йөзенә шымчы җибәргән. Кыргыз-кайсакларны безгә каршы котырту өчен. Нишлибез?

— Нишлибез дип, озын-озак баш ватасы юк монда,— дип кычкырды аңа каршы Елан-Эткол.— Артыннан куа чыгарга вә һәм чукмарга алырга үзен! Аксакаллар фатиха бирсә, бән үзем алынаем бу эшкә!

Алан аңа бер тавыш белән гөрләп җавап бирде:

— Афәрин, Эткол, бар, башын чап шул мөртәтнең!

Җыен төн уртасында бетсә дә, болачылар көн яктырганны көтмәделәр, дөм караңгылыкта эреп юкка чыктылар.

Батырша Мөслим старшина китергән кара-туры айгырга атланды. Иягрә менеп алган Әмин белән Борһан аның янәшәсенә бастылар. Өч җайдак Урал киңлекләренә чыгып китте. Алар халаекларны яуга өндәделәр. Күк Уралның һәр ике битләвендә ат дагалары астыннан очкыннар чәчелде, сугышка өндәгән оран авазы әллә кайлардагы ерак аймакларга яңгырады:

— Әй, халаек, яу-га! Яу-га-а-а!

Батырша атланган кара-туры урманны яңгыратып кешнәп җибәрде — үзенең аунап үскән төягенә кайтуын сизде хайван. Купшы юкәләр артында Мөслим старшинаның чолыклыгы урнашкан ачыклык шәйләнде. Әмин белән Борһан Батырша артыннан чаптырып киттеләр.

Кечерәк кенә аланга килеп чыгуга, мулла атын тыйды — ярсый башлаган кара айгыр кадаклангандай туктап калды. Аның кырыена җитүгә юлдашлары да атларын туктаттылар. Соңгы вакытта ешаеп киткән яңгырлар шифасыннан булса кирәк, бөтен аланда әрсезләнеп, кылган түшәге кабарган. «Әйа, узган гомернең эзе калмый,— дип уйлап алды Батырша, көрсенеп.— Хәер, монда булып үткән җыеннан соң да айдан артык вакыт үтте шул инде. Ага гомер, су кебек саркый».

Мәгәр Батыршаны сәерсендергәне бу түгел иде әле. Чолыклыктагы кабер тынлыгы гаҗәпләндерде аны. Ә бит, сөйләшү буенча, бүген биредә олы яу алдыннан соңгы тапкыр очрашырга, киңәшергә булганнар иде. Баксаң, җан ияләре ботенләй күренми. Нәрсә бу? Әллә соң яудан бөтенләй баш тартуларымы Нугай юлыныкыларның?!

Тып-тын гына булып, утырып яңгыр ява. «Спас башлануы микәнни?»,— дип уйлап алды мулла, кайнарланган битенә тамгалаган вак тамчыларны җиңе белән сөрткәләп.— Әлбәттә, спас — урыс исәбе белән, августның җиденче көне».

Ни кылырга белмәгәнлектән, юк-барны уйланып торган арада, якында гына коры чыбык-чабык шартлап сынганы ишетелде — аланның теге ягындагы каен төбендә бер карачкы пәйда булды. Батырша иңендәге җөясенә үрелде, юлдашлары исә кылычларын кыныларыннан тартып чыгардылар. Карачкы дигәннәре — ярсу болачы Елан-Эткол иде. Башлап Батырша исенә килде һәм, сорап куйды:

— Халаеклар кая?

— Кешеләрме? Кешеләр көтә-көтә көтек булдылар, Батыршаһ!

— Нихәл итмәк кирәк, юлы бик мәшәкатьле,— диде мулла.

Аның тыныч тавышы Елан-Этколны ярсытты гына:

— Бүгенгесен генә әйтмим,— диде ул, дорфаланып.— Һаман көтәбез, һаман мөрәлибез — сүз дә сүз. Җәй үтеп бара инә!

— Шул хакта киңәшергә дибез ләбаса...

— Тагы сүз! — Елан-Эткол ачуын селкеп атарга тырышкандай, ярсып җиргә төкерде.— Юк инде, Батыршаһ, юкка тел кашудан туйды халаеклар. Без иртәгедән кузгалабыз! Әйдәгез!

— Бәрәкалла, хәерле сәгатьтә!

Батырша атын килгән юлыннан кабат китеп баручы Елан-Эткол артыннан әйдәде, юлдашлары аңа иярде.

Караңгы лапылыкларда кулларын-битләрен тырнатып, киемнәрен талатып байтак бардылар. Менә алда ниндидер ачыклык яктырды — йөгерек сулы инеш ярына килеп чыктылар, су буйлап үргә таба тагы бераз бардылар да, каралып торган йөзъяшәр карагайлар төбендә торлесе-торле яры бәйләп куелган ат өеренә тап булдылар.

— Айгырларыгызны шунда калдырыгыз! — дип боерды Елан-Эткол.

Инешне чыгуга текә үр башланды. Атлаган саен үр текәләнде, алга бару кыенлашты. Батырша, күн итекләре белән капшанып, калкып-калкып торган ташларны эзләде — шулар саклап калды таеп егылудан. Алай да текәлек хәттин ашты — мулла буылырга тотынды. Ул, бер мизгелгә генә туктап, башын күтәрде һәм каршында түбәсе болыт томанына ашкан дивар сыман таш кыя күреп алды. «Кая алып бара бу шашкан җан?» — дип уйларга өлгермәде, әллә каян — өстән Елан-Этколның өндәве ишетелде:

— Бөнем арттан мүкәләп керегез!

Эндәште дә үзе юкка чыкты. Батырша эт сыман дүрт аяклап алга үрмәләде һәм, һич уйламаганда, бүре өнен хәтерләткән тишеккә тап булды.

Батырша башын мәгарә авызына тыкты, бисмилласын әйтте дә, караңгы куышлык буйлап мүкәләп китте. Әмин дә аннан калмый үрмәли иде. Әлеге әкияти юл күпмегә сузылгандыр да никадәр вакыт үткәндер, берзаман алда адәми затлар гөрләшкән тавышлар ишетелде, ул да түгел, күзгә зәгыйфь кенә яктылык чалынды. Тагы бер талпынуга, саран гына яктыртылган шактый киң вә иркен мәгарәгә килеп чыкты мулла.

Башта ул кәрәнсу диварларның төрле ягындагы ярыкларга кыстырып-кыстырып куелган чыраларны гына күрде, чыртлый-чыртлый яналар. Батырша, каршындагы иң якты чырагка карап хәл алган арада, каяндыр күләгәдән берьюлы берничә тавыш ишетелде:

— Әйа, вәлинигъмәт, исән-аман икәнеңне күреп, хуш булдык!

Кемнәрдер аны култыклап алды, каршыдагы иң зур утка таба алып китте. Сөремләнеп янган чыраг күләгәсендә шомарып беткән таш ята икән — тансык кунакны шуның өстенә утырттылар. Хас мөселманнарча сәлам алышу, исәнлек-саулык сорашу башланды.

Алай да бу серле төн бәндәләрне ашыктыра иде. Батырша хәлне тиз абайлап алды һәм, әңгер-меңгергә иярләшеп җиткән күзләрен мондагыларга төбәп, сорап куйды:

— Чакырылган кемсәләр бар да җыелганмы?

— Себер юлының Шайтан-Күдәй иләүеннән Юлай ыстаршина күренми.

— Юлай булып Юлай шундыен җыеннан калыр икән?!

— Өченче угланы туган, аңа Салават дип ат куя, имеш.— Бәрәкалла, бик тә мөбарәк эш,— дип, читкәрәк киткән сүзне үзенә кайтарырга тырышты Батырша.— Кем белә, явыз Каракошның канатларын ботарлау нәкъ әнә шул угланнар — Салаватлар өлешенә тияр, шәять... Әйа, ни хәл вә ни хәбәр?!

Яшьләрдән киң күкрәкле, карчыга борынлы, бөркет карашлы егет уртагарак чыкты, ихтилал башлыгына туры карап, ярып салды:

— Сүз боткасыннан тәмам гарык, хәзрәт. Эш кирәк, гамәл!

Моңа кадәр бер читтә тын гына торган Елан-Этколь халыкны этәега, теге гаярь егет кырыена килеп басты:

— Яубасар хагын әйтә, Батыршаһ! Артыгын түзәр чамабыз юк.

Качкын Самаров сүзгә кушылды:

— Сез ярсуын ярсыйсыз да, яшьләр, к-хым, ни бит әлә... Ян-җәясен вә кылычын тотып яу башына басар узаманыбыз ачыкланмаган.

Сатлык старшинаның сабыры төкәнде, Качкын сөйләп бетергәнне дә көтмәстән:

— Кем әйтә безне яубашсыз диеп? Әүлиягә тиң гакыллы, Гали батыр күк гайрәтле Баһадиршаһ хәзрәтебезгә ни булган?! Алып барсын безне кара йөрәкләр өстенә! — дип кычкырды.

— Хак, саф алдына бас, вәлинигъмәт!

— Атларга, ирләр, атларга!

— Аллаһе әкбар, аллаһә әкбар!..

Тау куышындагы адәмнәр, тәмам кызып, берсен-берсе тыңламыйча, үкерешкән шушы мәлдә, шәүлә булып кына урталыкка Көчекбай узды, күк күкрәгәндәй кычкырып җибәрде:

— Тукта, шашмагыз! Сез менә вәлинигъмәт яу башына бассын, дисез. Сүз дә юк, моңа гаярьлеге дә, гакылы да җитә аңың. Вә ләкин Баһадиршаһ хәзрәтнең үз шөгыле бар. Ул — сүздер. Мәгълүм булганча, сүз кылычтан үткердер. Әйа, вәлинигъмәт, тыңлама шул кайнар башларны! Үз юлыңа кит, күтәр халаекларны — бөтен Урал, Идел менсен атларга! Бусын, йәгъни эшнең иң олысын — халаекларны кыздырмакны сән генә булдырасың, хәзрәт! Ә кылыч, чукмар тоту — нәрсә ул?! Үзен

ир-егет дип чутлаган һәркайсыбыз алыр аларын. Әлхасыйл, төбәктәге яу башына басарлык егетләр җитәрлек монда. Әйа, ирләр, Баһадиршаһ хисен, кузгатсын бар халаекны, ут салсын, янгынны дөрләтсен!..

Елан-Эткол белән Яубасар тарафдарлары сикерешеп аякларына бастылар.

— Көчекбай хагын әйтә!

— Татарын-типтәрен вә мишәрне дә күтәрергә кирәк!

— Бар, вәлинигъмәт, кузгат бөтен мөселманны!

Батырша да аягына калыкты:

— Үзем дә хаклык Көчекбайда диеп уйлаймын, ирләр,— диде.— Ялгыз учак ялкынланудан дөньяны ут алмый. Янгынны Агыйдел вә Каридел ярларында да, Чулман вә Идел буйларында да дөрләтергә кирәк безгә. Әл-хәмде-лилаһи-рабби-л-галәмин!

Сатлык һәм аның тарафдарлары, сүзләре аста калудан үртәлеп кисәк урыннарыннан кузгалдылар, мәгарәнең бер тарафына ташландылар. Ул якта тау куышының тагы бер авызы булса кирәк. Тынлыкны ярсуы басылып бетмәгән Яубасар бозды:

— Әйа, хәзрәт, ашыга күр — кузгат гайнәләрне вә һәм дә башкаларны! Мәгәр юлың ерак вә хәтәр, Батыршаһ, үзең берлә берәр дистә егет алың! Сакланганны сакләрмын, дигән хода.

— Борчылма, егет! Ышанычлы юлдашларым бар бәнем: Әмин вә Борһан.

Төнката бер кәлимә сүз әйтми шәүлә булып кына йөргән Әмин борсаланып куйды, очрашканнарыннан бирле беренче кат ил әүлиясына каршы дәште:

— Бигайбә, вәлинигъмәт, сәнең берлә бара алмаем. Йөрәгемдә үчнәфрәт ташый бәнем. Асылбикәне харап итүчеләрнең җаннарын җәһәннәмгә олактырмый торып...

Сүзен әйтеп бетермәде, тамагына ниндидер төен калкып, буылып калды егет. Батырша кулын аның җилкәсенә салды, юатасы итте:

— Хәердер. Ниятеңә мәдех, Әмин! Иншалла без икәвебез генә дә узарбыз юлны.— Ул кулын егетнең җилкәсеннән алды, йодрыклап аны өскә күтәрде.— Шөкер, бу кул әле җәя-ук вә кылычны нык тота. Янә дә килеп, тарафдарларыбыз карья саен. Дошманнарыбыз күп икән, дустларыбыз да җитәрлек.

Сөйләшә-сөйләшә чыгар якка кузгалдылар. Көчекбай иң зур һәм иң якты чырагны кулына алды һәм юл күрсәтеп алдан китте.

— Ярый, хәерле сәгатьтә. Биссмиллаһи...

Аның тонык кына әйтелгән сүзеннән барысы да айнып киткәндәй булдылар, бердәм теләк теләделәр:

— Хәерле юл, хәзрәт!

— Сәфәрең уң булсын!

— Утның зурысын дөрләтергә насыйп әйләсен!

Кара шәүлә булып инеш буйлап китеп барган ике җайдакны күз карашы белән озатканнан соң, карагайлыкны галәм тынлыгы басты. Шул хәлдә күпме торганнардыр, әвәл өлеге дә баягы кылбырдык Яубасар телгә килде:

— Безгә дә йоклап ятуы оят, егетләр, кузгалаек!

Җавап көтмәде, кулын авызына куеп, божыр тавышы белән кычкырып җибәрде. Аңа караңгыдан «төкәрлек» җавап кайтарды. Шулчак Көчекбай яудашының беләгеннән тотып алды:

— Тукта, егетләреңне чакырмый тор, Яубасар! Кая һәм кем өстенә бармак буласың?

— Бәнем юлым сызган, угым төзәлгән. Атаемны мәсхәрә кылган мишәр Абдул-Ваһап ыстаршинаны басу капкасына асмый торып...

— Кызма, Яубасар. Карымта, ие, кан үче алу өчен генә купмадык без. Бәнем уемча, барчабызның егетләрен туплап, Зилаер кальгасына һөҗүм итү, андагы дырагуннарга кыргын салу лязим.

— Абдул-Ваһапны юк итү карымта гына түгел, Көчекбай. Беләсең килсә, яу мөртәтләрне кыйратудан башланырга тиеш тә. Батырша хәзрәтнең сүзе исеңдәдер: мөртәт — хас дошманнан да хәтәррәк. Нигә дисәң, ул — сатлык җан! Дошман ул — мылтыклы гына түгел, туплы булса да, дошман. Анысы танyла. Мөртәтнең исә кулы буш, куенында — таш. Әнә шул таш җитә дә инде ир-егетләр башына. Юк, бән Япанга, Абдул-Ваһап өстенә барам!

Сүзгә Елан-Эткол кушылуы көзге әтәчләрне сүрелдергәндәй итте:

— Җитәрегез! Бән, хаклык Яубасар ягында, дип беләм. Вакыйган, башлап үз мөртәтләребезне дөмектерү фарыз. Нигә дисезме? Тәүгедән урысларны сугып, кайберәүләрнең хата фикерен расламыйк. Без аерым халаекларга каршы яу чыкмадык, бәлкем ил-җир өстендәге зольмәткә каршы күтәрелдек! Алай да ялгыз башың кузгалырга киңәш итмим, Яубасар. Безне көт. Кайда тупланабыз?

Елан-Этколның соңгы сүзе Яубасарны уйланырга мәҗбүр итте. Мәгәр нияте какшамады егетнең:

— Ыстаршина Абдул-Ваһап вә аның берничә куштаны белән үзебез генә дә сүләшәбез без,— дип гайрәтләнде ул, тавыш-тынсыз гына үзләрен урап алган егетләренә ымлап.— Был егетләр белән бер түгел, ун Япанның астын-өскә китерергә була! Ә сез... ә сез яугирләрегезне кичкә Агыйдел буена алып килегез. Очрашу — Караңгы тугайда... Әй, Акбулат, айгырны китер!

Ниһаять, Яубасарның дулкын яллы тимеркүк айгырын китерделәр. Егет, селәүсендәй сикереп, аның сыртына менеп алды, озак тик торудан ялыккан ат ыргып куйды. Тик шунда ук җайдакның кулы ныклыгын сизде, сабырлана төшеп, авызлыгын чәйнәде. Җайдак исә, егетләрен барлап, аларга карап бераз торды да:

— Мөртәтләргә — үлем! — дип кычкырып җибәрде.

— Үлем! Үлем!! Үлем!!!

Ә табигать торган саен шашына: яңгыр инде гүя яумый, бәлки куе кара болытлар үзләре җир өстеннән ага кебек. Урманнар каядыр чигенеп, тирә-як Сусылу патшалыгына әверелде, елгалар ярларыннан ташып чыкты, һәр тарафта — су, су, су! Күк гүя котырынган: чатнап-чатнап ярыла, гөрелди, әйтерсең мәңгелек чал Урал ишелә.

Япан авылына әнә шул рәвешле зилзиләнең үзе булып килеп керделәр яугирләр. Авыл бик тә таныш иде Яубасарга, ул алдан карап-белеп йөрүчеләр җибәреп торуны кирәк санамады. Алты дистә җайдактан торган алай, томырылып килгән шәпкә, урталыкка — мәчет янына үтте. Ләкин анда тукталмады, шуннан ерак түгел бер тарафта үзе бер кальга булып утырган старшина йортына ябырылды.

Шушы җәйдә генә өлгертелеп, башы дранча белән ябылган, мәчеттән дә зуррак бу өй, чыннан да, тулы бер хәрби ныгытманы хәтерләтә иде. Ихатасы очлы имән текмә белән уратылган. Биек урыс капка старшина йортының куәтен раслап тора.

Алай да болачыларның ният-тәдбирләре текмә вә капка имәннәреннән ныграк иде. Яубасар, чаптырып килү уңаена, былҗырап кесәлгә әверелгән җиргә сикереп төште, ике сикерүдә дивар-капка янына килеп җитте, кай арададыр билбавыннан суырып алган чукмары белән каралырга да өлгермәгән капкага ике тапкыр каты итеп орды — имән такта чәрдәкләнеп ярылып чыкты.

— Әй, эттән туган Абдул-Ваһап, ач! — дип җикерде егет, яңа хасыйл булган ярыктан эчкә карап.— Әҗәлең килде.

Аваз бирүче булмады, өй һәм лапас кыекларыннан аккан суның чупырдавы гына ишетелә иде. Яубасар ярсып, чукмары белән имән такталарны төйде. Эчтән, каяндыр лапас ягыннан, ярсып-буылып эт өрергә тотынды. Ниһаять, ишек ачылып-ябылды, пычтырдаган авазлар ишетелде, йокылы саңгырау тавыш яңгырады:

— Кем йөри? Пычагым бармы төн өстеннән?

— Әй, ыстаршина куштаны — мишәр Сабир, башым сау калсын дисәң, ач капкаңны! — дип ябырылды Яубасар, кызып.

— Тот капчыгың — мулла булырсың.

— Әх, шулаймы!? Ябырыл, ват, сыт, егетләр! — Яубасар шашып үкерде, үзен-үзе белештерми, чукмары белән имән такталарны кыйнарга тотынды.

Яугирләрдән берише ныгытмага сөңгеләре белән ташландылар, икенчеләре каяндыр калын киртәләр, бастырыкише нәрсәләр сөйрәп килделәр — гөнаһсыз капканы җимерү башланды. Тоташ яңгырда күшегүләре җиткән иде, күрәсең, вату ниндидер бер дуамал ләззәт белән башкарылды, капка уылып — коелып төште.

Алай башлыгы керә-керешкә мишәр Сабир өстенә ташланды һәм чукмары белән бер сугуда тегенең башын изде. Абзарлар ягыннан атылып килүче икенче җансакчыны исә Әмин сөңгегә күтәрде. Ишегалдын кыргый чырылдау күмде.

Старшина йортын саклаучылар тагын да юкмы, дип як-якка каранганда, лапаслар рәтендә янә бер бөлкәйрәк өй күреп алды Яубасар. Шунда ташландылар. Әмма әле бая гына икенче җансакчы чыгып килгән ишек эчтән бикле булып чыкты. Димәк, анда тагы кемдер бар.

Хөер, фаразлап тормады алай башлыгы. Старшинаның писаре мишәр Айдукның Абдул-Ваһап ихатасында яшәп ятуы билгеле иде аңа. Ах хәсис битекче, бикләнеп алган бит! Яубасар каударланып тәрәзәгә килде, бер тибүдә аның пыяласын коеп төшерделәр. Мәгәр үзенә эчкә үтәргә туры килмәде — ике-өч егет, өр-яңа рамнарны ватып-сытып өйгә томырылдылар. Ул да түгел, ишектән килеп чыктылар. Үзләре белән ак күлмәк-ыштаннан гына булган писарьны да өстерәгәннәр.

— Йә, битекче, ясак кенәгәләрен чыгар! — дип җикерде аңар Яубасар. — Тиярдән артыгын җыйганны косар көнегез җитте, кабахәт!

Айдук мүкәли-мүкәли аягына басты һәм һич көтмәгәндә алай башлыгының битенә төкерде:

— Менә сиңа кенәгә, вор! Без вирнайларны падишаһыбызга хыянәткә этәрәсең, бәдбәхет!

— Һа, шулаймы?! — Яубасар писарьны пычракка сугып екты, егетләрдән биш-алты кеше битекче өстенә ябырылды.

— Җанын җәһәннәмгә олактырмай торыгыз, егетләр! — дип боерды алай башы һәм, корбанын бөркетләреннән аралап, канга баткан Айдук өстенә иелде. — Йә, чыгар кенәгәләрне!

Писарь эшнең уен-муен түгеллеген төшенде бугай, авызыннан канлы күбек агыза-агыза ыңгырашты:

— Кенәгәләр... Абдул-Ваһап агайда.

Яубасар аны тыңлап тормады, кисәк борылып, төп өйгә таба китеп барды. Ике-өч адым ясауга, артына борылды һәм аптырашып торган болачыларга тыныч кына әйтте:

— Теге җиреннән асарга үзен!

Писарьны кычкырта-кычкырта лапаска таба сөйрәп киттеләр.

Баш күтәрүчеләрнең бер төркеме старшина өен урап алган иде инде. Әмин:

— Ачмый, явыз, — дип сукранды.

Яубасар аңа җавап кайтармады, ашыгып ишеккә килде, аны тартып карады. Авыр имән ишек эчтән ныгытып терәтелгән иде. Егет болдыр рәшәткәсе аша җиргә сикерде, киң иркен ян тәрәзәгә килде һәм чукмары белән аның буяулы рамына орды — чалдырап пыяла коелып төште.

— Әй, сатлык җан, чык! — дип кычкырды Яубасар. — Кылганнарыңа җавап бир!

Кайтарып дәшүче булмады. Яубасар, каты кизәнеп, рәшәткә тимеренә китереп сукты. Шул минутта эчтә горселдәп мылтык атылды —

алай башлыгы янында кайнашучы егетләрнең берсе эчен тотып җиргә чүкте. Бар да тәрәзә яныннан читкә чөчелде.

— Яхшылык белән чыгасыңмы син, уйнаштан туган Абдул-Ваһап?! — дип кычкырды Яубасар, тәрәзә буендагы диварга ышыкланып.

Җавап урынына янә мылтык шартлады, тик инде ул бу юлы берәүгә дә зыян китерә алмады.

— Ут, ут китерегез! — дип үкерде алай башы, үртәлеп. — Каен тузы, печән ташыгыз, ишекне тыштан боргычлап куегыз!

Шулчак Яубасар кырыенда уралган бәләкәй буйлы чандыр егет шатлыклы кычкырып җибәрде:

— Бәнем ат сыртында җир мае да бар ич!

Чаптырып бер турсык җир мае алып килделәр, аны яңа өйнең диварына һәм йомычка өеменә сиптеләр. Калганын инде ут үзе хәл итте. Башта ул авыр гына ялкынланып китте, бераздан инде бөтен йортны ялмап дөрләде. Бу вакыт инде болачыларның күбесе урамга чигенгән, абзар өрлегенә урта бер җиреннән асып куелган писарь да тынып калган иде.

Авыл исә, әйтерсең берни белми, берни күрми иде. Ник кенә бер капка ачылсын да, урам-тыкрыкларда ник кенә бер җан иясе күренсен. Этләренең абайлап-котырынып өрүләре генә Япан кешеләренең мыштым гына нидер көтүләре турында сөйли иде. Алай да старшина йорты дөрләп яна башлауга, өй түбәләрендә, абзар-кура кыекларында ир-атлар күренгәли башлады: кешеләрдә — үз мөлкәтләрен саклау хафасы. Мәгәр үз мәнфәгатьләре белән кайнашучыларның күбесе карт-коры икән.

Урамда баштанаяк коралланган атлылар күренде — яшьләрдән ике дистә чамасы кеше баш күтәрүчеләргә кушылды.

Старшина йорты һәм аның хуҗасы тулысынча янып беткәнен күзәтеп тору, Япан авылындагы шул кальга-йортны камаганда шәһит киткән егетне күмү өчен тимерче Әмин башында биш егет калдырдылар да, үзләре Агыйдел буена таба кузгалдылар.

Давыл тынды, яңгыр басылды. Алай Караңгы тугайга килеп җиткәндә исә, әйтерсең табигатьтә берни дә булып узмаган, күк йөзе бөтенләй ачылып, сөмбелә кояшы бар куәтенә кыздыра башлады.

Өйләдән соң йөзләп егете белән Елан-Эткол килеп җитте, шатлыклы ыгы-зыгы, төртмә сүз белән сәламләшү, танышу башланды:

— Йоклап та күрсәтәсез соң, егетләр,— дип каршыладылар аларны Яубасарныкылар,— болай булса, ау беткәнне дә сизми калырсыз әле.

— Йоклаган диярләр. Без инде Сапсал ям ыстанының астын-өскә китердек, дистәдән артык урыс дырагунын теге дөньяга озаттык.

— Ә без?!.

— Беләбез. Абдул-Ваһапның җаны кара төтен булып, күккә ашып бараe.

Кичке буйда болачыларга Көчекбай алае килеп кушылды. Әмин егетләре кайтып төште. Көчекбай егетләре граф Сиверсның Ыргыз тамагында төзелеп ята торган Вознесенский заводына һөҗүм иткәннәр икән. Заводчыга кәнди тотып йөрүче вирнай башкортларны куып таратканнар, йөз утыз дүрт баш атларын ганимәт итеп алганнар, яңа завод өчен хәзерләнгән бихисап туз һәм бүрәнәне яндырганнар, мәгәр кара эшкә дип куып китерелгән урыс крестиәннәренә тимәгәннәр.

— Һай, аяныч, урыс түрәләреннән берсен дә эләктереп булмады,— дип уфтандылар Көчекбайныкылар.— Сизенеп тайганнар...

Тугайда уен-көлке, мәзәк, төртмә сүз куерды, учаклар янында коралын, иясе атын мактаучылар күбәйде, көч сынашулар башланды. Алай башлыклары карт тирәк төбендәге учак тирәли утырышып алганнар да, яуның киләчәк язмышы хакында бәхәсләшәләр. Барыннан битәр Көчекбай сүзендә нык тора:

— Ни генә димәгез, башлап Зилаер кальгасын урап алырга кирәк. Бригадир Бахмәт дырагуннарын кырып салырга. Шунсыз көн юк безгә, егетләр.

Яубасар белән Елан-Эткол башта ук зур коралды көч белән бәрелешмәү, әүвәл вак-вак отрядларны, бигрәк тә мәртәтләрне юк итү, башка иләүләрнең дә кузгалганнарын көтү ягында иде.

— Ашыкмаек, башта көч туплаек. Аннан инде Бахмәт кенә түгел, Ниплүй янарал үзе дә берни тормай безгә,— дип каршы килә Яубасар, ярсынып.

Елан-Эткол исә сабыр гына аның сүзен җөпли:

— Ие, әүвәл берегеп бетү кирәк.

Ярты төн узганчы бәхәсләшсәләр дә, бер фикергә килә алмадылар. Алай да таңнан Зилаев кальгасына таба кузгалырга булып, тирәк төбенә ятып йокладылар.

Япан авылындагы ялкын һәм явыз старшина Абдул-Ваһапның, аның яраннарының рәхимсез үтерелүе, күптән көткән оран-чакыру булып, яшен тизлегендә авылдан-авылга, җәйләүдән-җәйләүгә күчте — халаекларны кулларына корал алырга, атларга менәргә дәште. Бөрҗәнлеләр белән бер үк вакытта диярлек күршеләре — Тамьян, Тәңгәүер, Үсергән иләүләренең халаеклары күтәрелде. Аларга Бошман-Кыпчак һәм Чәнкем-Кыпчак волостьлары да кушылды. Мәгәр баш күтәрүчеләр берегергә, бер кул астына басарга ашыкмыйлар иде. Һәр иләүнең, хәтта һәр бәндәнең, уртак максаттан да элек, «үз» дошманы бар. Һәркайсы шулардан үч алырга ашыкты: заводлар кыйратылды, ям станнары пыр туздырылды, мәртәт «вирнай»лар үтерелде. Саташулы төшләр күрә-күрә тапталган үлән өстендә йоклап ятучы Бөрҗән алайларының башлыклары алары хакында белмиләр иде әле.

Болачылар төркеме өстендә әллә ничә йөз сөңге ялтырады. Бу инде шаяру түгел, олы бер чирүнең кузгалуы иде. Башлап Көчекбай үзен кулга алды:

— Болай сукыр килеш бару ярамас,— диде ул янәшәсендәге Елан-Эткол белән Яубасарга,— юртауллар юлларга кирәк!

Атлы күзәтчеләр Каны елгасы буйлап күп тә күтәрелмәделәр, юртауллар башы Әмин ике егете белән борылып килеп тә җитте. Алда — зур гына болында «вирнай» башкортлар заводчы Мосоловларның атларына печән чабып яталар икән. Атларын тышаулап, чирәмгә җибәргәннәр, имеш. Әлеге хәбәрне ишеткәч, Яубасар белән Елан-Эткол егетләрен печәнчеләр янына ашыктырдылар.

Тугай, чыннан да, гөр итеп тора иде. Чалгы янаган, сузып-сузып җырлаган тавышлар ерактан ук ишетелә. Димәк ки, куркыныч турында хәбәрләрендә дә юк. «Ур-р-р!» — дип өсләренә ябырылуга, әллә каян гына аллы-артлы мылтыклар шартлады — болачыларның икәве атларыннан егылып төште. Тик бары берничә кешенең генә каршылык күрсәтүе ташкын булып килгән алайны туктатырлык түгел иде. Түшәктәй күпереп торган пакуслар арасына канлы гәүдәләр авып-авып төште.

Беренче уңыш болачыларны канатландырып җибәрде, шатлыктан чыркылдашып-адаланып дөньяларын онытканнар икән, хәтта алга таба юртауллар да юлламаганнар. Урман юлындагы борылмадан кисәк кенә бер төркем коралды атлылар килеп чыккач кына, исләрен җыйдылар.

Киеренкелектә үткән бер мизгел тулы бер гомер булып тоелды. Мәгәр уклар атылмады:

— Әйа, үз мөселманнарыбыз лабаса!

— Курыкмагыз, егетләр! Мишәрләрбез, сезнең якка аварга булдык,— диделәр.

Шул ыгы-зыгы эчендә кайсы сизеп өлгергәндер, кемдер бөтен тавышларны күмәрлек итеп үкереп җибәрде:

— Качты! Шәрип ыстаршина ычкынды!

Җайдак бер күренеп, бер күздән югалып, алга — Мосоловның Каны-Никольский заводына таба томырыла иде. Халаекларның кан дошманын эзәрлеклəп килүчеләр дә кемне һәм ни өчен кууларын яхшы беләләр, атларын кызганмыйлар. Әмма ике алайның очрашуы вакытында Шәрип старшина байтак юл алырга өлгергән иде шул. Җитмәсә, заводы да моннан ерак түгел. Булса ни, болачыларга барыбер ич — бер урыс түрәсенең башкорт җирләренә китереп салган заводын кыйраталар икән, моның ни гонаһы булсын. Әминнең йөрәге очып китәрдәй булып талпына, каны кайный иде.

Завод диварлары күтмәгәндә һәм кинәт пәйда булды. Манарадагы каравыллар әлеге сөер бәйгене карап-күзәтеп торганнар булса кирәк, авыр имән капка шагырдап ачылды — Шәрип старшина атында очып килгән шәпкә заводка кереп шылды. Әминнең дә аты тыяр чикне узып ярсыган иде. Ул тыелгысыз ачык капкага томырылды. Ләкин тегесе шул мизгелдә иләмсез шагырдап ябылды, җайдак дәһшәтле киртәгә килеп бәрелəм дигәндә, атын читкә каерып өлгерде. Ул арада аллы-артлы мылтыклар шартлады.

Бераздан исә болачылар алае тулысы белән завод дивары янына килеп җитте. Әмма алар филгә һөҗүм итүче черкиләрне генә хәтерләтәләр иде. Болачылардан исә инде өчәве яраланып та өлгерде.

— Туктагыз! Укларыгызны юкка әрәм итмәгез! Чигенегез! — дип кычкыра-кычкыра, алай алдыннан Көчекбай чаптырып үтте.

Инде яугирләр дә завод-кальгага ук атуның иләк белән су ташу кебек үк мәгънәсез бер эш икәненә инандылар, теләр-теләмәс кенә урманга чигенделәр.

Карурман эчендәге аланга ялга тукталгач, Елан-Эткол белән Яубасар кичәгечә бәхәсләшмәделәр, сүзсез генә Көчекбайны тыңладылар, карулашмый гына аның һәр сүзенә ризалык белдерделәр. Бу инде аларның Көчекбайны болачы бөтен алайларның башлыгы итеп танулары иде.

Ничек кенә итсәң дә, әүвәл дошман ыстанын күзәтү, аның көч-куәтен, ниятен белү кирәк иде. Ишләренең сүзсез ризалыгы белән яу башы булып танылса да, бу эшкә үзе алынды Көчекбай. Тамакларын туйдыруга, ул Әминне һәм аның ике егетен ияртеп җәяүләп кенә төзелеп ята торган Зилаер кальгасы юлы өстендәге Преображенский заводына таба китеп барды.

Күзәтүчеләр кич йолдызлар калыккач кына әйләнеп кайттылар. Арыганнар, талчыкканнар. Алай да чырайларында — канәгатьлек. Салкын ит кабып, мәтрүшкә чәе эчә-эчә, Көчекбай күргәннәрен һәм ниятен сөйләп бирде:

— Чукынган татар Иван Тәүердәшевнең Урман-Зилаердагы заводында дырагуннар күп түгел — нибары биш-ун солдат. Мәгәр чиру кешеләре — татарлар вә башкортлар шактый күренә. Безнең бөтен өмет — төн караңгылыгында вә завут кальгасының кыр яклап корылып бетмәгән текмәсендә. Ул тур әлегә утыртма читән белән генә коршалган. Төн таңга авышканда, шуннан бәреп керсәк...

Монда аларны көтмиләр иде. Завод үлем йокысы белән йоклый. Алай да Көчекбай кинәт ябырылырга тәвәккәлләмәде. Алар, Әмин белән икәүләп, утыртма читәнне кеше сыешлы итеп сүттеләр дә аралыктан эчкә үттеләр. Көчекбай хәнҗәрен кулына алды, чатыр авызына килде, мыштым гына эчкә үрмәләде. Кисәк, төнге тынлыкны бозып, берәүнең өче ыңгырашуы ишетелде. Шуның артыннан ук чатыр эчендә ыгы-зыгы купты.

Калганы тиз һәм ансат башкарылды. Таң яктырып килгәндә, заводтагы коралы кешеләрнең иллесе бугазланган, дистәгә якыны гына Зилаер кальгасына качып котылган иде.

Бөрҗән иләүендәге төп коралы көч тупланган Зилаер кальгасына бүген үк һөҗүм итмәскә уйлаган иде Көчекбай. Анда драгуннар күп,

мылтык-дарылары җитәрлек, өстәвенә өч данә туплары да бар. Зилаерны камау һәм алу өчен зур әзерлек һәм дә болачыларның башка айлары килеп җитүен көтәргә кирәк. Заводтагы гаскәриләрнең беришекачып, кальгага кереп бикләнүе Көчекбайның ниятен бутады, ул булган кадәр көч белән крепостьны камап алды.

Инде эш бу кадәренә җиткәч, ашыгырга кирәк иде. Яу башы төрле тарафларга чапкыннар чаптырды, яуга купкан һәр алайны, хәтта һәр кешене Зилаер кальгасы янына чакырды.

Чапкыннарның берсе Әмин иде. Ул, күзәтче ике егетен ияртеп, үзенең туган төягенә — Талкыш күле буена юл тотты. Мәгәр авылына кайтып җитә алмады. Бәрәкол суы буенда урыс драгуннарының атларына печән чабып ятучы халаекларга тап булды.

— Нишләп ятасыз, әй?! — дип кычкырды ул, елга буен ярып.— Бар мөселман атларга менде. Ташлагыз сәнәкләрегезне! Әйдәгез!

Печәнчеләрнең берсе — әзмәвер гәүдәле булса да, җитез хәрәкәтлесе килә-килешкә агач сәнәген җиргә сугып сындырды. Әминнең каршына басты:

— Әйдә, батыр, алып бар безне! Әй, Моталлап, атларны китер!

Һич көтмәгәндә болачылар янына зур бер төркем егетләр ияртеп кайтты Әмин.

Сизә Көчекбай: болачылар да өлегә мылтык-тупларга каршы ташланырлык түгелләр. Ул тагы өстәмә көчләр көтте. Урал буеның яуга күтәрелүен раслаучы хәбәрләр, Көчекбайның йөрәгенә сары май булып ятсалар да, ярдәмгә килүчеләрнең азлыгы аны талый-газаплый иде. Хәбәрләрнең соңгысы аның күңелендәге шик-шомны төмам тутырып, чайпалдырып чыгарды. Кичке буйда гына әйләнеп кайткан чапкын һич көтелмәгәнне әйтте:

— Сатлык ыстаршина алае вә аның тарафдарлары граф Шуваловның Покрау завутын баштанаяк кыйратканнар!

Көчекбай чапкынны куышына алып керде һәм тәфсилләп төпченергә тотынды. Хак, Сатлык яклылар этлекләрен эшләгәннәр: завутны тулысынча яндырып, чиркәүне вәйран иткәннәр, андагы алтын-көмешне талаганнар. Болары ярасын да, ди. Ә менә андагы кара эштә эшләүче урыс крестьяннарын суеп бетерүләре белән һич кенә дә килешеп булмый. Юк, булмый!

Иртәнгә ул инде ныклы бер карарга килгән иде. Болачыларның барын бер төбәккә җыеп, киңәш-табыш итәргә, Сатлык ише явызларны хөкемгә тартып, акылга утыртырга, көчләрне туплап, артабан бердәм һәм дәррәү хәрәкәт итәргә. Туплану урыны итеп Агыйдел буендагы Бөгелчән авылын сайлады Көчекбай.

Үзен алла колы, чиркәү улы дип санаган Неплюев, язын Бөрҗән волостенда булып узган хәлләрдән соң, төннәрен гыйбадәт кылып үткәрә торган булып китте. Ярым караңгыда ялгызы укына-чукына да, бүлмәсен яңгыратып: «Шөкер, бүгенге көн дә тыныч үтте»,— дип куя.

Бүген дә ул эшенә, алласына шөкрана кыла-кыла, зур өметтә килде. Кабинетына үтәргә өлгермәде, секретаре Конбяжев, бөтен гадәт-тәртипләрне бозып, алдагы якта ук каршына килеп басты:

— Бригадир Бахметевтан ашыгыч депеша, галиҗәнап!

Иван Иванович, секретарена кырыс карап, пакетны кулына алды, җилләнеп бүлмәсенә узды. Аннан инде ашыкмады: каударланмый гына пакетны ачты, теләр-теләмәс кенә язуга бакты һәм... тетрәнеп китте. Анда бригадирның эре, гаскәриләр сыман тигез тезелеп торган хәрефләре белән түбәндәге сүзләр язылган иде: «Волостьның Агыйдел буенда яшәүче башкортлары, Мосолов заводыннан үрдәрәк, үзләренә яңа җибәрелгән старшинаны (Абдул-Ваһап), писарьны һәм ике мишәрне үтереп ташладылар. Аннан исә, илле-алтмыш чамасы кеше тупланып, Мосолов заводында эшләүче тугры башкортларга һөҗүм иттеләр. Күре-

некле старшина Шәрип Мерәковны, русларга тугрылыгы өчен, үтерергә маташып караганнан соң, хатыннары һәм балалары белән Сакмар башына таба китеп бардылар»...

Иван Иванович, хатның ахырына карап, датасын ачыклады — 9 август.

Губернатор урыныннан торды, киң иркен бүлмә буйлап йөреп китте. Кабат борылып килде һәм императрица Елизавета рәсеме каршына тукталды, аның азгын хатыннарча ирләрне ымсындыру өчен махсус шәрәләндерелгән күкрәк алмаларына карап алды, аннан, патшадан киңәш сорагандай, әйтеп куйды:

— Нишләргә соң? Кичекмәстән чарасына керешергәме? Әллә...

Мәгәр патшабикәнең тук чыраенда һич кенә дә борчылу, пошыну чалымнары юк, мутлык һәм канәгатьлек билгеләрс генә. Губернатор әле туктап, әле ишекле-түрле йөренә-йөренә озак баш ватты. Торган саен фикере үсте, ныгыды. Хәзергә чаң какмаска, яман хәбәрне берәүгә дә әйтми торырга булды. Ниятен ныгытса да, күңеле тыныч түгел иде Неплюевның. Аның кулыннан эш төште, менә-менә бизгәк өянәге кузгалыр сыман тоелды.

Шул халәтендә янә ике көн үтеп китте. Бригадир Бахметевтан тагы чапкын килде — фетнәчеләр төркеме барон Сивересның Вознесенский заводына һөҗүм иткәннәр, шунда эшләүче тугры башкортларның атларын алып киткәннәр, бүрәнә-туз ише нәрсәләрне, урман-биләмәләрне яндырганнар.

Димәк, ул ялгышты. Димәк, Бөрҗән волостендагы вакыйга очраклык түгел. Шундый нәтиҗәгә килергә өлгермәде, өстәленә янә бер пакет кертеп салдылар. Хәбәрнең монысы да хәерсез иде: Стравин дигән бер прапорщик, Үрге Җаек крепостеннан бригадир Бахметев янына кайтканда, бер генә станциядә дә ни ямчыларны, ни драгуннарны тапмаган, бер җирдә исә солдатларның үле гәүдәләренә тап булган, икенче бер урында патроннары тулы патронташка юлыккан...

Менә тагы бер хәбәр: «Фетнәчеләр Бәрәкол елгасы буенда эшләүче тугры башкортларны котыртып, үзләренә ияртеп киттеләр».

Калганнарын укып та тормады губернатор. Хатлар укып мавыгырга түгел, чарасына керешергә кирәк. Ул, ашыгып, ишеккә килде һәм кабул итү бүлмәсендәгеләргә эндәште:

— Конбяжев, кичекмәстән Хәрби советны җыярга кирәк!

Әйтәсен әйтте дә, ничектер боегып калды Иван Иванович, өстәле артына күңелсез генә әйләнеп кайтты. «Юкка гына җыям,— дип уйланды ул үзенең яраннары турында,— барыбер ул болваннардан акыллы сүз ишетермен димә. Һаман да шул үзең селкенсәң генә».

Стенадагы сәгать тыңкыш тавыш белән уникене сукты. Шуны гына көткәннәр икән, биек киң ишек ачылып китте, күз ачып йомганчы, кабинет офицерлар белән тулды. Губернатор керүчеләрне барлап, барына да сөзеп карап чыкты — командировкадагыларыннан башкалары бар да биредә иде. Неплюев саңгырау тавыш белән әйтеп куйды:

— Губернада восстание, әфәнделәр...

Бүлмәдә кабер тынлыгы урнашты. Әлеге өч сүзнең ни аңлатуы барына да мәгълүм иде.

Иван Иванович, сүзем барына да барып җиттеме дигәндәй, беравык тын торды да бастырып кына сөйләп китте:

— Мәгълүм булсын: бүгенге көндә безнең карамакта унөч полк, ягъни егерме дүрт мең ярым чамасы гаскәри бар. Шуның унбиш меңнән артыгы — регуляр армия солдатлары. Болардан тыш губернада дүрт меңгә якын Җаек казагы, бер мең тирәсе чукынган калмык, шул ук чамада татар, мишәр һәм башкортлардан торган регуляр булмаган кораллы кешеләр бар. Әмма, восстаниенең бөтен төбәкне чолгап алу ихтималын күздә тотканда, бу көч бик аз, әфәнделәр.

Неплюев туктап калды. Бераздан, дивар буена тезелешеп утырган гаскәриләргә карап, сүзен дәвам итте:

— Полковник Пальчиков! Бүген үк, менә хәзер үк Донга, Җаекка һәм калмыклар ханы Дундук Дашега чапкыннар җибәрергә кирәк! Оренбургка кичекмәстән мең Дон казагы, шул ук күләмдә Җаек казагы һәм дә мең калмык җибәрсеннәр! Монысы буладыр тагы өч мең кылыч.

Премьер-майор Кублицкий! Чапкыннар Петербургка чапсыннар, Сенат үзе вәгъдә иткән өч драгун полк. Болары буладыр янә дүрт-биш мең штык! Кирәге чыга калса, аларга өстәп, тагы Вятка, Себер, Курск, Ярославль һәм Ростов драгун полкларын да далага таба җибәрү турында киңәшелгән иде. Тиз үк Оренбургка таба кузгалсыннар! Болары үзләре генә дә — сигез-ун мең регуляр армия дигән сүз... Пальчиков! Мин сезгә әйтеп бетермәгәнмен. Бая аталганнардан тыш, тагы ике мең Дон казагы, биш мең Казан татарын китерүне тәэмин итәргә кирәк! Мәсьәләнең уен түгеллеге аңлашыладыр, әфәнделәр. Сүз белән мавыгып, вакыт үткәрмик, кузгалыйк. Алла юлдашыгыз булсын!

Офицерлар, дәррәү кубып, ишеккә ташландылар. Бер Котлымөхәммәт морза гына, төркиләр яшәгән далаларда очраштыра торган таш балбал сыман, йокымсыраган кешедәй, һич кымшанмый утыруында. Ул белә: гадәтенчә, губернатор аңа аерым эш кушачак.

Тәвкилев ялгышмады. Бүлмәдәге офицерлар чыгып бетүгә, Иван Иванович аның каршына килеп утырды һәм, маңгайга шапылдатып суккандай, керешсез-нисез әйтеп куйды:

— Менә шулай, Алексей Иванович, янә күрәшкә!

— Көләсез, Иван Иванович. Нинди яугир инде мин хәзер?! Мич башы хакында уйланыр чак җиткән.

— Менә монысы белән һич кенә дә килешмим, морза. Иң тирән буразнаны нәкъ менә без картларга — синең белән миңа сөрергә туры киләчәк.

— Юк инде, Иван Иванович, элеккеге гайрәтле Тәвкилев үлде, дип сана.

— Син мине тыңлап бетермисең, Алексей Иванович.— Неплюев өстәленә таба иелде һәм, кәгазьләрен актарып, арадан берничәсен морза алдына китереп салды.— Менә монысы — быелның 20 июнь указы. Сенат әһелләре восстаниеләрне бастыруда, гомумән, халык белән эш итүдә, кансызлыктан качып, крестьяннар белән саграк эш итәргә боералар. Бусы исә,— ул икенче кәгазьне кулына алды,—24 июльнеке: гаепләләргә җәза бирүдә ифрат сак булырга кушылган.

Морза чыраен сытты:

— Ворларны башларыннан сыйпарга алайса?!

— Сыйпарга да туры килер, Алексей Иванович. Минем тәкъдим белән Сенатта императорның махсус манифесты әзерләнә — үзләре теләп тәүбәгә килгән ворлар тулысынча гафу ителәчәк... Тәүбәгә килмәгәннәрнең бөтен милекләре тугры башкортларга һәм татарларга өләшенәчәк. Аны рус һәм татар телләрендә күпләп яздырып, губернага таратасы булыр. Мөселманнарга минем исемнән, әлбәттә, аларның бары да аңлый торган татар телендә махсус грамота язып таратырга, болага катнашулары өчен үкенеч-уфтану белдерүчеләргә һәртөрле байлык-игелекләр вәгъдә итәргә кирәк. Аннан да мөһиме — Оренбург ахунының халыкка мөрәҗәгать итүе зарур. Кешеләрне тынычланырга чакырсын! Батырша — явыз җинаятьче һәм фетнәчедән башка беркем дә түгел, ул дөнья болгатучы, аның болага чакыруы ахуннар фатыйхасыннан мәхрүм, шуңа да корьәнгә каршы, диелсен!

Морзаның карандашы, ташка төртелгәндәй, туктап калды, карашы түргә таба атлап барган губернаторга текәлде:

— Ай-һай, язар микән?!

Неплюев басынкы гына көлеп җибәрде.

— Картайган саен наивлана барасың, морза,— диде ул, ниһаять, көлүеннән туктап.— Ахунның язуы ни пычагыма сиңа?! Гарәп хәрефләрен онытмагансыңдыр, шәять. Үзең яз!

— Аңладым, галиҗәнап.— Тәвкилев ашыга төшеп язарга тотынды. Губернатор исә аның теркәп өлгерү-өлгермәвенә игътибар итмәстән, һаман да ишекле-түрле йөри-йөри, этләшү ниятләрен тезүендә булды:

— Исемә төшерүеңә рәхмәт, морза. Ул Батырша дигән бунтарьны тотып бирүчегә биш йөз сум ярлыкаш акчасы билгелисе булыр. Ә бәлки мең сум ук итәргәдер? Минем исемнән язылган грамотада шул хакта да әйтерсең.

— Бер такырбаш өчен бик күп булмасмы соң ул мең тәңкә?

— Һич күп түгел. Моның еракка китә торган тамырлары бар, морза. Безгә һич кичекмәстән татарлар белән башкортларны ызгыштырырга, Батыршаның восстаниене Идел-Кама буйларына күчерү хыялын юкка чыгарырга кирәк! Бу эш ике юнәлештә барырга тиеш. Беренчесе— губернада яшәүче татарлар белән башкортларны бер-беренә каршы кую.

— Акыллы, акыллы уйланган, галиҗәнап. Мондый ташламалар, татарларның киптәнге интересларына туры килгәнлектән, аларны көрәш юлыннан читләштерер.

— Тукта, морза, тыңлап бетер. Казан татарларының восстаниегә кушылып китү куркынычы шулкадәр зур ки, аларның ачуын соң чиккә җиткергән архиепископ Лука Конашевич һәм тагы берничә архирей бөтен губерналарга күчерелә. Хөкүмәт хәтта шуңа барачак ки, исламны христиан дине белән бер рәттә яшәргә хаклы дип, мәчетләр салырга рөхсәт бирәчәк.

— Ну баш та инде үзегездә, галиҗәнап!

Неплюев ялагайлануны кабул итмәде, чыраен сытып, морзаны бүлдерде:

— Куштанланма, Алексей Иванович. Восстаниенең монысы— элеккеләре ише генә түгел, морза. Региондагы бөтен мөселманнарны тупларга маташа Батырша. Димәк, бу— крестьяннарның гадәти баш күтәрүләре генә түгел. Ничек дип әйтим, э-э-э-әйе, Идел-Урал халаекларының азатлык хәрәкәте диярге кирәктер моны, мөгаен. Быелдан, ягъни 1755 елдан, тарихка «милли-азатлык хәрәкәте» дигән төшенчә кереп калыр ахры, Алексей Иванович.

* * *

Атна буе гасабилыкта интеккән алай башлыкларына хәбәрнең өрңасын талчыгып хәлдән тайган юртавыл алып килде:

— Капитан Шкапский кулы астындагы әтрәт Әүҗән-Петров заводына бара...

Көчекбай утырган ташы өстендә борсаланып алды, аның күзләре очкынланды.

— Тукта, утыр!— диде ул, таш кәндигә сабадан җылымса кымыз агызып һәм әчемлек тулы савытны юртавылга сузды.— Инде рәте белән сөлә: ничә кеше? Атлылармы?

— Бән аларны кичә көндезен Зилаер суы башында күрдем,— дип китапча тәзек итеп сөйләп китте юртавыл.— Бик тә сак, акрын хәрәкәт итәләр. Солдатларга юл сабучы татарның әйтүенә караганда, бер драгун ротысы, ул илле казак белән көчәйтелгән. Оренбург казакларының йөзбашы— Бирдебай.

Көчекбай түзмәде, урынынnan сикереп үк торды:

— Шулаймы? Алай ук коточарлык түгел алайса? Һәрхәлдә, безнең теш үтәрлек.— Ул янәшәсендә таш өстендә утырган Елан-Эткол белән

Яубасарга таба борылды.— Менә шулай, узаманнар, бән әйткәннәр килә. Без урыс пулкларын җиңә алмайбыз. Тау-урман арасында, аерым-аерым урап, кыйратырга иде фасикъларны. Йә, ни дисез?!

Яубасар да, Елан-Эткол да кайтарып сүз әйтмәделәр. Бу исә Көчекбайны үртәде, ярсытты гына:

— Куркасыз алайса?! Ярый, без сездән башка да... Әмин! Ишеттеңме сүзнең ни хакында барганын? Хәзер үк бер дистә егет ал да, ул урыс өтрәтен эзләп тап!

Көчекбай белән Әмин, дошман лагерын әйләнеп, бөтен яклап карап чыктылар. Юл сабучы татарның сүзләре хак: отряд артык зур түгел, мәгәр яхшы коралланган. Әнә, кузлага куйган мылтыклары гына да әллә ничаклы.

— Күз бәйләнгәндә, дәррәү генә якын киләбез дә, кяферләр өстенә ук яудырабыз,— дип сөйләде Көчекбай Әмингә, кызып-кызып.— Бу хәл Шкапскийны ярсытачак. Ләкин төнгә каршы эзәрлекләмәс алар безне. Шуннан инде без Агыйделне кичәбез да Тар үзәнгә китәбез. Ә син егетләрең белән монда каласың, Әмин. Иртән, таң яктысы сирпелүгә, солдатларга янә ук атасыз, үзегез аларның күзенә күренеп-күренеп китәсез. Алар, шашынып, сезнең арттан ташланачак...

Әминнекеләр исә бу төндә йокламадылар. Агыйдел буен куе томан басты. Шуннан файдаланып, лагерьга якын ук килделәр. Пыскып кына янган учаклар янында калгып утыручы каравылчыларның берсе Әминнең беренче угыннан ук авып төште, әмма йөрәк өзгеч тавыш белән кычкырып өлгерде. Чатырлардан драгуннар атылышып чыкты, һәркайсы мылтыгына ябышты. Томан эченнән очып килгән уклар ешайганнан-ешайды — солдатларның биш-алтысы җиргә капланды.

— Әй, сез камап алынган,— дип кычкырды Әмин, хәйләгә керешеп.

Шул сүз җитә калды. Драгуннар кай арададыр, билгеле бер тәртипкә тезелеп, тавыш килгән якка ташландылар. Ләкин бу вакыт инде Әмин, егетләрен ияртеп, Агыйдел кичүенә кереп бара иде.

Кысан урман юлы карательларны сөзәк үргә алып менә. Чагылның иң биек җирендә болачылар кабат пәйда булдылар. Монысында әшәке такмакларын такмаклап кына да калмадылар, мундирлы бәндәләр ягына таба берничә дистә ук та җибәрделәр. Ярсыган-шашынган казаклар төркеме моңа игътибар итмәде — сукыр ачу аларны һаман алга әйди иде.

Менә үзәнгә дә төшеп җиттеләр. Төркем алдында ялангач кылычын уйнатып барган Бирдебайның аты, аяклары сумалага ябышкандай, кинәт туктап калды. Ул арада, драгуннарын ияртеп, капитан Шкапский килеп җитте.

— Ни булды, сотник?— дип кычкырды ул, килә-килешкә.

— Сазлык.— Әйдә, бу җәһәннәм базын тиз генә үтик тә, берәр хозуррак җирдә тамак ялгарбыз!

Күпердән чыккандай, шакы-шокы килеп, түшәүлек өстеннән кузгалдылар. Агачлар сазламакка күптән салынганнар бугай, күбесе череген — атлар әледән-әле бот төбеннән бата, солдатларның әле берсе, әле икенчесе юкка чыга. Алай да алга бара отряд, инде түшәүлекнең урта бер җиренә җиттеләр.

— Чурт, юл түгел — әллә нәрсә бу,— дип сукранды Шкапский.

Ул сүзен әйтеп бетермәде, нәкъ каршысына, юлга аркылы карт чыршы шатырдап авып төште. Ни булганын аңышып өлгермәделәр, һавада нәрсәләрдер сызгырды, ул да түгел, капитан чайкалып куйды һәм гөрселдәп түшәүлек өстенә барып төште. «Әмин угы» дип Бөрҗән кешеләре теленә кергән укларның берсе аның күкрәгеннән тишеп чыккан иде. Мәгәр урман эченнән сызгырып килгән уклар шулкадәр ишле иде ки, йөзбашында капитан кайгысы калмады. Түшәүлек буйлап кирегә чаптырып киттеләр. Тик ук атар ара үтәргә өлгермәделәр, бу яклап та юлга аллы-артлы ике агач авып төште. Чарасыз калган яугирләр бер

урында бөтерелергә тотындылар. Нәкъ шул мизгелдә төркем өстенә гөрселдәп карт карагай ауды — дистәләп кешене һәм атны сытты. Агачлар әле уңнан, әле сулдан егыла башладылар. Отряд күз алдында эреп бетә бара иде.

Шулчак әллә каян гына ярсу атында Көчекбай килеп чыкты. Кулында — саллы гөрзи. Шуның белән әле уңга, әле сулга кизәнеп, каушап калган каратларның башларын изә.

Ниһаять, солдатларның исән калганнары, исләренә килеп, мылтыкларына ябыштылар. Берсе мушкетын Көчекбайга төбәде, тәтесен басарга чамалый. Шуны күреп алды да камчысы белән атына сукты Әмин, ыргып Көчекбай алдына чыкты, әлеге драгун өстенә ташланды. Шул мизгелдә мылтык гөрселдәде — егет бер якка янтайды.

Орыш башлануга чирек сәгать тә үтмәгәндер, түшәүлек өстен кан басты, ясалма юл үле гәүдәләр белән тулды. Болачылар тәмам ярсып, орыш комарлыгыннан кызып җиткәндә, Тар үзәндә бер генә исән драгун да, казак та юк иде инде. Әлеге канлы мәхшәрдән нибары берәү исән калды. Ул да булса, үлгәнгә сабышып ятучы юлбасар татар иде.

Болачыларның аны эзләп торыр вакытлары юк иде шул. Алар Көчекбай белән Әмин һәм шушы орышта шәһит киткән кешеләрнең үле гәүдәләрен, җитәктәге атлары сыртына салдылар да, килгән юллары белән кайтырга чыктылар.

Алар үр сыртына менеп җиткәндә, каршыларына, кара болыт булып, Елан-Эткол белән Яубасар алайлары килеп җиттеләр. Әмма боларына инде эш калмаган иде.

Урманга җиткәндә, каршыларына уктай атылып килүче җайдак:

— Ир-ләр! Оренбурдан бихисап урыс пуклары килә! Кяферләрнең исәбе-хисабы юк! — диде.

Байтак тын торгач кына Елан-Эткол телгә килде:

— Яудашларыбызны җирләек тә, өйләребезгә таралаек! Хатыннарыбызны, бала-чагаларыбызны, күтәрә-куа алган кадәр мал-мөлкәтне алып, Җаекка таба кузгалырбыз. Канкардәшләребез — кыр казаклары сыендырырлар әле!

Кич җитеп, кояш Бөрҗән карурманнары артына төшеп чумарга җыенганда, бөтен Нугай юлы купты. Хөкүмәт гаскәрләре якынлашудан өркеп, тәмам хафага төшкән ун меңләп татар-башкорт, елкы-сыерларын куып, Җаекка таба кузгалдылар. Казакъ далаларында үзләрен ни көтүен белмиләр иде әле алар.

*Ахыры киләсе санда*

# Газинур Морат

## Ачлык
ПОЭМА

*...Ирек хакына шәһит киту генә мәгънәгә ия була. Тик шул чагында гына кеше үзенең бөтенләй үк үлмәячәгенә ышана...*

Альбер Камю

1

Идел-йортлы ил идек,
Идел кичәр ир идек.
Иделләргә төн инде,
Илләргә кайгы килде.

Тәхет өчен талашып,
Үзара якалашып
Яткан чакта бишь надан,
Тотты Мәскәү якадан.

Тотты Мәскәү умырып —
(Йә, кем безне яклаган?) —
Тәре баганасына
Элеп куйды якадан.

Янәсе, татар, чынык —
Торабыз тыпырчынып.
Чайкалабыз җилләрдә
Туган-үскән җирләрдә.

Туган-үскән җир, имеш,
Килмешәк татар килеш.
Ватаны булмый колның —
Тәкъдирең белән килеш.

Колның булмый Ватаны,
Кичерү юк татарны.
Тизрәк язсын дененнән,
Тизрәк язсын теленнән.

---

Газинур МОРАТ (1959) — *шагыйрь, «Мин дөньяны тыңлыйм», «Җир хәтере», «Тылсымлы тел», «Оча җырлар» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Дененнән язган татар
Тугры була эт кебек,—
Анасын сатканда да
Онытмас ул этлеген.

Ирек, азатлык, имеш,
Муенчак кигән килеш...

Ә без менә эт түгел,
Этлек юк уебызда.
Сездә баскын уедыр,
Качкыннар уе бездә.

Качкынлык — каныбызда,
Качарбыз барыбыз да —
Качкан күк чукынудан,
Иманга тукынудан.

Качкын булу илеңдә
Мең каза, мең газаптыр.
Шуңа да без ил белән
Кычкырабыз: «АЗАТЛЫК!»

...Әләм булып илләрдә
Җилфердибез җилләрдә.

2

1991 елның май урталары. Нәкъ җырдагыча — алмагачларның чәчәккә узган чаклары.

Казан утлы таба сыман чыжлап тора. Әгәр ул-бу була калса, тәмуг сакчылары йөрәгеңне шул табага салып кыздырачак.

Ирек мәйданы күзгә күренмәс чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратып алынган. Бүген ул Лонг Кеш төрмәсен хәтерләтә.

Мәйданда — АЧЛЫК. 1981 елда ун ирланд егете Лонг Кеш төрмәсендә сәяси ачлык тотудан һәлак булган иде.

Безнең башка ниләр язды икән?

Үлем турында уйлыйсы да килми. Ачтан үлү коточкыч авыр, диләр. «Адәмнәр»не укыгач, моңа үзең дә ышанасың.

Ихтимал, мең еллар дәвамында ураза тотып яшәгән халык ачлыкны чагыштырмача җиңелрәк кичерәдер. Аның вөҗүде ачлыкка тизрәк җайлашадыр.

Хәер, безнең тарих болай да ачлыктан тора. Без инде 1552 елдан бирле ачыгабыз. Кайчандыр болгар бабаларыбыз урыс халкын ач үлемнән саклап калган.

Ә без — ачыгабыз...

Хөр булырга хакы бардыр җирдә
Һәрбер кызның, һәрбер угылның...
Ачлык тотып ачыклады халкым
Кояш астындагы урынын.

Ачлык тотып ачыклады халкым
Өлешенә тияр көмешен.
Кара йөзләр кабат каркылдады:
— Бөтенегез ачтан дөмексен!

Кара йөзләр кабат кара яга
Биләүдәге ирек йөзенә.
Ирек чыраенда күренмәсен
Татарлыкның хәтта эзе дә.

Русиянең ач күзенә төшкән
Ак кына да булды бу халык.
Ничә гасыр дөнья бутый-бутый
Үзе бетте Рәсәй буталып.

Бар үткәне фетнәләрдән тора,
Фетнәләрдән тора бүгене.
Фетнә дигән әфьюннән булыр
Империяләрнең үлеме.

Терәү белән терәтергә мөмкин
Ишелергә торган йортны да.
Терәүле йорт хуҗасының эше
Узмас ләкин ярым-йортыдан.

Ә терәүле йортның хуҗалары
Хәйран булып яши вәйранга...
Империя оныклары әнә
Чукмар айкап йөри мәйданда.

Империя оныклары әнә
Чукмар айкап саклыйирекне.
Кемнәр — хатын, кемнәр халкың кыйнап
Күрсәтәләр илдә ирлекне.

Азмы алар —
Мәгълүм әкияттәге
Бер дивана Иван хакына
Яулар чапкан кара полковниклар
Ата-бабасына, халкына.
(Тик үзеңнән качып булса икән,
Посып кына калкан артына.)

Танк белән таптарга да була,
Атарга да була безләрне.
Буй кыскара, уй кыскара бара,
Яши икән халкың тезләнеп.

Буй кыскара, уй кыскара бара.—
Кемгә хаҗәт — гарьләнә, гарьләнмә...
Без бәләкәй түгел, дия-дия
Әверелеп беттек кәрләгә.

Алып буйлы халык идек юкса,
Яралган соң нинди каннан без?
Илсез калмас, телсез калмас өчен
Ачлык тотар көнгә калганбыз.

Рәсәйне тик булмый ышандырып,
Сан юк сиңа — ачык, ачыкма...
Кытлык-мохтаҗлыкта яши-яши
Ул күнеккән инде ачлыкка.

Ачлык-патша хужа аңа күптән,
Ачлык-патша хужа тәхеткә.
Өч инкыйлаб күргән бабамны да
Ул озата барган ләхеткә.

Гомер буе иген иккән бабам,
Чабагачы исән һаман да.
Булмас, димә, булган, булган, туган,
Илдә чыпчык үлгән заман да.

Илдә хәтта чыпчыклар да үлгән,
Үлмәс дигәннәре — уйдырма.
Илдә бүген кемнәр антын сатып,
Алтын сатып тамак туйдыра.

Йортындагы соңгы мал-мөлкәтен
Сатып эчкән сәрхуш баш сыман,
Алтын сатып тамак туйдыралар...
Мәйданнарда ава таш сыннар.

Мәйданнарда таш балбаллар ава,
Мәйданнарда тагын инкыйлаб.
Инкыйлабның соңы — инкыйраздыр...
Инкыйлаблар белән ил кыйнап,

Яши Рәсәй һаман ЮКсыл булып,
Гел юксынып яши үткәнен.
Казан алып кабат ат казану
Телләрендә инде күпләрнең.

Күңелдәге, әйе, телгә чыга,
Сәрхушныкы һәрчак телендә.
Баскынлыкның кара макмырыннан
Айный алмый Рәсәй бүген дә.

Хөр булырга хокукы бар юкса
Һәрбер кызның, һәрбер угылның.
Ачлык тотып ачыклады халкым
Кояш астындагы урынын.

### 3

Татар күленнән Татар бугазынача сузылган Империя күмеләчәк каберне Литва бер ялгызы казый башлады.

Балтыйк иленең ирекка ачыккан халкы Империя танкларын кулга-кул тотынышып, җырлап каршылады.

«Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә»,— дигән мәхбүс татар шагыйре.

Бер төн эчендә 13 каһарманның җаны кыелды.

Алар арасында татар кызы Лорета Асанавичюте (Хәсәнова) да бар иде...

Кара эшләр караңгыда,
Кара төндә кылына.
Үрмәли мәкер —
Җаныңа
Якыная тын гына.

Үрмәли мәкер җанына,
Кара үрмәкүч сыман...
Ватаның сыйган —
Танкның
Йолдызлы мушкасына.

Ирекнең хакы һай кыйммәт,
Бирелми ирек бушка.
Учындагы бер йомарлам
Ирекне эзли мушка.

Үрмәли мәкер җанына,
Үрмәли тәнең буйлап.
Литва күген дегет белән
Куйганнар гүя буяп.

Үрмәли мәкер җанына,
Йотар булып тереләй.
Бу төн дә күчәр тарихка
Варфоломей төнедәй.

Кара эшләр караңгыда,
Кара төндә кылына.
Литва төне ясин чыга
Мөэмин татар кызына.

4

Иң шәп индеец — үле индеец, дигән генерал Шеридан.
Иң шәп татар — маңкорт татар, диләр Иван Пересветов оныклары.
Дәүләтсез халык маңкортлаша бара.
Маңкорт — кол дигән сүз.
Империя — коллар дәүләте ул.
Кол белән колонизатор бер үк тамырдан ясалган.
Адольф де Кюстин Рәсәйне халыклар төрмәсе дип атаган.
Маңкортлар шул төрмәнең назире булып хезмәт итә.
Ихтимал, татар дөньяда иң маңкортлашкан халыклар исәбенә керәдер.
Шаһгали — беренче татар маңкорты.
Маңкорт үзен һәрчак интернационалист дип саный.
Әйе, кол — интернациональ төшенчә: колның милләте булмый.
Социалистик Хезмәт Каһарманы М. К.нән аермалы буларак, мин үземне россиян дип исәпләмим.
Минем ирекле буласым килә...

Үч-кинә тотмыйм тарихка,
Билбауда йөртмим балта...
Җирдә моң кимегән саен
Илдә маңкортлар арта.

Җирдә моң кимегән саен
Кыскара бара хәтер.
Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ дигәннәре
Китап сүзе лә — хактыр.

Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ кавеменең
Дәвере килде мәллә?

Маңкортлыктан йолып калыр
Мәһдиең кайда, бәндә?

Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ кавеменең
Дәвере, димсең, алда?
Телсезлек, денсезлек күчкән
Кансызлык булып канга.

Кансызлар азмы халыкның
Ирегеn атты тәрәп.
Яши татар маңкортлары
Халкыма коллык теләп.

Яши татар маңкортлары
Сафсата сата-сата...
Улымны телсез калудан,
И Тәңрем, үзең сакла.

Сакла хәтерсез калудан,
Сакла Иделен, йортын.
Сакла берүк —
Хәтеребез
Болай да ярым-йорты.

Болай да ярым-йорты без,
Ярым-йорты ил, иләт...
Дәште Кыпчак карынында
Киләчәк ята иңрәп.

Тулгак тота чал Даланы —
Ауный дүңгәләк булып.
Безме ул — дүңгәләк кебек
Тамырсыз үскән буын?!

Үткәнен үтергәннең тик
Киләчәген кем таныр?..
Дәште Кыпчак карынында
Тыпырчына кентавр...

5

Казан алынгач, урыс патшасы ир затыннан булган һәммә татарны кылычтан үткәрергә әмер биргән. Арба чәкүшкәсеннән биегрәк буйлы һәр кешене шушы язмыш көткән.
Ихтимал, бу коточкыч җәзадан котылыр өчен, башын аска иебрәк, тәгәрмәчтән бәләкәйрәк күренергә тырышкан карсак ир-егетләр, малайлар да булгандыр. Кем белә, иелгән башны кылыч кисми, дигән тәгъбир дә бәлки шул заманнарда барлыкка килгәндер әле...

Тәкъдирен дә тәгъбир итеп язган,
Тәкъдир тактасында һәр сүз анык:
Арба тәгәрмәче буйлы калган
Тарих тәгәрмәче буйлы халык.

Тәкъдир тактасында һәр сүз тәгъбир,
Шагыйрь җаны сеңгән һәрбер сүзгә.
Башсыз калмыйм диеп баш имәгән,
Баш бирмәгән халык — димәк, түзгән.

Кисек башлы халык Кисекбашны
Юкка гына уйлап тапмагандыр.
Дию өннәреннән йолып алып,
Ил уллары аны яклагандыр.

Кисек башлы халык Кисекбашны
Бәетләргә салган, кыйссаларга...
Елмаерга хәтта өйрәнгән ул,
Куйганда да башын кискәләргә.

Елмаерга хәтта күнеккән ул —
Кисекбашлы тәкъдир күнектергән,
Тел яшереп телсез кала язган,
Денсез кала язган — дүнеп деннән.

Тел яшереп телсез кала язган,
Илсез кала язган аздан гына.
Камчылы бер ишан табылмаган
Базарында, бөтен Казанында.

Ник табылсын — ишан чалмасыннан
Ыштан тегеп кигәч заманасы.
Көпчәк буйлы калгач, көчектән дә
Каргаласы икән, таланасы.

Ә көчекләр Казан урамыннан
Өрә-өрә куа Кисекбашны.
Әгәр сиңа ялгыш абынса ул,
Урам ташы, берүк кичер башны.

Кичерә күр, кичерә күр берүк,—
Минем баш ул ауный,— татар башы.
Татар башын татар ашый-ашый,
Дуңгызлык та бетте татарлашып.

Татар атын татар сата-сата,
Калды атлар ишәк көннәренә.
И кадерсез атым, камчы тотып
Атланмады сиңа кемнәр генә.

Аранга да бикләп кыйнадылар,
Кыйнадылар тышау кидереп тә.
Тышау — зынҗыр.
Котылырмын димә
Аран аратасын кимереп тә.

И кадерсез атым, билләреңә
Мин атландым бүген —
Башсыз җайдак.
Тик язмасын берүк абынырга:
Еллар — түмгәк.
Барыр юллар — тайгак.

Тарих бизмәненме бизгәк тота —
Үзгә кыса, димәк, үзгә калып:
Кылыч буйлы булып калачактыр
Кылыч тотып ил яулаган халык.

## 6

Чиратлар иле бу.
Бу илдә чиратсыз туарга да, үләргә дә ярамый.
Үз вакытыннан алдарак туганнар гомер бакый каргалып, тукмалып көн итә бу илдә.
Халыклар баш итчегә чиратка тезелгән.
Ә түмәрдән телләр тәгәрәшә... телләр тәгәрәшә...

Ә халыклар ясак түли теллә тә.
Кабалага төшсәң, бар да талана.
И кардәшем, «мин — бәйсез», дип масайма,—
Анаң телен кыздыралар табада.

И кардәшем, «мин — бөек», дип масайма,—
Балаң телен талаталар этләрдән.
Иң дөресе — чиратка бас мунчага —
Арынырга вакыт мура-бетләрдән.

## 7

Ач торабыз. Ачыгабыз.
Ачынабыз язмышка.
Безнең тәкъдир-язмышларны
Иблис тә шул язышкан.

Ач торабыз. Ачыгабыз.
Ашыгабыз... җиңәргә.
Ачынабыз...
Дәҗҗал булып
Әҗәл баскан иңнәргә.

Ач торабыз. Ачыгабыз.
Ашкынабыз ирекkә.
Ә дәҗҗалдан юк котылу —
Ханбикәңне биреп тә.

Ач торабыз. Ачыгабыз.
Качкыннар без. Качаклар.
Бәхет эзләп чәчелгәнбез —
Без бәхеткә ач татар.

Ачыгабыз. Ач торабыз.
Баш орабыз... ташларга.
Держиморда гөрзиләре
Төште безнең башка да.

Ач торабыз. Ачыгабыз.
Асылда без —
Үлемсез.
Үлгәндә дә тик яртылаш
Үләрбез без —
Күрерсез!

Г о с м а н   Г о м ә р

# ЮЛБАРЫС ТЫРНАГЫ

МАҖАРАЛЫ ЧЫНБАРЛЫК

Иң әүвәл сезгә шундый бер сорау бирәсем килә: Толбаевны беләидегезме? Хәтерегезгә төшерегез әле: Толбаевны, Толбаевны!.. Хәзергеләр белми, әлбәттә. Ни пычагыма кирәк аларга синең Толбаев дигәнең?! Ә безнең замандамы — у-уу! Дөньясын дер селкетеп күрсәтте ул бәндә...

Толбай әдипләр белән гаять дус булып кыланды. «Әби патша» сыманрак. Ә үзенең кесәсендә һәрвакыт таш иде, теге яки бу язучыга томырырга гына торды. Иң бәйләнгән язучысы, революциядән соң бездән китеп Төркиядә яшәүче Гаяз Исхакый булды. Һай, сүкте дә инде эмигрант язучыны, каһәрләде, хурлады, ярый әле аның сүзләрен әдип үзе ишетмәде, белмәде. Хәтта шуңа барып җитте ки: төннәр буе утырып Г. Исхакый шәхесен пычратырга омтылып кандидатлык диссертациясе дә әмәлләде, әмма аны яклый алмады, чөнки язманың фәнни кыйммәте юк дип табылды. Моңа бик исе китмәде, чөнки Толбаевта башкаларга тәтемәгән хокуклар ансыз да җитәрлек иде ул елларда. Шул хокуклар аны Тилебайга әйләндерде дә инде.

Көннәрдән бер көнне язучы һәм галим Нәкый Исәнбәткә, аның олы хезмәтләрен искә алып, академик исеме бирү мәсьәләсе күтәрелә. Билгеле, үтенеч белән Мәскәүгә барып тезләнгәнче, башта Толбаев хозурына килеп басасың — тәртибе шул. Башлап йөрүчеләр шулай эшлиләр дә. «Нинди академик тагын?! — дип акыра Толбаев. — Академиклар Мәскәү кулында, кирәксә, шуннан чакырып китерегез». Ул бу минутларда үзенең диссертациясен исенә төшерде. Кабинетына кайбер галимнәрне җыеп, әсәрен тикшертүгә сарыф иткән вакытын кызганды, гарьләнде, бүген шуның үчен чыгаруы иде. Сталин лагерьларында җәфа чигеп кайткан Хәсән Туфан өчен фатир юллап килүчеләргә, иң элек сез аның кайда булганлыгын исенә төшерегез, дип кенә җибәрә. Җыелышларда үз фикерен ярып салучы Әмирхан Еникины бунтарьлыкта, фиркасезлектә гаепли. Җене сөймәгән тагын бер язучысы бар иде Толбаевның — Нәби Дәүли. «Кабан күле саега, Болак сасып ята, табигатьне корытабыз, чарасын күрергә кирәк! Читләрдән оят», — дип, Толбайның канына тоз сала торган иде Нәби ага. Аңа да җавап кыска: бу сиңа Германия түгел, кайдан кайтуыңны бик яхшы беләбез, янәсе... Яшьлеге белән абайламыйча, кызып китеп, әче сатирик хикәя язып бастырган Батулла чак-чак кына тимер рәшәткә артына кереп утырмый калды, заманасы-ние үзгәребрәк китте, өлгермәделәр.

Кыланышлары кырга сыймады Толбаевның. Соңыннан инде, эштән куылгач, әдипкә бер бүлмә кызганган әлеге тиранның уналты районда унҗиде дачасын, сигез мунчасын, берничә урында сунарчылык тыюлы-

гын, колхозлар хисабына тотылган умарталыкларын санадылар, милләттәшләренә карата эшләгән этлекләрен белделәр.

Әмма без бүген Толбаевка озаклап туктарга җыенмыйбыз, башкисәр улының акыл ирешмәслек мажараларын да тәфсилләп тормабыздыр. Хәзер сүз Тилебай-җитәкченең юлбарыс тырнаклы Назыйм Яраганов дигән койрыгы һәм кешеләргә бинигһая бәла-казалар китергән, шулай да вакытында тиешле җәзасын тапмаган Илмир хакында барачак. Бүген кешеләр ул агулы ерганакларның юлын кумәргә, саф сулы яңа чыганак эзләп табарга тиешләр.

* * *

Гомере буе зиннәтле зур бүлмәгә, дәрәҗәле урынга кызыгып яшәде Назыйм Яраганов. Хәер, ул аларга тиенде дә. Соңгы бүлмәсенең затлылыгын гына күр син! Икенче катның буеннан-буена сузылган биек зал, иркен дә, якты да, бөтен стенасы аксыл-сары сафьян белән тышланган. Урындык-кәнәфи тышчалары да шул ук төстә. Баш очында җидешәр утлы җиде яктырткыч балкый. Арка якта — чәй бүлмәсе, тагын да арырак — ялныкы! Юк, шәһәр Советында эшләгәндә Назыйм Яраганов боларны күрмәде.

Назыйм юлбарыс тырнагы тагылган алтын чылбырны бармагына урап уйнады. Уйлары исә, еракта калган Һиндстанны гизде. Тагын бер әйләнәсе иде шул якларны!

Мәскәү түрәләре, кайбер шәһәр мэрларын җыеп, алдынгы тәҗрибәне өйрәнү өчен, аларны Һиндстанга җибәрергә ниятлиләр. Казаннан кеше сорагач, Толбаев шунда ук үзенең яраткан шәригы Яраганов фамилиясен атый, алай гына да түгел, аны сәяхәтчеләрнең җитәкчесе итеп билгеләтә. Һиндстанның күп шәһәрләрендә булдылар алар. Назыйм шәһәр Советы хисабыннан бихисап бүләк-сувенирлар алып барган иде, тукталган һәрбер шәһәр саен шуларны өләшеп йөрде. Бомбей шәһәре мэрының хатыны Советлар иленнән килгән яшь, чибәр егет бүләк иткән чигүле татар читеген аеруча ошатты һәм, җавап рәвешендә, үзенең муеныннан шушы юлбарыс тырнагыннан эшләнгән амулетны салып бирде. Гади генә талисман түгел икән ул, икенче көнне шул хакта шәһәр газеталары шау килде. Язуларына караганда, Һиндстанның чытырманлы бер өлкәсендә кеше ашаучы бик зур юлбарыс яшәгән, күп кешеләрнең башына җиткән ул, исәннәргә әйтеп бетергесез курку салган. Ниһаять, юлбарысны атарга мәҗбүр булалар, халык иркен сулыш ала. Ерткычның тешләреннән, тырнакларыннан исә сувенирлар ясап саталар. Бер тырнагы Бомбей шәһәре мэры хатынына бүләк итеп бирелә. Бәясе — Американың йөз мең долларыннан да кыйммәтрәк, чөнки тырнакка һиндлеләрнең эпосыннан берничә шигырь күчереп язылган. Дөньяда тиңе юк бу амулетның!

Уйнады-уйнады да бүлмә хуҗасы бөти-амулетны үз муенына киеп карады. Килешә икән болай килешүен, тик республика күләмендәге җитәкче кешегә ярап бетмәс шул, партия бюросына чакыртып шелтә чәпәп куюлары да ихтимал. Элек яраган. Бөти кешене хәвеф-хәтәрдән саклаган, яу чыкканда җиңү китергән.

Шулай икән, димәк ки, талисманның урыны да түрдә, өстәл башында, хуҗасының күз алдында булырга тиеш. Алтын чылбырны Назыйм каршысындагы алтын каләмле кытай ручкасына — монысы кытайлылар бүләге — чорнап та куйды. Әйдә, җиткер әмереңне, юлбарыс тырнагы!

* * *

Изгеләр әмеренең сәгате-минуты белән ирешүенә ышанасыгыз киләме? Рәхим итегез! Ишектә алсу яңаклы, кара керфекле, яшел күз кабаклы, шәмәхә чәчле, көмеш тырнаклы, нечкә сыйраклы секретарь кыз күренде.

— Назыйм Тәлгатович, сезгә бер капитан ыргыла.
— Йомышы ни?
— Шәхси йомыш, ди.

Назыйм кызга текәлде. Тегесе көтә бирде. Башка чак булса, ник керүләрен ачыклап бетермичә, бусагадан атларга рөхсәт тә итмәс иде бу чәлән кызыена. Ярар, яңа вакыты, өлгерер әле анысына да. Нишләп шул тиклем нечкә икән соң моның аяклары? Кая бармакчы, ни кылмакчы бу киртә таяклары белән? Кем алган аны монда эшкә? Сүрияне кара — Толбаевның секретаре, шушындый чәлән идеме соң?! Тутырган тавык күк йөрде ич. Әгәр авыл малайларының каз көтә торган таякларына охшаган булсамы, Толбаев түгел, Брежнев үзе кушса да өйләнмәячәк иде Ярагaнов ул Сүриягә. Бала китермәсә дә, кеше арасына ияртеп чыгарлык чибәрлеге бар. Икесе тиң врачка күренделәр, резус-фактор дигәннәре дә туры килә югыйсә, ә бала юк. Садыйков дигән профессор турысын әйтте: «Аппарат ватылган шул монда, юкка өметләнмәгез», — диде. Ә менә шушы таяк сыйрак итәк тутырып бала үстерер әле, әгәр моннан вакытында китсә...

— Мин көтәм, Назыйм Тәлгатович.

Ярагaнов рөхсәтен белдереп баш какты. Артыннан кызны кызганып карап калды.

Милиция капитаны керә-керешкә кулын күкрәгенә куеп, бөгелә-сыгыла Ярагaнов өстәленә таба якынлашты. Кара, кешеләрдән чын маймыл ясап бетергәнбез икән инде. Синең белән үзен горур тотып сөйләшерлек бер генә адәм дә калмады, ахрысы. Бу да бирергә түгел, сорарга кергән, билгеле.

— Утырыгыз, — диде хуҗа, керүчегә тәрәзә буеннан урын күрсәтеп. — Мөмкин кадәр кыска тотыгыз.

Милиция капитаны Сатлыганов — фамилиясе шулай икән — үзенең авыру хатыны, ике баласы, университетның кечкенә бүлегендә укуы һәм бик начар шартларда яшәве турында сөйләде.

— Сез дөрес кермәгәнсез, капитан, — дип бүлде аны, ниһаять, Ярагaнов. — Мин бит хәзер Советлардан киттем. Партия җитәкчесе, бурычлар бөтенләй башка, аңлыйсыздыр.

Сатлыганов, йөгереп килеп диярлек, Ярагaнов алдына, келәмгә тезләнде.

— Барысын да белеп кердем. Зинһар куып чыгармагыз, Назыйм Тәлгатович... «Берәр мәсьәлә килеп чыкса, туры үземә керегез», — дигән идегез ич. Хәтерлисезме, узган җәй Вахитов мәйданында шоферыгыз бер шәхси машинаны бәрдергән иде. Беркетмәне, күз алдыгызда ук, үз кулларым белән ертып ташладым. Наратлыктагы дачагыздан кайтуыгыз иде, исегездәме? Үзегез вәгъдә иткәнгә...

— Ярар-ярар, тор, капитан кешегә һич тә килешми!

— Башка чарам калмады, алачыгыбыз сиксән сигез тераүле, — дип дәвам итте Сатлыганов. — Алдадылар, миңа бирәсе фатирны икенче берәүгә төрттеләр. Берсенә дә ышанмыйм хәзер. Инде менә, гафу итегез, иң зур кешегә, кем әйтмешли, юлбарысның үзе янына керүем.

Хикмәти хода, угын кыек атып, туры тидерде.

— Моны әйтәсезме?! — диде бүлмә хуҗасы, бөтигә ымлап, Сатлыгановнсүзләреннән бинииhая hушланып. — Башка җирдә күрә алмассыз сез аны!

— И һәм, юк та, — дип эләктереп алды капитан.

Ахырда һәммәсе дә Сатлыганов теләгәнчә килеп чыкты. Аңа фатир вәгъдә иттеләр. Әмма Ярагaнов хәерчесен болай ансат кына чыгарып җибәрергә ашыкмады. Үзе генә белми йөргән, күп икән Сатлыгановның бу фани дөньяда гаепләре: яшьләр үзара сугышып йөриләр, ял паркының рәте киткән, хулиган студентны митинг ясап күмгәннәр, чуалышлар, гайбәт күбәйгән, җәмһүрият җитәкчеләренең дәрәҗәсен төшерәләр. Барысына да милиция, шул җөмләдән, Сатлыганов гаепле икән...

— Без гаепле, мең кат без гаепле,— дип тәкърарлады капитан.— Төзәлербез, и һәм, кирәк икән, утка-суга керербез.— Бераз уйлап торды да әйтеп куйды: — Бәлки, дачагызда берәр нәрсә табылыр, Назыйм Тәлгатович. Балта эшенә кул ябышып тора минем.

— Дәүләт эше белән шәхси мәнфәгатьләрне бутамыйк, Сатлыганов. Кичке якта бик мөһим әмер җиткерелер үзегезгә!

* * *

Толбаев үзе күп сөйләшеп торучылардан түгел. Кисә дә куя. Ачуы кабарган чакларда тукмак кадәрле йодрыгын уйнатып алырга да күп сорамый. Ә үзе бердәнбер малаен тәртә арасына кертә алмый җәфалана, чөнки тегесе йөгәннән бөтенләй ычкынган.

— Кем идең, кем булдың?— дип сорау куйды ул бүген Яраганов алдына.— Һәм кем аркасында?

— Билгеле инде...

— Дәшмә, ичмасам, шул малайга күз-колак та була алмагач, ник асрыйм мин сине. Сүрия әрәм сиңа, валлаһи. Ә комсомолда күпме өстерәлеп йөрдең, шул студентлар белән уртак тел таба белмисең. Булдыра алмыйсың икән, башкаларны куш. Аннары ул картлар тагын, трамвайчы кыз... Син бар килеш, башкага кушыйммы? Әнә кая үрелдең бит, кайберәүләрнең төшенә дә керми торган дәрәҗә, берәү булса, чәче белән җир себерер иде. Әҗәтеңне тиешенчә түли белергә кирәк. Булдыра алмыйсың икән, бигайбә, иртәгә үк йомшак җиреңә тибәчәкмен. Иң элек Сүриягә шалтыратып әйтәм әле, белеп торсын, тарасын мамыгыңны бераз.

— Тарадыгыз ич инде.

— Алайса, күз алдымнан югал!

Лифт ишегенә җиткәч, уйланып торды Назыйм. Әйе, Толбаев үстерде аны, хак әйтә. Институтта үз янында аспирантурада калдырды, аннары партком секретаре булып сайлангач, Назыймны комсомол комитетына тәкъдим итте. Өч ай дигәндә икесе дә партиянең шәһәр комитетына барып кунакладылар. Шуннан китте дә китте. Болары өчен рәхмәт аңа. Ә нигә ул һаман Сүрияне китереп кыстыра соң әле? Имеш, аңа да, миңа да ярдәм иткән. Кешеләрне үстерүенә үкенә ахрысы Толбаев.

Сүрия Мөслим районында гади пешекче кыз була. Толбаев районга килгәч, гадәттәгечә, зур табын әзерләнә, аш-су чыгаруны, билгеле инде, иң чибәр кызга йөклиләр. Ояла-ояла гына ризык ташып йөри Сүрия, куллары-кулга йокмый, хәрәкәтләре җитез, күзләре очкын чәчеп тора, үзе яшь, сөйкемле, әйе, егылып китәрлек сылу. Бераз кыза төшкәч, Толбаев әйтеп куя:

— Бу кызның урыны — шәһәрдә!

Бер атнадан соң Сүрия Казанга килеп урнаша. Фатирлы да була. Кыскартылган программа белән укып, өч елда педагогия институтының биология факультетын тәмамлый. Имтиханнарын еш кына институт ректоры Туишев кабинетында кабул итәләр. Сүрия Толбаев белән Туишевка лимонлы чәй ясап кертә, аларга елмаю бүләк итә. Институт тәмамлагач та кыз барыбер үз эшен ташламады, рөхсәт итмәделәр. Сүрия, чыннан да, бер кашык су белән йотарлык кыз иде. Йомры гәүдә, лампа куыгыдай балтыры, озын керфекләре күзләренең серле карашы әсир итә. Назыйм беренче күрүдә үк гашыйк булды үзенә, юк-бар сәбәп табып, Толбаев тирәсендә бөтерелде. Хуҗа моны сизми калмады,' билгеле. Тора-бара кызны үзе үк димләде аңа. Тик... ярый әле башка бер юанычы — балдызы Ләлә бар дөньяда.

Студентлар мәсьәләсенә килгәндә, Толбаевның улы кемнәр беләндер тәпәләшкән. Шул көнне студентларның берсен трамвай астына этеп керткәннәр. Трамвай йөртүче кыз танып калган, имеш. Ә өченче көн тегe

студентны демонстрация ясап күмделәр. Бөтен шәһәр аякка басты. Җеп-нең очын Толбаев малаена китереп бәйләмәкчеләр. Һәлак булган егетнең әти-әниләре республика прокуратурасына барганнар, үтерүчене табып бирүләрен таләп иткәннәр.

Улларының өчесен уздырып, рухына Коръән багышлаткан кичтә, әкрен генә ишек шакыйлар. Ике егет килеп керә.

— Абзый кеше, сез теләсә ни сөйләп йөрисез икән, ташлагыз ул гадәтегезне. Улыгыз юк бит инде — аны барыбер терелтә алмассыз,— ди боларның берсе.

— Сез кемнәр? — дип кызыксына бичара ата.

— Безнең кемлекне беләсегез килсә, әнә, житкән кызыгыз бар, аны саклагыз! Чат саен теләсә нәрсә лыгырдап йөрмәгез, милиция, прокуратура юлын онытыгыз! Без кисәттек: кызыгыз турында уйлагыз!..

Милиция, врач белешмәләрендә язылганча, «уңышсызлыкка юлыгып, фаҗигале рәвештә һәлак булган студент эше» шуның белән туктатыла. Трамвай йөртүче кыз да берни күрмәгән, беркемне танып калмаган икән. Ул хәтта килгән журналистлар белән дә сөйләшергә теләмәгән.

Әмма Толбаев улының этлекләре кимеми. Үзенә кисәтү ясаган өчен, беркөн ул институт ректорына барып керә дә өстәленә пычак китереп кадый. Ректор, йөрәге туктап, егыла һәм шуннан мантымыйча дөнья куя. Толбаевка хәлнең кискенлеген аңлаталар. Вакыйга Толбаев малаен Сарытау университетына күчерү белән тәмамлана.

* * *

Ул чаклардан бирле Иделдә жиде тапкыр су ташыды, җиһанга жиде яз, жиде көз килеп китте, сигезенче көз исә, шактый соңарды. Беренче кар да Яңа ел алдыннан гына күренде.

Сәвия тунын киеп маташмады, иненә генә салды, аягына читек урынына тапочка эләктерде. Нәрсә, телефон-автомат урамның каршы ягында гына ич. Дус кызын чакырыр да керер, ул арада туңып үлмәс әле. Урамдагы аппарат бик начар эшли иде. Сәвия кат-кат кычкырып сөйләште.

— Гөлсем, мин әле бу — Сәвия...— Гөлсем!

Ул арада телефон будкасына кайры тунлы, озын буйлы, чибәр генә бер егет килеп сөялде. Сәвия аңа әллә ни әһәмият биреп тормады, рәхәтләнеп сөйләште. Ниһаять:

— Кил яме, көтәбез! — диде дә трубкасын элеп куйды.

— Исәнмесез! Менә кызык,— дип сүз катты чибәр егет.— Гөлсем кемнәргә килә инде, болай булгач: сезгәме, әллә безгәме? Мин бит аны каршы алырга чыктым, менә кабат шалтыратыйм, дигән идем. Безнең иртәдән үк сөйләшенгән, башкалар җыелып бетте, Гөлсемне генә көтәбез. Димәк, сез дә безгә керәсез, әнә теге йортка, тулай торак янындагы. Танышн булыйк — исемем Илмир.

Сәвия үзенең киенмәвен, халаттан булуын, менә тун бөркәнеп, тапочкадан гына чыгуын, шактый туңуын, өенә керергә ашыгуын әйтте. Илмир үзенең чәшке бүреген Сәвия башына батырды, култыгыннан алып, өстери үк башлады. Кыз карышты, егет өстерәде. Кулын җайсызрак борганга, авыртуына түзә алмыйча атларга мәҗбүр иде Сәвия. Кычкырыр иде: кичке сигезенче яртыда ник сөрән сала бу юләр, диярләр тагын.

Подъездга кергәч, Сәвия бөтенләй үҗәтләнде. Өстемдә киемем юк — бетте-китте. Алайса, Гөлсем, килгәнче генә кереп торырга димләде Илмир, кунакларның таралып бетүләре ихтимал икәнен әйтеп карады, кыз күнмәде. Ул арада өске каттан көчек иярткән бер хатынның төшеп килүе күренде. Егет Сәвияне почмакка ыграк кысты, аваз салырга ирек бирмәде. Хатын туктап, карап-карап торды да төкереп китеп барды.

Алар өченче катка чаклы менделәр, фатир ишеген ачып, егет кызны эчкә этәрде, аннары ишекне бикләп тә куйды.

— Шикләнмә, бездә беркем дә юк! — диде.

Йорт хуҗасы кунакның тунын көчләп салдырды, аны шифоньер эченә томырды, ә кофтасын кәнәфигә ыргытты.

Чыннан да, өйдә беркем юк икән, бернинди дуслары җыелмаган, Илмир Гөлсемне бөтенләй белми булып чыкты. Имештер, Сәвияне күргәч һуштан язган, әгәр ошатса, гомергә шушында яшәп калыр.

— Бу нинди бала караваты соң? — дип кызыксынды Сәвия.

— Кызымның истәлеге итеп саклыйм. Нарасыемны явыз хатын үзе белән алып качты. Шикләнмә, чишен, әйдә!

Сәвия ризалашмагач, Илмир, аның иңнәреннән тотып, урындыкка сылады, өчкә кадәр санаганчы чишенергә боерды. Кыз күз яшьләре белән җавап кайтарды. «Алайса, мин сине шушында хәл итәм, безгә кергәнеңне беркем күрмәде», — дип, Илмир Сәвияне караватына сугып екты...

Ерткыч җанвар кызны көчләп кенә калмады, садистларча кыланды. Сәвия һуштан язды. Хатын аңына килгәндә, теге бәдрәф ягында иде. Караватт шыгырдауга ук, Илмир кире борылды, ыжгырып Сәвия өстенә килә башлады, ләкин аның елмаюын күреп, туктап калды.

— Син нәрсә, бар инде, яхшылап юын, — дигән булды Сәвия.

Ниһаять, җиңгәнлегенә тәмам инанып, Илмир бәдрәф ишеген ябып ук куйды. Нәрсәдән шикләнәсең ишек бикле, ачкыч үзе белән ич аның.

Сәвия бая ук шәйләде: балкон ишеге бераз ачык тора. Бердәнбер котылу урыны шул. Халатын гына эләктерде дә балконга чыкты. Түбән карады, йөрәге жу итеп китте, караңгыда өченче кат артык биек тоелды. Исән калган тәкъдирдә дә гомерлек имгәк булачак. Кызын исенә төшерде. Нишләргә икән соң? Менә-менә теге бандитның чыгып җитүе ихтимал, ни әмәл кылырга? Балкон баганасына ябышып, Сәвия икенче катка төште, астагыларның тәрәзәсен шакыды, килүче, кертүче табылмады, өйдә юклар, ахрысы. Яланаяк килеш балкон кырыендагы ниндидер тимергә басты да су торбасына үрелде. Нәкъ шул чакта урамнан шаяра-көлә килүче өч пар күренде.

— Коткарыгыз, зинһар, коткарыгыз!

Егетләр-кызлар ук аткандай балкон турына килеп бастылар.

— Сикерегез, үзебез тотып калабыз! — диделәр.

* * *

Бу Илмир дигәне кем соң? Паспортыннан күренгәнчә, әнисе — Саркина Ләлә, әтисе — Саркин Барый, үзе Саркин Илмир була. Назыйм Тәлгатович Ярагановның бу «сарык бәрәненә» (авылда Барыйларның кушаматлары шундый) ни катнашы бар, дисезме? Хикмәт тә шунда шул! Бу сиңа Толбаевның азактан Иделдә җан тәслим кылган малае гына түгел. Сөйли китсәң, һай, озын бу тарих...

Ләлә сигезьеллык мәктәпне тәмамлап, авылдан Казанга килгәндә чандыр гына бер кызчык иде. Укырга һәвәслеге бик үк ташып тормаганга, апасының элеккеге һөнәре кулай булыр, үзе дә тазарып китәр, дип, аны шәһәрнең унынчы һөнәр училищесына пешекчелеккә укырга керттеләр. Билгеле инде, партия хезмәткәрләренә махсус салынган йортның ындыр табагы кадәрле өч бүлмәсендә икәү генә яшәгән Сүриянең бертуган сеңелесен тулай торакка чыгарып җибәрәселәре килмәде — кыз һөнәр алгач та, Ярагановларда яшәп калды.

Шәһәр тормышына тиз күнекте Ләлә. Чибәрлектә исә апасыннан да уздырган иде ул. Баштарак Назыйм аны, балага санап иркәләде. Сүриясе һаман да бала тапмый, Ләлә әнә шул бушлыкны тутыра сыман иде. Ай, шулай булып кына калса икән ул! Ләлә багалмасы булып җитеште. Теленә дә шайтан төкергән диярсең: «Җизни, күңелем синнән бизми»,

«Жизни үзебезнеке!» — дип, янбашы белән суктыра да китә, төртә дә уза, үзе башын артка борып, озын чәчләрен җилфердәтеп, энҗе тешләрен балкытып елмая. Сөйкемле, бик тә сөйкемле кыз Ләлә. Эштә, аш-суга дигәндә — аңа тиңнәр юктыр. Назыйм балдызы пешергән ашларны мактап туя алмый.

Дус-ишләре арасында оятсызрак шаяртулар да ычкындыргалый башлады: «Балдыз — ул җизнәкәйнең башланмаган кибәне», «Балдызның уң боты — җизнәкәйнеке, дигән китап...» Ләлә мондый шаяртуларга да тиз күнекте, чибәр, житәкче җизнәсенең мактавы ошый иде аңа. Апасы ял йортына киткән чакларда аеруча рәхәтләнеп шаярыштылар. Янынннан узып барганда йомшак җиренә җизнәсенең шапылдатып китүләрен дә кабул итә иде инде кыз.

Бервакыт шулай, Сүрия чираттагы ялга киткәч, алар икәү генә дачада яшәделәр. Тәүге кичтә үк, рәхмәт төшкере тычкан, эшне көйләде дә куйды. Йортның икенче катында йокларга яткан Ләлә, үрсәләнеп, аваз салмасынмы:

— Җизни, тычкан кыштырдый, мин куркам.

— Төш, алайса.

Башта бер караватта икесенә ике юрган иде, аннары берәү генә калды...

Озакламады, Ләлә үзе белән мәктәптә бер сыйныфта укыган Барый дигән егеткә кияүгә дә чыкты, дөресрәге, кияү үзе Казанга күчеп килде. Компрессор заводына слесарь итеп эшкә урнаштырдылар. Тимер-томыр арасында чыныгып үскән механизаторга бу һөнәр күптән таныш иде, тиз алдырды. Ярағанов сөекле балдызы өчен җәһәт кенә ике бүлмәле фатир юллады. Аннары, әллә житлегеп, әллә бераз гына ашыгып шунда өйләрендә сабый елаган тавыш ишетелде, Ләлә ике гаиләгә бер малай алып кайтты. Илмир менә шул чәрелдек була инде. Саркинның үзенә караганда бажасы яратарак төшә әлеге курчакны, аның белән рәхәтләнеп уйнады, үчти-үчти иттерде, сөйде, иркәләде.

Шуңа да бик иркә, тотнаксыз, тәртипсез булып үсте Илмир. Мәктәптә чакта ук әллә ниләр эшләп бетерде. Сигезенчедә укыганда классташына ияреп кайта да сабакташының үзеннән алты яшькә өлкәнрәк апасына ябыша. Икенче мәртәбә үзе белән бер ишек алдында яшәүче студент кызга ташлана, аны бәреп ега, җирдә аунатa, киемнәрен ертa. Хәзер үк әти-әнисен янына керәм дигәч кенә, ычкындыра тегене. Болары әле өйрәнең өсте генә, куерагы төптәрәк.

«...район эчке эшләр бүлеге. Беркетмә — 552. 1 сентябрь, 19... ел. Җинаять эше № 6554.

20.00 сәгатьтә М. Горький исемендәге ял паркында гр. И. Саркин тоткарланды. Ул, исерек килеш, гражданка Т. Петрованы көчләүдә гаепләнә».

Тикшерү башлана. Шаһит буларак Петрованың иптәш кызлары чакыртыла, алардан күргән-белгәннәре турында белешмә яздырып алына. Суд-медицина тикшерүе кызның чыннан да зыян күрүен раслый. Димәк, тимер рәшәткәнең ишегеи ачар чак килеп житкән. Монда инде Ярагановсыз бернәрсә дә барып чыкмаячак. Ләлә Саркина ашыгыч рәвештә командировкадагы җизнәсенә телеграмма җибәрә. Тегесе ике сәгать дигәндә әйләнеп тә кайта, йоклаганнарын уяттыра, утырганнарын аягүрә бастыра. Район эчке эшләр бүлегендә дә, Ярағанов кабинетында да ыгы-зыгы башлана. Петроваларның иске йортның бер бүлмәсендә чиләнүләре, пенсиядәге карчык акчасына көн күрүләре ачыклана.

Икенче көнне инде район эчке эшләр бүлегенә Петровадан яңа гариза алына. Ул беренче гаризасын артык дулкынланудан, йөрәге кубудан, ашыгычлык белән язып ташлаган икән. Саркин Илмирга карата бернинди ачу тотмый, җинаять эшен туктатуны үтенә. Атна ахырында Петровалар уныччы кварталдагы яңа төзелеп беткән йортка күчеп китәләр. Фатир эче яңа җиһаз белән тула.

Шуннан соң Илмирны Барый Саркин түгел, юлбарыс тырнаклы Яраганов үз кулына ала, аңа нукта урынына тимер авызлыклы йөгән кигезә. Йөгән дигәнебез — югары белемле ике репетитор, шуларның берсе — фән кандидаты, белем бирүчеләр, акылга утыргучылар, Яраганов Яраганов ... вның йөзәрлекләрен ай саен каерып баручылар. Әлеге ике кеше бу авыр йөкне телләрен салындырып ике ел буе тартып бардылар. Тик тирләп-пешеп тарткан арбалары гына буш булып чыкты, институтның өченче курсына життем дигәндә, дәресләргә йөрмәве, тапшырылмаган имтиханнары күбәеп китүе сәбәпле, студент Саркинны институттан чыгаралар. «Юлбарыс тырнагы» өчен бердәнбер чара кала — Илмирны хәрби хезмәткә озату, ләкин еракка түгел, Биектау районына гына, нибары бер елга. Аның каравы, кайткач, Илмирны институтның кичке бүлегенә, дүртенче курска кабул итәләр. Күрәсез, югары уку йортыннан вакытлыча куылуның файдалы яклары да бар икән. Күчерү турындагы приказга берьюлы өч кеше кул куя: факультетның деканы профессор Б. Сундуков, партбюро секретаре В. Галиуллин, профком рәисе С. Баһабиев. Бәйләнеп кара син шуннан соң?!

Илмир комсомол эшенә җибәреләә, җизнәсе Яраганов юлыннан китә. Өлкәннәр үрнәгендә ул анда бик тиз өстәл төяргә, тамак ярып акырырга, хәтта чаманы белештермичә сүгенергә өйрәнә. Заманы шул, урыны шул. «Яшьләр белән эшләү алымнарын камилләштерү» буенча семинарлар, табигать кочагында бергәләп ял итүләр оештырып, атналар буе юкка чыгып тора хәзер Илмир. Көтеп-көтеп тә күренмәгәч, Гөлфиясе, кечкенә кызын кочаклап, тагын җизнәләренә йөгерә. Җиңелчә генә шау-шу булып ала. Моңа тәмам күнегеп җиткән Гөлфия дә үз көнен үзе күрә башлый. Хәйран гына күңелле шөгыль икән ул үз көнеңне үзең күрү...

* * *

Сәвия үз фатирында гына күзен ачты, аңына килде. Сеңелесе Зифа һәм дус кызы Гөлсем ни уйларга да белми утыралар иде. «Әнием кая?» — дип кызы да аптырап бетергән.

— Болай гына калдырырга ярамый бу эшне,— дип, Гөлсем милициягә хәбәр итте.

Өч минут дигәндә, Теләшеваларга җинаять эшләре буенча оператив бүлек хезмәткәрләре Исламов белән Гармунов килеп тә җиттеләр. Алар Сәвияне үзләре белән милициягә барырга чакырдылар. Юл уңаеннан Илмирларга кагылдылар, ләкин җинаятьче өйдән чыгып киткән иде. Сәвия ни дә булса язар хәлдә түгел иде әле, ул сөйләгәннәрне Исламов язып барды, ахырдан сөйләүченең үзеннән кул куйдырды, тәртибе шул. Зыян күрүче үз кулы белән язып бирсә яхшырак, әлбәттә. Еш кына алай килеп чыкмый шул. Ә кул куйдырыла.

— Җитди эш,— диде Исламов, милиция дежурныена.

Республика прокуратурасында майор Сатлыганов дежурлык итә икән, ул да бик тиз килеп җитте. Әнә кая үрмәләгән, инде бер зур йолдызны эләктерергә дә өлгергән безнең таныш. Кыскача кайда, кем белән ни булганын сорашты да:

— Менә бу өстәлгә утырыгыз, барысын да бәйнә-бәйнә языгыз,— диде майор Сәвия Теләшевага.— Ә сез ул егетнең фамилиясен хәтерләмисезме?

— Ачыкладык, Илмир Саркин,— диде Исламов.

— Ә сез, егетләр, комачауламагыз, бүлмәдән чыгып торыгыз.

Теләшев белән озак кына сөйләшкәннән соң, ике инспекторга машинасын биреп, җинаятьченең төнлә дежурлык итүче хатынын, ягъни Гөлфия Саркинаны алып килергә җибәрде.

Майор Сатлыганов холыксызланды, ишекле-түрле йөренде, туктаусыз тәмәке пошкыртты, Теләшеваны әллә нинди сораулар белән тин-

терәтте. Аннары ул милиция дежурные янына чыкты, кемгәдер шалтыратырга тотынды. Телефон трубкасын учы белән томалап, дежурныйдан татарча аңлыйсыңмы, дип сорады. Тегесе, әйдә, сөйләшә бир, дигәнне аңлатты.

— Мин әле бу, Сатлыганов,— диде майор телефоннан.— Көчләү. И һәм, бозыклык юлы белән эшләнгән... Илмир Саркиннан шикләнәләр. Хәзер хатынын алып киләләр. Нишләргә кушасыз?

Сатлыганов мәсьәләнең шактый четерекле булуын, куллан килгәннең барысын да эшләргә тырышачагын әйтте. Соңыннан:

— Яхшы кеше баласы,— диде ул дежурныйга.

«Юкәдә икән чикләвек!» — дип уйлап куйды дежур милиционер. Ләкин бу инде аның эше түгел — әнә, тикшерүче, прокурор үзе шөгыльләнсен...

Гөлфияне дежурлыктан вакытлыча гына җибәрделәр. Ике оперативник белән кайтып кергәндә Илмиры өйдә юк иде, кызы әниләрендә, хатын көндез үзе илтеп куйды. Диванда целлофан пакетка салынган сары кофта, шефоньер эчендә ясалма тиредән теккән тун аунап ята. Идәндә йомшак тапочка, оекбашлар, хатын-кызның эчке киеме.

— Болар берсе дә минеке түгел,— диде Гөлфия.

— Үзе кайда икән соң?

— Әйтә алмыйм.— Яшь, чибәр хатын көрсенеп куйды.— Аның беренче эше генә түгел инде, җайлый, котыла килә. Хәзер сез мине кире эшемә илтеп куегыз инде, авыруларны ялгыз калдыра алмыйм,— диде Гөлфия, бу хәлләргә артык исе китмичә.— Ә әйберләрне үзегез белән алыгыз, безгә кирәкми алар.

— Әлегә ярамый, рөхсәт юк.

Сәвия прокурор өчен алты битле гариза язды, бер генә детальне дә төшереп калдырмаска тырышты. Шулай да Сатлыганов аны иртәнге сәгать бишкә чаклы тинтерәтте.·Гаризасын кире алырга кыстады, җинаять эше кузгатмавын үтенде, кешелекле булырга чакырды.

— Бәлки мохтаҗлыгыгыз бардыр?

— Сез ни турында? — дип сорады Сәвия.

— Зыян күрүче буларак дим. И һәм, матди ярдәм, мәсәлән. Андый чакта акча кызганмыйлар. Кайберәүләргә иркенрәк фатир кирәк. Яшь гаилә кызганыч, бер селтәнү белән җимереп ташлавыгыз ихтимал. Шуны әйтмәкче идем. Йә, ни дисез? Бәлки төптән — җирдән уйлап карарсыз. Балагыз да бар. Тирәнгә җибәрүнең ахыры...

— Иптәш майор, сезне телефонга.

39 нчы кварталда мәет табылган, ашыгыч рәвештә шунда чакыралар икән. Сатлыганов, киткәндә, Исламов кулы белән язылган гариза-беркетмәне дә, соңгы алты битлесен дә үзе белән алды. Эш судка барып җиткәч, Сатлыганов, теге чакта зыян күрүче гариза язудан баш тартты, дип белдерәчәк. Кварталга барышлый юл уңаеннан машинасында Гөлсемне өенә кадәр озатып куйды. Юл буе сөйләнеп барды:

— Бер дә чынга охшамаган бу хәлләр, и һәм, тотынырлык нәрсә дә юк монда, һичкем күрмәгән, беркем ишетмәгән. Кешене ничек җәзага тартасың? Бәлкем Теләшевага сез аңлатырсыз, юкка чаң суга ул, и һәм, үзе генә ямьсез булып калачак. Болай әле уртак тел табулары да бик мөмкин.

— Нинди уртак тел?

— Зыян күрүчегә саллы гына итеп түләргә тиеш булалар. Монда акыл белән эш итәргә кирәктер, минемчә.

Ул арада шәһәр буенча телеграмма тапшырылды:

*«Казан шәһәренең... район эчке эшләр бүлеге тарафыннан җинаятьче Саркин Илмир Барый улы эзләнә, туган елы... яшәгән җире... эш урыны... Тотылган очракта кичекмәстән хәбәр итүегез сорала.*

*РОВД начальнигы, полковник И. Батыров, тапшырды — Нуров, кабул итте — Ә. Сәлимуллина».*

Иртәгесен Теләшеваның эчке киемнәрен экспертизага җибәрделәр. Сәвиянең үзен дә тикшерделәр, аның уч төбе, кул сырты һәм аяк табаны икенче дәрәҗәдә өшегәнлеге ачыкланды. Эчке киемнәрдән кан таплары табылды. Саркиннарның балкон турысында карда аяк эзләре калган. Җинаятьченең гаебе расланды дияргә дә була.

Әмма шуннан соң мажара башлана, кәгазь боткасы пешерелә. Сәвия Теләшевага шул тозсыз ботканы ашарга кушалар.

* * *

Милиция идарәсеннән кайтып кергән Сәвияне Илмирның апасы белән җизнәсе көтеп утыралар иде. Сүрия ханым балавыз сыгарга тотынды, начальник Яраганов гомерендә беренче мәртәбә иренен чәйнәп канатты. Аннары алар икәүләп Сәвиядән милициягә язган гаризасын кире алуын сорадылар, ялындылар, ялвардылар. Хуҗабикә ризалашмады.

— Илмирлардагы тун, тапочка чыннан да сезнекеме? — дип кызыксынды Сүрия.

— Минеке.

— Назыйм, бар, чап, әйберләрне хәзер үк алып кил.

Яраганов чыгып киткәч:

— Әйдә, матурым, иркенләп бер сөйләшик әле, — дип дәвам итте Сүрия. — Үзең дә әни кеше, ата-ана хәсрәтен аңлыйсыңдыр. Күреп сөйләшергә үзләре килә дә алмадылар, әниләре түшәк өстенә ауды, кара кайгыга төште, бик борчыла. Бердәнбер уллары бит, юкка гына харап булуы бар.

— Ник «юкка»? Үзе гаепле ич!

— Соң, аптырагач әйтәм инде, — диде Сүрия, әңгәмәдәшенең итәгенә бармак очларын тиереп. — Сабыйларын кызганам, кызлары синекеннән дә кечкенә, нибары өч яшьтә. Тагын ни бит, Илмир яшьләр арасында эшли башлады, нинди дәрәҗәсе калсын болайга киткәч.

— Әйтәм комсомол значогы таккан, уйлаган идем аны...

Сүрия торып басты, өй эчен әйләнеп чыкты, башын селкеде, чыраен сытты, ниндидер ят елмаю белән елмаеп куйды.

— Өйдәш торулары җиңел түгелдер сиңа да, — диде ул хуҗабикә хәленә кереп. — Бу ягыңны җайлау Яраганов өчен чүп тә тормый. Телисең икән, акча ал, күпме сорыйсың?

— Сез нәрсә, мин тән сатучымы әллә?

— «Ситуация» диләр моны, җан кисәгем. Биш мең азрак булмасмы? Җидене сора! Табарбыз!

— Әгәр мин сезне милициягә җиткерсәм.

— Нәрсә дип? — Монысын Сүрия кистереп, тавышын нык күтәреп әйтте. — Эшне бөтенләй ябып куюлары да бик ихтимал, шунысын онытып торам икән бит.

Ул арада тун, тапочкалар күтәреп Яраганов кайтып керде. «Булдымы?» — диде ул, тирләгән маңгаен сөртеп.

— Юк әле. Уйларга бирик! — дип хатыны китәргә ашыктырды.

Яраганновларның соңгы ышанычлары кодагый, ягъни Гөлфиянең әнисе иде.

— Ничек, җаный, Илмирны гафу иттеңме? — дип сорады кодагый.

— Җинаятьче җәзасын алырга тиеш. Гаризамны югалткан булганнар, икенчене яздым, бүтән тикшерүчегә, артык сикерә алмаслар, — диде Сәвия.

— Ай-һай, җаный, барып чыгармы икән? Яраганов бөтен республиканы уч төбендә биетә бит ул, «юлбарыс тырнагы» диләр аны.

— Чыгарырбыз, Мәскәүнең үзенә барып җитәрмен!

Шунда көтелмәгән хәл булып алды: кодагыйлары әллә нишләде, елап ук җибәрде.

— Әрләмә әле мине, җаный, сабыр ит,— дип башлады ул сүзен.— Алар гозерләгәнгә генә килгән идем, гафу кыл. Каптырсаң, җаный, чыкмас тишеккә дөмектер шул бәдбәхетне. Әти-әнисе, бигрәк тә Ярагановлар сине зур акчага сатып алмакчылар, бирешмә. Шул имансызның әшәкелекләреннән йөрәк авыруы алдым үзем дә. Баламны шул гына харап итте, шул бозып бетерде. Нибары ундүрт яшендә иде Гөлфиям, өйләнүен өйләнде үзенә, ә бозыклык юлы белән яши. Әйтергә телем әйләнми... әшәке җан! Төрмәнең түрендә черергә тиешле кеше ул, имансыз.

Сәвия бу кадәресен көтмәгән иде. Кызы өчен сызланучы әлеге хатынны ул чын күңеленнән кызганды, аңа теләктәшлек белдерде, тынычландырды.

Мажараның күңелсез сериясен заводта күрсәттеләр. Заводның партия комитетында Саркиннар исеменнән язылган гариза алынган икән. Анда КПСС әгъзасы С. Теләшеваның әхлаксызлыгы, кеше гаиләсен бозарга маташуы турында бик хәтәр сүзләр бар. Сәвиянең тәртибен тикшергән, аның кемлеген ачыклаган арада милиция идарәсендә Илмирның яхшылыкларын тасвирлаган белешмәләр туплана торды. Шуларның кайберләренә күз салыйк әле.

*«...Комсомол эшендә үзен яхшы оештыручы итеп күрсәтте. Һәрвакыт төгәл, тәртипле, башкару осталыгына ия.*

*Профессиональ-техник училище директоры урынбасары Х. Зәкиева».*

*«ВЛКСМ өлкә комитеты оештырган «Данко» зона комсомол мәктәбенә барды. Актив. Тыйнак. Гаиләсе үрнәк гаилә...*

*Характеристика партбюро утырышында расланды.*

*Партбюро секретаре А. Кудашев»*

Мондый кешене утка салырга, суда батырырга, төрмәгә ябарга ярыймы соң? Кирәк икән, кәгазьләрне, белешмәләрне тагын да өстәргә, күрсәтмә бирергә була, аларны тормышка ашыручы гына табылсын.

*«...шул ук вакытта Саркинның кыланышлары социаль-әхлак нормаларын бозу булып тора, чөнки ул өйләнгән кеше, хатыны, баласы бар. Коллективта тикшерергә тәкъдим ителә.*

*Прокурор Г. Сергин».*

КПСС райкомының оештыру-масса эше бүлеге мөдире Ш. Тахтиев телефонга үрелә.

— Сез нәрсә, Саркинны кулга алмакчы буласызмы әллә? Яшь коммунистны?

— Эшне кабул иттем генә, берни дә әйтә алмыйм,— ди яңа билгеләнгән тикшерүче Ламберов.

— Без аңа үзебез дисциплинар чара күрәчәкбез. Бу — «беренче» фикере, аның сүзләре. Шәт, аңлагансыздыр?..

Нәтиҗәдә өр-яңа кәгазь язылә:

«Гражданка С. Теләшеваны көчләү турындагы җинаять эше, РСФСР җинаять кодексының 208 статьясы, икенче пунктына таянып, тикшерү барышында тиешле дәлилләр табылмау сәбәпле, туктатыла.

Район прокуроры, беренче класслы юрист В. Испорчин».

Туктатылмый гына торсын әле! Хөкем эшен һәр очракта «Юлбарыс тырнагы», муеннарына алтын чылбыр ураган мөртәтләр генә хәл итми. Гадел хөкем сагында үз эшен яратучы, аны җиренә җиткереп башкаручы намуслы юристлар күбрәк. Газеталар язганча, Хатыйп Хәбибуллин — шундый юристларның берсе. Ул, хокукларыннан тулы файдаланып, «юлбарыс тырнагы» тирәсенә тупланган мафиягә каршы чыга, эшне туктату турындагы карарны яңадан ачыклауны таләп итә, аны тәҗрибәле тикшерүче кулына тапшыра.

* * *

Гөлфиягә үз көнен үзе күрү алай начар түгел иде, киресенчә, ул аңа шул чаклы ошап китте ки, эшкә барышлый-кайтышлый булсын, яки буш вакытларында дисеңме, берәрсе белән танышмаса, каны кызыша башлый. Шулай бер көнне аларга үзе белән бергә эшләүче шәфкать туташы Виолетта Садриева килеп чыкты. Тегене-моны сөйләшеп утырдылар, соңгы яңалыкларны уртаклаштылар. Ләкин икесенең дә әйтелеп бетмәгән яшерен серләре калды әле.

— Диләрә кайда соң?

— Ул авырып тора шул, тамагы шешкән, әниләргә илтеп куйдым үзен, әле дә ярый алар бар,— диде Гөлфия.— Берәр банка бал кертеп чыгарга кирәк балага...

Кая да булса ычкынырга күңеле җилкенеп тора иде Гөлфиянең. Ул көзге каршына килеп басты. Бизәнүнең соңгы модасын Казанда беренчеләрдән булып Гөлфия үзләштерә. Керфекләренә калын итеп сөрмә тарта, күз кабакларын яшелләтә, яңакларына алсу иннек сөртә, иреннәрен шәмәхәгә буйый. Киемне кыска кияргә ярата. Очлы үкчәле туфләдән чык-чык басып яныңнан бер узып китсә, муенның кыегаеп калуы да ихтимал.

Чатка чыгып басуга, яннарына «Жигули» килеп туктады, дөресрәге, аны Гөлфия туктатты.

— Чау! — дип сәламләде Гөлфия шоферны.— Безне алмассыз микән?

— Мондый чибәрләрнең аяк астында туфрак булырга риза!

Гөлфия шоферны шунда ук ошатты. Теле тегермәнне шәп тарта икән, бар шул егетләр дөньяда!

— Кая илтеп куйсам да югалтырмын төсле үзегезне, әллә машинада гына каласызмы, кызлар?!

— Аптекага! — диде Гөлфия.

Шофер, Гөлфия даруга кергән арада, сорашты һәм белде. Гөлфия — ирдә булса да, ирекле кош икән, егетләр белән танышу-дуслашудан беркайчан да баш тартмый. «Кармак салып карарга ярый моңа, чибәрлеге бар»,— дип фикер йөртте шофер егет.

— Кузгалдык,— диде Гөлфия, үзе эчен тотып, көләргә ябышты.— Моны кара,— диде ул Виолеттага кечкенә кәгазь пакеттагы боҗраны күрсәтеп.— Японнарныкы, ди. Берсен биш сумга төртте. Миңа кирәкми, сиңа булсын Виолетта. Ә хәзер шофер безне Подлужныйга илтеп куяр.

— Башта мине кертеп калдырырсыз инде.

— Эш — шоферда. Исемегез ничек соң сезнең, егет?

— Әнвәр. Эштә Әнвәр Газизович дип йөртәләр.

— Бик кызу егет икәнсең син, Әнвәрчик, сабыр ит бераз!

Күреп торасыз: казандагы сөт кайнап чыкты, ярмасы салынган, мае әзер — ботка пешәчәк! Виолеттаны өенә илтеп куйгач, Әнвәр Газизович кузгалырга ашыкмады, чөнки ул матур хатыннарны үз гомерендә күп очратты. Төп башына бер генә мәртәбә утырып калмаган, шуңа күрә, җиде кат үлчәп, бер тапкыр гына кисәргә ярата. Ачыктан-ачык сөйләшеп, аныклап бетермичә урыныннан кузгалмаячак. Аннары, бәлки, акчасын да алып тормас. «Аз гына ял» дигән булып, бер-ике дәртләндергеч мәзәк тә сөйләп ташлады. Ни өчен Әнвәр Газизович дип йөртүләренең серен ачты. Үзе завод профилакториенда теш технигы булып эшли икән. Ә болай, һөнәре буенча, авиация институтын тәмамлаган, моторлар төзүче конструктор. Инде менә кешеләрнең сәламәтлек сагына баскан — изге эш, төшеме дә әйбәт. Авызларын алтын белән тутырырга яратучылар аны олылап Әнвәр Газизович дип йөртәләр, ди. Хәзер моңа үзе дә күнегеп беткән. Яше егерме җидедә, ләкин өйләнмәгән, ялгыз башы ике бүлмәле фатирда яши.

— Күңелсез түгелме соң? Алдыйсыңдыр әле?..

— Ник алдыйм, килгәч күрерсең.

Әнвәр Газизович блокнот битенә язылган телефон номерын сузды, Гөлфия исемен әйтте, шалтыратырга вәгъдә бирде.

* * *

Тикшерделәр ни дә Илмирны, рәхмәт кәгазе язып тоттырдылар ни — аңа барыбер, мыегы да селкенми. Өч көн буе заводның спорт һәм ял лагеренда типтереп ятканнан соң гына шәһәргә илтеп куюларын сорады. «Маяк» рестораны турында машинадан төште.

— Ресторан ябыла,— дигәч кенә исәп-хисап ясатты Илмир.

Соң инде. Гөлфиясе җиденче төшен күрәдер, кара, өйдәме икән ул бүген? Кайсы сменада эшләргә тиеш бу атнада? Юк, хәтерләми. Йоклый бирсен!

— Әй, бер генә минутка! — Ул төнге сменадан кайтып баручы билгесез хатынның беләгеннән эләктереп алды.

— Җибәрегез! Каравыл, ярдәмгә!!!

Хатынны этеп җибәреп, Илмир теленә килгән бөтен әшәке сүзләрне тезде, икешәр-өчәр катлы итеп сүгенде. Ул арада янына ике егет һәм бер милиционер килеп тә җитте. Үзен район эчке эшләр бүлегенә алып киттеләр, акт төзеп, айныткычка кертеп салдылар. Иртәгесен суд булды, кичәге батырлыгы өчен илле сум «премия» билгеләделәр үзенә, җәһәт кенә илтеп түләргә туры килде.

Илмир ялгышты, Гөлфиясе һич тә төш күреп азапланмады, кичке чаралар турында көндездән үк кайгыртып куйган иде ул. Әүвәл телефоннан шалтыратты:

— Әнвәр Газизович кирәк иде! — диде.

— Мин бу. Кем сорый?

— Чау!

— Әһә, таныдым, Гөлфия матурым икән. Рәхмәт шалтыратуыңа!

— Алым син, гөлем син — көтеп алган малым син. Шалтыратуыңа өметем калмаган иде инде. Бүген күгемә кояш булып чыктың, сине кайларга гына алып барыйм икән?! — дип тезде Әнвәрчик. Гөлфия машинага кереп утыргач.

— Ераккарак!

Кибеткә туктап, коньягын да, очрашу хөрмәтенә шампан шәрабен дә алды, татар ашлары йортыннан пешкән тавык, өчпочмак ишеләрен дә төрдерде Әнвәрчик. «Монда да сугылыйк әле!» — дип, «Бүләкләр» кибетеннән кыйммәтле хушбуй алып чыкты.

Машина элдерде генә. Без аларның кайларга баруларын, кайсы урман аланлыкларына тукталуларын карап йөрмик әле, ни сөйләшкәннәрен дә тыңламыйк. Алты-җиде сәгать буе сөйләшмәгән сүз, кылмаган гамәл калмагандыр. Анысы — алар эше. Ниһаять:

— Уһу! — диде Гөлфия, сәгатенә күз салып.— Уникенче ярты булып килә, кайтырга вакыт.

— Миңамы, матурым?

— Кызым әниләрдә.

— Ә теге... кем әле...

— Илмирны әйтәсеңме? Мин аңардан гарык. Бүген кайтып йоклыйдыр, бәлки.

— Мин сиңа шундый китаплар күрсәтермен, матурым, исең-акылың китәр. Китаплар — минем хобби. Тик укып кына өлгерә алмыйм. Фал китабым да бар. Галәм белән дә кызыксынам, фантастика! Хәзер чит планеталардан килеп йөрүчеләр ешайды — андый мәгълүматларны аерым җыям, әгәр сорасалар, бу темага сәгатьләр буе лекция укый алам. Китаплар күп миндә. Берсенә Мәскәүдә мең сум бирделәр, сатмадым, мин аны үзем дә 350 сумга алган идем.

— Китап-китаптыр инде,— диде Гөлфия, артык исе китмичә.
— Әй, матурым, алай түгел ул... Әле иданнән түшәмгә чаклы итеп эшләтәм шкафларны, бер дуста күреп кайттым, шәп мәгәр. Стенкага гына күпме китап сыйсын соң?! Эшләр күп әле минем алда, матурым. Менә синең киңәшләрне дә тыңларга исәп.
— Безнең йорт,— диде Гөлфия, узып китешли.
Гашыйклар өчен иң яхшы дәва — музыка, ишектән керү белән Әнвәрчик магнитофонын уйнатып җибәрде. Төн рухына бик тә тәңгәл килә иде Салих Сәйдәшевнең «Шәрык биюе».
Көтеп алынган төннең кадерен белергә кирәк! Алар төн буе «бәйрәм» иттеләр...

* * *

Телефон гашыйклар өчен — хәтәр нәрсә. Юлбарыс тырнагы шикелле. Бер эләктереп алса, ычкындырмый һич тә. Аннары үзеннең бармакларың ук телефонга сузылырга гына тора. Сөйләштерә, көлдертә, очраштыра.
Гөлфия дә еш әйләндерде телефон тәлинкәсен. Әйләндергән саен куна калды. Бер көнне иртән кайтып кергәч, Илмир сорау алырга тотынды:
— Кайда кундың?
Башын түбән иеп, Гөлфия сүзсез генә кухняга юнәлде.
— Кайда йөрисең син, ә?
— Син йөргән юлда.
— Мин өйдә йокладым.
— Ярый әле бүген чит хатынның тунын күтәреп кайтмагансың.
Сүз сөрешен аңлап алган Илмир әкрен генә хатыны янына килеп басты. Гөлфиянең чырае качкан, иреннәре, күз кабаклары шешенгән, мамыгын тәмам тараганнар иде.
— Әйдә, матур гына сөйләшик әле, ни булды? — диде Илмир.
Гөлфия, ни булганын төкми-чәчми хикәяләде. Башка хатын булса, әллә ниләр уйлап табар, елый-елый чәчен йолкыр,антлар итәр, ышанма күргән күзеңә — ышан әйткән сүземә, дигәндәй, инандырып ук бетермәсә дә барыбер иренең күңеленә вәсвәсә салмый калмас иде. Юк, Гөлфия андыйлардан түгел, әйтсә, турысын әйтә.
— Очраштыр мине шуның белән,— диде Илмир.
— Ярар,— диде Гөлфия.
— Мине кыйнатырга чакырасыңмы? — диде Әнвәрчик.
— Әнвәрчик!.. Бозау ич ул. Аның сине күрәсе килә, үзеңне! Нәрсә, син аннан хуже что ли? Бүген син киләсең, иртәгә — мин.
Әнвәрчик тәвәккәлләде. Ләкин саклык чараларын күрергә дә онытмады, карт бүренең койрыгын бозга катыра алмаслар, шәт.
Әнвәрне ирле-хатынлы икәүләп көтеп торалар иде тегеләр. Ирләр үзара таныштылар.
— Гөлфия белән танышсызмы? — диде Илмир.
— Ие.
— Ничә тапкыр очраштыгыз?
— Ике.
— Биш тапкыр,— диде Гөлфия.
— Йокладыгызмы?
— Юк.
— Бишесендә дә! — диде Гөлфия.
— Булды шул,— диде Әнвәр, борылыр урын калмагач.
— Булса, Гөлфия синнән авыру эләктергән бит,— дип сүз белән китереп терәде тегене Илмир.— Кара, моның ахыры начар бетәчәк. Әйдәле, читкәрәк китеп сөйләшик, Гөлфия син торып тор.

Ахырдан Гөлфия ни сөйләшкәннәрен иреннән сорашып белде. Әнвәр бүтән очрашмаска вәгъдә иткән. Дуслашканнар. Шәп егет икән Әнвәр. Ике ирнең мәсьәләне шулай тыныч юл белән хәл итәселәренә ышана иде Гөлфия.

Ул кичне яшь Саркиннарда бәйрәм ясалды. Бер кичлек бәйрәм. Аннары аны икесе дә оныттылар.

* * *

Трамвайдан төшкәч, кыз туктап калды. Әллә Ваня сөйләгәннәр дөрес инде?! Таллыклар тып-тын. Әле ярты сәгать элек кенә алар бакчада өздереп сандугач сайравын тыңладылар. Монда тынлык.

— Бүген җәйнең кыл уртасы, кошлар төн уртасына чаклы гына сайрыйлар, син өегезгә кайтып җиткәндә, кош тавышын ишетмәссең,— дип, озатып калды Ванюшасы.

Чыннан да, Энергоинститут бакчасы тынып калган иде. Сәгать төнге беренче биш минут.

— Туташ, сезне бер генә минутка мөмкинме?

Фәризә борылып карады, туктады.

Егет кызга килепябышты:

— Бәлки танышып китәрбез. Үзем озатып куям.

— Мин ирдә бит.

— Кая әле балдагыңны күрсәт,— дигән булып, егет Фәризәнең кулын борып алды, куаклар арасына өстери башлады.

— Авырлы мин.

Егет хатынны тынычландырырга ашыкты, бераз утырып торырга тәкъдим итте, үзен кызгандырып сөйләргә кереште.

— Гафу ит,— дигән булды төнге аучы.— Мин ычкынып киттем бугай. Хәлем шулайрак. Күптән түгел машина һәлакәтендә ике дустым үлде, аларны җирләдем, сөйләшер, киңәшер кешем калмады.

Сүз бозау имезә, диләр. Болар да сөйләшә-сөйләшә шактый җир атладылар. Яшьләр үзәге янындагы бакчага килеп җиттеләр, эскәмиягә утырдылар.

Фәризәнең, мин ирле, дигәне бик үк дөреслеккә туры килеп бетмәсә дә, авырлы булуы хак иде. Алар Иван белән бер коллективта эшлиләр. Еш кына кыз егетендә куна кала. Бүген дә, хәер, инде кичәгенәк дисәң дә ярый, Фәризә сменасын тәмамлаганда, Иван килеп тә җиткән иде, бергә аларга кайттылар. Ашап-эчкәч, урамда йөрделәр, аннары егете аны трамвайга чаклы озатып куйды. Җәй уртасы, кошлар турында шул чакта сөйләде.

Менә хәзер ниндидер башка егетне тыңлап утыра Фәризә. Ул кабалана башлады.

— Кайтыйк! Соң инде, бер сәгать утырдык,— диде Фәризә.

— Башта чишен, сал чалбарыңны!

Әлбәттә, Фәризә ризалашмады, юлга чыгып, кешеләрне ярдәмгә чакырасын әйтте. «Шушында үләсең килсә, әнә, бар»,— диде дә егет тегенең корсагына китереп орды. Аннары... көчләде, хайванча, әшәкелек юлы белән.

Егетнең кем булуын чамалагансыздыр инде. Әйе, нәкъ үзе — Илмир Саркин. Ул бераздан хатынны үзләренә кайтырга чакырды. Теге күнмәгәч, синең бүгенге эшләреңне кешеләргә таратам, ничәнче ательеда эшләгәнеңне беләм бит, диде, кулын борып, өйләренә өстерәде...

— Бу — дустымның фатиры, үзе командировкада, ике көнсез кайтмый әле,— дип ялганлады Илмир.

Ни буласын укучым алдан ук сизенгәндер. Сәвия хәлләре бүген дә кабатланды, ләкин бу эш иң әшәке, кабахәтлек ысуллары белән эшләнде.

Озак интектерүдән Фәризә үзен-үзе белештермичә калтыранды, укшыды, косты, аннары аны күзән җыера башлады, ниһаять, һуштан язды. Әмма вәхшинең монда әллә ни исе китмәде.

Илмир иртәнге дүртләрдә генә йоклап китте. Тагын да монда калырга ярамый иде — Фәризә әкрен генә торып киенде, ишеккә барды, ул бикле иде. Кухняга керде, тәрәзәдән балконга чыкты, торбага ябышып аска таба шуышты, җиргә төште. Сәвия эзләрен янгыр юган, үләп каплаган шул инде. Бу йорт тирәсендәге шау-шулар да басылган. Хәер, аларны Фәризә белми дә ич.

* * *

Әнисе, кызын күргәч, елап җибәрде. Чөнки Фәризә яртылаш мәет кыяфәтендә кайтып керде өйләренә. Булган хәлләрне яшермичә сөйләде.

— Милициягә бардыңмы? — дип сорады әнисе.

— Ваняга ишетелер, бер айдан туй бит инде, әни.

Үз йортлары белән яшәгәнлектән, Фәризәләрнең дошлары юк иде. Ул иптәш кызларына барды, чистарынды, сафланды. Узган төн афәтләре һич тә аның исеннән чыкмады, күз алдыннан китмәде. Кисәк-кисәк күзән җыерып азаплады, калтыранды. Ләкин барыбер эшкә барырга кирәк иде.

Сменасына иртәрәк килеп утырды Фәризә. «Авырып торам,» — диде хезмәттәшләренә. Ә Ванянын сеңелесе килеп хәлен сораша башлагач, түзмәде, һәммәсен дә ачыктан-ачык сөйләп бирде.

— Әгәр милициягә белдермәсәң, үзем барып сөйлим, — диде яшь кыз. — Мондый нәрсәне болай гына калдырырга ярыймы соң?

— Ә абыең?

— Синең ни гаебең бар монда? Аңа әйтми торырбыз.

Ул көнне Фәризә, кәефем юк дигән сылтау белән, эшеннән сорап китте. Ни килеп чыгар тагын?

* * *

Тикшерү бүлеге начальнигы Хатыйп Хәбибуллинның телефоны зәһәр чәрелдәде. Шкафтагы «эш» папкаларын актара иде, тиз генә барып трубканы күтәрде.

— Исәнмесез, Хатыйп Заһитович! Мин әле бу — Батыров, — диде телефоннан сөйләүче коры гына. — Тагын Саркин. Хәтерләдегезме? Аналогик күренеш: шул ук фатир, шул ук балкон, шул ук качу ысулы, җинаять алымнары төгәл кабатлана.

— Кемгә дә булса шалтыратырга өлгермәдегезме әле, Ибраһим Зарипович, — дип кызыксынды Хәбибуллин. — Алайса, бик яхшы, хәзер үк барып җитәм, калганын шунда сөйләшербез.

Начальникнын тәмам үзгенә үтте бит шул юньсез кеше. Суд яклый тегене, прокурор кире кага, суд аклый, прокурор тагын үз билгеләмәсен чыгара, эшне кире кайтара. Инде ел ярымга сузылды, әле очы-кырые күренми — теләсәң-теләмәсәң дә, ниндидер мафия кулы уйный дип әйтердәй буласың. Менә шуны ачыклыйсы иде бит.

Хәбибуллин эшне тикшерү-экспертизадан башлап җибәрде. Бүлмәдә дүрт егетне тезеп утырттылар да зыян күрүчене чакырып керттеләр.

— Әйтегез әле, гражданка Сабитова, боларның кайсы җинаятьче сезнеңчә? — дип сорады Хатыйп Заһитович.

— Менә бусы — Илмир исемлесе, үзе әйткәнчә.

— Ну, мин, мин булам, шуннан нәрсә? — дип әтәчләнде Саркин. — Ләкин мин бит сезгә бернинди мәгълүмат бирмәячәкмен.

— Сөйләрсең, сөйләрсең, бу юлы ычкына алмассың.

— Кайда монда майор Сатлыганов? Китерегез аны, ул тикшерсен, ул барысын да белеп эш итә.

— Булмаячак Сатлыганов, өметләнмә аңа.

— Ну, сөйләмим.

— Теге чакта язылганча, бала вакытта миегез селкенү, травма алуыгыз дөресме, Саркин?

— Беркайчан да бернинди травма алганым юк, операция ясамадылар, наркоман түгел, психоневрологик авырулар исемлегендә тормыйм, гомумән, шифаханәдә ятканым юк. Канәгатьме шуңа? Сез әйткән очрак буенча Сәламәтлек саклау министрлыгы экспертиза үткәрде ич инде, анда барысы да язылган, шуны укыгыз, миннән башкасын сорамагыз. Тик шуны искәртәсем килә: ахырдан үкенергә туры килмәсен үзегезгә, юлбарыс тырнагына килеп каба күрмәгез. Хәзер үк мине чыгарып җибәрүегезне таләп итәм!

— Ашыкма — ашка пешәрсең.

— Кемнең авызы пешкәнне күреп көләчәкмен әле мин...

Саркинның сөйләгәннәре магнитофон тасмасына яздырып барылды. Ләкин бу әле чын тикшерену түгел, якынча сөйләшү, хәлне ачыклау гына иде. Хәбибуллин урын-җиргә, кием-салымга төгәл һәм җентекле экспертиза үткәрергә кушты.

Анализ нәтиҗәләре күрсәткәнчә, урын-җирдәге, кухня тәрәзәсендәге, балкондагы эзләр җинаятьнең Саркин тарафыннан башкарылуын раслап тора иде.

Хәбибуллин бу адәмнең элеккеге җинаятьләрен исенә төшерде. Ул чакта да дәлилләр җитәрлек булган, күбесен юкка чыгарганнар. Өстәмә дәлилләр таләп итеп, күпме баш әйләндерделәр. Әле суд эше ябылмаган ябылуын. Теге чактагыча тере шаһитлар сорап тинтерәтүләре бик ихтимал. Теләшеваны күтәреп өенә китергән алты кешене эзләп таба алмадылар, бәлки табарга да теләмәгәннәрдер. Бу юлы андый хәл кабатланырга тиеш түгел. Димәк, Саркинны иректә калдырырга, аның белән кемнедер очраштырырга һич тә ярамый. Ә нишләргә соң? Бүген җомга, дүшәмбегә кадәр ничек сакларга бу ерткычны? Дөрес, тикшерүче аны вакытлыча тотыла торган изоляторга ябып куярга хаклы. Ләкин җитмеш ике сәгатькә генә, шуннан артыгы ярамый.

— Без моны чыкмас тишеккә урнаштырыйк, Ибраһим Зарипович,— диде Хәбибуллин, район эчке эшләр бүлеге начальнигы, Батыровка мөрәҗәгать итеп.— Нык яшер, сорасалар, Хәбибуллин Лаеш тирәсенә алып китте, диярсез. Җаваплылыкны үз өстемә алам. Кысарлар, тик, зинһар, бирешмә, мине күрсәт.

— Минем канга да күп тоз салды ул,— диде Батыров, килешеп.

Кайтышлый Хәбибуллин шоферын кат-кат кисәтеп куйды. Синнән Саркинны Лаешка илттегезме, дип сорарлар. «Илттек»,— диярсең. Бәлки куркытырлар, янарлар — сүзеңнән кайтма, бу шундый ситуация, туганкай.

Шимбә иртәсендә мәхшәр купты, яшерелгән Саркинны эзләделәр. Таякның авыр башы Батыров җилкәсенә төште. Аны телефоннан да, кабинетына кереп тә кыстылар. Берәүләре җайлап-майлап кына сөйләшергә тырышса, икенчеләре тавыш-приказ белән алдырырга омтылдылар, янадылар, өркеттеләр.

— Гражданин Саркинны Лаешка Хәбибуллин алып китте,— ди Батыров, рәсми җавабында.

Кара, ак «Волга»лар Кама буена чапты. Район эчке эшләр бүлеге начальнигын тотып селкеделәр. Теге бичара, Казан кунаклары кыланышыннан, каушап калган иде, бернинди Саркинны китермәүләрен, күргәне дә юклыгын раслап антлар итте, өстәлгә партбилетын чыгарып салды. Монысын инде ышандыруның еллар буе сыналган әмәле, ләкин аңа ышанмадылар, партбилетыңны өлкә комитетына килеп алырсың, дип, аны үзләре белән Казанга алып кайтып киттеләр.

Чыдасын Батыров. Әмма дә батыр йөрәкле булып чыкты Батыров — берсенә дә бирешмәде. Хәтта килүчеләргә берничә бүлмәне ачып та күрсәтте — юк иде Саркин.

— Булган җирегездә юньләп сөйләшмәгәнсез, карамагансыз,— дип үзләренә бәйләнгәндәй итте әле.

«Волга»ларның асфальт игәүләп кузгалып китүләрен Батыров мыек астыннан гына елмаеп карап калды.

Икенче рейска тагын бер «Волга» өстәлде, анысына Ярагановы үзе генә утырган иде. Йөрәге түзмәде, башкаларга ышанып бетермәде, шуңа кузгалуы иде Ярагановның. Бу юлы, Лаеш милициясе башлыгын әгузебисмилласыз гына өшкерергә керештеләр. Сәяси эшләр буенча урынбасары янында кукраеп тормаса, валлаһи, кычкырып елап җибәрергә дә әзер иде начальник. Ул тотлыга-тотлыга баягы сүзләрен кабатлауны гына белде.

— Әһә, син шулаймы әле!..

Телефоннан партия райкомының беренче секретарен тыкырдатып китерделәр. Ә теге мескен, кемнәр чакыртуын белеп, шыр җибәргән иде: исәнләшүенең дә рәте-чираты булмады.

— Мондый кадрлар белән ерак китә алмассыз, кемнәрне җыйган бит үз тирәсенә, районны таркатырга тотынган,— дип, турыдан-туры гаеп ата башладылар беренче секретарьга.

— Бир ачкычларыңны,— диде беренче, әзрәк хәлләнә төшеп.— Актарам казаматыңны һәм үзеңне үк шунда ябып калдырам, акылга утыртам мин сине. Бер сәгатьтән үзеңне бюрога алып килерләр.

Актарды, дөресрәге, бергәләп актардылар. РОВДның астын өскә китерделәр, хәтта, шкафларны, бәдрәфләрне ачып карадылар, тик Казан «кунагын» тапмадылар.

Казан сәяхәтчеләре саубуллашмыйча гына машиналарына төялештеләр дә китеп бардылар. Начальник тегеләр артыннан, өч бармагын укмаштырып, чукынып калды.

Килүчесе кем бит әле — Ярaганов үзе, Толбаевның уң кулы. Начальник узгандагы бер вакыйганы исенә төшерде. Гадәтенчә, Толбаев, семинар сылтавы белән, бер көтү яраннарын ияртеп, җәйге ауга килгән иде. Бөтен урманны айкады, әмма бер генә кыр тавыгы да, көртлек, төлке дә ата алмады. Шуннан соң тавыш куптарды, беренче секретарьны селкеде, башкаларны тиргәде, оештырып җиткермәгән өчен Ярагановка да эләкте. Нәрсәсен оештырасың инде, җәй уртасында үрдәк аталар димени, кош-кортның йомырка өстендә утырган, бала чыгарган чагы бит әле.

— Кама-Идел тыюлыгына! — дип команда бирде Ярaганов.

Ул көнне күп кенә кошларның йомыркалары суынгандыр, инде дөньяга чыккан сары авызлы чәрелдекләрнең байтагы туйдыручысыз ятим калгандыр. Югыйсә, «Юбилейная» фабрикасыннан алып килгән тавыклар да җитәрлек иде. Патшалар ухасы ансыз булмый икән ул. Башта тавыкны пешереп алалар, аннары шуның шулпасына киек кошлар, чөгә, корбан балыкларын салалар. Менә сиңа патшаларның балык шулпасы!..

Әкәмәт истәлекле булды ул пикник, ахырдан шул хакта мәзәк итеп бик озак сөйләп йөрделәр. Ни өченме? Кызыклыгы өчен. Урман аланында ике табын әзерләделәр. Берсе — түрәләр һәм аларның күңелен ачучылар өчен, икенчесе — шоферларга, җыен вак-төяккә. Шоферлар, кара халык, шулпа пешкәнче дип, куаклар арасында аз-маз күтәргәләп утыралар, карта сугалар. Шулчак табын уртасына күктән шап-шоп итеп пешкән тавык ява башлый, парлары чыгып тора! Бу ни?

Аңлашыладыр: патша шулпасы хуҗалары пешкән тавыкларның күбесен ботыннан тотып агач арасына томыралар икән. Кем ашап бетерсен аны?! Ярaганов белән начальник шунда якыннан танышкан иде. Инде башка очрашырга насыйп итмәсен...

— Хәзер кая? — дип сорады шофер, шәһәргә кергәч.

— Батыров этләнә, күрәсең, тагын кысып карыйк юньсезне!

Әмма ышанычлары барыбер акланмады. Батыровның ватылмас чикләвек икәнен күреп, Лаеш хәле кабатлануын сизделәр.

Батыровны иңбашларыннан тотып селкеп тә булмый, кешесе ул түгел, үз дәрәҗәсен бик яхшы белеп эш итә. Әмма йомгакны сүтәсе, җепнең очын табасы иде бит.

Юрист халкының фикере алдан йөгерә, вакыйгаларны узып баручан була, шул эзлеклелеге аны куелган максатына илтеп җиткерә дә. Үзләре телендә әйтсәк, логик фикерләү осталыгы, диләр моны. Бу юлы да нәкъ шулай килеп чыкты: Саркинны эзләүчеләр Хәбибуллинның шоферына барып ябыштылар. Алай-болай, агай-эне, син яхшы, намуслы шофер, барысын да белеп торасың, начальствога тугрылыклы хезмәт итәсең... Кичә-бүген дә эш җитәрлек булгандыр үзеңә.

— Бүген мин беркая да чыкмадым,— диде шофер.

— Кичә дибез, Лаешка баруыңны әйтәбез.

— Ә-әә.

— Сез анда Саркин дигән берәүне илтмәдегезме?

— Озаттык, нигә, ярамый идемени?— дип, бераз кыландырып та җибәрде шофер егет. Алдан сөйләшенгән иде ич.

Менә сиңа пәрәмәч! Озаттык, ди бит. Ә алар милиция идарәсенең тикшермәгән тишеген калдырмадылар. Юк, нindидер ис бар монда. Шулай да версиянең икесе Лаешка килеп терәлә. Димәк, куркак начальник дигәнебез нык яшергәндер, башка биналары бар, күрәсең. Тарихны хәтерлик, Лаеш шулпасын эчүчеләре, элек-электән үзенең төрмәләре белән дан тоткан авыл бит ул. Безгә дә Лаеш шулпасын чөмертә бу, вәт, эттән туган! Бәлки, Саркинны аннан да ераккарак алып киткәннәрдер?..

Соңгы шикле сорау «сәяхәтчеләр»не өченче тапкыр Лаешка барудан туктатып калды. Алар күрше район телефоннарын эшкә җигәргә карар кылдылар.

Их, вакытсыз ычкынды бит Толбаев та. Күрсәтер иде күрмәгәннәрен җыен әкәм-төкәмнең. Үз күләгәләреннән куркып яшәүчеләр арасында калды бүген Ярганов.

* * *

Гаиләсен алып ике көнгә авылга кайтып киткән иде Хәбибуллин. Үзе генә белмәде, туктаусыз шалтыраудан телефоннары чак-чак кына янып чыкмады.

Дүшәмбе көнне Хәбибуллин, прокурордан санкция алып, Саркинны тикшерү изоляторына кертеп утыртты. Моның ни икәнен юристлар һәм җинаятьчеләр үзләре яхшы беләләр. Төрмәгә килеп эләксәң, аның ишеген бары тик суд кына ачып чыгара яки дәлилләре ышанычлы булган прокурор хәл кыла — башка юлы юк. Ә суд карары өчен тикшерү үткәрәсе бар. Ярганов юрист түгел шул, мондый хикмәтләрне кайдан белеп бетерсен. Ул, Лаеш урманындагы шикелле, туры төбәп атарга өйрәнгән. Тыюлыкта, Толбаев өчен җиде үрдәк атып, рекорд куйды бит ул теге чакта. Тормышны хәзер дә шулайрак, туры төбәп ату дип белә. Әмма заманалар үзгәрде, һай, үзгәрде...

Республика прокуратурасына кара күзлекле, караңгы чырайлы, ләкин ифрат та һавалы бер адәм килеп керде. Җайлап-майлап сөйләшүчеләрдән түгел икән, кем тарафыннан җибәрелүен белеп кылана, соравын турыдан бәрде:

— Йә, Саркин белән нишләмәк буласыз инде сез?

Гомердә булмаган хәл: сабыр холыклы Хәбибуллинның кинәт ачуы кабарды. Шулай да үзен тыеп калды, күтәрелеп бәрелмәде. Нindирәк кеше икән соң бу? Ни әйтәсе билгеле инде. Үзе нindирәк кеше? Явыз, юньсез адәмнәрне күп күрде юрист, алар белән көн дә диярлек очрашып

тора. Менә шулай, пырдымсыз кереп, тупас кыланучылар сирәк очрый. Әллә бераз шаяртыргамы икән үзен, дип уйлап куйды бүлмә хуҗасы.

— Нишләтик икән соң гражданин Саркинны?

— Миңа сезне, бик коры кеше, дигәннәр иде.

— Нәрсә, юешләндем димәкче буласыңмы?

— Ә сез шаян икәнсез!

— Алайса... исем-фамилиягезне әйтмәдегез, эш нәрсәдә?

— Үзем дә шуннан башлаган идем шул,— дип дәвам итте килүче.— Ни бит, яхшы кешеләрнең баласы, Саркинны әйтәм.

— Юньле кеше баласы җинаять өстенә җинаять эшлиме?

Кергән кеше кабат үзенең элекке хәленә кайтты, кара янып чыкты, башын артка чөеп җибәрде: янәсе, күр, без кемнәр, төшеп калганнардан түгел.

— Шулай да сез кая барып төртелгәнегезне онытмасагыз икән!...

Хәбибуллинның әңгәмәдәше янаулы тонга күчте. Тагын ни әйтәсе калган икән соң моның? Бәлки, тәмам ачылып бетәр.

— Кая барып төртеләчәк инде мин?

— «Юлбарыс тырнагы», диләр аны, бер эләктереп алса — ай-ай, нык каптыра, тыныгыз да чыкмас.

— Туктагыз әле, тукта, Саркин үзе дә әйткән иде миңа ул тырнак хакында, төшенеп җитмәдем, башкалардан да колакка чалынды, кем ул «Юлбарыс тырнагы?!»

— Муен тамырыңнан каптырып алмыйча белмисең инде анысын, хөрмәтле начальник.

Барысы да «Юлбарыс тырнагы» турында сөйлиләр, ә аның кемлеген яшерәләр, куркалар, димәк, яшерен эш йөртүче булып чыга. Эзенә төшәргә тырышып карады Хәбибуллин, ләкин шушы көнгәчә берни дә ачыклый алмады. Тирән базда утыра явыз.

Сүз көрәштерүнең файдасы юк иде. Милиция чакыртып, бу беткән җан белән озак маташасы килмәде Хәбибуллинның. Иң яхшысы — кирәген әйтеп озату.

— Теге чакта, чыннан да, сезнең тарафтан кемнәрдер сатып алынды, сорау алу беркетмәләре юкка чыгарылды, эшнең сузылуына ирештегез,— диде Хатыйп Заһитович, суд карарын укыгандагы шикелле аяк өсте басып.— Әнә, улыгыз (кем ул сезгә?) изоляторда ябылуда, кодрәтегездән килсә, тартып чыгарыгыз! Монда инде юлбарысның тырнагы гына түгел, казык теше дә үтмәячәк. Шуны белеп китегез.

Әлеге «илче» ишектән чыкканда, имән бармагын кәкрәйтеп, кара күзлеге турысында берничә мәртәбә селкеп алды. Хәбибуллин аңлады: «Юлбарыс тырнагы»ннан сак бул, янәсе. Нәрсә ди әле украинлы бер дусты: «Хохолны дуңгыз мае белән куркытмыйлар» — диме? Дөрес әйтә, юристны да законсызлык белән өркетергә кирәкми — ул аны болай да шәп белә.

* * *

Саркин эшен үзенә бирүләрен сорап кергән Сатлыганов шик астында калды. Моннан элек тә эшкә аның катнашы булган, беренче беркетмәләрне нәкъ менә ул югалткан. «Мин бернинди беркетмә язмадым, гариза кабул итмәдем»,— дип барды. Шуңа күрә, бу юлы аны Саркин тирәсенә якын җибәрмәделәр. Ләкин теге һаман активлык күрсәтүдән туктамады, кемнәр беләндер сөйләште, кемнәргәдер киңәш бирде, үтенеч тапшырды. Гөлфия Саркинаны ияртеп, берничә мәртәбә эчке эшләр бүлегенә барып чыккан. Тегесе гаризасын калдырган. Имештер, Илмир ниндидер кызны, хатынын көнләштерер өчен генә, алып кайткан, чөнки Гөлфия аңа хыянәт иткән. Дәлилләре бар: партнеры Әнвәр Газизович әйтеп торачак.

— Сатлыганов шуннан артыгын булдыра алмас шул инде,— диде Хәбибуллин, Саркина гаризасын укып чыккач.

Административ чара күреп, тиешле шелтәсен чәпеп, Сатлыгановны бүтән эшкә күчерделәр. Әмма күзгә күренми торган шөпшәләр бызылдады. Алары бигрәк тә Хәбибуллинны чагарга тырыштылар. Кемдер Саркиннарның бик зур суммада акча әзерләп куюларын искә төшерде. Юк кына эш өчен акыл җитмәслек сумма, имеш.

Баштарак Хатыйп Заһитович боларны колак артыннан гына үткәреп җибәрде. Ә бер көнне почта әрҗәсеннән табылган хатны укыгач, тәмам хәйран калды. Менә ул хат:

*«Хөрмәтле Хатыйп Заһитович!*

*Сизеп торам, Сез Саркин мәсьәләсендә принципка киттегез, ахрысы. Узгандагы очрак өчен үч алырга җыенасыздыр инде. Ул сезгә ни бирә икән — шуны төшенмим, бары тик коры принцип кынадыр дип өметләнәм. Бер тиле башны төрмәгә утыртудын беребезгә дә файда булмас. Әйе, файда булмастыр...*

*Менә нәрсә, Хатыйп Заһитович, СССР дәүләте төзелгәннән бирле Татарстанда күрелмәгән акция тәкъдим итәм: Сезгә — йөз мең сум! Алыгыз һәм рәхәтләнеп кулланыгыз, һич кызганусыз бирәм, чөнки бала кадерлерәк. Илмир бит Саркинныкы түгел — минем малай, ышанычыгызга керү өчен серне ачарга туры килде. Сәбәбе җитди, үзегез төшенәсездер. Принципка — принцип, уйлап карагыз әле!*

*Икенче вариант. Беләсездер, мине «Юлбарыс тырнагы» дип йөртәләр. Бу — дөрес. Асылда миндә андый тырнак та бар — физик ягын әйтәм. Кыйммәте безнең өчен билгесез, бәлки миллион сумдыр, һәрхәлдә, доллар белән берничә йөз мең исәпләнә — Һиндстан малы. Телисез икән — ул сезнеке булыр, тик икенең берсе белән килешик кенә.*

*Инде шуңа бәйле рәвештәге операциягә күчик. Ул бик гади. Сез — юрист кеше, нинди дер качышлы уены уйнарга җыенмыйм, анысына ышаныгыз, шикләнмәгез. Әгәр тәкъдимемә күнсәгез, кичке якта кабинетыгызда яшел ут кабызыгыз — бу йөз мең сумны аңлатыр, зәңгәр ут икән — мин сезгә Юлбарыс тырнагын бирергә мәҗбүр булам һәм сез аны алырсыз.*

*Ике яктан да гадел булыйк. Качышлы уйнарга ниятләсәгез, мин өченче вариантны кулланырга мәҗбүрмен. Зинһар, дөрес аңлый күрегез, куркытуым түгел, просто, дүртенче вариантым юк әлегә.*

*Сездән яшел якты нур көтәм.*

*«Юлбарыс тырнагы».*

*16 август, 1989 ел».*

— Ультиматумлы хат республика прокуратурасын аякка бастырды. Тиешле бер вакытка Хәбибуллин өчен шәхси сак билгеләнде. Ниһаять, «Юлбарыс тырнагы» баш калкытты — аны тозакка эләктерергә кирәк. Прокуратураның Хәбибуллин эшли торган бүлмәсендә атна буе кичләрен зәңгәр ут янды. Ләкин килеп керүче дә, аваз салучы да юк. Оператив группа борчыла ук башлады. «Юлбарыс тырнагы»ның көтелмәгән берәр этлек эшләп ташлавыннан шикләнделәр. Язу стиленә, катлаулы ситуациягә килеп эләгүенә караганда, аның башка әмәле дә юк, чыгарга тиеш ул өненнән.

— Әни, менә мин нәрсә таптым,— диде Хатыйп Заһитовичның беренче катка газеталар алырга төшеп менгән кече улы.

— Ташла хәзер үк чүп чиләгенә, теләсә нинди тимер-томырны син ташыйсың өйгә,— дип тиргәде хатыны улын.

— Тимер түгел ич ул — сөяк, чылбыры гына тимер...

— Бар, ташла.

Үз бүлмәсендә сәер хат белән мавыгып киткән Хатыйп Заһитович чак-чак кына ишетеп калды тегеләр әрепләшүен һәм атылып диярлек малай янына чыкты.

— Каяле, улым, кая, китер әле шул нәмәстәкәйне монда.

— Әти, чылбырын үземә бирерсең, яме, ачкыч тагып йөрим мин аңа.

— Кайдан таптың?

— Безнең почта әрҗәсенә төшергәннәр, кәгазьгә төреп.
— Беткәнмени хулиган,— диде хуҗабикә, үзсүзләнеп.
Хәбибуллин «чүпне» үз бүлмәсенә алып кереп китте дә җентекләп карарга тотынды. Ай-йай, бар икән монда хәлләр! Чылбыры иң яхшы сыйфатлы, алтыннан эшләнгән. Аның мондый олы тырнакны гомерендә дә очратканы юк, шоп-шома, ялтыратылган, ниндидер бизәкләр төшерелгән сыман. Тиз генә зурайткыч пыяланы алып килде дә, янадан юлбарыс тырнагына иелде: бөтен бер китап икән бит монда, инглизчә язылган. Зурайткыч белән генә ерып чыгарлык, укып аңларлык түгел, нечкә эш. Чын сәнгать әсәре бу — нинди осталар кулы башкаргандыр үзен?!
Ул арада телефон шалтырады.
— Хәерле кич, Хатыйп Заһитович! Хәзер үк почтагызны алып менегез әле. Без сүзебездә тордык, инде эш сезгә терәлде,— диде сөйләүче. Шуннан соң телефон еш-еш сигналлар бирә башлады.
— Сак эшли, эттән туган,— дип куйды Хәбибуллин.— Үзен танытырга теләми.
Моннан берәр сәгать элек кенә алар подъездына бер яшь хатынның кереп чыгуын шәйләүче дә булмады. Почта әрҗәсенә бөти-амулетны шул төшереп җибәргән иде.
«Юк, өйдә сакларга ярамас,— дип фикер йөртте Хәбибуллин,— арзанлы сувенир булырга охшамаган бу». Ул телефоннан үзенә билгеләнгән тән сакчысын һәм ярдәмчесен чакыртып китерде дә республиканың иминлек саклау комитетына китте.
Анда юлбарыс тырнагын, рәсми исәпкә теркәп, сейфка бикләп куйдылар.
Комитетта Хатыйп Заһитовичка артык күзгә ташланмаска, саграк йөрергә, активлык күрсәтмәскә киңәш иттеләр.

* * *

Яраганов башкалар аша Илмир Саркин белән даими кызыксынып торды, әмма өметләнерлек хәбәр ишетелмәде. Шулай ук борчылырлык нәрсә дә юк кебек.
Тик вакыт дигәнең бер дә Яраганов файдасына эшләмәгән булып чыкты. Юк ла, Саркин хакында түгел әле монда. Бер зәһәр депутат Югары Совет сессиясендә ниндидер йорт мәсьәләсен күтәргән. Имештер, «Теплоконтроль» заводының бер төркем эшчеләре череп-ишелеп беткән баракта яшиләр икән. Шулар шәһәр Советы башкарма комитетына килеп, үзләрен кайчан адәм рәтле квартираларга күчерәчәкләрен белешкәннәр. Әйтәләр тегеләргә: сез бит инде күптән тугыз катлы йортта яшисез, барагыгыз моннан өч ел элек сүтелде, диләр. Тикшерә торгач, баракларның үз урыннарында утыруы, тугыз катлы йортның, гомумән, салынмавы, ә йөз меңнәрнең кемнеңдер кесәсенә кергәнлеге ачыклана. Җепнең бер очын Ярагановка китереп бәйләмәкчеләр. Ул үзе белеп тора: бер түгел, биш депутатның да теше үтмәс, җепнең очы нык төйнәлгән, чишәләр икән, аның җаваплы кешеләре бар, куркырлык берни юк. Тик Хәбибуллин гына төп башына утыртмасын.
Бүрегә белән киңәшкәннән соң, тиешле кешеләренә әмерләрен житкереп, Яраганов бераз ял итеп кайтырга ниятләде. Вакыт бар әле, ул кайтуга, Хәбибуллин эшне җайлап куярга тиеш. Беркөн шалтыраткач, өметләндерде бит, «Уйлашабыз-уйлашабыз»,— диде. Тик менә очрашырга омтылуын гына ошатып җиткермәде Яраганов, анысы барып чыкмас, моны ул нык лап төшендерде, тагын бер айдан малай чалбарын салып, минем алда басып торсын, каешны әзерләп куярмын, дип тә шаяртты ахырдан. Рәхәтләнеп көлде Хәбибуллин телефон трубкасына.

Иң яхшысы — беразга күздән югалу, тынычлану. Путевкамы? Анысы аның «Теплоконтроль» заводы эшчеләренә тансык. Тик менә сәламәт кешегә кайда уңайрак булыр икән соң? Әлбәттә, Кара диңгез буендагы ял — ял түгел инде ул, ата кызны, ана улны белми, мәж килә халык анда бу вакытта. Су болгатып, авыру таратып тик яталар. СПИДы да ерак йөрмәс хәзер. Аннары Чернобыль фаҗигасе дә телгә керде. Иң яхшысы — Балтыйк буе, үзе тыныч, суы саф, шартлар менә дигән.

— «Юрмала»га рәхим итегез, Назыйм Тәлгатович,— диде профком рәисе.

Ял акчасын да, җиде хезмәт хакы күләмендә өстәмәсен дә алып салды кесәсенә Ярағанов. Самолет билетын шул ук профком рәисе кайтарып тоттырды. Питрәч ягыннан бер әрҗә кымыз китерделәр, латышларны милли эчемлек белән сыйларга ниятләде. Коньяк, бальзам аларның үзләрендә дә тулып ята.

— Болай булгач, сезне кире бормаслар инде, Назыйм Тәлгатович, рәхәтләнеп кенә ял итегез, тазарып кайтыгыз. Тәтәйләрдән баш тарта күрмәгез тагын, сәламәтлек өчен бик файдалы ул,— дип киңәш итте, бу эштә шомарып беткән профсоюз лидеры.

— Авызыңны ерма,— дип бүлде аны Ярағанов,— кара аны, ике колагың тиң үрә торсын, төрле гайбәткә, имеш-мимешләргә юл куймагыз, төптән килеп эш итегез. Төшендеңме сүзнең ни хакында барганын. «Теплоконтроль» иснәнүчеләрен әйтәм. Син дә кулыңны күп җылыттың, чүп җыюны миңа калдырма. Тиреңне терелә й тунармын юкса, белеп тор!

* * *

Юлбарыс тырнагы — тикшерүчеләр кулында, тик ул берни сөйли алмый. Талисманның хуҗасын табарга кирәк. Үзен «Юлбарыс тырнагы» дип йөртүченең Саркин аркасында әллә ниләр китереп чыгаруы да бик мөмкин. Димәк, җинаятьчене тиз арада суд каршына китереп бастыру хәерле.

Хатыйп Заһитович төрле версияләрнең картасын эшләде. Иң әүвәл аның игътибарын майор Сатлыганов җәлеп итте. Саркинның беренче эше аның кулына килеп керә — бу кадәресенә бәйләнеп булмый, чөнки ул көнне прокуратурада дежурлык эше график буенча аңа тапшырылган. Ләкин бит зыян күрүче Теләшеваның беренче язган гаризасын да, беркетмә дә Сатлыганов тарафыннан юкка чыгарылган. Сатлыгановның Саркиннар белән нинди бәйләнештә торуын ачыкларга кирәк иде. Хатыйп Заһитович бүлек егетләрен шушы эшкә җикте.

Район эчке эшләр бүлегендә заманында Сатлыгановның кем аркылыдыр ансат кына ике бүлмәле фатир алуын әйттеләр. Эш урынындагы чираты әле бик артта булган, ә торакны турыдан-туры шәһәр Советы аша эләктергән. Шул рәвешле эзләнә торгач, сукмак егетләрнең берсен Ярағанов кабинетына китерә. Тик үзе чираттагы ялда икән, күреп сөйләшә алмаган, борылып кайткан. Аның каравы, университетта кайбер нәрсәләрне ачыклаган. Университетның кичке бүлегендә укучы Сатлыганов, берничә имтиханын тапшыра алмый интеккәч, деканатка Ярағанов шалтыраткан, милиционерга ярдәм итүләрен үтенгән — эшне көйләгәннәр. Сукмакның бусы Ярағанов кабинетына икенче яктан килеп керә.

Лаешка да Ярағанов дигән кеше килгән түгелме соң? Хатыйп Заһитович шунда ук район эчке эшләр бүлегенә шалтыратты.

— Бездә Ярағановны белмәгән кеше юк. Толбаев ничә мәртәбә килсә, Ярағанов та шул чаклы булды, хәтта артыгын да,— диде эчке эшләр бүлеге начальнигы.— Әмма соңгы килүен төшенеп бетермәдек, кемнедер эзләде, җәнҗал куптарып китте.

— Ярағанов, дисең инде алайса?— дип кабатлап сорады Хатыйп Заһитович, беренче мәгълүматны китергән егеттән.

— Әйе, тик үзе Юрмалада ял итеп ята.

Егетнең бу хәбәре әллә ни куандырмады Хәбибуллинны. Әгәр фараз кылу дөрес икән, мондый җаваплы чорда ник китеп барган әле ул ял йортына? Башка сыймаслык хәл бу! Ярар, ә сыйдырып карасак? «Качышлы уйнарга ниятләсәгез, мин өченче вариантны кулланырга мәҗбүрмен»,— дигән ич. Аның белән качышлы уйныйлар түгелме соң? Сизенә, димәк, аңлаган эшнең нинди юнәлеш алуын һәм эзне югалту өчен вакытлыча шәһәрдән юк булып торырга ниятләгән. Аннары бәйләнеп кара син аңа. Ярар, без дә төшеп калганнардан түгел, дип куйды Хәбибуллин үз-үзенә. Судны бу атнадан да соңга калдырмаска иде. Энәсеннән җебенә кадәр тикшерелгән, фактлар җитәрлек, барысы дәлилләнгән. Саркинның да теле ачылды, борылыр урыны калмагач, һәр ике очракны үзе үк расларга кереште. «Эш»не судка тапшырасы гына калды.

* * *

Табигате матур Юрмаланың, ләкин холыксыз кәләшсыман ул: әле генә күзне камаштыра торган җете кояш балкый, биш-ун минуттан инде, шәһәр өстен ак болытлар басып ала да шабырдатып яңгыр ява башлый, агач ышыгына яшеренергә генә өлгерәсең, тагын ялтырап кояш чыга. Яраганов диңгезгә кереп бер-ике чумып алды да, кире йөгерде, суының салкынлыгын ошатмады, комлыгына яткан иде, көпшәк гәүдәсеннән үтәли җил өрә башлады. Шуннан соң ул яр буена килмәс булды.

Аның каравы кафе, ресторанда озаклап утырды, бакча уртасында куелган яшь бала зурлыгындагы шахмат фигураларын шалт-шолт сугып уйнаучылар янына тукталгалады, карап кына торды, үзе бу эшкә катнашырга җөрьәт итмәде, чөнки барыбер оттырачак, игътибарсыз уйный. Ә менә, оттырса да, биллиард өстәле янына еш килде. Монысын акчага маташтыралар, ичмасам, кемлегеңне күрсәтү мөмкинлеге бар.

Акча мәсьәләсенә килгәндә, аны рәхәтләнеп тотуның җае да чыкты бит әле. Беркөн шулай ресторанда аз-маз гына төшергәләп утырганда, менә сиңа кодагый дигәндәй, Яраганов өстәле янына ике метрлы, аксыл чәчле, Балтыйк күгедәй зәп-зәңгәр күзле бер чибәр килеп басты.

— Лабдиен — исәнмесез! — диде кыз.

— Цвекки — сәлам! — дип сәламләде аны Яраганов. Ул инде бу сүзләрне беренче көнне үк отып алган иде.

Зәңгәр күз белән алар ресторан ябылганчы сыйландылар, икесенең дә буыннары шактый йомшарган иде. Чыккач та ерак китмәделәр, шул тирәдәге аулаграк эскәмиягә барып утырдылар. Яраганов кызга тәмам күнегеп җитте, күңеле ял, наз сораган икән шул. Тик менә Сармите — кызның исеме шулай иде — борчыла башлады.

— Нишләргә икән миңа? — диде ул кинәт.

— Ни булды, Сармите?

— Мин бит путевкасыз, Ригада кунакханәдә яшим.

— Баш өсте, бүлмәм аерым люкс,— диде Яраганов, шатлыгыннан нишләргә белмичә.— Аннары, башка көннәрне сиңа да барып чыгарбыз. Ә хәзер миңа кирәбез.

— Мин бик бәхетле бүген, Назарис!

Назарис, Назарис... Ошатты бит Яраганов әлеге яңа исемен. Назыйм да, Назар да түгел, Назарис! Нишләп тынчу Казанда ятты икән соң ул шушы көнгәчә?! Менә дөньяның рәхәте!.. Юрмалада төгәл бер атна кунак булгач, Сармите Ярагановны Ригага чакырды.

— Хәзер сине, Назарис, якташың Нәфисә Әпсәләмовна белән таныштырам,— диде кыз Ярагановны «Ленинград» кафесына чакырып.— Ул монда кунак залының мөдире булып эшли.

Ләкин кунаклар заказны Нәфисә Әпсәләмовнасыз гына бирделәр, чөнки бүген мөдирнең сменасы туры килмәгән. Коньяклы кофе эчтеләр,

латышларның милли ашы — дуңгыз мае туралган кара борчак ашадылар. Яраганов кара уылдык, йомшак пешкән ит, шешәсе белән бер коньяк та китертте.

— Хәзер кая?

— Костелга, орган тыңларга!

Яраганов колак тондыргыч уылдауны барыбер ошатмады. «Чыгыйк әле, баш авыртып тора»,— диган булды. Сармите чыгуын чыкты, тик автобуска утыртып, Назарисны тагын каядыр алып китте.

— Адаштырмакчы буласың, ахрысы, матурым,— диде Яраганов, автобуска кереп утыргач, Сармитенең култык астына башын төртеп.

— Назарис! — Гаҗәпләнү, иркәләү белән әйтте Сармите бу сүзләрне.— Ачык һавадагы этнографик музейга алып барам мин сине.

— Ә син чибәр дә, акыллы да, Сармите! Син үзең Балтика, Сармите! Бал-ти-ка! Рәхмәт, җаным,— дип тә өстәде Яраганов.

— Нәрсә дидең, Назарис?

— «Рәхмәт»не татарча әйттем.

— Рэх-мэт, рэх-мэт...

Тау башында, нарат урманы уртасында үзенең күп санлы һәм күп төрле җил тегермәннәре, сиртмәле, чыгырлы коелары, озын-озын ригалары — борынгы йортлары белән этнографик музей күренде. Латвиянең төзек һәм чиста башкаласы Рига шәһәреннән соң бер генә гасырга булса да кире кайту иде бу.

Кызык. Ярагановлар авылында элек өсте ябулы ындыр табагын «рига» дип йөртәләр иде. Күрше урыс авыллары Зюзино, Наумовкада да шулай атыйлар иде аны. Латышларда «рига» торак диганне аңлатсын да ди, ә ул ничек итеп татарларга килеп кергән? Монысы гаҗәбрәк. Төпченеп карый торгач, Яраганов ике арадагы ниндидер уртаклыкны да табып алды. Рига дигәннәре, дистәләрчә метрга сузылган бер төсле тигез бүрәнәләрдән салынган озын бина. Аның бер башында терлек-туар асралган, аннан соң утынлык, печәнлекләргә бүленгән, урталыкка сугылмаган көлтәләр, ашлык буралары куелган, шуннан соң торак йорт өлешен ясаганнар. Тарихи авыл музее латышларның үткәндәгеләрен мәңгеләштергән.

Аннары, алар елга буйларын, милли тыюлык зонасына кергән табигать байлыкларын, җәнлек, кош-кортларны карап йөрделәр. Ригага кичке якта гына кайтып төштеләр.

* * *

Күргәннәре бай, кичерешләре тәэсирле булса да, Ярагановның күңеле тыныч түгел иде. Әллә күп йөреп йончыдымы, әллә инде Казан хәлләре исенә төштеме — нигәдер үзәге өзелде. Үзе музей карады, табигать кочагында йөрде, уй-фикерләре Казаннан арына алмады. Ул, бу халәтеннән котылырга теләп, уйламаска да тырышып карады — барып чыкмады. Инде Сармите «Ай» ресторанына өстери башлагач, ныклы бер карарга килеп, аңа санап-нитеп тормыйча бер уч акча тоттырды да, үзе элемтә бүлегенә кереп чыгарга ниятләде.

— Ни кирәк, шуны ал: тавык ите, уылдык, коньяк, гомумән, үзең беләсең,— дип Сармитене ресторанга озатып калды.— Шушында килермен, көт, озак тормам.

Бирелгән заказның бик тиз үтәлүенә шаккатты Яраганов.

— Кая югалдың син, туң баш? — дип чәрелдәде Сүриясе.— Нигә шалтыратмыйсың? Телеграмманы алгансыңдыр бит?..

— Тукта, туктале, юньләп кенә сөйлә, ни булды? — дип ялварды Яраганов, үзенең эче жу итеп китте. Сүриянең аның белән беркайчан да болай дорфа сөйләшкәне юк иде.

— Шулмы җизнәлегең, яратуың?— Сүрия үксеп еларга тотынды.— Харап иттеләр балакайны. Сигез ел...

— Югары суд бар ич әле, Сүрия, җайланыр.

— Син инде үзеңне җайла, яме,— диде хатыны ачу белән.— Барысын да актаралар монда.

Ярагановның башка сөйләшер әмәле калмады, телефон трубкасын ташлап, ишеккә юнәлде. Ничек тә иртәгә кадәр түзәргә кирәктер инде.

— Ой, ой, ни булды сиңа, Назарис?— дип, куркып каршылады аны Сармите. Чыннан да, мәет төсенә кергән иде Яраганов бу мизгелдә.

— Берни юк, хәзер үтәр ул, арылган. Хәзер кая барабыз?

— Әйттем ич, миңа, дип. Бер генә чат аша. Син әйткән ризыкларны җыйдым, җитәрлек. Киттек алайса!

Сармите диңгезчеләр кунакханәсендә яши икән. Даугава елгасының уң яр буена урнашкан. Тәрәзә каршына кораблар туктаган. Урамы тыныч, аулак. Сайлый белгән Сармите кунакханәне.

Бер кичкә — кер мичкә, диләрме, Яраганов иртәгегә кадәр һәммәсенә дә түзәргә карар кылды. Хәер, аның башка чарасы юк та иде бугай бу минутларда. Ашыгып ни бар, бүген-иртәгә генә хәлне үзгәртеп тә булмастыр, юктыр, сабыр итәргә, бушанырга һәм төптән-җирдән уйлап эш итәргә кирәктер. Бу сары телеграмм баганасы белән дә араны иртәгә үк өзәчәк.

Кунакханәнең бормалы тар баскычларыннан күтәрелгәндә, аннары керсәң адашып калырлык бормалы тар коридорларны үткәндә Сармите туктап-туктап сөйләп барды.

— Беләсеңме, Назарис, элек бу йорт фәхешханә булган. Сугыш елларында, немец офицерлары монда рәхәтләнеп типтергәннәр. Күрәсеңме коридорлар ничек кисәк кенә борыла, тарлыгын кара, тарлыгын! Менә бусы — минем бүлмә, үзем сайлап урнаштым. Эт тә таба алмас үзеңне, шикләнмә! Хәзер без синең белән рәхәтләнеп ял итәрбез, мин шундый арыдым, Назарис, басып торыр хәлем дә калмады. Йә, күтәр башыңны, нигә шул тиклем мәлҗерәдең әле. Берәр рюмка тоткач бетә ул, борчылма!

Бәлки коньяк, чыннан да, юып төшерер күңелендәге юшкынны. Әле Сармите такылдый бирсен, аннан ни зыян. Кинәт кенә күңелсезләнеп калган Ярагановның кәефен күтәрү өчен кыз барысын да эшләде, өстәлне мул хәзерләде, кыстый-кыстый сыйлады, коньякны рюмкага салып кына торды. Башка чакларда нормадан чыгуны белмәгән Яраганов бүген чөмерде дә чөмерде, ничек түнүен сизми дә калды.

— Назарис, тор инде тор, озак йокладың, бар, юынып кил,— диде киенергә өлгергән Сармите.

— Баш чатный.

— Төзәтерсең, юын.

Кичтән җыештырылмаган табынга утырдылар. Яраганов баш төзәтерлек дәрәҗәдә генә коньяк салды.

Сармите өстәл янынннан беренче булып кузгалды, тумбочка янына барып утырды. Анда акчалар тузгып ята иде.

— Игътибар белән тыңла әле, Назарис,— дип сүз башлады кыз.— Синең монда нибары өч мең сум акчаң калган, үзеңә тотарлык кына. Миңа егерме мең кирәк. Хатыныңнан соратып ал әле шуны!

— Син — авантюристкамы?

— Атналар буе хезмәтемнән файдаланганда авантюристка булмадым бер дә,— диде Сармите кинәт кырт борылып. Ул Ярагановны тишеп үтәрдәй итеп текәлде, ике кулын аның тез башларына куйды.— Давай-давай, сатулашма, дәваланырга кирәк миңа. Һәм, уйлавымча, сиңа да. Минем монда бик яхшы профессор бар, ләкин аңа күп акча түләргә кирәк — шунсыз алынмый. Үземә генә булса, бәлки ун меңгә дә ризалашыр иде, сине дә әйтсәм, егермесез сөйләшеп тә тормаячак.

— Мин авырмыйм бит, Сармите.

— Анысын миннән сора инде син, Назарис. Миндә — СПИД,— диде Сармите.— Чит илгә йөрүче диңгезче егет бүләге. Азынганнан-азына бара.

Яраганов кисәк кенә айнып киткәндәй булды, коелып ук төште. Каптым, беттем, гомернең өзелүе шушыдыр, дип уйлады ул. Куркуы ачу булып кабарды, Сармитены нишләтергә икән хәзер дип уйлады.

Кичә бүлмәгә килеп кергәч, Яраганов чәчәксез, сусыз кукыраеп утырган бәллүр вазаны өстәлдән алып, телевизор өстенә куйган иде. Күзе шуңа төште. Тагын бер кат карашы белән бүлмәне айкап чыкты, ләкин ул авыр вазадан да кулай әйбер күрмәде.

— Син дөресен сөйлисең инде алайса, Сармите? — дигән булды, кызны сискәндермәс өчен, йомшак кына итеп.

— Минем көннәр санаулы.

Яраганов, нindидер бер кыргыйлык белән вазаны эләктереп алды да, аны ике куллап тотып, бар көченә Сармитенең башына китереп орды.

Ул ничә тапкыр сугуын да белештермәде, стенага, тумбочка-өстәлләргә кан чәчрәде. Яраганов тиз генә пиджагын барып алды да кесәләренә акчаларын тутырды, паспортын Сармите күкрәгенә яшереп өлгергән икән, шуны күреп, бераз сөенде дә шикелле, кан тапларын сөртә-сөртә, аны акчалары янына салып куйды.

Инде кеше күзенә бик чалынмыйча гына чыгып сызарга кирәк бу мәхшәрдән. Бүлмәне бикләде дә ачкычны палас астына яшерде. Бәхетенә күрә, вахтер хатын дөньясын онытып кем беләндер сөйләшеп калды — чыгучыны шәйләмәде. Хәер, монда андый төпченү гадәте юк икән. Кичә дә, кем белән керәсез, ник керәсез, дип сорашып маташмадылар.

Урамга чыккач, Ярагановны яңа курку басты. Туктале, ул бит кеше үтерде. Хәзер кая барырга соң? Кай тарафка юл тотарга? Мәскәүгә? Ленинградка? Башта Таллингадыр, бәлки? Иң элек бу тирәдән ераграк китәргә, әлбәттә, эз калырга тиеш түгел.

— Эй, такси!

Кешесе юк икән. Яраганов арткы утыргычның бер почмагына кереп сеңде.

— Кая барабыз? — дип сорады таксист.

— Шәһәр читенә.

— Риганың, бер ягы су булса да, өч ягы җир бит аның, гражданин.

Яраганов тагын дерт итеп китте, чөнки аңа беркайчан да болай эндәшкәннәре булмады. Җинаятьчеләргә, гаеплеләргә генә шулай дип мөрәҗәгать итәләр. Гомерендә суд юлын күрмәгән адәм бүген кеше үтерде. Юк-юк, аның берәүне дә үтерәсе килмәде. Сармите үзе шуны сорагандай кыланды ич. Нәрсә диде, син дә үләчәк, сиңа хәзер акча кирәкми, диде ул.

— Мин сезгә йөз сум, мең сум түлим.

— Миллионермы әллә сез? Шәһәрнең кайсы ягына барабыз,— дип сорыйм.

Таксист, әллә гаҗәпсенеп, әллә шикләнеп, Ярагановка борылды, аның киндердәй агарынган йөзенә текәлде.

— Сездә бәхетсезлекме? — дип кызыксынды таксист.

— Шулайрак.

— Алайса, сүзем юк.

Юл озын иде. Яраганов Сармите турында бөтенләй уйламады. Ул күңеле белән Казанны гизде. Аны иң беренче төп башына утыртучы Хәбибуллин икән. Теге чакта зәңгәр ут яндырып алдаган, шуның аркасында юлбарыс тырнагы кулдан ычкынды. Ул бит аны ничә еллар бәла-казадан саклап килде, карьерага юл ачты. Изге әйберне акча урынына салмаска иде шул. Акча гына биргән булса, үкенмәс тә, мондый хәлләр килеп чыкмас та иде, бәлки. Җимерелде дөньясы, чәлпәрәмә килде планнар. Казанга кайту тәмугка үз аягың белән барып керү түгелме соң? «Син дә, мин дә үләчәкбез»,— диде бит әле теге әшәке

хатын. Үзе дөмекте ич инде. Ә Назыйм нишләргә тиеш? Ул кая бара? Ул кайчан үлә?

— Таксист, сулга борыл, асылма юл вагонына утырасым килә, мине шунда калдыр, ә үзең күпердән Гауяның аргы ягына чыгып, мине көт. Мә, акчасын хәзер үк ал.

Биш данә йөзәрлекне кулына тоттыргач, таксист тотлыгып ук калды. «Бу ничек була, бу ничек була?» — дип кабатлап торды. Ә эченнән генә, бу кеше — йә чит ил шпионы, йә бик хәтәр бандит, дип уйлап алды. Милициягә тапшырасы иде үзен...

Аска карасаң, баш әйләнерлек биеклек. Ә анда ыжгырып Гауя елгасы ага. Ярагановның мондый тиз агышлы суны беренче күрүе, кичә, гаҗәпкә калып, ярында басып торганнар иде.

Кечү станциясендә бүген туристлар күренми, билетны шунда ук тоткарлыксыз сатып алды. Вагонда да ике-өч кенә кеше. Ярдан ерагаеп, елга уртасына якынлашкан саен биеклек арта сыман тоелды. Ярaганов җиргә, станция ягына карады. Әнә утлы, сарыга буялган ике машина килеп туктады. Милиция! Юк, әнә, кузгалып та киттеләр, аска, күпергә төштеләр. Нигә килгәннәр? Кая баралар? Каршы як ярга, әлбәттә. Аны эзлиләрме? Булмас ла?! Ә нигә кабаланалар соң? Башта станциягә, вагонга өлгермәгәч, теге якка ычкындылар. Кара, ничек җилдерәләр, инде күпергә дә керделәр...

Ярaганов сиздермичә генә вагон ишеген ачты да бушлыкка сикерде, аның йөрәк яргыч тавышы гына ишетелеп калды. Күпер өстендә туктап калган милиция машиналарын ул инде күрмәде, гомумән, үзе белән ни булганын белмәде, рәхәтлек катыш газап эчендә йөзгән мизгелен генә тоеп калды.

Кичкә таба Ярагановның гәүдәсен Гауя елгасының түбән агымыннан табып алдылар. Врачлар аның суга тончыгып түгел, йөрәге ярылып үлгәнлеген ачыкладылар. Һавада очып төшкәндә үк, куркудан шартлаган мәрхүмнең сабыр йөрәге.

Тагын шунысы гаҗәп: Ярагановның мәетен Казанга алып кайтырга дип Ригага Сүрия түгел, балдызы Ләлә килгән иде. Әмма аңа җизнәсенең үлеме турында ачык кына берни дә әйтеп тормадылар, фаҗигале рәвештә һәлак булды, диделәр.

Казанга кайтып төшкәндә кара-шомырт чәче ап-ак булган иде Ләләнең. Килешми икән аңа ак чәч, чибәрлеге югалды. Ак чәч янәшәсендәге кара фаҗига төсмерләрен ул үзе генә чамалый иде.

## Зөлфәт

# МАТУР БАБАЙ

Чор куркыныч булган...
Шул чорда да
Булганбыз ла без —
шук малайлар!
Шуклык өчен колак бора торган
Авылга бер Матур Бабай бар.

Һай, соклангыч иде яралары! —
Кылыч, камчы, богау эзләре...
Зарланганын һичкем ишетмәде,
Сызланганын беркем сизмәде.

Тиран чоры мыни шул балачак? —
Без — кәлҗемә буын — сизмәдек:
— Матур бабай гел Ысталин сыман,
Бигрәк чибәр! — диеп сөйләдек.

— Их, егетләр! — дияр иде бабай.—
Яратуны сезме беләсез?! —
Сез бит көлеп кенә үбәсез дә,
Үбеп туйгач ятып көләсез...

Ә мин менә
Чапай белән чакта
Бозлы суны йөзеп чыктым да
Чибәркәйнең кочагына аудым —
Сикергәндәй булдым упкынга!

Ә сез?..

...Шаян бабай, Матур Бабай!
Тәрәзәңнән карап торасың,
Шомыртларың аша карыйсың да
Серле итеп тамак кырасың.

Матур Бабай! Йортың алдындагы
Ак шомыртлар һаман куерды —
Ил тутырып чәчәк атарга соң
Ходай үзе мәллә боерды?

Ак шомыртлы синең йорт ишыгың,
Урам ягындагы читәнең
Аулак оя булды гашыйкларга,
Мин дә аны читләп үтмәдем...

Ләхетлеккә такталарың әзер...
Шаккаттырдың кинәт авылны —
Хәтта ләхет такталарың, бабай,
Сөю нуры булып кабынды.

Көннәрдән бер гаҗәеп бер көндә
Сискәндереп Сәрби апаны,
Алып чыкмасынмы Матур Бабай
Ләхетенә дигән тактаны!

— Чөкердәшсен әле гашыйклар! — дип,—
Борчылма,— дип,— карчык, бул тыныч!—
Ясап куйды шомырт ишыгына
Гөл шикелле матур утыргыч.

— Былбыл моңыннан да дәртлерәк шул
Мәхәббәттән янып әйткән сүз...
Гомер буе юктан йомгак чорнап,
Юк йомгакны, карчык, сүткәнбез!

Килче, кая, бер кочаклыйм әле...
Шомырт исе килә бөркелеп!
— Яшьләр сүзен тыңлап котырасың! —
Сүт шул утыргычны, карт тиле!

...Кайттым. Күрдем.
Матур Бабай салган
Йорт нигезе иңгән. Чүп баскан.
Безне кавыштырган утыргычның
Эзе дә юк хәтта ичмасам...

Участковый миңа сөйләп бирде:
— И туганкай, ниләр әйтергә?
Күптән дөньяда юк Матур Бабай,
Елмаюы гына хәтердә.

Сөя белми бугай яңа буын...
Бер дуңгызы, әнә, нишләде —
Гашыйкларга дигән утыргычта
Төнбоектай кызны көчләде!

Матур бабай үлгәч,
Утыргычта
Сүгенешеп һаман эчтеләр
Һәм тән язар өчен
Матур карттан
Калган йортны хәтта иштеләр.

Денсез буын килде бу дөньяга —
Итек салмый түргә менүче.
Бисмилласыз агач утырткanбыз —
Шуңа сөмсез аның җимеше!

...Матур Бабайлы чор! Сөю чоры!
Җилләренә кадәр исемдә! —
Төш күрмичә йокла, Матур Бабай —
Безне күрүең бар төшеңдә...

Оҗмахта да шаяртасыңдыр син:
— Җәннәт бакчасымы чын бакча? —
Их, гашыйклар сайрашадыр анда —
Минем утыргычта таңгача!

Сөю сүзе сеңгән шомырт исе...
Менә кайда иде чын җәннәт! —
Кош сайратып үбешәләр анда —
Кайтып килик мәллә, җәмәгать?!.

...Кемнәр булып үсәр
бүген җиргә
Яланаяк баскан малайлар?
Яраттыра торган утыргыч юк...
Һәм күптән юк
Матур Бабайлар.

## Чишмә күзләре

Сикерәм дә чыгам читәннән һәм...
Карт бер каен
ындыр артында.
Җаны елый мәллә шул каенның? —
Төпләреннән чишмә саркыла...

Юклыгына күптән ул каенның.
Йомылдылар чишмә күзләре.
Карашларын аның тоймак булып,
Үле җиргә килеп тезләндем.

...Җан түрендә уянды шул чишмә.
Шавын каен чөеп болытка:
«Икәү чагылдыгыз суда! — диде, —
Бәдрә малай, шуны онытма!»

Җан түрендә уянган бу чишмә
Чылтырасын шулай, җырласын!
...Дөньяда юк чишмә күзләреннән
Томраеп син карап торасың...

## Шайтан коткысы

Син коега төкерергә өйрән!
Утка төкер! Ризык капканда
Бисмилланны берүк әйтә күрмә!
Сүгенеп ят кичен ятканда!

Гел атлап чык яткан көянтәне.
«Эһ-һем!» димичә ач мунчаны.

Дустың йортына гел терәп кенә
Тергезгәләп җибәр учагын.

Кызлы капкаларга дегет буя.
Күпләп бурыч ал да — түләмә.
Чын дөресен белсәң, эчеңә йом —
Һичкемгә дә берүк сөйләмә!

Өйрәнеп ал аяк чалу серен —
Мәтәлсеннәр! Үзең мәтәлдер,
Үзең тартып торгызгандай кылан.
Тормый икән — җырла матәмне.

Елый-елый мәдхияләр сөйлә!
«Җаным!» — диген
жанын алганда.
Шулай яшәсәң дә, агай-эне,
Туры гына килер таманга!

Яраттыр да чыгып ычкын һәрчак:
«Көт, жаныем, хәзер кайтам!» — дип...
А што? —
Һичкем синең паспортыңа
Язмаган бит әле: «Шайтан» дип!

## Гозер

Дулкын гомерен бир миңа, Ходам! —
Җил һәм диңгез мине бар итсен.
Мине кабер түгел —
еракларда
Кыяларга тигән күк көтсен...

Язсын берүк
төпсез күккә ыргып,
Азат куәт булып дуларга —
Актарылып
горур таш кыяга
Ташланырга... Шунда тынарга.

Гөрселдәсен йөрәк тибешләре,
Шул кыядан ашсын күкләргә —
Күтәрелсен барлык хыялларым
Күкләр белән бергә күкрәргә...

...Исән чакта
«Яши» димәсеннәр,
«Нинди дулкын килә!» дисеннәр,
«Гашыйк булган! Бу кушылган ахры
Тиле дулкын белән!» дисеннәр.

Мин теләмим язмышларын утның,
Җилнең, болытларның, тимернең...
Тик бер генә гозерем бар, Ходам:
Бир син миңа дулкын гомерен!...

...Ниләр генә уйлатмыйсың, дингез!
Каян килә юләр бу фикер?
Чынга ашмас хыял!
Ә шулай да...
Бәлки Ходай мине ишетер?..

## Язгы су

Хәтерлисең микән —
кар астында
Сулар чылтыраган ул кичне?
Җир җылынды йолдыз карашыннан,
Үзәннәргә язгы су төште...

Чылтырады сулар кар астында...
Бу — безнең яз иде!
Әле дә
Митингитлы сырхау бу дөньядан
Колакларым тонган хәлемдә.

Элмәк эләр өчен җайлы урын
Эзли торган кыен чакларда
Кар астыннан шул яз чылтыравы
Саркып чыга... Җанны актара.

Мин йотлыгып эчәм бу дөньяны!
Әллә соң бу — үзе язмышмы?
...Җем-җем килеп кар астында ага
Мәхәббәтем минем — язгы су...

## Имән

Кайчан илһам килгәнен мин беләм
Һәм һәрвакыт әзер мин аңа —
Борын заманнарда яшәгән бер
Имән шавы җанда уяна.

Җан күчәнә, диләр...
Газраилнең
Канат җиле миңа тигәндә
Бер өн булып күчәр ахры җаным
Мәңге гүләп торган имәнгә.

Йолдыз нурын эчәр ябалдашлар,
Нык тамырлар җирдән сут ташыр —
Гаҗәеп бер яңа язмыш булып,
Җир белән Күк миндә тоташыр...

Әлләни сер түгел лә ул бәхет,
Күптән аңладым ла мин аны!
Бәхет —
пакь чирәмгә ялгыз ятып,
Имәнгә баш салып уйлану...

# Роза Хафизова

## АККОШЛАР СЕРЕ

ПАРЧАЛАР

Диңгез өстендә яктызадә аккошлар гаиләсе йөзә. Озын муенлы, мәһабәт гәүдәле ата аккош янәшәсендә әле яңа гына тернәкләнеп килгән ике бала кош. Аларның әлегә канатлары да кыска, муеннары да нечкә. Әмма үз-үзләрен тотышыннан, салмак, зифа хәрәкәтләреннән үк күренә: болары да мәһабәт, горур аккош булып үсәчәкләр.

Алардан унбиш-егерме метр читтә җыйнаграк гәүдәле, таушалганрак кыяфәтле әнкә аккош йөзә. Ата аккош белән балалары, башларын суга тыга-тыга, тыныч кына тамак ялгыйлар. Ара-тирә өчесе бердәй чөкердәшеп алалар. Андый чакта әнкә аккош башын аларга таба борып, озак кына карап тора. Кайчакларда чөкердәшкән гаиләсенә таба омтылып та куя. Әмма ата кошның үзенә таба ыслап сузылган башын күреп, шундук читкә борыла. Ата аккош тамак ягын кайгыртып, балаларыннан читкәрәк китә-нитә калса, әнкә кош шундук балалары янына томырыла, алар белән чөкердәшкәндәй итеп ала. Әмма мондый бәхетле мизгелләр аңа бик сирәк насыйп була. Ата аккош һаман балалары сагында тора. Әнкә аккошның балалары янына борылуын күрүгә үк, дөньясын онытып, аңа ташлана һәм рәхимсез чукый-чукый куалап җибәрә.

Әнкә аккошның бөтен барлыгы, торышы, кыяфәте миңа аңлаешсыз ниндидер моң, хәсрәт пәрдәсе белән өртелгән кебек тоела. Ни булган бу аккошлар гаиләсенә?! Әнкә аккошның үз гаиләсе, балалары алдында ни гаебе бар аның? Әллә соң аккошларда да бер-береңә хыянәт итү кебек гадәтләр бар микән? Әллә соң бу әнкә аккош үз юлдашына хыянәт иткәнме? Аккошларны бер-берләренә бик тугры, ялгыз гына яши дә алмыйлар, берсе һәлак булса, икенчесе аның артыннан үзүзен кыя-ярдан атып, дөнья белән бәхилләшә, диләр иң. Биредә исә хәсрәтеннән ябыгып, нәүмизләнеп калган әнкә кошны ата кош нәнилере янына якын да җибәрми.

Балтыйк ярына йөрергә чыккан саен аккошлар гаиләсен күзәтәм. Әнкә аккошны кызганып, аның өчен йөрәгем сызлана. Аларны күзәтүче бер мин генә дә түгел. Биредә ял итүчеләр һәммәсе аккошлар янына тукталып, шушы хәлгә игътибар итәләр. Һәркемнең телендә бер сорау: нигә шулай? Әмма беркем дә бу табышмакка җавап таба алмый. Барысы да әнкә аккошны кызганалар. Алып килгән күчтәнәчләрен әнкә аккошка ыргытырга тырышалар. Тик ризык бик сирәк очракларда гына әнкә аккошка эләгә. Чөнки ата кош аның ризыкка үрелүен күрүгә, канатларын дәһшәтле җилпеп, гайрәтләнеп оча-йөзә килә дә аны бастырып куып җибәрә. Тегесе, гадәтенчә, каршылык күрсәтми, сабыр гына читкә йөзеп китә. Әйтерсең лә гаиләсе алдында чамасыз зур гаебе бар аның һәм шуның җәзасын күрә.

Бүген дә кичке аштан соң диңгез буена төштем. Әнә ул минем серле, табышмаклы аккошларым. Ата аккош балаларын канат астына алган да тыныч кына йоклый. Алардан шактый читтә, башын канат астына тыгып, әнкә аккош баскан. Аның йокысы да борчулы, ахры. Ара-тирә кузгалып, тирә-юньне күзәтеп ала.

Башымны бертуктаусыз бер уй боргычлый: ни булды сезгә, аккошларым? Ник бер-берегездән биздегез? Аккошлар бит сез, яктызадә кошлар.

Мин аларның серен аңламакчы булып газапланам. Шулчак башыма гап-гади уй килә! Күпвакыт кешеләр хәтта үз тормышларында да акны карадан аера алмыйча адашып йөриләр ич. Бер-берләрен өзелеп сөйгән кешеләр дә йә чамасыз җүләрлек, йә кыюсызлык, йә булмаса башка юк кына сәбәп аркасында кавыша алмый ялгыз гомер кичерәләр. Бәс, шулай булгач, кешегәме соң аккошларның серен аңлау?!.

## АКЧАРЛАК ЯЗМЫШЫ

Акчарлаклар! Аклыклары, пакълекләре белән дан алган, җырларда җырланган диңгез кошлары! Дюналар, безнеңчә әйтсәң, ком бураналары өстенә басып, акчарлакларны күзәтәм. Алар диңгез өстендә анда-санда уйнаклап алалар да, төркемнәре белән шәһәргә таба очалар. Шәһәрәтле Балтыйк диңгезе буена беренче генә килүем, шуңа күрә биредә миңа һәрнәрсә яңа. Ни-нәрсә белән туклана икән бу кошлар, дип уйланам. Шактый вакыт инде яр буенда килəп сарам, әмма бер генә акчарлакның да судан балык эләктергәнен күрмәдем. Кара диңгездә акчарлакларның судан балык аулавын кәлә-кәлә күзәтә идек ич.

Көн эссе булуга карамастан, диңгездә су керүчеләр анда-санда гына. Ял итүчеләр күбрәк ком өстендә кызыналар яки яр буйлап, ашыйкмый гына әрле-бирле йөреп торалар. Шундый эссе көнне, аяк астында мул сулы диңгез ымсындырып торганда, су коенмый ничек түзмәк кирәк!

Тиз генә чишенеп, суга таба йөгердем. Әмма су читенә җитүгә, кисәтүле тавыштан туктап калдым.

—Диңгездә су коенырга рөхсәт ителми. Диңгез суы бактерияләр белән зарарланган!

Бер аягым белән суга кергән килеш ымсынып, зәңгәр дәрьяга карап каттым. Аяк астымда анда-санда үлгән балыклар елкылдашып ята. Алар су өстендә дә күп икән ич. Менә сиңа мә! Диңгез хәтле диңгез суын коенырга яраксыз итәр өчен, ай-һай, күп тырышырга кирәк булгандыр.

Баш очымнан гына чыркылдаша-чыркылдаша акчарлаклар көтүе узды. Кәефем кырылды. Суында коенырга ярамый торган диңгез ник кирәк ул миңа?

Тиз генә киендем дә шәһәргә юл алдым. Гүзәл архитектура байлыгы, халкының югары мәдәниятле булуы белән дан алган гүзәл кала! Таш түшәлгән шәһәр урамнарының чисталыгына, йортларның төрлелегенә, реклама-белдерүләрнең зур зәвык белән эшләнүенә сокланып авыз ачып йөрим. Шәһәр күгендә бертуктаусыз акчарлаклар очына. Алар, аксыл тәтен пәрдәсе каплаган күктә уйнаклап алалар да, дәррәү каядыр төшеп юк булалар. Нишли икән бу кошлар шәһәр эчендә?!

Түзмәдем, акчарлаклар төшеп югалган бер төбәктә шәһәрнең үзәк урамыннан читкә тайпылдым һәм, бер-ике адым атлауга, гаҗәпләнеп туктап калдым. Ике йорт арасында тезелгән тимер чүп әрҗәләре өстендә йозләгән акчарлаклар кунган. Алар, кырмыскалар кебек, зур тырышлык белән чүплектән ризык эзлиләр. Бер-берләре белән чукышып алалар, чыркылдашалар. Ара-тирә дәррәү һавага күтәрелеп очалар. Ап-ак кошлар, акчарлаклар! Зәңгәр диңгезләрнең аерылгысыз бизәкләре! Чүплекбаш иялəренә әверелергә мәҗбүр булган горур диңгез кошлары!

Акчарлакларның чүплек өстендә әвәрә килүләрен, йөрәгем әрнеп, озак күзәттем. Аларның ачынып чыркылдашуларында бөек диңгезне агулаган һәм горур кошларны шушындый хурлыклы хәлгә төшергән адәмнәргә каһәр-каргыш ишетелә кебек иде.

Ибраһим Сәлахов

# КАРА КӨННӘР

ИСТӘЛЕК

1956 ел. Көз. Казан. Инде иртәдән бирле кар катыш яңгыр ява. Җил. Мин «Татарстан» кунакханәсеннән Бауман урамындагы Матбугат йортына киләм, култык таякларында. Җил каршы. Салкын тамчылар битне камчылый. Мин, алардан сакланырга тырышып, йөземне әле уңга, әле сулга борам. Ул арада таяклар таеп-таеп китә — егыла язам. Узып баручылар тотып калдылар, рәхмәт төшкере. Ә мин һаман барам, ашыгам. Күңелдә... яз! Сөенеч! Кемгә генә соң аларны түгеп-ярып салырга! Ташый, чайкала, дулкынлана күңел. Бу көтелмәгән шатлыктан ярсып ашыгам.

— Йа, алла! Янымнан ашыгып узып барган бер ханым, җан тавышына кычкырып, тотып калырга тырышып, миңа кулын сузды. Ә минем таяклар кинәт таеп китеп, икесе ике якка атылдылар, үзем карлы асфальтка капланып төштем. Кемнәрдер күтәреп торгыздылар, өс-башымны каккаладылар, сөрттеләр. Бүрегемне кигезделәр. Таякларымны тоттырдылар. Ниһаять, Матбугат йорты!

Ниндидер бер миһербанлы кыз, зур авыр ишекне ике куллап тартып, каерып ачып торды. Мин ашыгып, рәхмәт әйтергә дә онытып, таякларым белән шакы-шокы килеп, эчкә уздым — аллага шөкер!

30 нчы елларда бу «аякларына бастырып» куелган китап шөкелендәге мәһабәт бина урынында, кеп-кечкенә кибетләр — НЭПның соңгы, сулып барган «чәчәкләре» тезелгән иде. Аларны бер көндә сүтеп ыргыттылар. Аннан тирән-тирән чокырлар казыдылар. Ә без — Гажур ячейкасындагы комсомоллар — аркаларга камытлар асып, кирпеч ташыйбыз. Өмә! Һаман биегрәк, биегрәк!

Хәзер мин ялгыз, үз-үземне көчкә-көчкә күтәреп, киң мәрмәр баскычлардан абына-сөртенә, әнә егылам, менә егылам дип, югарыга ашкынам. Язучылар Союзы идарәсенә! Кесәмдә 14 ел зарыгып, өметләнеп вә өметсезләнеп көткән соңгы таяныч: әбелхаят — яшәү кәгазе! Бу бөек сөенечне кем белән генә бүлешергә! Кемнән сөенче сорарга!

Арып-талып, тирләп-пешеп, мышнап күтәреләм дә күтәреләм. Таяклар шыгыр-шыгыр киләләр. Бер баскыч. Икенче. Кинәт өске каттан, кемдер ашыгып килеп төште дә, мине кочаклап алды:

— Ибраһим! Бу синме...

Таяклар, шалтыр-шолтыр килеп, баскыч буенча түбән тәгәрәделәр.

Кави аганың кайнар күз яшьләре минем битемә тамды.

1931 елны мине «Яшь ленинчы»дан «Кызыл яшьләр» редакциясенә, әдәби бүлек мөдире итеп күчерделәр. Бу күчерү, нигездә, баш редактор Фатих абый Исхаковның, фанер белән бүленгән кетәге артыннан коридор уртасындагы озын өстәлгә — газетаның җаваплы сәркатибе Галимҗан Мөхәммәтшинга каршы килеп утырудан гына гыйбарәт иде. Чөнки без өч редакция «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Авыл яшьләре» журналы редакцияләре барыбыз да элекке бер кибетханәдә (Пассаж) урнашкан идек.

Безнең бу берләштерелгән «үзәк»кә кичкырын олы язучылар, шагыйрьләр дә килеп чыгалар — безгә үзләренең яңа әсәрләрен укыйлар, кайберләрен редакциягә калдырып китәләр иде.

Аларның барысы да ни өчендер хәрби киемнән (шинел, шлем, итекләр). Тик күбесенең шинель яка очларындагы кызыл петлицалар сүтеп алынган. Такташ, Әбүзәр Түрәй, Әсгать Айдар, Габдрахман Минский... Ә менә бездә сирәк-мирәк кенә күренеп китә торган урта буйлы, тулы гәүдәле, озынча шадра битле Кави ага өстендә һәрвакыт затлы постаудан тегелгән шинель. Шинель петлицаларында янып торган чия төсендәге өчәр шпал. Башында калыплап тегелгән, бер җыерчыксыз шлем. Аякларында ялт-йолт итеп торган хром итекләр. Димәк, ул — хәзер дә хезмәттә һәм югары дәрәҗәдәге хәрби комиссар. Ул чор газета-журналларында һәрдаим аның шигырьләре, хикәяләре, мәкаләләре күренә: бер-бер артлы китаплары басылып тора иде. Ул инде «биш йолдыз» (Такташ, Туфан, Кутуй, Кави, Толымбайский) арасында үз урынын алган.

Ул еллардагы татар әдәбиятының менә шундый йолдызлары килгәндә, безнең караңгы редакция бүлмәсе чын-чынлап яктырып, нурланып китә — дәрт, илһам белән тулып ташый иде. Аларның бит әле һәркайсы безгә иҗади ярдәм кулын суза — шигырьләребезне, хикәяләребезне «иплә-сипләп» калыпка кертә — матбугатка чыгарлык хәлгә китерә. Ул гына аз булса:

— Кара әле Сәләх (Ул елларда фамилиянең койрыгын кисәләр иде.)...— шулай бер көнне Галимҗан Мөхәммәтшин кайдандыр ашыгып кайтып керде дә, гадәтенчә, ишектән үк тавышланып, сөйләп китте: — Кремль мәйданында Кави аганы очраттым, бүген сәгать бишләрдә Сәббух Рафиковны, Ибраһим Сәлаховны алып, дивизия сәяси бүлегенә кил! Бик әһәмиятле эш бар,— диде.

Мәскәүдә Востоккино идарәсе, аерым республикаларда милли киностудияләр торгызу максаты белән, быел өч шәһәрдә: Ташкент, Казан һәм Бакуда киносценаристлар әзерләү цехы ача икән. Кави ага болай диде:

— Без ТАПП (Татарская ассоциация пролетарских писателей) утырышында киңәштек тә сезләргә тукталдык. Кино тудырыр өчен иң элек талантлы сценаристлар әзерләргә кирәк.— Кави ага сүзен бүлеп, өстәл тартмасыннан бер табак кәгазь алды да, һәрберебезгә тукталып, тәфсилләп исем-фамилияләребезне, туган елыбызны, белемебезне, иҗат жанрыбызны язып чыкты һәм, ниһаять, елмайды. — Шулай итеп менә сез, төти егетләр, алла язса, яхшы укып чыксагыз, татар милли киносының нигез ташы буласыз. Хәерле сәгатьтә, картлар әйтмешли!

— Кави ага,— Галимҗан гадәтенчә чәчрәп торды,— кайда, кайчан, кемнән укыйбыз?

— Бәй,— Кави ага кычкырып көлеп җибәрде,— менә бит, бәйрәмгали, нәкъ кирәген әйтергә онытканмын! Колагыгызга киртләп куегыз: иртәгә, кич сәгать алтыда «Бегемот»ның Чернышев урамы ягындагы 3 нче ишегеннән икенче катка күтәрелеп, 34 нче бүлмәгә керегез. Анда Каюм Поздняков булыр. Ул барлык сорауларыгызга җавап бирер. Төшендегезме?

Икенче көнне без әйтелгән вакытта тагын киттек. «Бегемот»ка. 34 нче бүлмәдә Кави агадан башка тагын бер ир кеше, кара чәчле яһүдә дә утыра иде. Бу юлы сүзне күзлекле ир башлады, Каюм Поздняков дигәннәре. Ул безгә бик сөер тоелды. —Исеме татар, фамилиясе башка. Соңыннан белдек, ул кеше кинорежиссер икән. Хәтерем ялгыштырмаса, татар тормышыннан алынып куелган беренче һәм бердәнбер «Булат батыр» картинасын тудыручыларның берсе шушы иптәш булган икән.

Һәр атнаның җомга,шимбә кичләрендә без өчәү — «татар киносының нигез ташлары» — «Бегемот»ка барабыз. Теге чибәр яһүдә ханым безне сценарий язарга өйрәтә. Билгеле инде, иң элек сценарий язуның тарихын, кануннарын, үрнәкләрен, мастерларын сөйләде. Соңга таба төрле темага заданиеләр дә бирә башлады. Бара-тора без чын-чынлап киносценарийлар яза башладык. Каюм Поздняков темалары буенча. Ул арада яз җитте. Цех көзгә хәтле каникулга ябылды.

Ул көзне инде мине Кызыл армия сафларына чакырдылар. Шулай итеп, бу кызыклы укулар, кызганычка каршы, очланмыйча калды. Мин армиядә өч ел хезмәт итеп, редакция әһелләреннән озакка ераклаштым. Шуның өчен бу цехның — бик кирәкле изге башлангычның ничек очлануын да әйтә алмыйм. Армиядән кайткач, институтка кердем, институттан — төрмәгә!

Бу елларны Черек күлнең Пассаж ягында 5 катлы бик зур торак йорт салдылар. Менә шушында минем бер дус, ничектер, бер бүлмә алу бәхетенә

ирешкән. Зур сөенеч! Котларга киттем. Ишек яңагындагы төймәгә бастым. Бераздан ишек ачылды. Мин, имәнеп, артка чигендем.

— Гафу итегез! Мин ялгыштым ахрысы.

— Юк-юк, нинди ялгышу ул,— дип Кави ага, кулымнан тотып, бусага аша тартып алды да ишекне япты.— Әйдә, әйдә, уз, бик мактап йөрисең икән. Әле генә кечке чөйгә өзерләнә идек.— Ул каршыдагы ишекне ачты.— Сәрвәр, каршы ал, синең якташың килгән.

— Хәзер! Хәзер! — ерактан, мөгаен, аш бүлмәсеннән тавыш килде.— Нәрсә анда, кунакны бусагада тотасың.

Чишенеп өстәл янына уздым. Йомшак урындыкка утырдым. Үзем аптыраган: теге дус егет квартира номерын ялгыш яздырган, рәтсез, оятка калдырды.

— Исәнмесез, Сәрвәр апа! /Мин инде аны язучылар җыелышында күргәләгән идем, шуңа төсмерлим/.

Ул, кулларын алъяпкычына сөрткәләп, елмаеп, миңа таба килде.

Менә шулай, бер дә уйламаганда, мин Кави ага, Сәрвәр апаларның яңа квартираларына килеп кереп сумсалар, вареньелар белән тәмләп чәй эчтем. Әйтерсең лә, Күкчәтауга — өйгә кайттым. Мондый ризыклар безнең ише буйдак егетләрнең төшенә дә керми бит.

— Сәрвәр апаң Троицкидан, синең кебек үк казакъ илендә кымыз эчеп үскән.

— Сез Ибраһим, кайсы яктан?

— Күкчәтаудан.

— Күршеләр икәнбез бит! — Сәрвәр апа миңа таба үрелеп, аркамнан какты.— Бик якыннар, өйе бит, энем. Болай булгач, зарыктырмыйча килеп йөр, оялма!

Мин үземнең бу квартирага башка бер кешене эзләп килеп, ялгыш монда эләгүемне әйттем.

— Габдрахман Бикмөхәммәтов дисеңме? Ул бит нәкъ шушы квартирада, безнең каршыдагы бүлмәдә тора ич, сеңлесе белән.

— Менә сиздем! — Кинәт Сәрвәр апаның күзләрендә, хәтта тавышында шуклык чаткылары чәчрәде.— Син мөгаен, Габдрахманны түгел, аның сеңлесе Гайшәне күзләп йөрисеңдер әле.

— Күзләсә, Ибраһим кемнән ким. — Кави ага мине яклады.— Буе-сыны коеп куйган. Таланты ташып тора.

— Гайшә дә төшеп калганнардан түгел, чибәр кыз.

— Менә бусы дөрес, җанкай. Әле мин үзем дә шул кызга күз ташлап йөрим.

— Кит, картлач! — Сәрвәр апа, өстәл аша үрелеп, Кави аганың аркасына шап иттереп сукты.— Әгәр дә мәгәр, моннан соң Гайшәгә күз ташлыйсы булсаң, валлаһи дип әйтәм, тотам да менә шушы тәрәзәдән Черек күлгә ыргытам!

— Әлгиязи билләһи,— Кави ага як-ягына төкеренгәндәй итте. — Әйттем исә кайттым. Моннан соң коридордан кергәндә күзләремне йомып керәм.

— Абынып егылсаң?

— Соң күтәреп алырсың, җанкисәгем.

Рәхәтләнеп көлештек. Мин хуҗаларга рәхмәт әйтеп кузгалдым. Кави ага мине киендерде һәм коридорга озата чыкты.

— Яшерен-батырыны юк, мин үземнән беләм: буйдак егеткә йорт ашлары тансык, килеп йөр.

— Килеп йөр! — Сәрвәр апа да бусагада тора икән. Без башкалар кебек «кара көнгә» акча тупламыйбыз. Дус-иш белән ашап-эчеп, йөрешкәнне хуп күрәбез.

Кави ага үз ишекләрен ачып югалды. Мин коридорда ялгыз калдым. Күңелдә бер төен пәйда булды. Ни дигән сүз икән ул «кара көннәр?» Безнең илдә кара көннәрнең булуы мөмкинме соң?!.

1932—35 елларда мин Казандагы 1 нче укчы полкында хезмәт иттем. Килгәч тә алты айлык полк мәктәбенә билгеләделәр. Аны тәмамлагач кече командир итеп петлицаларга икешәр өчпочмак беркетеп, атлы дивизионга җибәрделәр. Казакъ даласында үскәнгә, җылкы малы миңа кече яшьтән үк таныш — якын. Безнең үзебездә дә җирән кашка бар иде. Күршеләрдә дә. Җәйге кичләрдә малайлар җыелышып далага — ат багарга барабыз. Төн йокламый учак тирәсендә уйныйбыз, бәрәңге «тәгәрәтебез» /көлгә күмеп пешерү/. Барганда, кайтканда да чабышабыз, узышабыз. Бәйгеләргә дә катнашабыз. Беренче булып килә алмасам да, арттан өстерәлеп хурланганым-елаганым юк иде. Шуңадыр, кавалерия дивизионына теләп килдем.

Читтән, урамда карап калганда кызык: башларын югары күтәргән тәкәббер, сылу атлар, тигез сафларда тып-тып басып биеп киләләр. Аларның өстендә өр-яңа иярләр, яшь, таза кыю егетләр кавалеристлар. Күңелле. Бу — ерактан караганда шулай. Чынында...

Монда эшләр башкачарак тора. Пехотага караганда ярты сәгать алдан конюшняга йөгерергә — атның астын тазартырга, үзен кыргычларга, тоякларын арчырга, сугарырга, солы-җим бирергә. Синең атның хәле-торышы, йөреше башкаларга үрнәк булырга тиеш. Чөнки син, кечерәк булсаң да, командир кавеменнән.

Шулай, иртәләрнең берсендә, атымны сыйпап-сыпырып бетердем дигәндә генә, йөгереп-мышнап посыльный килеп чыкты.

— Иптәш кече командир! Сезне полк командиры чакыра.

Кабинетка шакып, рөхсәт сорап кердем. Бастым, рапорт бирдем.

— Утырыгыз,— диде полк комиссары Зариф Иманкулов. /1937 елда ул, халык дошманы, дип кулга алынды. 10 ел төрмәгә хөкем ителде. Бер камерада утырырга туры килде/. Озын буйлы, таза гәүдәле, башкортка тартым киң битле, соргылт кысынкы күзле ир уртасы кеше. Өр-яңа, үзенә ятышып торган какао төсендәге постау френч кигән. Киң күкрәктә янып торган «Кызыл байрак» ордены — басмачылар белән сугышта күрсәткән батырлыклары билгесе.

— Сез армиягә хәтле кайда эшләдегез?

— «Кызыл яшьләр» газетасы редакциясендә.

— Алай булгач, сез газета эше белән таныш. Безнең полкта «Укчы» исемле татарча, күп тиражлы газета чыга. Аның редакторы хәзер авырый. Сезне шуның урынына күчерергә уйлыйм.

Аягүрә бастым, честь бирдем:

— Рәхмәт, иптәш комиссар!

Редакция-типографиядә без өчәү: хәреф җыючы, газета басучы һәм мин — редактор. Безнең эш вакыты, полкның гомуми көндәлек хезмәт тәртибенә ятмый. Чөнки безгә көндез материал эзләргә, редакцияләргә, кичен газетаны басарга кирәк. Старшина безгә кагылмый. Без казармага үзебез теләгән вакытта кайтабыз, теләгән вакытта торып китәбез. Бу хәл, минем өчен бик игелекле булды — иҗат эшенә вакыт кала.

Казанда, Кызыл Армия йортында ЛОКАФ /Литературное объединение Красной Армии и флота/ оештырылды. Анда мине дә әгъза итеп алдылар. Атнасына бер тапкыр кичен утырышыбыз була. Казан гарнизонында хезмәт итүче — әдәбият белән шөгыльләнүчеләр /кызылармеецлар, командирлар/ җыела һәм үзләренең яңа язган әсәрләрен укый. Җитәкче — Мөҗәй Хәйретдинов. Атлет гәүдәле, һәрвакыт пөхтә итеп кырынган /хушбуй исе килеп тора/ ихтыярлы ир. Өстендә, үзенә бик ятышлы гимнастерка, портупея, галифе. Итекләрне әйткән дә юк — кояш. Петлицаларында — өчәр дүртпочмак. Бөгелми-сыгылмый, нәкъ хәрбиләрчә һавалы атлый. Сөйләгәндә — яна! Армия тормышыннан бик матур, тәэсирле шигырьләр язып килә һәм ялкынланып сөйли. Безгә аның «Бәр, мылтыгым, бәр!» дигән шигыре аеруча ошады:

Бәр, мылтыгым, бәр!
Дошманнарның күкрәгенә
Үткер ук җибәр!

Мөҗәйдән башка монда тагын Габдрахман Минский, Габдулла Зөлкәрнәев, Габдрахман Теләш, Әбүзәр Турай һ. б. килеп үзләренең әсәрләрен укыйлар иде. ЛОКАФның рәсми һәм рухи җитәкчесе — Кави Нәҗми. Ул еш килә, теоретик лекцияләр укый һәм «Кызыл Армия» газетасының эш планы белән таныштыра. Чөнки бу түгәрәктә укылып, уңай бәя алган әсәрләр соңыннан «Кызылармеец» газетасына — Кави агага юл ала. Соңгарак, шундый әсәрләрнең берсе буларак, минем «Дуэль» повестының һәм «Мәхәббәт һәм өмет» романының баш өлешләре Кави ага редакциясендә газетада урын алдылар.

1934 ел. Мәскәү. СССР язучыларының 1 нче гомумсоюз съезды. Максим Горький докладый. «Татар әдәбияты» турында Кави Нәҗми докладый. Бу татар әдәбиятының ул чордагы дәрәҗәсе, күрке турында әйтеп торган куанычлы хәл иде.

Съездан кайту белән Кави ага яшь язучыларны Союзга әгъза итеп әзерләргә, аларга һәр тарафтан иҗади шартлар тудырырга тырышты. Литфондта

әгъза булмауларына кармастан, ул аларга акчалата ярдәм, санаторийларга, ял һәм иҗат йортларына бару өчен путевкалар белән тәэмин итү, еш авырый торганнарны /Г. Мөхәммәтшин, С. Рафиков, С. Хәким һ. б./ махсус шифаханәгә беркетте. Яшьләрнең иҗат осталыгын чарлауга аерым игътибар. Иң унышлы дип танылган әсәрләрне, тизрәк рус теленә тәрҗемә итеп, Үзәк матбугатка җибәрү. Бу яктан иң алдынгыбыз Галимҗан Мөхәммәтшин иде. Бер сәер хәл: Галимҗан еш авырый, шифаханәгә керә һәм шуннан бер кочак менә дигән шигырьләр күтәреп кайта иде. Галимҗанның байтак шигырьләре «Комсомольская правда», «Правда» газеталарында, хәтта беренче битләрдә үк чыга башлады. Бераздан мондый мөмкинлек миңа да якынлаша язган иде.

Ләкин... насыйп булмады. Язмышымда кара көннәр башланды.

Була икән, була икән ул кара көннәр. Бездә дә. Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Галимҗан Мөхәммәтшин, Фатих Кәрим, Сөббух Рафиков, Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин, Мөхтәр Мутин, Кави Нәҗми, Сәрвәр Әдһәмова һәм башкалар башына кара көннәр килде.

Ниһаять, мин үзем дә — шул караңгы читлек эчендә. Ни өчен? Нинди гөнаһ шомлыгына? Әле кичә генә безнең белән бер фиркадә, бер кыйблага табынган фиркадәшләр бүген ничек соң зобаниларга әверелделәр һәм безне, юк җинаятьне таныттырырга тырышып, вәхшиләрчә изәргә, гариплендерергә тотындылар, бинахак кешеләрне, күз дә йоммыйча аттылар, төрмәләргә яптылар, сөргеннәргә сөрделәр. Нигә? Нигә? Нигә?

Миндә Фатих Кәримнең, Кави Нәҗми белән бергә Казан төрмәсендә утырган чагында, Кавига багышлап язылган озын бер шигыре саклана. Анда, менә мондый юллар да бар:

... Күпме? Илле грамм килер килмәс,
Күксеп беткән ипи кисәген,
Хыянәтсез, нәкъ урталай бүлеп
Ашаганнар синең истәме?
Исеңдәме, көзге кабер кебек
Карцерларда бергә утыру,—
Хаксызлыкка нәфрәт игълан итеп,
10—15 көн буе ач тору?
Белүчеләр әле дә сагынып сөйли,
Ул чактагы безнең дуслыкны
Дуслык белән чөнки тутырдык без
Тормыштагы бүтән бушлыкны...

Узган ел азагында, Казанда «Тайгак кичү» романын укучылар белән очрашуларда миңа бик күп сораулар бирделәр. Шул сораулар арасында мондые да бар иде.

— Кави Нәҗми төрмәдә утырган вакытта язучылар өстеннән ялган күрсәтмәләр биргән, дигән сүзләр йөри. Шул дөресме?

Мин бу сорауга түбәндәгечә җавап бирдем.

Беренчедән, мин Кави Нәҗми белән нәкъ бер вакытта, бер үк төрмәләрдә /Черек күл каршындагы Эчке төрмәдә, Пләтән төрмәсендә/ янәшә камераларда утырдым.

Икенчедән... Төрмә биек. Камералар — йозакта. Ишек алдына алып чыгу юк /ул бары судтан соң гына/. Мәхбүсләр үзара аралашмасын өчен барлык чаралар күрелгән.

Шулай да төрмәдә өзлексез хәбәрләшү булып тора. Тәрәзә рәшәткәләре арасыннан түбән каттагыларга җеп белән шырпы каплары /эче тулы хәбәр/ төшерәләр. Бәдрәф диварларында гарәп хәрефе сызмалары пәйда була. Әинде камера арасында хәбәрләшүнең иң ышанычлы ысулы — шакып сөйләшү. Камерага бүген кемне алып килгәннәр, кайдан? Кемне алып киткәннәр? Кем сораудан ни хәлдә кайткан, ни әйткән? Кемнәрне күрә алган, ни ишеткән? Кем белән күзгә күз очраштырганнар? Бу мәгълүматлар камераларга тапшырылып тора.

Мәсәлән Татарстан халык комиссарлары Советы председателе Кыям Абрамовның сорау барышындагы кыйнау-имгәтүләргә чыдый алмыйча, сораудан чыкканда, коридор баскычыннан цемент идәнгә ташлануы, Татарстан партия өлкә комитетының секретаре Галим Мөхәммәтҗановның каты кыйнау-имгәтүләрдән соң, комсомол өлкә комитетының 1 секретаре Мәхмүт Баһаветдинов белән күзгә-күз сорау-җавапка чыгып:

— Син дә безнең милләтче-контрреволюцион оешмада әгъза булып тордың,— дип әйтүе һәм шундук тикшерүче борылган арада,— күбрәк кеше тарт-

сак, иптәш Сталин тизрәк тикшерер,— дип пышылдавы. Татар коммунистик университеты ректоры Вольфовичның: «Мин махсус задание белән контрреволюцион кадрлар әзерләдем»,— дип, күрәләтә үз-үзенә яла ягуы һ. б. барысы да шул ук көнне Казандагы барлык төрмәләргә, камераларга ирешә.

Әмма минә Кави Нәҗминең кем өстеннән булса да ялган күрсәтмә бирүе — яла ягуы турында хәбәр ишетелмәде. Булмады!

Өченчедән. Нигә Кави Нәҗми башкалардан алда котылган? Олы яшьтәге иптәшләр, могаен, хәтерли торганнардыр: 1938 елда «Правда» газетасы битләрендә «Ирекле-ирексез дошман» /«Вольный, невольный враг»/ дигән сүзләр күренә башлады. Бу термин кулланыла башлаганчы хөкем ителмәгән кайбер тоткыннар төрмәдән азат ителде. Бу үзенә күрә бер мәкерле чара иде: «Күрәсез, без гаепсезләрне тотмыйбыз». Бу иң кабәхәт рәвештәге хаинлык. Совет халкының ышанычын таплау-алдау иде. Менә шундый «ирексез дошманнар» рәтендә ул көннәрдә: генерал Якуб Чанышев, Кави Нәҗми, Мирсәй Әмир һ. б. азат ителделәр.

Татарстан язучылар берлеге идарәсенә кереп, андагы язучылар белән күрешеп, куанышканнан соң, әле һаман мине җитәкләп диярлек йөрткән Кави ага, ниһаять, җилкәмә кулын салды:

— Җитәр, Ибраһим, безгә кайтып, Сәрвәр апаң белән чөкердәшеп чәй эчик,— диде.

Без ишек ачып кергәндә, Сәрвәр апа аш бүлмәсенә узып бара иде, безне күргәч, кинәт туктап калды. Күзләре миңа текәлде. Тетрәнде. Кулындагы тастымал төшеп китте.

— Сәрвәр,— Кави ага ашыгып барып аны кочты, авып китүдән тотып калды,— Сәрвәр, ни булды? — Ул арада мин дә килеп, Сәрвәр апаның култык астыннан алдым.

— Әнә анда,— Кави ага караватка ымлады,— шунда салыйк.

— Мә, Сәрвәрҗан, валерианка йотып җибәр!

Тетрәнеп карап торам. Нинди таза, бит алмалары тулып, алсуланып торган, сылу хатын иде бит ул теге елларда. Ә хәзер сулган. Суырылган. Маңгаендагы тирән сырлар — төрмә, каторга эзләре...

Мин сак кына чишенә башладым. Әйләнеп кергәндә, Сәрвәр апа инде күзләрен ачкан иде. Миңа карап, ничектер ямансу елмайды.

— Менә, кунаклар, ресторан ачык,— Кави ага буы бөркеп торган электр самавырын өстәлгә куйды. Рәхим итегез!

Тагын кайнар сумса, карлыган вареньесы белән төмләп чәй эчтек. Ләкин бу мәҗлес Кави аганың Сәрвәр апаның күңелен күтәрергә тырышып, шаяртуларына, мәзәкләр сөйләп көлдерүләренә дә карамастан, теге вакыттагы кебек ваемсыз, күңелле мәҗлес була алмады. Кави ага, ниһаять, авыр сулады, чынаягын каплады:

— Менә бит, Сәрвәрҗан, син гел, безнең илдә кара көннәр булуы мөмкин түгел,— дип кабатлый идең.— Ул урыныннан торып ишекле-түрле йөри башлады.— Була икән, була икән ул кара көннәр бездә дә...

— Ярар, Кави, әле бетешеп тә җитмәгән җәрәхәтне кабат кансыратма!..

Бу юлы Кави ага белән Сәрвәр апа мине, кунакханәгә җибәрмичә, үзләрендә торырга калдырдылар. Мин аларда бер атнага якын тордым, әмма сүзләребез бетмәде, хәтта йокыга да вакыт такы-токы кала иде. Мин китәргә җыенгач, Кави ага, такси чакыртып, мине вокзалга алып барып, поездга утыртып, кулымны каты итеп кысты:

— Хуш бул, Ибраһим, тагын кил! Сәрвәр апаң ямансулап калды бит,— диде.

Бу безнең соңгы хушлашуыбыз булган икән.

Өстәмә.

Югарыда язганымча, 1988 елның ноябрь айларында мин Казанда булдым һәм рәсми документлар белән танышырга туры килде. Шулардан күренгәнчә, Кави Нәҗми әле 1947 елда ук Муса Җәлилне реабилитацияләү турында ходатайство белән Татарстан Югары Советы Президиумына мөрәҗәгать итә һәм нәкъ шул эчтәлектә СССР Язучылар Берлеге идарәсе рәисе Александр Фадеевка да хатлар яза. Партиянең XX съездыннан соң исә, гаепсез җәзаланган татар язучыларын /Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Мөхәммәтшин, Соббух Рафиков һәм башкаларны, шул җөмләдән, мине дә/ аклау турында Татарстан АССР Югары Советына язып бирә һәм, СССР Югары Судының Хәрби коллегиясендә безнең эшләр киредән каралганда, бу язмалар игътибарга алына.

**Мәсгут Гайнетдинов**

# XVIII ЙӨЗДӘ ТАТАР ЯҢАРЫШ ХӘРӘКӘТЕ

## (Чукындыру: гамәл һәм нәтиҗәләр)

1746 елда, эшендәге ниндидер зур кимчелекләр өчен, Казан губернаторы А. Г. Загряжский урыныннан төшерелә[1]. Яңасы килгәнче эшләр губернатор ярдәмчеләре — хәрби көчләр командующие бригадир Бердекевич, Казан шәһәр коменданты полковник Блохин, полиция башлыгы полковник Маматов кулына тапшырыла. Патша һәм Сенат, аңлашылса кирәк, хәрбиләр хөкеменә тапшырылган Казанга яңа губернатор билгеләргә ашыкмый. Мәчет яндырулар күмере сүнеп бетмәгән, күчерүләр, өстәмә салымнар, талаулар көчәя барган бер заманда патша һәм Сенат Казан бердекевичларыннан, маматовларыннан нәрсә көткәнлеген бу соңгылар бик яхшы аңлаган. Казан губернаторлыгын үз кулына алу турында татлы уйларга күмелгән Бердекевич, әрхәрәй Лука Конашевич белән киңәшеп, Маматов ярдәмендә булса кирәк, татарларның куркынычлы кузгалышка әзерләнүләре турында ялган әләк-хатлар яздырып, махсус ялланган керәшеннәр аркылы губерна секретаре Полянский, комендант Блохин, полицмейстер Маматовларга бирдерә. Бу хатларда, масленицаның беренче көнендә татарлар, җыелып, Казанда яши торган урысларны суярга әзерләнүе хәбәр ителгән була. Хатлар хакында шунда ук Сенатка хәбәр бирәләр Казанда гаскәр аз булуын күрсәтәләр. Ялган сигнал буенча күтәрелеп, үзләре генә уйлап чыгарган күләгәләр белән сугышканда, мондый бердекевичлар даһи «таланты» күрсәтергә сәләтле. Һичнинди каршылыксыз, ялгышу-кичегүсез, бюрократик машина хәрәкәткә килә. Хәрби коллегия Оренбург ныгытмаларындагы драгун полкларына, Саранскидагы Ростов, Азов полкларының өч ротасына ашыгыч рәвештә турыдан-туры Казанга таба кузгалырга боерык бирә. Тамбов янында торган Левашев командасындагы өч полк Казан губернаторы ихтыярына тапшырыла. Казанга губернатор килеп җиткәнче бу көчләрнең һәммәсенә Бердекевич җитәкче итеп билгеләнә. Югарыда күрсәтелгән гаскәрләр Каманың бирге ягындагы татар авылларына һәм Казанның татар бистәсенә урнаштырылалар. Билгеле, бу гаскәрләр тынычлык, тәртип саклый торган көч рәвешендә түгел, бәлки үч алу, җәза отрядлары буларак китерелә. Татар халкы авылларга кертелгән андый отрядларны «бирәннәр командасы» дип атый. Андый командалар авылларда халык хисабына яши: икмәген тартып ала, терлекләрен суеп ашый, һичнинди закон, кагыйдә белән якланмаган халыкның хатын-кызларын көчлиләр, ирләрне бер сәбәпсез суктыралар, җәзалыйлар. Халыкны куркытыр өчен, аерым кешеләр кыйнап, кайсылары атып үтерелә; кемнәрнедер төрмәгә, «хөкемгә» озаталар. Кыскасы, өлкә хәрби көчләр тарафыннан аяк астына салып таптала, тар-мар ителә.

Хатлар буенча кичекмәстән тикшерү башлап җибәрергә күрсәтмә бирелә. Сенат ашыгыч рәвештә Грековны Казанның яңа генерал-губернаторы итеп билгели. Аңа шундук Казанга китәргә, юлда, Мәскәүнең аръягындагы авылларда, татар шымчылары, үгетчеләре юкмы икәнен яшерен аныкларга, Казанда тикшерү эшләрен тизләтергә күрсәтмә бирелә... Хатны китерүче керәшеннәр һәм аларның танышлары: «Татарлар шул чакта шулай янады», «Болай дип әйткән иде» — дип ызгышлар вакытында ачу белән әйтелгән янау сүзләрен бу «эш»кә китереп кушалар. Полиция башкисәрләре ул мәгънәсез янау сүзләрен «мас-

[1] ЦГАДА, 248 ф. 5 тасвир, 238 төпләм. Бу бүлектәге һәммә материал шушыннан алына һәм аның битләре текст эчендә күрсәтелә.

Ахыры. Башы 7 санда.

леницаның беренче көнендә Казанга һөҗүмгә әзерлек» дип раслату эшендә үзләре теләгән максатка ирешмәстән туктамыйлар. Сенатның бу эшне тикшерү планында тирә-яктагы авылларга ышанычлы кешеләр җибәреп, татарлар арасында очрашулар, җыелыш-киңәшмәләр юкмы икәнен яшерен тикшерергә дә кушыла. Андый тикшерү-искәнүләр башта һичнинди нәтиҗә бирми. Ниһаять, Яна Чишмә ныгытмасы төбәгенә җибәрелгән капитан А. Жданов Кама аръягында, Шушма елгасы буенда, татарларның ниндидер очрашуы булганлыгы хакында бер хәбәргә юлыга. Инде шул очрашу (киңәшмә) хакында материаллар туплый башлыйлар. Туймәт авылының Шәяхмәт Туктамышев шул киңәшмә карары нигезендә бер керәшен авылына сөңгеләр сатып алырга килгән, имеш (87, 104 бб.). Юныс авылының Биккол Бикиев тә, җәзалаганнан соң, Шушма елгасына Җөри һәм Нугай юлыннан 18 авыл вәкилләре җыелганын күрсәтә. Ул киңәшмә Ибрай авылында Якуб дигән кеше өендә үткәрелгәнлеге ачыклана (91 б.). Шул киңәшмә карары нигезендә, Зирекле авылының сотнигы Исмәгыйль Лебасов авылларны фетнәгә әзерләнергә чакырып йөргән, имеш (110 б.). Исемнәре аталган кешеләр кулга алына. Алардан, әлбәттә, бу очрашу әлеге хатларда күрсәтелгән вакыйгага әзерлек булганын раслауны таләп итәләр һәм, кирәкле җавап алганчы, иң шәфкатьсез рәвештә җәзалыйлар. Кайдадыр, ниндидер киңәшмә — житәкче орган булуын Казан губерна кәнсәсе Сенатка коточкыч серләрнең ачылуы итеп тәкъдим итә. Бу яңа дәлилләр нигезендә яңа полклар хәрәкәткә китерелә. Тагын күп татар авылларына «бирәннәр командасы» кертелә. (111 б.). Татар иле тарихындагы иң кара, иң дәһшәтле көннәрне кабат башыннан кичерә. 1748 елда Якупны кулга алып, Казанга китерәләр. Ул үзенең мир эшләре буенча, мир хисабына, Санкт-Петербургка барганын, мир акчасын ничек туздыруы турында хисап алыр өчен, төрле авыллардан аның өенә өч сотник, бер абыз, ике урысча грамоталы кеше җыелуын, ике көн аның өендә булуларын, фетнә турында һичбер сүз кузгалмаганын сөйли. (124 б.). Ул күрсәткән кешеләрне дә тотып китерәләр. Җәзалап сорау алулар вакытында башка катнашучылар исемнәре дә ачыкланып, барлыгы ун-унбиш кеше кулга алына. Инде тикшерүчеләрнең төп игътибары ул кешеләрдән сорау алуга юнәлә. Кайбер сотниклар, җәзалап сорау алган вакытта түрәләргә кирәкле беркетмәгә кул куйсалар да, төп гаепләнүчеләр — Якуб һәм Актау авылы сотнигы Рахманкул Арысланов, дүрт-биш мәртәбә каты җәзалап сорау алганда да, тик элеккеге әйткәннәрен генә раслый. Бу хакта хәбәр алганнан соң, Сенат 1748 елда, ут белән җәзалап (яндырып, пешереп, көйдереп) сорау алыгыз, дип күрсәтмә бирә.

Җәй көннәре якынлаша. Шулкадәр шау-шу күтәреп, күп гаскәрләрне хәрәкәткә китереп башланган тикшеренүләр бер нәтиҗә дә бирми. «Якуб эше»ндә һаман унсигез авыл сотниклары турында гына сүз бара. Халыкның газабын кузгаткан губерна башлыклары инде гаскәрләрнең Казан губернасыннан чакырып алынуларыннан куркалар. Яңа ялган «эш»ләр кузгатырга туры килә. Баштагы кебек үк шау-шу белән, Пермь провинциясе Кунгур өязендәге татарлар, Тәфкилевне талар өчен, Минзәлә якларына һөҗүм итәргә әзерләнүе ачыкланганын 1748 елда Сенатка хәбәр итәләр. Бу «куркыныч» хәлне фаш итүдә дә махсус әзерләнгән керәшеннәр төп рольне уйный. Казан хәлләрендә әле кешене ышандыра алырлык күпмедер төсмер бар. Пермь «эш»ендә исә ясалмалык, ялган үтәдән-үтә күренеп тора. Петербург инде бу эшне тагын да сузу-катлауландыруны теләми, тиз арада тикшеренүләрне азагына җиткереп, гаскәрләрне үз төбәгенә кайтарып җибәрү турында күрсәтмә бирә. И. Неплюев кебек үткер сәясәтчеләр бу эшнең ялганлыгын баштан ук аңлыйлар. Җәй житә. Урал буе далаларында, Казахстанда халыкларны төрле хәвефле хәрәкәт ихтималыннан саклап торыр өчен, Оренбург полкларын ашыгыч рәвештә үз урыннарына кайтару кирәк булып кала. Неплюев бу хакта апрель аенда ук инде Сенатка һәм Хәрби коллегиягә рапорт артыннан рапортлар җибәрә. Казан түрәләре гаскәрләрне татар авылларында яшәтүнең — губерна халыкларын иң соңгы чиккәчә хәлсезләндерүнең яңа чараларын эзли күрәсең, 1743 елда Сенатка яңа хат табылуы турында хәбәр ителә. Шул ук кул белән шул ук татар сөйләменә стильләштереп язылган бу хатта автор Бердекевичны: «Син — безнең брат, үз кешебез», — дип атый. Ә губернаторны исә «юләр», «сатлык» дип начар сүзләр белән тирги. Хатта татарларның Казанны яндырырга әзерләнүе хәбәр ителә. «Масленица вакыйгалары»нда татарлар губернаторга секретаре аша 18 мең сум акча биреп, тамагын тыгылдырдылар. Губернатор бистә байларына, бистә байлары хатыннары белән губернатор өенә кунакта йөрешәләр. Элгәредә Кабан күле буена сакчылар куелмаган иде. Гаскәр кертелгәнне күреп, татарлар фетнә күтәрмәде, коралларын, дарыларын төнлә Кабанга ташладылар да иртән исән-сау өйләренә, авылларына таралышып киттеләр, ди хатны язучы (247—249 б.). Хат полицмей-

стер Маматовка адресланган һәм Бердекевич белән бергә укылсын дип күрсәтелгән. Хатны алу белән Бердекевич, Маматовлар, Сенаттан санкция көтеп тормастан, ашыгыч чаралар күрәләр. Татар бистәсенә Горин командасы һәм яңа алынганнар отрядлары кертелә. Бистәдә һәр квартирга өчәр солдат урнаштырыла. Нәкъ сугыш кырындагы кебек, аерым урыннарга пикетлар куела: көнтөн хәрби разъездлар йөреп тора. Хәллерәк татарлар тотык итеп кулга алына, Саранскидан майор фон Гекенберг командасында өч сотня Казанга чакырыла. Әмма Сенат бу хат хәбәренә карата комарлык күрсәтми. Бары ул хатны язучылар белән генә кызыксына. Шундый «куркыныч хәлләр» турында кисәтеп торган өчен 500 сум акча биреләчәк, дип игълан эләргә, хәбәр таратырга боерык бирә. Билгеле, бу 500 сумны алырга берәү дә килми. Сенатны татарларның Казанны яндыру ихтималына караганда (ул аның ялган икәнен яхшы аңлый), дәрәҗәле чиновнигына ихтирамсызлык (губернаторны сүгү) күрсәтү күбрәк борчуга сала. Ул тагын бер мәртәбә ут белән җәзалап сорау алырга, яңа мәгълүматлар табылмаса, шул тикшерү материаллары нигезендә карар чыгарып, кулга алынганнарны хөкем итәргә һәм тикшеренүләрне туктатырга күрсәтмә бирә. Инде тикшерү хат мәсьәләсенә генә каратыла. Хатлардагы кайбер үзенчәлекләр нигезендә, Сенатта: «Бу хатларны Бердекевич яздырмады микән?» — дигән шик туа. Моны тикшерүнең планы эшләнә. Губернаторга, яшерен рәвештә, хатларның нәкъ үзенә охшаган күчермәләрен әзерләргә, шуннан соң ул күчермәләрне, инде бу хатларның кирәге бетте, дип ачыктан-ачык яндырырга күрсәтмә бирелә. Бер үк вакытта әлеге керәшеннәр кулга алынып, хатларны кайдан «табу»лары, кем язганлыгы хакында җавапка тартылалар. Соңгы хатны Чура авылының керәшеннәре Сергей Иванов һәм Павел Афанаев Черек күл яныннан «табып» китергәннәр. Кулга алыну Сергей Ивановны шүрләткән, күрәсең, ул «февраль аенда масленица алдыннан миңа, Чура авылына, Павел Афанаев килде. Ул бистә керәшене Якупта әрхәрәй подьячие Прибыловский язган хатлар барлыгын сөйләде. Аларга ул хатларны ташлаганнары өчен унар сум акча тәкъдим иткәннәр икән. Павел Афанаев исә Сергей күрсәтүләрен кире кага һәм элеккеге хатларны ташлаган кеше керәшен Моисей Герасимов»,— дип күрсәтә (260 б.). Губернатор: «Керәшеннәр җавабында һич тәртип, мәгънә юк. Җәзалап хакыйкатьне әйттерер идек, императрицаның идарә урыннарында яңа чукынганнарга гаделлек, хакыйкать нигезендә йомшак мөнәсәбәт күрсәтергә, дигән указы бар. Нишләтик?» — дип Сенаттан киңәш сорый. Сенат, иң каты чаралар кулланырга, хакыйкатьне ачарга, дип боерык бирә. Әмма Бердекевич, Конашевичлар да йоклап ятмаганнар, төрмәдәге керәшеннәргә, сорау алганда, үзләрен ничек тотарга кирәклеген каты кисәткәннәр, күрәсең. Бистә керәшене Яков Лукьянов (Якуб) җәзалау вакытында да: «Мин әрхәрәй подьячие Прибыловскийдан, укытканда малаемны кыйнаган өчен үч алу, яла ягу максатында шулай әйттем. Аңардан һичнинди хат алганым юк»,— дип күрсәтә. Яков Прибыловскийның гаепсезлеген раслады, дип әрхәрәй подьячиен, сорау алмастан, төрмәдән азат итәләр. Хатларны кемгә бирергә, кая тапшырыга күрсәтмәләр бирүче Алексей Федоров (Саин) хатны язучыны тәгаен белгәндер (өч хатны да аның аша алалар). Әмма ул икенче мәртәбә җәзалап сорау алу вакытында ук үлә, (дөресе — үтереләдер). Шуннан соң: «Керәшеннәрнең җавапларында һич тәртип юк, мәгънә табу кыен булганга, сорау алуларны туктатырга»,— дигән карар чыгарыла. Ел артыннан ел үтә. Гүя, бу керәшеннәрнең төрмәдә утыруларын да оныталар. Бер-бер артлы Сергей Иванов, Афанаевлар да теге дөньяга күчә. 1757 елда гына Сенат исән калган Яков Лукьянов белән Моисей Герасимовларны чыбыркы белән кыйнап җәзаларга һәм Рогорвикка гомергә каторга эшләренә сөрергә карар чыгара (335 б.).

Хат мәсьәләсе буенча чокчынуларның бер очы, әйткәнебезчә, Бердекевичка да кагыла. Әмма Бердекевичны «тикшерүләр» Прибыловскийныкына караганда да мәгънәсезрәк һәм нәтиҗәсезрәк тәмамлана.

1748 елның көзендә Бердекевич губерна кәнсәсе турында шундый ук ялган әләкләр яздырырга инде татарлар арасыннан кешеләр эзли башлый. Җыелышхәрәкәтләр турында эзләнүләр өчен яз башында Яңа Чишмә нигытмасы төбәгенә җибәрелгән капитан Аверьян Жданов сотник Дусәй Искәндәров белән очрашып танышкан була. Ул чакта, куркытып һәм янап, Жданов Искәндәревтан Якуб Мостаев өендә татарлар җыелу турындагы хәбәрне сөйләткән. Инде Жданов, Бердекевич исеменнән, аңа тагын биш-алты сотник табып, губерна секретаре һәм башкалар өстеннән, салымнардан азат итәргә вәгъдә биреп ришвәт алды, дип әләк язарга куша. Әләкне Бердекевич Сенатка җибәрәчәк, анысы бу мәсьәләне тикшерүне Бердекевичка тапшырачак. Бердекевич исә тикшеренүләрне сезнең файдага хәл итәчәк, дип ышандыра ул (278 б.). Ләкин Искәндәрев бу хакта

Сенатка түгел губернаторга хат язып хәбәр итә. Губернатор ул хәбәрне Сенатка житкерә. Сенат өченче хат белән бу яна әләк әзерләү арасында уртаклык барлыгын шунда ук чамалап ала (губернаторга кизәнү). Сенат, баштагы хатлар тексты белән шаһәдәтнамәләр арасында охшаш сыйфатлар булмасмы дип, Бердекевичка яшерен тикшерү үткәрәсе итә. Сенат Хәрби коллегиягә Бердекевич хезмәт иткән районга инспекция сылтавы астында, әлеге тикшерү бурычын аңлатып, кеше жибәрергә күрсәтмә бирә. Әмма, карга карганың күзен чукымый дигәндәй, Хәрби коллегия бу эшкә катнашудан баш тарта. «Бездә андый жаваплы эшкә ярарлык кеше юк. Неплюевта андыйлар бардыр да, генерал-майор Штокман — немец урысча белми, полковник Игнатьевнын дәрәжәсе буенча, бригадирны тикшерергә хокукы юк. Сенат генералитеттан үзе теләгән кешене үзе билгеләсен»,— дип жавап кайтара. Сенат бу эшкә башта генерал-майор Козловны, сонра, Петр Сумароковны һәм шул ук көнне өченче берәүне — Семен Раевскийны билгели. Бу хәлнең мәгънәсен аңлата торган материаллар «эш»тә юк. Күрәсең, Хәрби коллегия тирәсеннән кемнәрдер баштан ук бу эшкә каршы чыккан, билгеләгән кандидатларны бармаска үгетләгән. Мәскәүгә барып житкәч, Раевский да бу эштән баш тарта. Мәскәү аның урынына статский советник Иван Баметовны билгели. Ләкин Баметов Сенат һәм Хәрби коллегия теләмәгән характердагы кеше булып чыга. Патшаның, Сенатның чиновникларының, чиркәүнең татарларга карата чын ниятләрен ул белеп бетермәгән, күрәсең, дөрестән дә мәсьәләнең асылын табарга, аңларга хәрәкәт итә башлый. Сенатка жибәргән язуында ул: «Татарлар яхшы коралланган икс сотняга да каршы тора алмас иде. Полковник Фраундорф, гаскәр белән татарларны коралсызландырырга йөреп, 23 авылдан биш мылтык та таба алмаган. Шул татарлар арасында яшәгән Биләр, һәм Чишмә воеводалары фетнә турында бер хәбәр дә ишетмәгәннәр»,— ди. Мондый фикерләрдән Сенат түрәләренең чәчләре үрә тора. Алар: «Ул үзенә тапшырылмаган эшкә тыгыла»,— дигән сылтау белән Баметовны тизрәк бу эштән читләштерү ягын карыйлар. Шуннан соң Бердекевич мәсьәләсен тикшерү эше 1751 елда Калубаровка тапшырылган билгеле. «Тырышлыклары» өчен, Бердекевич инде бу вакытта «бүләк» алган була, документта аны генерал-майор дәрәжәсендә күрәбез...

Бу дәһшәтле вакыйгаларның да соңгы битләре әлеге «эш»тә юк. Кулга алынган бичаралар, гаепсез булганнары хәлдә, жәзага тартылган булырга тиеш. Ә гаскәрләр кире үз урыннарына кайтарылгандыр. Шул рәвешчә, татар бистәсе һәм авыллар хәрби көчләр аяк астына салып таптатыла.

Әмма гаскәрләр китү татарларны эзәрлекләүләрнең туктатылуын аңлатмый. Солдатлар талавы, жимерүе аркасында авыллар инде тәмам сафтан чыгарыла. Казанның татар бистәсен дә шул хәлгә калдыру өчен, өч-дүрт елга сузылган тагын бер шундый ук вәхши погром үткәрелә. Бу погромда да баштагы дәвердәге кебек үк, хөкүмәт ул эшне башкаруны башлыча жирле сатраплар ихтыярына ышанып тапшыра. Бу соңгы баскычта әрхәрәй Лука Конашевич, губернатор Греков кебек дәһшәтле бәндәләр елгырлыгы алгы сафка чыга.

1748 елның көзендә Хәрби коллегия: ныгытмалар тирәсендә, 130 сажин ераклыккача, биналар булмаска тиеш, ныгытма эчендә шәхси өйләр калдырылмаска тиеш, дигән карар чыгара. Казан ныгытмасы (Кремле) эчендә һәм тирәсендә исә өч монастырь, алты чиркәү һәм күп попларның агач өйләре урнашкан була. Көн тәртибенә аларны күчерү мәсьәләсе куела.

1749 елда зур янгын булып, Казанның татар бистәсе бөтенләе белән янып китә. Элек Кремль тирәсендә яшәгән поплар: «Татар бистәсенең урыны — Казанга иң якын жирләр, Христиан динендәге кешеләр булган жирдә һәм чиркәүләргә якын урыннарда мөселманнар яшәмәскә тиеш, дигән указ нигезендә, татарлар аннан куылса, без өйләребезне шунда күчереп салыр идек»,— дип Казан епархиясе башлыгы Лука Конашевичка гариза бирәләр. Лука Конашевич 1742 елгы янгын турында: «Татарлар, үчләнеп, шәһәргә ут төрттеләр»,— дип патшага шикаять яза. Кремль тирәсендә яшәүче попларны каядыр күчереп урнаштыру мәсьәләсе чыкканда, аларга урын әзерләр өчен, 1749 ел янгынын (1742 ел янгынына жавап дигән булып) ул үзе оештырган булу ихтималы да юк түгел. Бу шикне Л. Конашевичның татарларны бистәдән куугa чамадан тыш тырышуы да куәтли. Поплар хатын да ул үзе кинәш биреп яздырган булуы, бик мөмкин. Лука губернаторга поплар хаты турында доклад яза. Губерна кәнсәсе шул мәсьәлә буенча Сенатка мөрәжәгать итә. Хакимнәрнең санкциясен көтеп тормастан, бер үк вакытта Лука Конашевич бистә татарларына каршы көрәш башлап жибәрә. Янгынның икенче көнендә үк яна өй салуга керешә алырлык хәлле хужалыклар

бистәдә байтак булган. Әмма аларны төзү эшләрен башлаудан катгый тыялар. Тиздән Лука Конашевич, Зөя архимандриты Сильвестр һәм «Крешенская контора»ның ике майоры җитәкчелегендә бер төркем фанатикларны җыеп, татар бистәсе уртасында, «булачак чиркәү» урынын билгеләп тәре кагу тантанасын оештыра. Татарлар яңа көчләүләр турында губерна кәнсәсенә үтенеч бирә. Әмма губернатор бу вакыйгаларда тулысынча әрхәрәй яклы була. Шуннан соң инде бистә выборныйлары гаризалар белән Сенатка йөри башлый. Лука татарларга каршы Синодны өстерә. Дөресрәге, ул үзе Синод киңәше белән Казанда эш йөртә. Билгеле булганча, 1552 елда татарлар шәһәрдән Болак һәм Кабан артындагы баткак җирләргә куып чыгарыла. Тырыш хезмәт белән алар ул баткаклыкларны да тәртипкә китергәннәр, күрәсең. Инде әрхәрәй, урыс обывателенең татар бистәсе җирләренә күзен кыздырып, ике халык арасына яңа дошманлык орлыклары чәчәргә омтыла.

Әрхәрәйне бистәне яндыручы итеп күрсәткән К. Насыйри язмаларында бистә халкының ул көннәрдәге хәле шактый калку сурәтләнә: «Ул арада әрхәрәй үзенең һаман мөселманнарга җәбер кылуында мәсьйр булып, бистәне яндырып, вә һәм мәчетләр, өйләр салырга рөхсәт бирмәенчә, мөселманнарны издихамда (тыгызлыкта) калдырып, вә һәм чукынсагыз — торыгыз, чукынмасагыз шәһәрдән чыгыгыз, дип кысып, күп яманлыклар кылыр икән... Ул арада бистә янган, һәммә җире пусто булып, кеше буе алабута, кычыткан, тигәнәк үсеп, халык алабута эчендә ятыр икән. Бистә халыкының олуглары — Ишбулат мулла углы Габдеразак дигән кеше икән. Аксак Каратун аңа бигрәк каныгыр икән, ягъни халыкны чукындырырга ирек бирмидер, нәсихәт кыладыр дип. Кешеләр җибәреп, мөселманнарны, кыйнап-сугып, тәгъзиб (газап) кылырлар икән. Ул вакытта бистәдә, Чумарлар бабасы, Йосыф дигән вә һәм Тәкә Сәйфулла атасы Ибраһим дигән бик һиммәт (гайрәтле) егетләр бар икән. Алар Аксак Каратуннан килгән кешеләргә каршы алабута арасыннан күсәкләр күтәреп чыгып: «Монда ник килдегез? Сезгә ни кирәк?» — дип каршы торырлар икән. Аксак Каратун кешеләре: «Кая Габдеразак?» — диерләр икән. «Менә Габдеразак! — дип, Йосыф бабай белән... Ибраһим күсәкләрен күрсәтерләр икән. Шулай итеп, Габдеразак бабайны Аксак Каратун кулына төшермичә сакларлар икән. Аксак Каратун урамнар чатына качлар (тәреләр) утыртып, урамнарда драгуннар йөртеләләр икән...»1749 елның 28 июнендә бистә «выборный»лары — мулла Мөхәммәтәмин Ермаков һәм Исмәгыйль Килеев тә үтенеч белән Сенатка килеп җитәләр. Бу үтенечтә бистә йомышлыларының дәүләткә хезмәтләре санап чыгыла. Кабан, Болак арты җирләренең татар бистәсенә бирелүен раслый торган дәлилләр китерелә. Сенат утырышында бу гариза да тикшерелә. Сенат: «Казан — дәүләтенең эчке төбәгендәге шәһәр. Анда чиркәү һәм башка биналарны ныгытма эчендә калдырырга мөмкин булмасмы икән?» — дип белешергә, губерна кәнсәсеннән исә шәһәр тирәсендәге буш җирләр һәм татар бистәсе турында мәгълүматлар сорарга, дигән карар чыгара.

Хәрби коллегия: Казан ныгытмасы эчендәге барлык хосусый биналарны читкә чыгарырга, ныгытмадан 130 сажин читтәрәк, ныклы план буенча, киң урамнар калдырып өйләр төзәргә, дигән карар кабул иткән икән. Һичнинди чара таба алмаган Сенат: «Чиркәү хезмәтчеләре, обывательләр, шул исәптән, татарлар да үзләренең элекке урыннарына өй салсыннар»,— дигән каршылыклы карар чыгара. Хәрби коллегия карары нигезендә, чиркәү хезмәтчеләре үз урыннарында калдырыла алмаганлыгы күренеп тора. Димәк, Сенат карары, читләтеп әйтү рәвешендә, башлыча бистә татарлары таләбен канәгатьләндергән була. Мөхәммәтәмин Ярмәк улы кул куеп, шул указны алып кайтып китә. Указ хәбәрен алу белән, Лука Конашевич атлар җиктерә дә, үзенә карашлы авылдан җәйге чиркәүне сүттереп, татар бистәсенә китереп, тәре каккан җиргә өйдереп куя. Аңа «Изге Елизаветта чиркәве» дигән исем бирәләр. Инде: «Без, алла дошманы татарлар өй салсын дип, изге чиркәүне сүтә алмыйбыз»,— дигән сылтау табыла.

Мөхәммәтәминнәр кабат Сенатка баралар һәм татарларның кышка каршы бала-чага белән урамда (өйсез) калуы турында яңа үтенеч бирәләр. Кабат Сенат алдында тартышулар башланып китә. Синод Сенатка язган хатында Луканың эш-хәрәкәтләрен яклап чыга. Сенат татар бистәсе, мәчетләре һәм зиратлары планын, бистә территориясенең күпмесе чиркәү һәм монастырьга алынганын күрсәтеп җибәрүне сорый. Губерна кәнсәсе инженер-подпоручик Зверев алган планны җибәрә. Бу планда татар бистәсе җирләре азайтып күрсәтелгән була.

1750 елның җәендә бистә татарлары Сенатка бөтен бер вәкиллек булып киләләр. Алар 1750 елда Сенатка унлап үтенеч бирәләр. Бу вакытта инде бистәдә

элеккеге 378 йортның 150 се төзелгән була. Үтенечләр буенча, бистә татарларының кәсебен, матди хәлләрен берникадәр күз алдына китерергә мөмкин. Алар Адмиралтействога эшкә беркетелгәннәр. Эштән буш вакытларда һөнәр һәм сәүдә белән шөгыльләнәләр. Кәрван сарайда кайберәүләрнең үз кибете бар, икенчеләр рус сәүдәгәрләре кибетен хак түләп арендага алып файдалана. Әстерхан, Кавказ, казакъ даласы, Хива, Бохара, Себер, Иран белән сәүдә мөнәсәбәтендә торалар. Инде бистәдән байтак кеше качып киткән, калганнарын да Лука шуңа мәҗбүр итә. Лука хезмәткәрләре бистә татарларына карата күп башбаштаклыклар эшли. Төзегән өйләрне кабат җимерәләр, кешеләрне сәбәпсез кулга алалар, консистория базына ябып, кыйнап, көчләп, җәберләп, бистәдән күчү турындагы кәгазьгә кул куярга мәҗбүр итәләр, кул куймаса, көчләп чукындыралар. Мәсәлән, 1750 елның 8 гыйнварында әрхәрәй экономы унбишләп полицай ярдәмендә бистә старшинасы сотник Бикмәт Котлинны кулга алып китеп, кыйныйлар, көчлиләр, соңра чукындыралар. Кулга алу вакытында шау-шуга җыелган халык: «Суд карары нигезендә, закон буенча, җинаять эшләгән кешене генә кулга алыгыз»,— дигәч, эконом һәм аңа ярдәмләшүче полиция: «Сотникны гына түгел, һәммәгезне шулай бәрәмләп алып бетерәчәкбез»,— дип җавап кайтаралар (872 б.). Исмай, Йосыф Котлиннар, 20 кешедән гариза җыеп, Оренбургның Каргалы бистәсенә күчәргә рөхсәт сорап, Сенатка килгәннәр. Сенат аларга Казаннан Оренбурга күчәргә рөхсәт бирми. 1750 ел указы белән Сенат: «Чиркәү салынган тирәдән татар өйләрен күчерергә. Аларның бу урында күпме җирләре булган булса, бистәгә якын урында чиркәүгә карашлы җирләрдән, күршедәге Пләтән яки Поповка дигән монастырь авылларыннан шул кадәр үк урын кисеп бирергә. Бистәнең яңа чиркәүдән читтә калган почмагына татарларга үзләренең иске урыннарына өй салырга рөхсәт итәргә. Татарлар бер җирдәрәк яшәргә тиеш. Аларның йортлары арасында урыслар һәм яңа керәшеннәр яшәмәскә тиеш»,— дип яңа күрсәтмә бирә. «Күчеп килгән Казан татарлары булса, андыйларны кире Казанга куып җибәрергә» дип, Оренбург губернаторына да указ җибәрелә. Оренбург губернаторының Сенатка җавап хатыннан күренгәнчә, 1745—1749 еллар арасында Адмиралтийская контора рөхсәте белән Казан бистәсеннән ир затыннан 141 җан (22 гаилә) Оренбурга күчкән. 500 дән артык хуҗалык иске урыннарда кала. 400 гә якын хуҗалык җире яңа чиркәү урыны дип билгеләнә. Җирләре чиркәүгә калдырылган хуҗалыклар йә Пләтән авылы кырына, яки Поповка авылы җирләренә күчеп утырырга тиеш була. Бу күченүчеләр өчен яңа кыенлыклар туа. Пләтән кырыннан кисеп биргән җиргә генә алар сыеша алмыйлар. Димәк, бистәдән еpактагы җиде-сигез йортлы Поповка авылын Пләтән кырына күчереп, Поповка урынына болар урнашырга тиеш була. Аларны әз хуҗалык белән дәүләтнең бетмәс-төкәнмәс салымнарын түләү мәсьәләсе дә борчый. Үз өй урыннары яңа чиркәү өлешенә калган Мөхәммәтәмин Ермаков, Исмәгыйль Килиевлар кабат Мәскәүгә киләләр дә, татарларны бер-берсеннән аермыйча һәммәсен Поповка кырына күчерүне сорап, Сенатка гариза бирәләр. Сенат моңа каршы килми.

Беренче карашка әллә ни әһәмиятле булмаган менә шул факт, бистә вакыйгаларында гына түгел, гомумән, XVIII йөз башындагы яңару өчен көрәш тарихында бер дәвернең соңгы чик сызыгы булып тора. Хәрәкәтнең дәүләтчелек, дәүләткә хезмәт итү идеалы белән рухланган, патшадан, сенаттан гаделлек, закон эзләп табу өметендә яшәгән баскычы тәмамлана. Шул чиктән Уркиннар, Батыршалар, Морадлар, Пугачев полковниклары исемнәре белән характерланган яңа заман башлана. Бу заман байрагына инде дәүләт, чиновниклар гаделсезлекләренә каршы, милли мәсхәрәләүләргә каршы кискен көрәш шигарьләре язылган.

Өйләре янган, утар урыннары тартып алынган йомышлылар үзләре үк бистәне башка җиргә күчерүне — губернатор, әрхәрәй күсәк белән кыйнап мәҗбүр иткән нәрсәне сорап, Сенатка гариза бирәләр. Әмма бу йомышлылар җиңелүе — татар халкының тезләнүе түгел иде. Җәмгыять тормышы таркалу чигенә житкәндә дә, татар халкы барыбер царизм тәкъдим иткән хурлыклы чукынуны кабул итми. Бистә дә Мөхәммәтәминнәр тәкъдимен хупламый, бу капитуляциягә аяк терәп каршы торырга карар бирә. Бистәнең бу каршылык күрсәтүе Сөләйман Уркин чыгышында аеруча калку чагыла.

Сөләйман Уркин[1] — бистәнең бай сәүдәгәре. Улы Давыт белән бергәләп ерак Себер (Троицк, Эрбет, Тубыл, Томск) ярминкәләрендә сәүдә итә. Аның

[1] Архив материалларында аның фамилиясе — Уркин; Е. Маловның «О Новокрещенской конторе» дигән китабында — Нуркин; Ш. Мәрҗанидә — Чуркин, К. Насыйрида — Куркин дип бирелә.

Яушык (Явшенка) авылында — 6, Тамгач авыланда — 13 крепостное һәм жир биләмәләре булган. «Эш»тә аңа һәм Мөэмин Атнагулов, Мөнасыйб Абдрязаков дигән ике иптәшенә икешәр елга бирелгән паспорт күчермәсе китерелә. Пеләшләнә башлаган чал чәчле, аксыл йөзле, соры күзле, буйчан (178 см) бу картка ул чакта 68 яшь булган. Кәсебендә адым саен законсызлыклар, башбаштаклыклар белән бәрелешеп яшәргә мәҗбүр бу гайрәтле ирне бистә халләре тәмам ярсыткан, кискен көрәшкә кушылырга мәҗбүр иткән. Җәй башында Мәскәүгә килгән выборныйлар арасында аның исеме дә бар. Ул да башкалар да: «Казаннан, Лукадан качып, яшерен рәвештә паспортсыз килдек, кайтырга паспорт бирегез»,— дип сораган.

Мөхәммәтәмин мулла татарларның һәммәсен бергә күчерү турында указ чыгартканнан соң, бистәдә калган милләттәшләребезне моңарчы күрелмәгән төстә тагын да дәһшәтлерәк эзәрлекләүләр башлана. 1751 елда, бистәнең күпме җире яңа чиркәүгә бирелгәнен билгеләр өчен, инженер подпоручик Зверевкә шул биләмәләрнең планын алырга боерык бирелә. Зверев, Лука Конашевич, Греков һәм губернатор ярдәмчесе Толстой Поповкада татарларга тапшырыларга тиеш җирләрне күздән кичерәләр. Сенат һәм Синод карары нигезендә, барлык татарларны аермыйча Поповка җиренә күчерергә кушыла.

1751 елның җәендә Себердә бергә йөргән иптәшләре белән С. Уркин Сенатка шикаять бирергә кабат Мәскәүгә килә. Мөхәммәтәмин үтенечләрендә бистә халыкларының шул җиргә хокукларын раслый торган документларга томанлы ишарәләр, аннан өзекләр генә бар. С. Уркин үтенеч белән ул документларның төгәл күчермәләрен Сенатка тапшыра («Ишбулат мулла указы» һ. б.).

С. Уркин Казан белән тыгыз бәйләнештә тора. Яңа эзәрлекләүләр турындагы хәбәрләр Казаннан килеп җитүгә, ул шунда ук яңа үтенеч белән Сенатка керә. Анда ул оятсыз көчләүләрне санап китә: бер гаепсез кешеләрне төрмәгә ябалар, богаулап, үтергәнче кыйнап, Поповкага күчәргә ризалыгы турында кул куярга мәҗбүр итәләр. Казан полицмейстеры Исмәгыйль Котлинның өен, кар базын, ашханәсенең түбәсен җимерткән. Пләтән ир-атларыннан иллеләп кеше җыелып, Уркин йорты коймасының 57 баганасын кискәннәр, 61 түтәл яшелчәсен таптап юкка чыгарганнар һәм йөзгә якын алма куакларын кискәннәр. Тагын жиде кешенең бакча коймаларын җимереп, яшелчәләрен таптап, алма куакларын кисүләрен яза ул бу шикаятьтә (974 б.). Губернатор һәм полиция боерыгы буенча, Поповка авылы крестьяннарының өйләре шул җимерелгән бакчалар урынына күчерелергә тиеш, имеш. Аларны яңа чиркәү тирәсендә калдырылган җирләргә урнаштырырга мөмкин иң. Пләтән бәндәләре зур урам очын койма белән киртәләп куялар — юлны каплыйлар. Губернатор һәм аның яраннарын катнаштырмыйча, бистә халкын эзәрлекләүләрне закон һәм указлар нигезендә тикшерү үткәрелүен сорый Уркин. Шул тикшерелүләр тәмамланганчы, бистәдә иске урыннарына өй салып урнашкан 500дән артык хуҗалык Поповкага күчергә мәҗбүр ителмәсен, ди.

Губерна кәнсәсенең Сенатка хәбәр итүенә караганда, тиздән бистәдәге барлык татарларны полиция көче белән Поповка кырына күчерүләр башлана. 1751 елның 6 июне Яңа бистәгә нигез салынган көн[1]. Җирләре чиркәү кулына күчмәгән татарлар исә, «Вәкилләребез кайтканчы урыныбыздан кузгалмыйбыз»,— дип кенә җавап кайтаралар, сүзләрендә нык торалар. 1751 елда ук инде губерна кәнсәсе С. Уркинга каршы суд гаугасы башлап җибәрә. «С. Уркин үзендәге калмык малайларын көчләп сөннәтләткән, ислам диненә күчергән»,— дигән гаепләү белән, аны кулга алып, Казанга конвой астында кайтарып җибәрүне Сенаттан сорый.

1751 елгы хатында Казан губерна кәнсәсе Поповка крестьяннарының өйләре, сүтелеп, татар бистәсе бакчаларына күчереп салынганын хәбәр итә.

1751 елда Уркин үтенечләре һәм Казан губерна кәнсәсе хатлары нигезендә, Сенат «Яңа чиркәүгә дип калдырылган җирләрдә яшәгән 200 йорт татарларны Поповкага күчерергә, калган җирдә яшәүче татарларны күчермәскә: губерна кәнсәсе карары белән өйләре җимерелгән булса, кабат үз урыннарына өй салырга рөхсәт итәргә»,— дип указ чыгара. С. Уркин үтенечендә тәкъдим ителгәнчә, мәсьәләне тикшерү өчен полковник Колударов (соңра — Бердекевич) җитәкчелегендә комиссия төзелә. Поповкага күчәргә риза булмаган өчен генә кулга алынган һәммә кешене азат итәргә күрсәтмә бирелә. Ә губерна кәнсәсе исә элекке

[1]Яңа бистә башта Поповка урынына салынган. 1774 елда исә Поповкадан хәзерге урынына күчерелә.

указларда, барлык татарлар Поповкага күчерелсен, дип күрсәтелмәгән хәлдә бу гаугаларны ни өчен кузгатуы турында кичекмәстән Сенатка аңлатма язарга мәҗбүр ителә. Поповка крестьяннары татар бистәсе җиренә түгел, бәлки Пләтән авылына күчерелергә тиеш була. Пләтән бәндәләренең бистә татарларын җәберләвен тикшерүне полковник Колударов комиссиясенә тапшырырга, комиссия материалларны өйрәнеп тә берәр карарга килә алмаса, үз фикерләрен белдереп ул материаллар Сенатка тапшырылырга тиеш, дип күрсәтмә бирелә (1034 б.).

Губерна кәнсәсе Сенатка 22 битле аңлатма җибәрә. Анда татарларның христиан динендәге кешеләргә якын җирдә яшәмәскә тиешлеге турында 1743 ел указы, Лука Конашевич хатлары һәм Синод күрсәтмәләре буенча эш йөртелүе күрсәтелә.

Әмма 1751 ел указы да Казандагы гаугаларга чик куя алмаган. Лука Конашевич, указны алгач та, элеккечә эш итәргә карар бирә. 1751 елның 16 октябрендә руханилар һәм фанатиклар белән янадан тәре күтәреп иске бистәгә килә дә аның нәкъ уртасында урнашкан Бикмәт Ермаков, Әбдерәшит Мөмәдәлиев, Хөсәен Габдулов өйләрен җимертеп, шул урынга яна тәре кага — җылы таш чиркәү салыр өчен урын билгели. Тиздән яна чиркәүгә нигез дә салып куялар. Бу хәбәрне алу белән С. Уркин шул хәлләр турында яна үтенеч белән Сенатка керә. Яңа салынган чиркәү тирә-юнендә әле һичкем яшәмәвен сөйли, җылы чиркәү киреәксә, элек калдырылган җирдә дә аңа урын житәрлек, дип күрсәтә. Губерна кәнсәсе аңлатма хаты күчермәсен алганнан соң, С. Уркин 1751 ел декабрендә Сенатка тагы гариза бирә. Монда ул, губернатор боерыгы буенча, бистәдә 70 йортның түбәсе — түшәме һәм мичләре җимерелү турында яза. Полиция капитаны Яков Левашев 100 кешелек команда белән бистәгә килеп мичләрне, түшәмнәрне җимерә. Аерым өйләрне бөтенләй сүтеп ташлыйлар, халыкның милкен талап китәләр. Аннары шул ук хәл Маматов житәкчелегендә өченче кат кабатлана. Полиция идарәсе йорт коймаларны кабат күтәрүгә юл куймый. Койма белән сакланмаган йортлардан төнлә барлык нәрсәләрне урлыйлар. Полицмейстер җимерелгән түшәм һәм түбәләрне төзәтүне дә тыя.

Лука Конашевич губернаторга язган хатында, Синодтан указ алганга кадәр, калган җирләрдә татарларга өй салырга рөхсәт итмәвен сорый. Уркинны исә, чиркәүгә, дингә каршы көрәшеп йөрүче явыз, дип гаепли. Шул ук гаепне ул татар халкы өстенә дә ташлый, моны «чирмеш һәм ар кызларына өйләнәләр», — дигән кебек «какшамас» дәлилләр белән раслый.

Бу шау-шулар вакытында Казан шәһәре кешеләренең кайберсе Татар бистәсе хисабына бөтәеп калырга тырышкан. Афанасий Чублин дигән кеше иптәшләре белән 1750 елда ук Болак буена урнашкан иске татар каберлегенә тире һәм сабын заводлары сала. Данила Крюков, Иван Протопоповлар бистәдән шәһәргә килә торган юлны бикләп, бакча утырталар һәм каберлек өстеннән яна юл салырга мәҗбүр итәләр. Иван Мухин, Василий Уржумов, Родион Карпичевләр каберлек өстенә йортлар салалар, яшелчә бакчалары ясыйлар.

Бистә татарлары җәберләүләр турындагы барлык материалларны туплап Колударов-Бердекевич комиссиясенә тапшыруны Рәхмәтулла Хөсәеновкә йөкләделәр. «Биредә губернатор, полицмейстер, инженер командасы җәберләүләре дә язылган. Безнең комиссиягә Пләтән мужиклары җәберләүләрен тикшерү эше генә йөкләтелде», — дигән сылтау белән, комиссия ул материалларны 1752 елда кире кага, Р. Хөсәенов ул материалларны Сенатка җибәрә. Бердекевич комиссиясенең 1753 елда Сенатка җибәргән хисабына: алмагачларны кисү, коймаларны җимерү нәтиҗәсендә бистә татарларына 982 сумлык зарар китерелгән, дип билгеләнә. Әгәр түләтик дисәгез, законда күрсәтелгән тәртиптә, ул җимерүчеләрнең исемен атап, судка бирегез дә аларның гаепле икәнен исбатлагыз, дигәч, татарлар Пләтән старшиналарын хөкемгә тартып карыйлар. Бу хөкем мәшәкатьләре судлашып йөрүче татарларның берәр ай төрмәдә ятып чыгуы белән тәмамлана (1118—1191 бб.).

Казандагы хәлләрне төгәл күз алдына китерер, шул урынның планын алыр өчен, Сенат Казанга махсус геодезия офицеры җибәрергә була. Шул максат белән 1752 елда Казанга капитан Иван Алябьев килә. Лука Конашевичка да, Сенатның төгәл карарын алганга кадәр, кышкы чиркәү төзүне туктатып торырга күрсәтмә бирелә. Тиздән капитан Алябьев Сенатка Казанның татар бистәләре планы белән командировкасы турында язма хисабын тапшыра. Чиркәүгә иркен итеп 250 йорт урнаштырырлык урын калдырылган. Әлегә анда биш рухани һәм бер керәшен яши торган алты йорт бар. «Татарлар элекке бистә урынына 123 йорт салганнар, әлегә күпме кешенең йортсыз булуы миңа билгесез», — дип күрсәтә ул. Янгынгача ул җирдә 215 йорт булган. Поповка урынына (Яңа бистәдә) татарлар 128 йорт

салган. Яз көне су күтәрелеп, бу авыл урынын шәһәрдән аера. Аннан ике ай ярым буе көймә белән генә Плэтән аша шәһәргә чыгарга мөмкин була.

1753 елда, ниһаять, татар бистәсендә дүрт ел ярым буена дәвам иткән башбаштаклыкларга чик куйган указ кабул ителә. Бу указда, Иске бистәдә өй салган татарларны үз урыннарында калдырырга, чиркәүдән ераграк җирдә аларга мәчет салуны рөхсәт итәргә күрсәтмә бирелгән. Шул указга кадәр йорт салмаган татарларга Иске бистәдә өй корырга рөхсәт ителми. Бу указны С. Уркинның иптәшләре Мөэмин Атнагулов һәм Мөнасыйб Әбдразаковлар алып кайта. Уркин үзе исә нәкъ шул көннәрдә башка бер «мәхшәр көнен» башыннан кичерергә мәҗбүр ителә.

С. Уркин — башкаларга караганда булдыклырак, гайрәтлерәк шәхес кенә түгел, бәлки татарлар арасындагы шул хәрәкәтнең оештыручыларыннан, җитәкчеләреннән берсе. Моны турыдан-туры раслаучы дәлилләр булмаса да, ихтыярсыз шул фикерне уята торган документлар байтак. Мәсәлән, Сенатны да ул бик тиз үз фикере белән хисаплашырлык хәлгә куя алган. Сенат аның белән мөнәсәбәтләрне ныклы кануный нигезгә куя, аның фикерен, таләпләрен игътибарсыз, җавапсыз калдыра алмый (ул куйган таләпләр сүзгә сүз диярлек указларда чагыла). С. Уркин — царизмның ерак яшерен максатларын аңлый алган, шул мәкерле максатка каршы хәрәкәтнең дөрес юлын билгеләгән алдынгы сәяси фикер иясе, сәяси эшчәнлеккә сәләтле кеше буларак күз алдына килә. Мәсәлән, татарларның Поповкага күчәргә теләмәвен, ул: «Поповка шәһәр чигеннән тышта», — дип дәлилли. Ягъни Поповкага күчү ул — бистә халкын иманага — крестьянлыкка күчерүнең беренче адымы. С. Уркин эшчәнлеге аша бу көрәштә бистә татарлары арасында күпмедер оешкан максатлы хәрәкәт булганын төсмерли алабыз. Губерна кәнсәсе һәм әрхәрәй конторасы Сенатка һәм Синодка бу мәсьәлә буенча язган хатларының күчермәләрен татарларга бирмәгән билгеле. С. Уркин исә үтенечләрендә шундый хатлардагы фикерләр белән бәхәскә керә. Күрәсең, ниндидер юл беләндер ул хатларның күчермәләрен кулга төшереп, Казаннан Уркинга җибәреп торганнар. Гомумән, С. Уркин Мәскәүдә вакытында Казан белән сизелерлек яхшы оештырылган тыгыз бәйләнештә торган.

Казан генерал-губернаторы Грековның мөнәсәбәте дә С. Уркинның гадәтидән өстен, бистә татарларының гамәли башлыгы кебек бер кеше булуын искәртә. Греков җыелган күп халык алдында аңа: «Мин сине, сотник Котлин кебек, көчләп епископка озатып чукындыртам...» — дип яный (1234 б.). Генерал-губернатор теләсә кем белән чат саен әрләшә торган зат булгандыр, дип уйлый алмыйбыз. Сенатка хатында да губернатор, өлкәнең иң зур түрәсе, үзен С. Уркиннан яклауларын сорый, епископ та (Лука) шул хакта ук үтенә. Ничек тә С. Уркиннан тулысынча котылыр өчен алар законның иң шәфкатьсез матдәсенә мөрәҗәгать итәләр.

Исай Исмәгыйлов дигән бер бистә татары Әстерханнан Манжу Кижяков дигән ятим калмык малаен сатып ала. Аннары бу баланы сөннәткә дә бирә. 1748 еллар шау-шуы башлангач, бу сер чишелеп, үзенең элмәккә эләгәсен сизеп алгач, ул чукына, әрхәрәй йортында яши һәм фамилиясен дә Лука исеме буенча, «Лукин» яздыра. Шул Иван Лукин, Лука Конашевич белән киңәшеп, билгеле, (яки аның киңәше буенча), рухани консисториягә (чиркәү судына): «С. Уркин йортында сөннәтләнгән калмык балалары яши», — дип әләк яза. 1749 елда Лука, Конашевич С. Уркин белән әлеге калмык малаен кулга алып консисториягә тапшыруларын сорап, губерна кәнсәсенә мөрәҗәгать итә. Әмма бу вакытта С. Уркин сәүдә эшләре белән Себергә киткән була. Лука бу хәбәрне Синодка җиткерә. Синод бу мәсьәләне тизләтү чараларын күрмәгәне өчен губернаторга кисәтү ясый. 1750 елда бистәдә һәм өязләрдә, татарлар арасында яшәгән барлык калмык ирләрен һәм хатыннарын тикшерү өчен, губерна кәнсәсенә җибәрү турында губернатор күрсәтмәсе таратыла. 1750 елның яз башларына таба Уркин Казанга кайта. Аны калмыклары белән кулга алырга дип барсалар, Гөлсолтан дигән хатыны: «Ике атналар элек ул хатыны һәм балалары белән каядыр китте», — дип белдерә. Бистә сотнигы Котлин: «Халык аның Мәскәүгәме, Питербургамы китканлеге турында сөйли», — дигән хәбәрне ишеттерә. Уркинның малае Давыт Манжу белән Себердә сәүдә кылып йөри икән, губерна кәнсәсе ул кешеләрне табып һәм конвой белән Казанга кайтаруларын үтенеп Эрбет ярминкәсенә һәм Кяхта ныгытмасына хат җибәрә.

Губерна кәнсәсе: «Үзенең гаепле икәнен белеп, икенче мәртәбә инде Казаннан качты», — дип, Уркинны тотып Казанга җибәрүләрен үтенеп Сенатка мөрәҗәгать итә. Моны ишеткән Уркин үзен консисториягә җибәрмәүләрен, мәсьәләне Адмиралтейство конторасындагы үз командалары аша тикшерүләрен үтенеп

Сенатка гариза бирә. Бу гаризаны Сенат утырышында тикшерәләр. Уркин һәм калмыклар турындагы «эш»не кичекмәстән Сенатка җибәрүләрен сорап, Казан губерна кәнсәсенә хат юллыйлар. Губерна кәнсәсе Уркин «эш»ен Сенатка ике ел буе җибәрми, бәлки аның үзен Казанга, консистория хөкеменә кайтаруларын дәгъвалап (күрәсең, анардан үч аласылары бик килә). Сенатка хат арты хат яудыра. Уркин да, шул хатлар буенча аңлатмалар биреп, Сенатка гаризалар яза. Сенат: «Бу мәсьәләне тикшерү өчен Бердекевич һәм Колударов житәкчелегендәге комиссия төзәргә. Шул комиссия тикшеренүләрне бетергәнче Уркин һәм аның иптәшләрен эзәрлекләмәскә, аларга басым ясамаска»,— дип карар чыгара. Уркин исә: «Бу эшкә губернатор һәм аның кәнсәсе тыкшынмаса, мин комиссиягә губернаторның халыкны бөлгенлеккә төшерүен, ришвәт алуларын исбат итәчәкмен»,— дип вәгъдә бирә. Яңа оештырылган комиссия, тикшерү башлар өчен, консисториядән һәм губерна кәнсәсеннән «эш»ләрне сорый, әмма губерна кәнсәсе инде аларны Казандагы комиссиягә дә бирми. 1751 елда Бердекевич Сенатка: «Губерна кәнсәсеннән әле һаман «эш»ләр килгәне юк. Уркин үзе дә юк. Улы Йосыфны китертеп сорау алсак, әтисен Петербургта диде»,— дип яза. 1752 елгы үтенечендә Уркин бу «сорау алу»ларның ничек булганы турында Сенатка шикаять бирә. Хәтта өендәге хатын-кызларны да кулга алып ике атналап газаплаганнар. Үзе турында ул: «Мин — гаепсез, шунлыктан үлемне түгел, җинелрәк җәзаны да күтмим,— ди.— Качканым да юк. Беренче комиссия вакытында сәүдә эшләре белән Себердә идем, икенчесе исә выборный булып Сенатка үтенеч белән килгән вакытка туры килгән»,— дип аңлатма бирә. 1752 елда Сенат Уркинга: «Кичекмәстән комиссиягә кайтырга»,— дип күрсәтмә бирә. Дөрестән дә, С. Уркин Казанга кайта. «Эш»тә: «С. Уркин калмыкларын һәм кызларын тикшерү комиссиясенә китерде» — дигән язма бар. Әрхәрәй Уркинны, әлбәттә, шәфкатьсезрәк закон элмәгенә эләктерергә тырыша. Бистә сәүдәгәре Үтәгән Солтанов кулындагы бер калмыкны әләк буенча тикшергәндә, аның сөннәтләнмәгәнлеге беленә. Уркин калмыклары белән дә шул хәл килеп чыкса, барыбер гаепләргә урын калсын, дип, аның кулындагы башкорт хатыны Яхшыбикәнең улы Юлдашны калмык Садбашка малае дип күрсәтүне оештыралар; сатып алынган ике Бохара кызын калмык дип, аларны ислам диненә тарту гаебе тагыла.

Уркинның башкорт кызы Яхшыбикә турындагы күрсәтмәләре игътибарга лаек. Яхшыбикә — Акай батыр милкендәге Мукай авылыннан. Бер урында Уркин: «...Башкорт комиссиясе аны миңа драгун аты бәрабәренә югары Минзәләдә указ чыгарып бирде,— дип күрсәтә. Икенче урында исә, Яхшыбикәне Минзәләдә бер драгун офицерына саталар. Офицер аны Казанда Уркинга сата, дип күрсәтелә (1335 б.). Бу Яхшыбикә башкорт кузгалышы житәкчеләреннән Акай батыр яки аның якыннарының кызы булып, Уркин аны шундагылар үтенече буенча, әсирлектән йолып калу өчен, Минзәләгә махсус барып сатып алган булу ихтималы да юк түгел. Шуңа күрә ул бутала, төгәл җавап бирә алмый. Яхшыбикә, Ишбулат дигән татарга кияүгә чыгып, Яүшәк авылында яши. Инде 36 яшендәге Яхшыбикәнең 10 яшьлек малае Юлдашның 26 яшендәге Садбаш малае була алмаслыгын, Бохара кызларының да калмык түгел икәнен исбат итү Уркинга авыр булмый. Хәер, бу исбат итүләрнең кирәге дә калмый. Комиссиядә Манжуның сөннәтле булуы ачыклана да Уркин белән икәвен шунда ук кулга алалар. Комиссия: «Манжудан җәзалап сорау алырга»,— дигән карар чыгара. Җәзалардан интеккән Манжу 1752 елда христиан диненә күчәргә ризалык белдереп гариза яза. Аны азат итеп, әрхәрәй өенә озаталар. Анда Манжу С. Уркин турында әрхәрәй теләгән рухта күрсәтмәләр бирә: үзен Уркин өендә, хуҗаның күз алдында сөннәтләделәр, дип күрсәтә. Уркин үз кулындагы калмык малайларын бистә абызына биреп укыткан. Алар татарча укый-яза беләләр. Уркинны Манжу белән кара-каршы китереп сорау алалар. Инде Манжу: «Сөннәтләнү Уркин боерыгы буенча булганмы-юкмы, моны белмим. Ул хакта һичкемнән ишеткәнем дә булмады»,— дип күрсәтә. Үткәндә биргән күрсәтмәсен исенә төшергәндә: «Сөннәтләнгән вакытта, күрше бүлмәдә кем беләндер кычкырып сөйләшкән ир-ат тавышын ишеттем. Шул кеше Уркин булмады микән, дип кенә күрсәтүем»,— рәвешендә анык булмаган җавап белән чикләнә. «Уркин ислам законнарыннан нәрсәләр өйрәтте?» — дигән сорауга: «Сакал сыпырырга һәм ураза тотарга өйрәтте»,— дип җавап кайтара. Менә шунда инде Уркинга үзен акларга юл ачыла. Ул: «Кая сорагызчы, тагын нәрсәгә өйрәттем икән»,— дип сорый. Манжуның «мөселманлык»тан шуннан башка бернәрсә дә белмәве ачыклана. Уркин «Сакал сыпыру, ураза, сөннәт әле мөселманлык түгел. Югары Курса ахуны Рәфикъ Бикеев, Алат

авылы мулласы Сәфәр Умяровларны чакырыгыз да, мөселманлыкның нигезе нәрсә, Манжуны мөселман дип буламы икәнен сорагыз»,— дип белдерә.

Комиссия губерна кәнсәсенә аталган кешеләрне чакыруны сорап мөрәҗәгать итә. Губерна кәнсәсе Уркинның аклануыннан хәвефләнеп, аны яклаучыларны чакырырга теләми. Уркин Манжуны әләкче Исай Исмәгыйлов — Иван Лукин сөннәтләткән булу ихтималын әйтә. Комиссиянең һәм губерна түрәләренең максаты Уркинны батыру түгел, хакыйкатьне ачу теләге булса, әлбәттә, ул кешене чакырып сорашырга тиешләр. «Фәрештә канаты астында — Лука Конашевич ышыгындагы җинаятьчене, билгеле, аларның борчыйсы килми. Уркиннан, танганы өчен, фәлән законнар нигезендә, «җәзалап сорау алырга»,— дигән карар чыгаралар. Уркин җәзалап сорау алганда да һаман үз сүзен кабатлый, гаепне өстенә алмый. Комиссия бу мәсьәләдә: «Христиан диненә күчкән кеше буларак, Манжу азат ителде. Ул төгәл дәлилләр белән Уркинның гаепле икәнен фаш итә алмады. Материалларны Сенат карамагына тапшырырга»,— дигән карар белән генә чикләнергә мәҗбүр була. Сенат исә, ул материаллар Уркинның гаеплелеген исбат итә алмаганлыктан, 1753 елда аны төрмәдән азат итү турында карар чыгара. Бу кешенең шуннан соңгы язмышы билгеле түгел. К. Насыйри язмаларына ул халык риваятьләрендәге эпик образга әйләнеп килеп керә: «...бер сәүдәгәр... Идел буе калмыкларыннан берничә яшь угланнар сатып алып килгән икән. Шуларны ул заманда бер мәэзин... мөселман итеп... Гайса баба ул калмык балаларын сөннәткә утырткан икән. Ахыр, бу эш урыс түрәләренең колагына төшеп, бу өч кемсәнәләрне алып, һәртөрле газап белән ахырында чукындыргач, Гайса бабаны чиркәү астына ябып асрап, ахыр шунда картаеп вафат булмыштыр. Әммә баягы сәүдәгәр, урыс диненә ихлас куйган булып, хәтта, бер мөселман юлыкканда, аркан әйләнеп һәм мөселманнарның йөзенә карамаган булып, әрхәрәйне ышандырыр икән. Ләкин үзе иманында сабит булып, мәэзин белән Мәскәүгә китмәккә сүз куешып — вәгъдәләшеп, Мәскәүгә елышмакчы булганнар. Ахыр, мәэзин ничек булса Казаннан китеп, сәүдәгәр ялгыз калгач вә һәм әрхәрәй, бу сәүдәгәрнең урыс диненә ихласы бар кебек сизгәч, Казаннан ераграк, эчкәрерәк әтрафлардан кара халыкны — Нугай юлы һәм Кама арьягы халкын димләп чукындыру хезмәтен кушыптыр. Никадәр аракы, прәннек, зеннәр вә һәм берничә мичкә кач биреп чыгарып җибәрептер. Мәзкүр сәүдәгәр, Казаннан чыгып киткәч, бер уңай урында, ул нәрсәләрне сатып, хәрежгә акча ясап, шул хәреж белән Мәскәүгә барыптыр. Мәскәүдә, Ука суында коенганда, мәэзин белән сәүдәгәр, бер-берсенең колач салып йөзүеннән танып, юлыгышыплар. Шуннан соң патшага Казан татарларының әрхәрәйдән тарткан җәфаларын күрсәтеп кәгазь биреп, шуннан үзләре Истанбулга качыптыр...»[1].

Бу дәһшәтле еллардагы коточкыч мәкерләр, гаделсезлекләрнең халык күз алдында гәүдәләнеше булып калыккан Лука Конашевичны исә татар фантазиясе менә болай «җәзалый»: «Аннан соң патша һәм, уяныл, Казанга әмер җибәргән. Аксак Каратунны, төшереп, Зөя монастырена япканнар. Шунда күп гомер сөреп, ахырында, йөзе тискәре әйләнеп вафат булмыштыр. Безнең бистә халкы, Мәкәрҗәгә барганда, монастырь ишек алдында койма ярыгыннан карарлар икән: Аксак Каратун һаман арлы-бирле шунда йөрер икән: йөзе тискәре килгән икән...»[2].

К. Насыйри язмаларында С. Уркин хезмәтенең гадәттән тыш, мөмкин булмаган хәл икәненә басым ясала, шул эшне — «Казан татарларының әрхәрәйдән тарткан җәфаларын күрсәтеп патшага кәгазь бирүне» үтәп чыгар өчен, ул христиан диненә күчкән булып кыланырга, Мәскәүгә качып барырга, «патшага кәгазь биргәч», үзе Истанбулга качып китәргә мәҗбүр. С. Уркинның хезмәтенә халыкның биргән бәясе менә шундый. Дөрестән дә, XVIII йөзнең беренче яртысында татар җәмәгатьчелеген, иң тирән катламнарына кадәр актив хәрәкәткә китергән ул «үтенеч бирү» хәрәкәте иң киеренке көрәшнең чагылышы иде. Бистә аерылу вакыйгалары ул хәрәкәт дулкынының иң югары ноктага күтәрелүе була. Бистә вакыйгаларында хәрәкәтнең яңа зур казанышлары күзгә ташлана. Каршы якны үзе белән җитди санашырга мәҗбүр иткән С. Уркин кебек танылган җитәкчеләр үсеп чыга. Хәрәкәтнең заманына лаеклы рухи нигезе төсмерләнә башлый. Дөрес, әлегә ул киләчәктә үсеп китәчәк милли-азатлык хәрәкәтенең яралгысы дәрәҗәсендә генә.

Бу көрәшләрнең тагын бер зур казанышы — татар азатлык хәрәкәтенең алдынгы урыс кешеләрендә теләктәшлек табуы, ике халык вәкилләре арасында үзара аңлашу башлавы. Моны Иван Хализов дигән кеше язып биргән үте-

[1]К. Насыйри. Сайланма әсәрләр, т. I. Казан, 1974, 73—74 битләр.
[2]Шунда ук, 75 бит.

нечләргә карап һәм өлешчә Адмиралтийская контора житәкчеләре Баранчеев һәм Бахметевлар чыгышларыннан төсмерләп була. Татар выборныйлары Сенатка бирергә дигән үтенечләрне Петербургта (яки Мәскәүдә) укымышлы урыс чиновникларыннан яздырып алалар. Генераль почтамттан эштән куылган канцелярист Иван Халезов белән татарлар христиан диненә күчкәннәр салымнарын түләтмәс өчен гаризалар бирү вакытында ук танышалар.

Җәберләнгән татарларга ихлас күңелдән теләктәшлек күрсәтеп публицистик пафос белән язылган И. Халезов үтенечләре татар выборныйларында да канәгатьләнү хисе уята, Сенат чиновниклары арасында да башкаларга караганда зуррак игътибар казана. Ул, Русия законнарын яхшы белгән кеше буларак, бу чорда татарларны эзәрлекләүләрнең закон бозу, җәмгыять нигезләрен какшату икәнен фаш итә. Соңга таба татарлар үтенечләрен И. Халезовтан гына диярлек яздыра башлый. Көрәш кискенләшкән саен, И. Халезов гаризаларының рухи кайнарлыгы, законсызлыкларны фаш итү дәрте дә арта бара, алдынгы урыс фикеренең изелгән халыкларны яклап күтәргән авазы булып яңгырый башлый. Үз кул астындагы йомышлы татарларның дәүләткә хезмәтеннән канәгать булган Адмиралтийская контора обер комиссары Баранчеев һәм статский советник Бахметов та Бистә татарларын оятсыз рәвештә мәсхәрәләп көчләү, закон бозып җәберләүләргә чыдый алмыйча, керәшеннәр өчен салымнар түләтү чорында, татар хуҗалыкларының аяныч бөлгенлеккә төшеп таралуы хакындагы хакыйкатьне Сенатка хәбәр итәләр. Бистәне эзәрлекләү, таркату хәрәкәте вакытында да алар, татарларга теләктәшлек күрсәткәндәй итәләр: көчләп чукындырылган сотник Бикмәт Котлинга һәм эзәрлекләнүче С. Уркинга, Сенатка барып шикаять бирер өчен, паспорт юнәтәләр. 1750 елгы изге Петр һәм Павел бәйрәмендә, иеромонах Патрикий бу эшләре өчен аларга чиркәү мөнбәреннән ләгънәтләр яудыра, аларны, диннән язган кешеләр, дип игълан итә. Татарларның бу хәрәкәттәге казанышларында, самодержавиене татарлар таләбе белән исәпләшергә мәҗбүр итүдә И. Халезов язган үтенечләрдәге сугышчан рухның да, Баранчеев, Бахметев кебек кешеләр теләктәшлегенең дә өлеше юк түгел. Урыс кешесенең изелгән халыклар хәлен, аларның таләбен аңлавы, шуны яклап аваз бирүе колонизатор сәясәтенең төп кагыйдәсе — «бүлгәлә һәм хакимлек ит» шигаренең какшый башлавын чагылдыра иде.

Татарларның бу хәрәкәте моңарчы тарихта абайланмаган яна бер нәрсә булган кебек, аның белән бәйләнештә туган сыйфатлар да тарих өчен бөтенләй яңа казаныш тәшкил иткән. Ул «яңа» күренешнең асылын яңарыш, урта гасырчылыктан арыну дип аңларга мөмкин. Бу яңарыш өчен татар тормышында объектив һәм субъектив шартлар житлеккән иде инде. Объектив шартлар — социаль-икътисадый мөмкинлекләр. Югарыда сурәтләнгән вакыйгалар татар җәмгыятендә тирән социаль үзгәрешләр баруын — феодаль сыйныфның нигездә юкка чыгуын, крестьян демократиясендә капиталистик үсеш юлы белән китү омтылышының көчәюен ачык искәртеп тора. Крестьян хуҗалыкларының базар, сәүдә мөнәсәбәтләренә тартылуы да шул омтылышны куәтли иде. Субъектив шартлар — халык һәм аерым кешеләрнең шул яңарышны кабул итәрлек, үстерерлек хәлгә килүе дә замана вакыйгаларында ачык күренә: шул яңарышка каратылган эшчәнлеккә С. Уркин кебек кешеләр атлыгып торалар. Татар җәмгыяте яңарыш өчен инде эшкәртелгән, ашланган, уңдырышлы җирлек хәленә килгән була. Әмма ул басуга яңалык орлыкларын сибүчеләрне шәфкатьсез эзәрлекләп торган самодержавие һәм христиан чиркәве хакимлек итә — алар яналык үсентеләрен төбе-тамыры белән йолкып атырга тырышалар. Ләкин тарих агышын алар бөтенләй кирегә бора алмый.

Югарыда тасвирланган көрәш татарлар арасында яңарыш хәрәкәте икәнлеген аның соңрак урын алачак вакыйгаларга тәэсире дә ачык искәртеп тора. Ә ул тәэсир, дөрестән дә, гаять көчле һәм дәвамлы булган: карышу хәрәкәте самодержавиене татарлар белән берникадәр санлашырга мәҗбүр иткән. Яна баскычтагы шундый хәрәкәт куркынычы астында царизм кайбер тупаслыкларыннан әкренләп рәсми рәвештә баш тартырга мәҗбүр булган. Татар халкына чиксез дошманлыгы белән яманаты чыккан Лука Конашевич 1755 елда Казаннан Белгород шәһәренә епископ итеп күчерелгән. 1756 елның сентябрь, октябрь указлары мөселманнардан керәшеннәр өчен рекрут алуны туктаткан: туган, торган җирләреннән көчләп күчерүләрне шактый чикләгән. 1764 елда «Новокрещенская контора»ны ябу турында указ чыгарылган. Өч-дүрт дистә ел яшәү дәверендә Идел буе халыкларына карата хисапсыз күп әшәкелекләр кылып өлгергән бу оешма соңгы көннәрендә дә яманатын тараткан: имән урманнарын тикшерергә җибәргән подполковник Свечин мөселманнардан керәшеннәрне сакларга бил-

геләнгән майор Ларионов, Лазарев һәм тагын унбер түрәнең яңа керәшеннәрдән ришвәт «каезлавы» турында Сенатка хат яза. Әмма үзләре дә шул талаучылар белән бергә кесәләрен калынайткан Синод түрәләре, Казан губерна кәнсәсе һәм епархия кебек кодрәтле оешмалар: «Бу хакта җирле халык, крестьяннар үзләре гариза биргәне юк»,— дигән сылтау белән гөнаһлыларны гадел хөкемнән йолып кала[1].

Әлеге погромнардан соң татар халкы самодержавие белән мөнәсәбәтләрне кабат мондый кискенлеккә китермәскә тырыша. Икенче яктан, самодержавие дә вәхшәтне берникадәр киметкәндәй итә. Көчәя, җитлегә барган урыс прогрессив һәм демократик көчләре эшчәнлеге, аның татарлар арасында да теләктәшлек уятуы аны шулай ук сагайта. Конфликтлар килеп чыгуга сылтау калмасын өчен, православ руханилар һәм самодержавие таләбе буенча, татарлар урыс һәм христиан динендәге башка халыклар белән мөнәсәбәтләрне мөмкин кадәр чикләргә мәҗбүр ителәләр. Бу теләк татарлар тарафыннан шул дәрәҗәдә төгәл үтәлә ки, шул ук реакцион православ руханилары инде бу адымны татарларны христиан динендәгеләрдән фанатикларча читләшүе, йомыклыгы, кыргыйлыгы итеп бәяләргә ашыга.

Царизмның көчләп чукындыру сәясәтенә җавап рәвешендә, татарлар арасында ислам дине тәэсире күрелмәгән дәрәҗәдә арта башлый. Азатлык хәрәкәтен яшерен хуплау мөмкинлекләре дини риваятьләрдә, дини бәхәсләрдә дә барлыгы аныклана. XVIII йөз азакларында ук инде рухи тормышта дин хәтта халык авыз иҗатыннан килгән традицияләрне кысып чыгара башлый. Азатлык хәрәкәте кебек халык язмышы өчен иң әһәмиятле мәсьәләнең дини фәлсәфә, иман чикләрендә гәүдәләндерү мәҗбүри бер нормага әйләнә бара. Шул рәвешчә, яңарыш хәрәкәте «нәтиҗәсе буларак», дин тәэсире көчәя башлый. Заманасына күрә иҗтимагый мәйданда старшиналар, зур ахун, муллалар, бай сәүдәгәрләр активлаша. Бу катламнар тарихын төгәл күзалларлык материаллар әлегә барланмаган. Әмма билгеле булган кайбер материалларга таянып, аларга бәя биреп була. Яңарыш керәшеннән соңгы старшиналарның әхлакый-сәяси йөзен, мәсәлән, 1755 ел кузгалышы вакытында хәрәкәтнең җитәкчесе турында хакимнәргә хәбәр итеп, акча эшләп алган Яныш старшина, Батыршаны тотып биреп мең сум бүләк алган Сөләйман старшина Дибаевлар хезмәтенә карап билгеләп була. Халыкның бу типтагы старшиналарга мөнәсәбәтен дә шул шәхесләр язмышы ук күрсәтеп тора: алар икесе дә акча алырга барган җирләреннән өйләренә кайтып җитә алмыйлар, юлда «йөрәк авыруыннан» кинәт җан тәслим кылалар. Руханилар катламы сыйфатлары да шундыйрак булганын морадчылар хәрәкәте турында әләк язган, Морадны һәм аның иптәше Аёт Уразмәтовны бәйләп Оренбур төрмәсенә тапшырган (1771) ахун Габденнасыр Габдессәләмов «тырышлыгында» күрергә мөмкин»[2].

Бай сәүдәгәрләр катламының типик вәкиле итеп 1802 еллардан соң үлгән Рәкый байны күрсәтергә була. К. Насыйри аңа мондый бәяләмә бирә: «Мөхәммәдрәхим бине Вәлид бине Мөслим бине Мәмеш,— Рәкый бай дирләр иде,— Орнаш Башында олуг вә мәшһүр бай иде. Һиммәт вә мөрәүвәт иясе адәм иде. Хәерияте күп иде. Яңа Бистәдә урта мәчетне ул бина кыйлдырмыштыр. Фәсыйхелкәлам вә йомшак сүзле галим адәм иде. Вә тәкъвалыгы, вә гайрәтлеге үз заманасында мәшһүр иде. Бай заманында, түрә-караны үзенә багындырып, үз кауленчә гамәл кыйлдырыр иде. Вә угрыларны, вә каракларны тоттырып,— үзенең таштан салган хибесханәсе бар иде,— анда ябып, җәза бирер иде. Юлда йөргәндә, артыннан-алдыннан, казаклар, төрәгъ төрук, төркем булып кычкырышып барыр иде. Ахыр гомерендә фәкыйрьлектә вафат булмыштыр»[3]. К. Насыйриның Казан сәүдәгәрләрен сурәтләүләрендә: «Фиргавен сыман үзсүзле, холыксыз кеше иде» (Исхак бине Мостафа, 36 бит). Яки: «Күп хатын алмак белән мәшһүр иде. Бер кызны алып, ихласы кайткач аерса, тәмам күп мал биреп вә йорт салып биреп аерыр иде»... кебек сыйфатлаулар да бар. Билгеле, болар арасында инде С. Уркин тибындагы шәхесләр очрамый. Иҗтимагый эшчәнлек күрсәтүдән көчләп тыелган өске катлау вәкилләреннән бөтән рухтагы сыйфатлар көтү мөмкин дә түгел.

---

[1]Малов Е. О Новокрещенской конторе. 244—245, 251—255 бб.
[2]ЦГАДА, 1381 ф., 303 тасвир. 281 төпләм, 5.49 бб.
[3]К. Насыйри. Календарь 1883 елга, 33 бит.

Әйе, татар тормышындагы социаль күренешләрдә XVIII йөз уртасы вакыйгалары тәэсире үзен һәрчак сиздереп тора торган факторга әйләнгән. Менә шуңа күрә дә татар тарихындагы соңгы 150 ел эчендәге хәлләрне, элгәреге ерак вакыйгаларны һәрчак истә тотып, шулар белән бәйләп карау мәҗбүри булып кала. Әйтик, абсолютизмның татар халкын эзәрлекләве шартларында, ике арадагы мөнәсәбәтнең гадәттән тыш киеренкелеге безнең җәмгыятьтәге консерватив көчләр эшчәнлеген сүлпәнәйтүе игътибарга лаек. Туган халкының ачу-нәфрәтеннән куркып, консерватив көчләр асыл табигатьләрен яшерергә мәҗбүр була. Менә алар иҗтимагый активлыктан ваз кичеп, үзләренә күпмедер дәрәҗәдә якын торган ислахчыларга иярү аша ирешәләр. Мондый шартларда татар җәмгыятендә иҗтимагый кәефиятнең рухын билгеләүче — яңа идеология яралгыларын тудыручы, куәтләүче бердәнбер көч булып демократик көчләр мәйданга чыга һәм башка катлауларны да үзенә иярергә мәҗбүр итә. Дини-мифологик инанулар яңа заман татар тормышын кырыс аскетлык, дәрвишлек шаукымнары белән сугарды. Әмма демократик көчләрнең өстенлеге татар иҗтимагый аңын яңа баскычка, Көнчыгыш мәгърифәтчелеге югарылыгына күтәрүгә дә хезмәт итте. Татар иҗтимагый аңы, социаль хәрәкәтенең болай үсеп китүе очраклы хәл түгел, сәяси, милли хәятенә баглы кануный үсеш-үзгәреш иде.

*1976.*

Нурихан Фәттах

# БАШКОРТ ҺӘМ БАШКЫРТ

I

Халык исемендә халык тарихы саклана. Берәр халык турында сүз барганда иң элек аның исеменә игътибар итәләр. Кайдан, ничек барлыкка килгән, кем сүзе һәм нәрсә аңлата, кайчан кулланыла башлаган — берсе дә калмый. *Рус* сүзе турында инде гасырлар буена бәхәс бара. *Татар* турында да бәхәснең тынып торганы юк.

Барлык халыкларның исемен тикшерү гаеп саналмагач, әйтик, *башкорт* атамасының нәрсә аңлатканын белергә тырышу да гаеп саналмаска тиеш иде сыман. Ләкин чынлыкта бик үк алай булмады шул. Башкорт халкының һәм башкорт сүзенең килеп чыгышын тикшерү башкортның үзенә генә түгел, татарга да кагылса да, безнең өчен бу әлегәчә тыелган тема булып кала бирде. Татарның башкорт белән дуслыгы турындагы сүзләрдән башка ни дә булса әйтсәң, ни өчендер башкортны кимсетү һәм мыскыллау булып аңлашылды. Шуңа күрә без үзара мөнәсәбәтләр турында, тарих турында сөйләгәндә «дус»тан, «интернационализм»нан башка сүзләр кулланмаска тырыштык. Кунакка йөрештек, мактаныштык, бер-беребезгә бүләкләр алып бардык.

Шул ук вакытта Башкортстанның үзендә татарга, Казанга карата күз күрмәгән, колак ишетмәгән дошманлык котырды. «Карабах» иң элек Карабахта түгел, нәкъ менә Башкортстан җирендә башланды. Гомер-гомергә татар исәпләнгән авыллар көчләп «башкорт»ка әйләндерелде, татар мәктәпләре ябылды, татар теле, татар әдәбияты урынына көчләп башкорт теле, башкорт әдәбияты укытыла башлады. Халык санын алу вакытларында татарларны көчләп, куркытып һәм төрлечә фальсификация кулланып, «башкорт» яздылар. Башкортстанда татар язучыларын, атаклы шәхесләрне, беркем белән һәм берни белән исәпләшмичә, җиңел генә «башкорт» ясадылар. Эшләр шул дәрәҗәгә барып җитте — хәтта Тукайга, Галимҗан Ибраһимовка «башкорт чапаны» кидерергә, «башкорт курае» тоттырырга азапланулар булды. Башкортча әлифбаның Октябрь революциясеннән соң гына барлыкка килүе бөтен дөньяга мәгълүм булса да, борынгы башкорт әдәбияты турында, «башкорт классиклары» Кол Галиләр, Акмуллалар турында сөйләнүләр көчәеп китте. Башкортка әйләнергә теләмәгән татарларны төрлечә кысу, җәберләү һәм мыскыл итү табигый хәлгә әйләнде. Үз милли хокукларын яклап көрәшкән татарларга, нәкъ Фирганәдәге сыман, «Казанга китегез! Татарстанга китегез!» — дип кычкырдылар. Күзенә ак-кара күренмәгән кайберәүләр Татарстанның көнчыгыш районнарына дәгъва белдерүдән дә тартынмадылар.

Татар белән башкорт һәрвакытта да дус-тату булган дип әйтәсем килми. Шулай да безнең беркайчан мондый күңелсез һәм хурлыклы хәлгә тарыганыбыз булмагандыр кебек. Монда барыннан да элек Мәскәү кулы уйнаганлыгын ачык итеп әйтергә кирәк. Ләкин монда башкорт милләтчеләренең дә роле юк түгел. Озак вакытлар дәвамында башкорт үзен татар белән чагыштырганда ни өчендер кимчелекле итеп сизгән. Милләт буларак үзен күрсәтү өчен аңа, бер яктан, рус хакимлеге комачаулаган, икенче яктан, татар комачаулаган яисә комачаулый сыман тоелган. Элегрәк ул кысучыларга каршы баш күтәрү белән җавап биргән булса, хәзер инде мондый нәрсәләр мөмкин түгел. Шуңа күрә дә ул бүген, олы абзыйга аркаланып, үзенең иң якын туганына, кан-кардәшенә ташлана. Хәер, монда башкорт халкының бер гаебе дә юк. Аны күбрәк башкорт тиресенә төренгән татар манкортлары кыздыра.

## II

Башкорт турында беренче мәгълүматлар X гасырга карый. Бу хакта башлыча гарәп авторлары яза. Соңгырак чорларда безнен якларга килеп чыккан Көнбатыш Европа сәяхәтчеләре дә башкортларга игътибар итәләр. Бу уңайдан Ибн-Рустә, Ибн-Хәукәл, Ибн-Фадлан, Әл-Бәлхи, Плано Карпини, Рубрукларны күрсәтергә була. Арада иң атаклысы, әлбәттә, Ибн-Фадлан. Барлык авторлар башкортларны узып барышлый гына, сүз арасында гына телгә алсалар, Ибн-Фадлан аларга аерым туктала һәм безнең өчен күп кенә кыйммәтле мәгълүматлар теркәп калдыра.

Ибн-Фадлан тасвирлавынча, башкортлар сугышчан халык булалар. «Без алардан курыктык һәм алар белән ничек тә уяу-сак булырга тырыштык, чөнки алар төрекләрнең иң яманы... башкаларга караганда да кеше үтерүгә әвәсрәкләре», — дип яза Ибн-Фадлан[1]. Башкортлар турында ул тагын шундый сүзләр дә әйтә: «Берәр кеше икенче бер кешене очратса, ул анын башын кыеп төшерә, башын алып китә, гәүдәсен калдыра»[2].

Ибн-Фадланның менә шушы һәм шуна охшаш кайбер башка сүзләре башкорт галимнәренең бик нык эчен пошыра. X гасырда татарларның бабалары болгарлар ислам дине кабул итәләр, чит илләр белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыралар, шул ук вакытта башкортлар, имеш, кыргыйлык хәленнән дә чыкмаганнар. Тигезлек түгел ич бу.

Моннан мең еллар элек башкортлар, чыннан да, бернинди тәртипкә буйсынмаган һәм очраган бер кешенең башын чабып төшерүдән тартынмый торган юлбасар булганнар бугай. Шуңа күрә башкорт исеме дә «баш-кырт!» дигән мәгънәдәге сүзләрдән ясалган, ахрысы. Башкорт турында менә шундыйрак аңлатма бар. Бу сүзне «башы-корт!» дип аңлатучылар да юк түгел. Корт монда «бет» дигәнне белдерә. Монысы инде күрәләтә мыскыл булып яңгырый. Ләкин Ибн-Фадланда бет турында да әйтелгән шул. Күрәсез, башкорт — башкырт сүзен **о** белән язсаң да, **ы** белән язсаң да, бөтен бер халыкны мыскыл итү өчен җай чыгып кына тора икән.

Башкорт атамасын «баш-кырт!» яки «башы-корт!» дип аңлатучылар күбрәк татарлар булган. Татар галимнәре түгел — кара халык, надан халык. Галимнәр исә бу сүзне башкачарак аңлаталар. Кайберәүләр башкорт сүзендәге *корт*ны «бүре», дип, *баш*ны «бүз» дип исәплиләр. Туласм бу «бүз бүре» мәгънәсендәге сүз булып чыга. Бүз бүре «соры бүре»гә әйләнә ала. Башкорт галиме Р. Кузеев тә кортны «бүре» дип, *баш*ны «җитәкче», «беренче» («главный») дип аңлый. Татар галиме М. Зәкиев башкортны башка-ар-т рәвешендә тарката һәм әлеге сүзне «чит кабилә кешеләре белән катнашкан кабилә» дип аңлата[3].

М. Зәкиев гипотезасының дәлилсезлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора. Шуңа күрә бу хакта фикер алышуның кирәге дә юк. Ләкин башкорттагы *корт*ны «бүре» дип аңлаучылар белән бәхәсләшмичә мөмкин түгел. Башкорт ул — «бүз бүре», дигән гипотеза безне ышандыра алмаса да, башкорт — баш бүре гипотезасында нидер бар сыман тоела.

Борынгы төрки телдә «бүре»нең *корт* дигән атамасы булган. Угыз телле төркиләрдә *курт* әле дә «бүре» дигәнне белдерә. Мәсәлән, төрекләрдә шулай. Төркиләрнең бүрегә табынган булулары билгеле нәрсә. Шулай итеп, башкортлар кайчандыр баш курд яисә баш корт — «баш бүре» булганнар булып чыга. Киңрәк мәгънәдә бу: «бүрегә табынучы баш ыру-кабилә, әйдәүче, җитәкләүче ыру-кабилә», дигән сүз була. Менә нинди бөек һәм изге сүз икән ул башкорт-башкурт!

Ләкин, беренчедән, башкорт телендә бүренең корт (курт) дигән исеме юк.

Икенчедән, башкортларның кайчан да булса, кайда да булса «баш бүре» — баш ыру-кабилә булулары билгеле түгел. 1919 елның 23 мартында игълан ителгән Башкорт АССРны исәпләмәгәндә, тарихта берәр төрле төрки башкорт дәүләте булуын без белмибез.

Өченчедән, бүрегә (куртка-кортка) борынгы төркиләрнең барлык ыру-кабиләләре табынган. Бүре барлык төркиләрнең изге хайваны саналган. Шуңа күрә башкортларны гына бүрегә табынучылар, җитмәсә ниндидер башлык ролен үтәүчеләр итеп аңлату тарихи дөреслеккә туры килми.

---

[1] Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу. М.-Л., 1939, 66 бит.
[2] Шунда ук.
[3] М. З. Зәкиев. Татар халкы теленең барлыкка килүе. Казан, 1977, 179, 180 битләр.

Дүртенчедән, борынгы башкортларның бүрегә табынган булулары-булмаулары гомумән, билгеле түгел. Ибн-Фадлан башкортларның бер төркеме жыланга, икенче төркеме балыкка, өченче төркеме торналарга табына; барлык башкортлар ир кешенең җенес әгъзасына табыналар һәм агачтан ясалган җенес әгъзасын муеннарына тагып йөриләр, ди[1]. Әгәр дә мәгәр башкортларда бүрегә табыну булган булса, гарәп сәяхәтчесе бу хакта да, һичшиксез, берәр нәрсә әйтеп калдырган булыр иде.

Шулай итеп, башкорт — баш бүре гипотезасы да ялган белән ялгышны берсе өстенә икенчесен өю нәтиҗәсендә генә барлыкка килгән икән, дип әйтә алабыз. Шуңа күрә әлеге гипотеза да галимнәр тарафыннан яклау таба алмады.[2]

## III

Башкорт атамасының нәрсә аңлатканын белү өчен эзләнүне, безнеңчә, бүгенге башкорт патриотының милли хисләреннән яисә интернационализм карашларыннан түгел, бәлки бөтенләй башка нәрсәдән — тарихтан, читтән, ерактан башларга кирәк.

Төрки халыклар борын-борыннан кояшка табынганнар. Кояшка табыну аларның телендә, дини-мифик карашларында, йолаларында, гореф-гадәтләрендә һәм сәнгатьләрендә чагыла. Кояшка табынуның формалары һәм символлары төрлечә булырга мөмкин. Монда без үзәклек принцибына гына игътибар итмәкче булабыз. Бу принципның төп эчтәлеге шуңа кайтып кала: җирдәге барлык җанлы-җансызның атасы — кояш. Кояшны олылаучылар — иң көчле, иң изге халыклар. Мондый халыкларның патшалары кояш уллары исәпләнелә. Кояш улларына һәм кояш дәрәҗәсендәге изге патшаларга карата кадер-хөрмәт тә зурдан булырга, ягъни барча кешеләр, барча халыклар кояш улын олыларга һәм берсүзсез аңа буйсынырга тиеш.

Патшаларның урыны һәрвакыт түрдә, югарыда, уртада булган. Патша бөтен илнең хакиме исәпләнгән. Ил башлыгы бер генә ыру-кабиләдән, бер генә нәселдән билгеләнеп куелган. Ләкин бөтен ил белән, гадәттә, өч-дүрт ыру-кабилә җитәкчелек иткән. Менә бу өч-дүрт ыру-кабилә — аксөяк, башкалар — кара сөяк саналган. Мәсәлән, Казан халыгында шундый бүленеш хөкем сөргән. Казан ягы — ак як, Казаннан читтәге җирләр — *кара як*, дип аталган. Кара якны *кыр ягы* дип тә йөрткәннәр.

Эшкәртелгән һәм иген игү өчен яраклы җир татарда басу дип атала. Кайчагында *кыр* сүзе дә басу мәгънәсен белдерә ала. Шулай да бу аның төп мәгънәсе түгел. Кыр ул читтәге, кырыйдагы җир һәм аның игенчелеккә бернинди катнашы юк. Яр кыры, урман кыры, авыл кыры дигәндә һәрвакыт читтәге, кырыйдагы җир кисәге күз алдына килә. Кыр сүзенең *кыра* варианты да билгеле. Себер төркиләрендә ул шулай кыра дип атала[3].

Кыр-кыра сүзе *кара*дан үзгәргән, дип фикер йөртәбез. (Моның шулай ук шумерча «чит җир» мәгънәсендәге *кура*дан үзгәргән булуы да ихтимал). Кайчан һәм кайда? Кайчан икәнлеген төгәл әйтә алмасак та, кайда икәнлеген без шактый дөрес чамалый алабыз. Бу хәл, безнеңчә, иң элек Төньяк Африкада, борынгы Мисыр җирендә булган.

Кара төс татар телендә кайчагында уңай сыйфатларны белдерә ала. Мәсәлән, кара күз, кара чәч һ. б. Тик шулай да кешегә карата кулланылганда *кара* иң начар һәм иң каргалган төс булып аңлашыла. Кара ул түбән дәрәҗәле, надан, томана, булдыксыз, динсез, тәртипсез, башбаштак кебек сүзләрне алыштыра ала. Кара йөз, кара йөрәк дисәк, бу инде туры мәгънәсендә дошман дигәнне аңлата.

Җир йөзендә кара тәнле, кара йөзле кешеләрнең бары тик Африкада гына булуы һәркемгә мәгълүм дип исәплик. Әйтик, моннан ун-унбиш мең еллар элек тә шулай булгандыр, дип уйларга тулы нигез бар. Мисыр кешеләре ак тәнле, европеоид кыяфәтле булганнар. Кара тәнлеләр белән иң элек, күрәсең, алар очрашкан һәм караларга карата дошманлык та иң элек аларда барлыкка килгән. Бу хәл бүгенге татар телендә бернинди үзгәрешсез дип әйтерлек сакланып килә.

Борынгы Мисыр кешесенең бөтен тормышы Нил елгасына бәйле булган. Монда ул иген иккән, җимеш, яшелчә үстергән, мал-туар, кош-корт асраган. Нил үзәненнән беркадәр читкә киткәч тә бернинди иген, җимеш, яшелчә үсми торган

---

[1] Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу, 66 бит.
[2] В. А. Никонов. Этнонимия.— «Этнонимы», «Наука», М., 1970., китабында, 18 бит.
[3] В. В. Радлов. Опыт словаря тюркских наречий. С.-Пб., 1893—1911, 735 бит.

комлы чүл башланган. Чүлдә төрле ерткычлар һәм ниндидер ят, дошман, кара кешеләр яшәгән. Нил үзәне *ил* булса, менә шул чит жирләр *кыр* (кыра-кара) булган. Шуңа күрә дә ил катнашында ясалган сүзләрнең барысы да яхшылыкны, изгелекне, байлыкны, муллыкны, тәртипне, оешканлыкны аңлатса, *кыр-кыра* катнашында ясалган сүзләр бары тик кире сыйфатларны гына белдергән. Мәсәлән, кыргый, кырау, кыран, кырылу һ. б.

*Кыз-кыркын* бүген, гомумән, кызларны аңлата, ләкин элегрәк бу сүз кыр ягыннан китерелгән кара тәнле кол хатын-кызны гына белдергән булса кирәк. Мәсәлән, чыгытай телендә *кыркын* «кара тәнле кол кыз» дигәнне, кырнак «төрекмәннәрдәге һәм кыргызлардагы (казакълардагы?) кол кыз» дигәнне аңлаткан[1]. *Кырык* сүзе дә *кыр* катнашында ясалган. Кырыкмаса-кырык — бик күп, иксез-чиксез дигәнгә туры килә. Ләкин «илдә — илле, кырда — кырык» дисәк, кырык илледән азрак булып кала. Димәк, *ил* һәм *илле* күбрәк һәм көчлерәк була.

Кыр-кыры кабиләләре никадәр дошман булып тоелмасын, ил кешеләренә алар белән дә аралашырга туры килгән. Ил кешеләре кырга яу чапканнар, караларның авылларын талап кайтканнар. Шул ук вакытта каралар да тик ятмаган — жай чыгу белән алар да бай күршеләренә каршы ябырылганнар. Шул рәвешчә илне каралардан, дошманнардан саклау зарурлыгы барлыкка килгән. Чик буйларын баштарак илнең төрле жинаять өчен хөкем ителгән үз кешеләре саклаган, ара-тирә бу эштә буйсындырылган, юашлатылган караларны файдалана башлаганнар. Кырда яшәүче кара ыру-кабиләләрнең төп вазифасы дәүләтнең чик буендагы жирләрен дошман яуларыннан саклау булган. Төрки телдә *кара* сүзе төсне яисә язу карасын гына аңлатмый. Боерык фигыльдән һәм язу карасыннан тыш аның тагын *халык* һәм *гаскәр* дигән мәгънәләре дә бар.

Төрки халыкларның иң әүвәлге ватаны, бүгенге галимнәр исәпләгәнчә, Көнчыгышта — Монголия, Алтай якларында түгел, Көнбатышта — Мисырда, Шумерда, Урта диңгез бассейны илләрендә булган. Төрле табигый һәлакәтләр, сугышлар, ызгышлар нәтиҗәсендә алар үзләренең ватаннарыннан күченеп китәргә мәжбүр булганнар. Аларның күпмедер өлеше төрле халыклар арасында таралып-югалып беткән. Әмма төньякка һәм көнчыгыш якларга таба хәрәкәтләнүчеләр иксез-чиксез далаларда, буш жирләрдә яңа дәүләтләр, яңа берләшмәләр төзеп, безнең көннәргәчә исән калганнар. Көнчыгышка таба хәрәкәтләнүче күчмәләр хәзерге Монголия һәм Кытай жирләренә кадәр барып житкәннәр. Әүвәлге ватаннарында идарә һәм хужалык ысуллары нинди булган булса, монда да тулысынча дип әйтерлек шул килеш калган. Алар кояшка табынганнар һәм үзләренең патшаларын изгеләштергәннәр. Дәүләт белән аксөякләр идарә иткән, карасөякләр чик буе жирләрендә яшәгәннәр.

Урта гасырларда Абакан һәм Кем (Енисей) буйларында барлыкка килгән Цигу биләмәсенең исемен кайбер галимнәр Кыргыз дип аңлаталар. Кытай язмаларындагы Цигуны Г. Е. Грум-Гржимайло Билге каган кабер ташында телгә алынган *чик* халкы исеменә тәңгәл дип исәпләгән[2]. Шул рәвешчә, кыргыз атамасы «чик буе кешесе (халкы)» дигәнгә туры килә икән. Чик сүзенең I варианты чит булачак. Күрәсез, *чик, чит, кыр* өчесе дә бер үк мәгънәдәге сүзләр булып чыкты.

Б. э. к. V гасырда, ягъни моннан 2400 еллар элек яшәгән Геродотның «История»сендә Кремны (Кырым) атамасы бар[3]. *Кыр* катнашында ясалган Кырым да кайчандыр ниндидер төрки дәүләтнең чиге, чите, кыры исәпләнгән, дип әйтә алабыз. Бүгенге Украинаның Кырымга якын урнашкан булуы да игътибарга лаек. Укра(ина) борынгыдан килә торган кыр жирләре атамасының славянлашкан варианты гынамы, әллә соң ул Рус дәүләтенең яңарак чорда барлыкка килгән көньяк *кыр*ын аңлата микән?

## IV

Идел буе болгарларының дәүләт төзелеше дә бик борынгы төрки принципка нигезләнгән. Монда да өч кабилә хакимлек иткән һәм алар, күрәсең, аксөяк

---

[1] В. В. Радлов. Шул ук хезмәт. 11 том, 864 бит.
[2] С. Г. Кляшторный. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. «Наука», М., 1964, 105 бит.
[3] Геродот. История в девяти книгах. Л., «Наука», 1972. IV, 20,110 битләр.

саналган. Болгар иленең чик буе җирләрендә яшәүче төрки һәм төрки булмаган ыру-кабиләләр каралар исәпләнелгән. Бүгенге Татарстанның көнчыгыш районнарында гына түгел, төньягында һәм көнбатышында да *кыр* катнашында ясалган авыл исемнәре очрый. Мәсәлән, Буа, Кама Тамагы, Куйбышев районнарында Кырлангы, Кыр Тәүгелдесе, Кыртапа, Кырый Йорткүл дигән авыллар, Арча ягында Кырлай, Саба ягында Кырбаш авыллары бар. Бу төбәкләр, күрәсең, кайчандыр Болгарның, ихтимал, хәтта Казанның кыр җирләре булгандыр, дип уйларга туры килә.

XII—XIII гасырларда мордваларның бер өлеше русларга, бер өлеше болгарларга буйсынган. Әлеге мордва җирләре дә Болгарның кыры булгандыр, дип әйтә алабыз. Болгар дәүләтенең көнчыгышында һәм көньягында башкортлар яшәгән. X гасыр авторы Ибн-Хәүкәл, мәсәлән, «башҗирт»ләрнең бер өлеше болгарлардан көньякта яши, ди[1]. Әл-Бәлхи «башҗар»лар ике кабиләгә бүленәләр, бер кабилә Гузлар иленең чик буенда, болгарларга якын җирдә яшиләр. Алар болгарларга буйсына. «Башҗар»ларның икенче кабиләсе бәҗәнәкләр белән чиктәш, ди[2]. Монда шуңа да игътибар итәсе килә: башкортларның ике кабиләсе дә чик буена урнашкан. Болгарга Урта Азия ягыннан — көньяк-көнчыгыштан килгән Ибн-Фадлан да иң элек башкортлар белән очраша[3].

X—XII гасырлар өчен дә, соңгырак чорлар өчен дә Болгар иленең чикләре төгәл билгеле түгел. Без бары кайбер маякларны гына күрсәтә алабыз. Мәсәлән, Лаврентьев елъязмасында 1229 елда болгарларның Җаек (хәзерге Урал) елгасы буендагы сакчы гаскәренең монгол яулары белән очрашуы турында әйтелә[4]. Димәк, Болгарның көнчыгыш чикләре Җаек буеннан үткән. Болгарның көньяктагы чикләре бу вакытларда хәзерге Самара шәһәреннән астарак булган дип уйланыла.

XIII гасыр башында Болгарга монгол яулары басып керә, болгарлар җиңелә һәм Болгар иле Чыңгыз ханның өлкән улы Җуҗи биләмәсенә әверелә. Җуҗи улусында Алтын Урда дәүләте барлыкка килә. Алтын Урда таркалгач, XV гасырның икенче чирегендә, элекке Болгар иленең төньяк җирләрендә Казан ханлыгы оеша. Казан баштарак Яңа Болгар дип атала. Бу аның Болгар варисы булуын, дөресрәге, шундый варислыкка дәгъвасын белдерә. Ләкин чынлыкта Казан элекке Болгарның барлык җирләренә түгел, хәтта төньяктагы җирләренә дә тулысынча хуҗа була алмаган. Казан ханлыгының көнчыгыш биләмәләре Нократ һәм Чулман буйларына кадәр сузылган. Көньяк-көнчыгыштта исә бу вакытта яңа дәүләт — Нугай ханлыгы хакимлек иткән. Элекке Болгарның Җаектан алып Чулманга кадәрге җирләре, шулай итеп, нугайлар кулында калган. Нугай ханлыгы белән Казан ханлыгы арасындагы чик буе сызыгы тотрыклы булмаган, ахрысы. Кайбер елларда Казан ханнарының хакимлеге Чулманның аргы ягына — Агыйделгә, Уфа суы тамагына (хәзерге Уфа шәһәре тирәләренә) кадәр барып җиткән.

## V

Башкорт дип языла торган сүзне без *башкырт* дип язабыз һәм «баш кыр-т» рәвешендә таркатабыз. Болгарның һәм Казанның көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш җирләре гасырлар буена баш кыр — иң әһәмиятле чик буе булган һәм гасырлар буена монда чик буйларын саклаучы «баш кыр кабиләләре» — башкыртлар яшәгән. Шуңа күрә дә Ибн-Фадланнан алып рус авторларына кадәр барысы да диярлек башкыртларның сугышчан булулары, ханнарга-патшаларга атлы-коралы гаскәр белән хәрби хезмәт күрсәтүләре турында язалар.

Ни өчен Болгарның, Казанның көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш җирләре баш кыр булды икән соң дигәндә, шул — бу төбәкләргә якыннан гына Көнчыгыш белән Көнбатышны, Төньяк белән Көньякны тоташтыра торган олы сәүдә юллары үткән. Якыннан гына — бөек даладан шулай ук бар нәрсәне кырыпҗимереп олы яулар үткән, барлык иле-көне, мал-туары белән кубып канлы илбасарлар үткән. Яулар-сугышлар һәм ил-көн белән күченүләр вакытында

---

[1] Б. Н. Заходер. Каспийский свод сведений о Восточной Европе, том II, 28 бит.
[2] С. И. Руденко. Башкиры. Историко-этнографические очерки. М.—Л., 1955, 31 бит.
[3] Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу. 66—67 битләр.
[4] С. М. Шпилевский. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. Казань, 1877, 159 бит.

дошман халыкларның чикне үтеп, йортка басып керү куркынычы булганлыктан, бу яктагы кыр җирләрне саклау беркайчан да үзенең әһәмиятен югалтмаган. Яу куркынычы булмаган очракта да чик буе җирләрен саклау һәрвакытта кирәк булган. Бит сәүдә юллары тыныч булса, сәүдәгәрләр дә күбрәк йөргән, дәүләт казнасына керем дә күбрәк килгән. Шуна күрә дә Болгар һәм Казан ханнары баш кыр җирләрендә махсус чик буе кабиләләре тотарга мәҗбүр булганнар да.

XV—XVI гасырларда башкыртларның бер өлеше Казан ханлыгына, бер өлеше Нугай ханлыгына, бер өлеше Себер ханлыгына буйсынган.

Буйсыну төрлечә булырга мөмкин. Әйтик, бала атага-анага буйсына, солдат командирга буйсына, кол хуҗага буйсына. «Башкыртларның Казан ханлыгына нинди формада һәм нинди дәрәҗәдә буйсынулары турында язма истәлекләрдә бик аз мәгълүмат сакланган»,— дип яза башкырт тарихчысы А. Н.Усманов[1]. Ләкин, шуңа да карамастан, бүгенге тарихи хезмәтләрдә Казан-башкырт мөнәсәбәтләре шактый бозып, ямьсез итеп тасвирлана. Казанга карата буйсындыручы гына түгел, басып алучы, талаучы кебек сүзләр кулланыла. Башкыртларның Рус дәүләтенә кушылуларына 400 ел тулу уңае белән язылган хезмәтләрендә Р. Кузеев белән Б. Юлдашбаев: «Вековая зависимость от Казани, угнетения, бесконечные унижения и притеснения, которые они испытывали от завоевателей, сказались на их позиции в заключительный период войны. Башкирские войска... покинули Казань и ушли в свои земли,[2]— дип язалар. Тагын да: «...башкиры отказали в поддержке Казанскому ханству. Это было своеобразным выступлением против угнетения, в течение столетия притеснявшего и грабившего башкирский народ»[3]. Шуңа охшаш фикерләр «Татарстан АССР тарихы»нда да әйтелә: «Казанские феодалы различных рангов управляли трудящимися подчиненных ханству народов (чуваш, мари, удмуртов, мордвы, башкир и др.), грабя и жестоко притесняя их»[4].

Башкорт — башкырт атамасының мәгънәсен «бүз бүре», «баш бүре» дип аңлатудагы кебек, монда да ялган белән ялгыш берсе өстенә берсе өелгән. Без монда барлык ялгышларга һәм ялганнарга тукталып тора алмыйбыз — бу эшне киләчәктә яңа буын тарихчылар башкарыр, дип ышанасы килә. Монда без өстә яткан кайбер фактларга гына игътибар итмәкче булабыз. Мәсәлән, башкыртның Казанга буйсынуы турында сүз барганда «басып алучы» («завоеватель») дигән тәгъбир кулланып буламы? Юк, булмый.

Беренчедән, Казанның башкыртларны яулап алулары турында бернинди язма истәлекләр билгеле түгел.

Икенчедән, «яулап алу», «басып алу» XV—XVI гасырларда бары тик Казан ханлыгы белән Нугай ханлыгы арасында гына яисә Казан ханлыгы белән Себер ханлыгы арасында гына була ала. Ни өчен дигәндә, башкыртлар яшәгән җирләрдә бары алар гына тулы мөстәкыйльлеккә ия һәм ил эчендәге барлык җиргә-суга, барлык ыру-кабиләләргә алар гына хуҗа.

Өченчедән, Казан ханлыгы, әйтелгәнчә, элекке Болгар дәүләтенең варисы буларак барлыкка килә. Болгар җирләренә ия булу процессында Казан «башкырт җирләрен» басып, яулап алмый, бәлки үзенә тиешле мирасны кире кайтарып кына ала. Болгар хакимлеге чорында болгар «гражданнары» булган ыру-кабиләләр хәзер Казан «гражданнары»на әвереләләр. Шунысын да әйтергә кирәк, башкыртлар бик озак вакыт үзләрен болгар дип исәпләгәннәр. 1890 елда В.

---

[1] А. Н. Усманов. Присоединение Башкирии к Русскому государству. Уфа. 1960, 52 бит.

[2] Р. Кузеев, Б. Юлдашбаев. 400 лет вместе с русским народом. Уфа, 1957, 37 бит. Татарчасы: «Гасыр буена Казанга бәйле булу, басып алучылар тарафыннан изелеп яшәү, бетмәс-төкәнмәс кимсетелүләр һәм кыерсытылулар сугышның ахыргы чорында аларның (башкыртларның — Н. Ф.) позициясендә чагылыш таба. Башкырт гаскәрләре... Казанны калдырып, үз җирләренә кайтып киталәр».

[3] Р. Кузеев, Б. Юлдашбаев. Шул ук хезмәт, 38 бит. Татарчасы: «... башкыртлар Казан ханлыгына ярдәм итүдән баш тарталар. Бу аларның изүгә, йөз ел буе дәвамында Казан ханлыгының башкырт халкын җәберләвенә һәм талавына үзенчәлекле бер җавабы була».

[4] История Татарской АССР. Том I. Казань, 1955, 119 бит. Татарчасы: «Ханлыкка буйсынган чуваш, мари, удмурт, мордва, башкырт h. б. халыкларның хезмәт ияләре белән Казанның төрле дәрәҗәдәге феодаллары идарә иткән, аларны талаган һәм кансыз рәвештә җәберләгән».

Кудрявцев язганча, «Уфа губернасының урман башкыртлары әле дә үзләрен болгар дип атыйлар»[1].

Җәбер-золым, кысу һәм талау мәсьәләсенә игътибар итеп карыйк. Казан ханлыгындагы халыкның зур күпчелеге «кара халык» дип аталган. «Кара халык» шәхси яктан ирекле булган һәм ханга, биләргә-бәкләргә ясак-салым түләгән. Ясакны мари, удмурт, чуваш, мордва һәм башкыртлар гына түгел, татарлар да түләгән. Казан ханлыгында «хезмәтияләренә» карата бернинди җәбәр-золым булмаган дип әйтсәк, бу, әлбәттә, дөрес булмас иде. Ләкин, җәбер-золымның нинди һәм ни дәрәҗәдә булуына да карамастан, барлык «кара халык»ның юридик хокуклары, безнеңчә, бер чамада булган.

Шуңа күрә башкыртка карата гына ниндидер авыррак аерым җәбер-золым булган сыман итеп фикер йөртү берничек тә ышандырмый. Кайбер башкырт тарихчылары нәкъ менә шулай фикер йөртәләр дә. Р. Кузеев белән Б. Юлдашбаев, мәсәлән, югарыда телгә алынган хезмәтләрендә: «Еще издавна, с момента подчинения Западной Башкирии Казанскому ханству, одной из тяжелых повинностей башкир была военная служба. Наряду с уплатой обременительного ясака, башкиры принуждены были по требованию хана выставлять определенное количество вооруженных воинов для участия в завоевательных походах и набегах Казанских ханов»,[2] — диләр.

Казан ханнарының Мәскәү патшалары белән бәрелеше вакытында бары башкыртлар гына сугышка мәҗбүр ителсәләр, монда әле күпмедер дәрәҗәдә җәбер-золым, кыерсыту турында сүз алып барырга да булыр иде кебек. Ләкин Мәскәү белән сугышта башкыртлар гына түгел, Казан ханлыгының барлык халыклары — татарлар, мари, удмурт, чуваш һәм мордвалар да катнашкан. Марилар, мәсәлән, Казанны саклауда татарлар кебек үк зур батырлыклар күрсәткәннәр. Аннан соң теләсә нинди чорда, теләсә нинди дәүләттә илнең, ватанның бәйсезлеге өчен көрәш һәркем өчен изге һәм мәҗбүри саналмаганмыни?! Әйтик, Советлар Союзында барлык милләт вәкилләре совет армиясендә хезмәт итәргә, бернинди каршылыксыз уртак дошманга каршы сугышларда катнашырга тиеш түгел идемени?! Ни өчен әле XV—XVI гасырларда Казан ханлыгы «гражданнары» башкыртлар гына илбасарларга каршы сугышта катнашмаска тиеш булдылар икән дә, ни өчен аларның Казанны яклап сугышулары бүгенге акыллы тарихчыларга «авыр бурыч» булып тоелырга тиеш икән?

Р. Кузеев белән Б. Юлдашбаев хезмәтеннән китерелгән өзекләрдән күренгәнчә һәм шулай ук башка тарихи хезмәтләрдән билгеле булганча, Казанның иң авыр вакытында башкыртлар сугыш кырын ташлап китәләр һәм, уртак ватанга хыянәт итеп, дошман алдында бил бөгәләр. Мондый эшнең бернинди мактауга лаек түгеллеген бүгенге тарихчылар аңламый түгел, аңлыйлар. Шуңа күрә дә алар тарихны төзәтү, дөресрәге, колонизаторлар идеологиясенә яраклаштыру белән шөгыльләнәләр: хыянәтне — патриотизм, куркаклыкны батырлык итеп күрсәтергә азапланалар. Ләкин күптән инде билгеле: тарихны төзәтеп тә, үзгәртеп тә булмый. Аны бары дөрес итеп аңлый һәм аңлата белергә генә кирәк.

Монда шундый сорау куясы килә: Казан ханлыгындагы «җәбер-золымга, талауга-көчләүгә» түзә алмыйча, Рус дәүләтенә үзләре теләп кушылган башкырт Шаһгалиләре, Камайлары нәрсә оттылар икән соң — ясак түләүдән, хәрби хезмәттән котылып, үз ирекләрендә яши башладылар микән, әллә хәтта мөстәкыйль Башкырт дәүләте төзи алдылар микән? Юк, Казан ханлыгында алар нинди хәлдә булсалар, Мәскәү хакимлегендә дә шундый ук хәлдә калалар — тиешенчә ясак түләргә, патшага хезмәт итәргә, киреге чыгу белән, патша һәм феодаллар ягында торып, канлы сугышларда катнашырга тиеш булалар[3].

---

[1] А. Н. Усманов. Күрсәтелгән хезмәт, 51 бит.

[2] Р. Кузеев, Б. Юлдашбаев. Күрсәтелгән хезмәт. 36 бит. Татарчасы: «Элек үк, ягъни Көнбатыш Башкыртстан Казан ханлыгына буйсындырылган заманнардан ук, башкыртлар өчен иң авыр бурычларның берсе хәрби хезмәт булган. Авыр ясак түләүдән тыш башкыртлар, хан таләп итү белән, Казан ханнарының басып алу сугышларында һәм яуларында катнашу өчен, билгеле күләмдә коралллы сугышчылар бирергә тиеш булганнар».

[3] А. Н. Усманов. Күрсәтелгән хезмәт. 36, 53 битләр.

## VI

Казан ханлыгында да, Мәскәү патшалыгында да башкыртлар аксөяк була алмаганнар. Ләкин шул ук вакытта аларның күп кенә өстенлекләре дә булган. Үзенә бүленеп бирелгән җирдә башкырт ел тәүлеге буена диярлек күченеп йөргән һәм күпмедер дәрәҗәдә үзен бәйсез һәм иректә сизгән. Бу уңайдан Дон һәм Кубань казакларын искә төшерергә була. Казаклар да сугышчан һәм ирек сөючән халык булалар. Аларның да төп эше атлы гаскәр белән чик буе җирләрен саклау була. Казан ханлыгындагы башкыртларны Рус дәүләтендәге казаклар белән янсә, киресенчә, Рус дәүләтендәге казакларны Казан ханлыгындагы башкыртлар белән чагыштырырга булыр иде.

Казан җиңелгәч, чик буе халыкларына карата Мәскәү патшалары нинди дә булса яңалык уйлап тапмаганнар. Алар, берни үзгәртмичә, Казан политикасын гына дәвам иттергәннәр. Шунлыктан без, Мәскәү патшаларының башкыртларга карата нинди мөнәсәбәттә булуына нигезләнеп, Казанның башкыртларга карата нинди мөнәсәбәттә булуын да күз алдына китерә алабыз.

Башкырт тарихчысы А. Н. Усманов язганча, буйсындыруның баштагы чорында руслар башкыртларның эчке идарә эшенә бөтенләй тыкшынмыйлар. Рус язмаларында «каралар» («черные люди») дип аталган башкыртлар белән бийләр-бәкләр, соңыннан старшиналар идарә итә. Халык җыеннары да беркадәр үз көчендә кала. Ислам дине һәм җирле халыкның гореф-гадәтләре, йолалары тыелмый. Башкыртлар Рус дәүләте казнасына ясак түләргә, үз исәпләренә гаскәр булдырырга, сугышларда катнашырга һәм Мәскәү дәүләтенең көньяк-көнчыгыш чикләрен күчмә халык яуларыннан сакларга тиеш булалар[1].

Тарихи чыганакларны җентекләп өйрәнгән В. Н. Витевский язганча, башкыртлар Рус дәүләте казнасына бик аз еллык ясак («небольшой ясак») түләргә тиеш булалар. Бу ясак 90 тиенлек бер батман балдан, 80 тиенлек бер төлке тиресеннән янсә 40 тиенлек бер сусар тиресеннән гыйбарәт[2].

Әгәр башкыртлар Казанга да шундый ук күләмдәге «небольшой ясак» түләгән булсалар, Казан ханнарының бер гасыр буена башкырт халкын изүе, талавы турындагы сүзләрне бүгенге тарихчыларның гадәттәге бер уйдырмасы дип кенә исәпләргә туры киләчәк.

Болгар ханнары да, Казан ханнары да тора салып үзләренең караларын талау-көчләү белән шөгыльләнмәгәннәрдер, дип уйларга кирәк. Казан ханлыгында төрки булмаган халыкларны көчләп төркиләштерү янсә мөселманлаштыру политика үткәрелмәгән. Казан ханлыгы чорында мордва, чувашлар да, мари, удмуртлар да тулысынча үз телләрен, үз йолаларын, гореф-гадәтләрен саклап кала алганнар. Бары тик Казан җиңелгәч кенә төрки булмаган халыкларга карата да, татарларга карата да төрле көчләүләр — көчләп чукындырулар, көчләп урыслаштырулар, көчләп җирне-суны тартып алулар һәм берниндн кызганусыз асу-кисүләр башланган.

Бу чорда рус патшаларының канлы политикасы бары башкыртларга гына артык кагылмаган. Мәскәүнең дала ягындагы чик буе җирләрен саклау зарурлыгы бетмәгәнлектән, рус патшалары башкырт җирләренең борынгыдан килә торган статусын үзгәртмәскә тырышканнар. Шул ук вакытта төрлечә кысуга, җәбер-золымга түзәр тәкате калмаган элекке Казан халкы — татарлар, чувашлар, мари, удмурт, мордвалар авыллары-авыллары белән «ирекле» башкырт ягына агыла башлыйлар. Монда килгәч алар хуҗалардан җир сатып алалар һәм озакламый үзләре дә җир-су хуҗаларына әвереләләр. Башкырт җирләрендә авыллар-шәһәрләр барлыкка килә, һөнәрчелек үсә башлый.

Башкыртлардан алына торган ясакның азлыгына һәм «башкырт» булуның өстенлекләренә кызыгып, Казан ягыннан күченеп килүчеләр үзләре теләп «башкырт» язылалар. Мондый башкыртлар арасында татарлар, чувашлар, удмурт, марилар гына түгел, хәтта руслар да, дала ягыннан килгән казакъ-кыргызлар да була. Башкырт ягына күченү гасырлар буена дәвам итә һәм бары 1863 елдан соң гына туктап кала[3]. Бүгенге көндәге «башкорт»ларның күпчелеге менә шул күченүчеләрдән гыйбарәт.

---

[1] А. Н. Усманов. Күрсәтелгән хезмәт. 39, 137,138 битләр.
[2] А. Н. Усманов. Күрсәтелгән хезмәт. 17 бит.
[3] Д. Б. Рамазанова. Формирование татарских говоров Юго-Западной Башкирии. Казань, ТКИ, 1984, 75—82 битләр.

Баш кыр кабиләләре тумыштан ук дигәндәй профессиональ сугышчылар, чик сакчылары булганнар. Шуңа күрә дә аларга авыл-шәһәр кору, утрак тормыш белән яшәү, иген игү тыелган. Үзләренең төп эшләрен онытмас өчен алар бары сугыш һөнәренә өйрәнгәннәр дә аучылык белән шөгыльләнгәннәр һәм тамакларын туйдыру өчен мал-туар асраганнар, умарта караганнар.

## VII

Башкыртларга кагылышлы тагын бер четерекле нәрсә бар. Урта гасыр язучылары безнең яктагы башкыртларны гына түгел, Дунай буендагы венгрларны (мажарларны) да «башкырт» дип атыйлар. Мәсәлән, XII гасыр авторы Әбү Хәмид әл-Гарнати шулай дип яза[1]. Венгрлар, билгеле булганча, төрки телле түгел. Алар фин-угор телле халыклар рәтенә карыйлар. Шул нигездә безнең яктагы башкыртлар да кайчандыр фин-угор телле булган һәм алар соңыннан гына төркиләшкән дип фикер йөртүчеләр дә бар. Шул ук вакытта венгрлар, киресенчә, төрки телле булмады микән, дип уйлаучылар да юк түгел. Ни өчен дигәндә, бүгенге венгр телендә күп кенә төрки сүзләр кулланыла икән. Идел-Урал буендагы башкыртлар белән венгрларның туганлыгы турында сүз алып бару өчен башка төрле сәбәпләр дә җитәрлек.

Мондый сәбәпләрнең иң әһәмиятлесе шул: венгрларның борынгы ата-бабалары хәзерге Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәкләрендә яшәгәннәр һәм IX гасыр азакларында Дунай буйларына күченеп киткәннәр. Археологлар Каманың сул ягында венгрларга гына хас каберлекләр, каберлекләрдә элекке венгр әйберләре тапканнар. Тарихи истәлекләрдә язылганча, Дунай буе башкыртлары (мажарлар) да сугышчан халык булганнар һәм озак вакытлар дәвамында тирә-яктагы күршеләренең котларын алып торганнар. XII—XIII гасырларда Дунай буе башкыртлары безнең яктагы башкыртлар белән аралашып торганнар, ахрысы. Тарихта мажар-башкыртларның Идел-Урал буйларына килеп чыгулары һәм мондагы башкыртлар белән кызыксынулары, һәр ике төр башкыртларының бер-берсен аңлаулары турында истәлекләр сакланып калган.

Венгрларның Идел-Урал буйларыннан Дунай буйларына күченеп китүләрендә дә тирән мәгънә бар. Монда, Дунай буенда, аларга кадәр килеп урнашкан һәм аерым дәүләт булып яшәгән Болгария була. Димәк, мажар-башкыртлар күпмедер дәрәҗәдә үзләренең танышлары, ихтимал, хәтта кан кардәшләре янына омтылганнардыр, дип әйтергә була. Аннан соң, безнең яктан күченеп киткән мажар-башкыртлар фин-угор телле генә булмаганнар шикелле. Дунай буе башкыртлары арасында төрки телле бәҗәнәкләр, кыпчаклар һ. б. булуы мәгълүм. XII—XIII гасырларда Идел-Урал буендагы башкыртлар арасында «онытылып» калган фин-угор кабиләләре дә булган булырга мөмкин. Төрки телле дәүләтләрдән еракта, Венгриядә фин-угор телле кабиләләр җиңеп чыккан булса, Болгар, Казан шартларында төрки тел җиңеп чыккан.

Дунай буендагы венгрларның кайчандыр хәзерге Татарстан, Башкыртстан җирләрендә яшәүләре һәм башкорт дип аталулары безнең башкорт-башкырт исемен «баш кыр кешеләре» — чик буе сакчылары дип аңлатуыбызга өстәмә дәлил булып тора. Бу шулай ук башкырт кабиләләренең каршылыклы табигатен, буталчык тарихын аңларга да ярдәм итә. Баш кыр җирләрендә беркайчан ил булып, дәүләт булып оешкан кабиләләр берләшмәсе булмаган. Болгар, Казан чорында да, Мәскәү хакимлеге чорында да һәрвакыт монда этник чуарлык өстенлек иткән. Тел һәм чыгыш ягыннан төрле булган бу чуар төркемнәрне бер сүз — «башкырт» атамасы берләштергән.

---

[1] Путешествие Абу-Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131—1153 гг.). М., 1971,37—49; 75 битләр.

## Миргазиян Юныс

# МАЛ БҮЛӘБЕЗМЕ?

Кем малы? Аны кемнәр бүлә? Ничәгә? Бүленгән өлешләре гаделме? Әлегә шушы сорауларның берсенә дә җавап юк, шуңа карамастан, барыбер күңелдә бер сәбәпсез шом барлыкка килә. Чөнки мал бүлү бик сирәк очракта гына гаугасыз, рәнҗүсез тәмамлана. Адәм баласының табигатендә, аның психологиясендә канәгатьлеккә караганда комсызлык көчлерәк булганга шулаймы икән ул, әллә мал бүлү һәр очракта диярлек гаделсезлек белән тәмамлангангамы? Бергә кушу, уртаклашу, киресенчә, сирәк очракта гына канәгатьсезлек уята, чөнки уртаклашу — дуслар эше, бүлешү — дошманнарныкы.

Башкорт һәм татар галимнәре, башкорт һәм татар әдипләре берәр фән өһелен, язучыны, күренекле шәхесне бүлә башласалар, Паола Веронезеның бер рәсеме күз алдыма килеп баса. «Сөләймән пәйгамбәр хөкеме» дип атала ул рәсем. Ике хатын Сөләймән пәйгамбәргә бер бала алып килгәннәр. Хатыннарның икесе дә «бала минеке» дип бара. «Ярый алайса,— ди Сөләймән пәйгамбәр,— сезнең икегезне дә рәнҗетмәс өчен баланы урталай бүлеп бирәм». Баланың чын анасы, аны газапланып тудырган хатын, шундук баладан баш тарта. Юк, миңа ярты бала кирәкми, аңа бирегез, ди. Һәм Сөләймән пәйгамбәр баланы нәкъ шул баш тарткан хатынга бирә.

«Казан утлары»ның 1991 елда чыккан 12 нче санында Әдхәт Синугылның «Бер мираска — ике караш» (Акмулланың тууына 160 ел тулу уңаеннан) исемле мәкаләсе басылган. Сүз Әхәт Вилдановның Уфада басылып чыккан «Мәгърифәт, яктылык йырсыһы» дигән китабындагы төгәлсезлекләр турында бара. Китаптагы барлык төгәлсезлекләрне, риясыз ычкынган һәм уйлап эшләгән ялганнарны бергә кушып әйткәндә, Ә. Вилдановның китабы Мифтахетдин Акмулланы башкорт милләтеннән икәнлеген исбатлауны күздә тота.

Күренекле әдипләрне, галимнәрне, тарихта тирән эз калдырган зур шәхесләрне бүлү инде күптән бара. Аның башлануына ничә ел икән? Илленче елларның азагында мин «Һади Такташ иҗатының башкорт шигъриятенә тәэсире» дигән темага диплом эше яздым. Һади Такташ, чыннан да, башкорт шигъриятенә тәэсир иттеме икән? Бу турыда башкорт галимнәре һәм шагыйрьләренең фикерен беләсем килеп, тоттым да Башкортстан язучылар союзына хат яздым. Дистәгә якын хат белән җавап килде. Әйе, Һади Такташның башкорт шигъриятенә ясаган тәэсире көчле иде, диделәр алар. Ә бүгенге көндә шундый хатка җавап килер идеме икән? Һәм җаваплар ничегрәк булыр иде? Минем шуны беләсем килә. Шул хаттан соң башкорт галимнәренә, башкорт шагыйрьләренә, әдипләренә карата ихтирам хисе уянган иде. Ул ихтирамым әле дә яши. Шул ук вакытта, шушы ике милләтнең интеллигенциясе арасында мал бүлү башланса, ничектер күңелсез булып китә. Югарыда күрсәтелгән «Сөләймән пәйгамбәр хөкеме» дигән рәсемдә күрсәтелгән низаг искә килеп төшә. Шушы ике халык галимнәре, әдипләре арасындагы «мал бүлүгә» әһәмият бирми дә башлаган идем. Пүчтәк эш бит, нигә борчылырга? «Бер мираска — ике караш»ны укыганнан соң исә нигәдер җан әрни башлады. Акмулланы ничек тигезләп икегә бүләргә? Икегә генә түгел, өчкә бүләргә кирәк бит әле. Ә нигә соң казакълар үз өлешләрен сорамыйлар? Аларга да бит бер өлеш бирелергә тиеш. Һәм иң читене, иң гонаһка барып житкән мәсьәлә — мәрхүмнең каберен казып, мәетне җир өстенә күтәреп бүлгәләргә микәнни? Бәлки, бөек шагыйрьнең шигырьләрен генә бүләргә кирәктер? Татар җирендә язылган шигырьләрне татарларга, башкорт җирендә язылганнарын башкортларга һәм казакъ җирен-

дә иҗат ителгән шигырьләрне казакъларга бүлеп бирергә кирәктер? Һәм бәлки аның каберенә дә өч таш куярга кирәктер? Өчне куймаган очракта да, кабер ташының беренчесен табып, урынына утыртырга кирәктер, бәлки? Кешелек дөньясында иң зур гөнаһ бар. Ул — мәетнең истәлеген пычрату (осквернение праха) дип атала. Кабергә куелган ташны урлап алып китеп, яңа, ялган таш кую әнә шул эш төгелме соң.

«Бер мираска — ике караш»ны башка кеше язган булса, мин әллә ни әһәмият тә биреп тормас идем. Әдхәт Синугыл язган. Мин аны ихтирам итәм.

Әле менә шул мәкаләне укыганнан соң туктаусыз җан сыкрый. Әдхәтнең шигырьләрен яратып укыйм, аның чын-чыннан культуралы, интеллигент шәхес булуын беләм. Ләкин язмаска кирәк иде ул мәкаләне! Бу очракта андый тәнкыйть сүзе, әллә ничек, урынсыз тоела. Ни сәбәп? Әдәби әсәрне, фәнни эшне тәнкыйтьләп була. Андый тәнкыйть әдәби әсәрдән, фәнни эштән ялгышлык яисә төгәлсезлек табып, дөресе ничек булуын күрсәтә. Баштанаяк ялганга корылган, ялганны максат итеп алып, шул ысулда язылган мәкаләгә исә тәнкыйтьнең ярдәме тими. Андый мәкаләне тәнкыйтьләп тә булмый. Гомумән, шагыйрьнең яисә башка берәр күренекле шәхеснең нинди милләттән булуы фәнне кызыксындырмаска тиеш. Үзен галим санаган кеше мондый эш белән шөгыльләнергә дә тиеш түгел. Кемнең нинди милләттән булуын ачыклау — кадрлар бүлегендә эшләүче вак чиновник эше. Кемнең кайсы милләттән булуын ачыклап, анкетаның бишенче пунктына теркәү КГБ өчен эшләнә иде. Бигрәк тә җаваплы эшкә яисә зуррак урынга утырыр алдыннан кирәк була иде кемнең нинди милләт вәкиле булуы. Хәтта хатыны нинди милләттән икән дип җентекләп тикшерәләр иде әле кайчакта.

Галимне, минемчә, бары тик гыйльми мәсьәләләр генә кызыксындырырга тиеш. Минем өчен, мәсәлән, Акмулланың шигырьләре феноменаль, башка шагыйрьләрнең иҗатларында чагылмаганча үзенчәлекле булуы белән кызыклы. Ул — мәгърифәтче. Башка мәгърифәтчеләрдән Акмулла шул ягы белән аерылып тора: ул — гамәли мәгърифәтче, турыдан-туры аудиториягә мөрәҗәгать итеп, үзенең аудиториясендә яшәп, үзенең укучылары һәм шәкертләре белән турыдан-туры мөнәсәбәткә кереп эш итүче остаз, шагыйрь, чичән, сердәш, киңәшче һәм дәрвиш. Акмулланың өстенә алган пәйгамбәрлек вазифасын русча бер сүз белән дә аңлатып була, ул — проповедник. Проповедниклыкны ул татар, башкорт, казакъ, кыргыз арасында алып барган һәм, гаҗәп талантлы шәхес буларак, шушы дүрт телдә дә аңлашырлык лексика туплап, шул төрки телләрнең күбесендә актив кулланылган сүзләр белән шигырь язган. Ул бит әле шигырьләреннән тыш, аудиториягә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп, аларның телендә дә сөйләшкән булырга тиеш. Шигырь язу аның гаҗәп зур күләмле эшенең бары тик кечкенә бер өлеше генә булган дип әйтергә тулысынча хакыбыз бар. Мулла буларак, ул Коръән укыган, кирәк чакта яшьләрне никахлаштырган, бәхәс-низаг чыккан очракта казый булып, хөкем дә чыгарган. Акмулла масштабындагы шәхес, билгеле, игенчелек эшен, мал асрау гыйльмен һәм сәүдә-финанс гамәлен дә белми калмаган. Балаларга дәрес бирү, укырга-язарга өйрәтү — бусы инде табигый хәл. Гомумән, унсигезенче гасырның азагыннан алып, егерменче гасыр башына кадәр яшәгән татар руханиларында Ренессанс чорына хас универсализм, киң тармакта хәбәрдар булу күзгә ташланып тора. Шушы фикерне дәлилләү өчен Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗәни белән Ризаэтдин Фәхретдиновның исемнәрен атау да җитә торгандыр дип уйлыйм. Ренессанс ысулында иҗат итү Акмулланың шигырьләрендә җәйрәп ята.

Өстенә алган пәйгамбәрлек вазифасын эшкә ашырганда Акмулла, һичшиксез, татарлар белән татарча, башкортлар белән башкортча һәм казакълар белән казакъча сөйләшкән. Ул чакта бу тугандаш телләр бүгенгегә караганда бер-берсенә якынрак торганнар. Ленин бабай ярдәмендә халыкларны сортировать итеп, аларның араларын чик белән бүлгәннән соң, төрки телләрдәге аерма елдан-ел көчәя, алар бер-берсеннән ерагая башладылар. Акмулла исән чакта башкортлар аны үз шагыйрьләре итеп санаган булулары да мөмкин. Һәм әгәр бүгенге көндә дә аны үз итсәләр, бу эш өчен мин башкортларны гаепләмәс идем. Шуны да истә тотарга кирәк. Күренекле шәхесләрне башкорт итәргә теләп дәгъва куптарганда, күптән сынап йөрим, башкорт галимнәре беркайчан да төшеп калганнарны сайламыйлар. Кол Гали, Мәҗит Гафури һәм менә Әхәт Вилданов әфәнде «дәлилләгән» Мифтахетдин Акмулла.

Шушы мәкалә белән минем татар галимнәренә, әдипләренә мөрәҗәгать итәсем килә. Башкортлар татарның күренекле шәхесләренә кул сузганда бу эшкә бер дә каршы килергә ярамый.

Гомумән, бу темада бәхәсләшүнең бер тиенгә дә кирәге юк.
Әйтик, Акмулла күләмендәге шагыйрьне тагын берничә милләт үз итсә — ул аларга да җитәр, безгә дә калыр. Бөек шәхес бүлеп алганга карап кына кимеми, киресенчә, аның күләме, әһәмияте арта. Шунысын да онытырга ярамый: «мал бүлү» фәнне баетмый, киресенчә, вакытны һәм көчне алып, фәнгә шактый зур зыян китерә. Кабат мөрәҗәгать итеп, үтенеп сорыйм: хәтта безнең барлык язучыларыбызны, галимнәребезне, тарих битендә эз калдырган шәхесләребезне йөз процентка башкорт итеп бетергән очракта да, җавап язып вакыт әрәм итәргә кирәкми. Киресенчә, андый галимнәргә рәхмәт кенә әйтергә кирәк! Безгә реклама ясыйлар бит.
Әллә вакытларын һәм көчләрен шул татардан башкортлык эзләп исраф итеп бетергәнгә, Башкортстан галимнәре үз әдәбиятларындагы бер гаҗәп зур казанышны шушы көнгә кадәр бәяли алмыйлар. Сүз Талха Гыйниятуллин иҗаты турында бара. Бу язучының әсәрләре, һичшиксез, дөнья әдәбияты тарихына кереп калачак. Беренчедән, Талха сугышның моңа кадәр беркем күрсәтә алмаган бөтенләй яңа ягын ачып бирде. Гыйниятуллинның әсәрләрендәге сугыш теге «ура» кычкырып атакага бару белән генә чикләнми. Ул җиңүгә һәм җиңелүгә дә әһәмият бирми. Җиңү һәм җиңелү — вакытлы хәл. Без бүген шул нәтиҗәне күрү бәхетенә ирештек: җиңүче вөҗдан хөкеме каршында җавапка тартылып, бар җинаятьләре өчен җәза ала. Талханы сугышның адәм баласы психологиясенә ясаган тәэсире кызыксындыра. Сугыш дигән нәрсә кешенең психологиясенә көчле тәэсир ясый. Шул тәэсир инде күптән юкка чыккан бик борынгы, кыргыйлык чорындагы әшәке инстинктларны уятып, җанландырып җибәрә. Гыйниятуллин үзенең әсәрләрендә менә шушы феноменны күрсәтә алган. Аннан соң ул сугышның канга сеңеп калуы, сугышка катнашкан кешегә гомер буе тәэсир итеп торуы һәм шуның аркасында тулысынча бер буынның сугыш корбаны булуы турында яза. Әйтик, Толстойдан, аннан соң Хемингуэйдән соң («Сау бул, корал») сугыш турындагы әдәбиятка әллә ни яңалык өстәгән язучы юк диярлек иде. Башкорт язучысы Талха Гыйниятуллин табигый тыйнаклык белән дөнья әдәбиятына зур өлеш кертеп куйды. Белмим, башкортның әдәбият белгечләре кая карый торганнардыр? Әллә бу зур һәм үзенчәлекле иҗатны яктыртырга аларның тешләре үтми, әллә Гыйниятуллинның каны чиста түгел. Кан чисталыгын тикшерү бит ул гөнаһсыз эш түгел. Теге Алман фашистлары чорында кан чисталыгын өйрәнү белән мавыгуга әле бит бары тик ярты гына гасыр үтте...
Талха Гыйниятуллинның иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнгән очракта, аның әсәрләрендәге яңалыкларга таянып дистәләгән докторлык диссертациясе язарга мөмкин. Татар галимнәреннән мин шуны үтенер идем: бу язучының иҗатын өйрәнә башларга иде! Әгәр шушы эшне татар галимнәре башлап җибәрсә, беренчедән, башкортның әдәбият белгечләренә зур ярдәм булыр иде, икенчедән, бу эш таш белән атканга аш белән ату булыр иде.
Минем туган авылым Ык елгасының сул як ярына урнашкан. Уң як ярдан Башкортстан җире башлана. Шушы ике тугандаш милләт күп гасырлар бер табыннан ашап, шатлык-михнәтне үзара бүлешеп, колонизация шартларын бергә кичереп, сокланырлык матур мөнәсәбәттә яшәп килгән. Башкортстанда туып үскән татар язучыларын, шагыйрьләрне алыйк. Алар аеруча моңлы һәм яңгыравыклы итеп яза беләләр, чөнки ул төбәкләрдә фольклор исән сакланган, халык табигатькә якынрак яшәгән һәм борынгы гореф-гадәт, борынгы йолалар күбрәк сакланган. Гади халык арасында дошманлык хисе яшәвен белмим мин һәм аның булуы да мөмкин түгел. Язучыларның зурлары, галимнәрнең чыннары арасында да татар-башкорт дошманлыгының булуы мөмкин түгел. Совет чынбарлыгы, гыйльми галимнәр белән беррәттән, номенклатур галимнәр дә үзерләде. Урта белемсез вуз дипломына ирешү, фәнни эрудициясез, мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәнеп тормыйча гына диссертация язу һәм шуны яклап, фән кандидаты, фән докторы дигән дәрәҗәне күрсәтүче диплом алу... Андыйларның фәнни «багажлары» шуның белән чикләнә иде. Менә шушы юл белән галимлеккә ирешкән кеше ничек инде фән белән шөгыльләнә алсын?
Башкорт һәм татар галимнәре, ике милләт язучылары арасында еш кына кубып киткән чүлмәк давылын наданлык һәм культурасызлык кына аңлатып бетерә алмый. Колониаль изелүгә дучар булган, империянең дагалы итеге астына эләгеп имгәнгән милләтләргә хас гауга бу. «Бүлгәлә һәм идарә ит» — колониаль сәясәтнең барлык кануннары шушы аксиомадан башлана. Татар белән башкортны маңгайлары белән чәкештермәгән очракта, ничек

шушы ике горур, азатлык сөюче халыкны тулысынча буйсындырып, кол итеп булыр иде икән?

Инглиз колонизаторларының Һиндстаннан китүенә ярты гасырдан артык вакыт үтте. Британия империясе кан коюсыз диярлек таркалды. Бәрелешүгә, кан коюга якыная башлау белән инглиз колонизаторлары пароходларга төяләп, туган җирләре Альбионга кайтып киттеләр. Алар киткәннән соң милләтләр арасында бугазлашу, кан коюлар булды. Тегеләр: менә без идарә иткән чакта колониаль халыклар үзара дус яшиләр иде, күрәсезме, без киткәч нишлиләр, дип колониаль сәясәтне акларга азапланып та карадылар. Нәкъ шул сүзләр Кавказдагы кан коюга карата да кабатлана.

Патша чорында башкортлар ничәмә тапкыр колонизаторларга каршы баш күтәреп, азатлык юлында шәһит китте. Татарлар исә, (сүз колга әйләнмәгән, азатлык төмен югалтмаган татарлар турында бара бер генә сәгатькә дә үзләренең мөстәкыйль яшәгән чорларын онытып тормадылар. Империя олтаны астында яшәү милләтләргә никадәр генә авыр булмасын, патша чорында алар бүгенге хәлгә җитеп бетмәгәннәр иде. Троицкидагы, Уфадагы, Оренбурдагы татар яшәгән барлык төбәкләргә җан җылысы, мәгърифәт нуры биреп торучы үзәкләр... Шул төбәкләрдән күтәрелгән Галимҗан Ибраһимов, Дәрдеменд, Сәгыйть Сүнчәләй, Сәгыйть Рәмиев, Шәехзадә Бабич кебек шәхесләр... Гомумән, башкорт ягының мохите, ни сәбәптер, талантлар тәрбияләү өчен бик тә шифалы булган.

Татар белән башкорт арасындагы киеренкелек «халыклар дуслыгы» байрагы астында алып барылган җаһиллекнең чәчәк аткан чорында, Шакировлар һәм Табеевләр хакимияте вакытында көчле үсеш алды. Татар мәктәпләрен бетерү, паспортка һәм анкетага татарны башкорт итеп теркәүне башкорт халкы оештырмаган. Ул гаепле түгел. Бу эштә ике тугандаш халыкның катнашы да, гөнаһы да юк. Шакировның куштаннары, аның иярченнәре, аларның Мәскәүдә Старая площадь сараенда утыручы хуҗалары өчен кирәк булган ул җинаять. Башкорт һәм татар галимнәре, башкорт һәм татар язучылары арасында гауга кузгалган очракта, аның каян килеп чыгуын аңлар өчен шул милләтләрне бетереп, алардан «тарихи бердәмлек» дип аталган манкорт ясау процессын тикшерергә кирәк.

Татар галимнәре һәм язучылары мине аңларлар дип ышанам. Туктатырга кирәк бу файдасыз вакчыллыкны. Рәнҗемәскә тырышырга кирәк татарны башкорт итеп күрсәтүчеләргә. Бу ике милләт арасындагы тугандашлык ерак гасырларга киткән. Халыкта тугандашлык хисе әле дә исән, әле һаман яшәп килә. Күп гасырлар буе бер-берсенә ярдәм итеп, авырлыкларны бергә кичереп яшәгән ике тугандаш халыкның бүлесе малы, бирәсе әҗәте юк икәнлеген галимнәр, язучылар, башкорт һәм татар интеллигенциясе аңларга һәм аңлатырга тиешләр. Дөрес, автономия төзегән чакта бу төбәктә дә Карабах феноменын кыстырып калдырырга тырышканнар. Шуңа карамастан, акыл белән, шәфкатьлелеккә таянып эш иткәндә, ике туган арасында бернинди низаг һәм киеренкелек булуы мөмкин түгел. Киресенчә, башкорт халкында мул сакланган фольклор байлыгы, аларның табигатькә якынрак яшәүләре, бу халыкка хас самимилек татардагы чыдамлык, мөстәкыйльлек чорыннан бүгенге көнгә кадәр килеп җитә алган көнкүреш культурасы киләчәктә дә кирәк булачак. Бәлки менә шушы сыйфатларның синтезы һәм шуны үзләштерү тәэмин итәдер башкорт ягында талантлы шәхесләрнең күп булуын?

Ике тугандаш халык алдында торган катлаулы мәсьәләләрне дуслык шартларында гына уңышлы хәл итеп булачак. Мин шул мәсьәләләрнең әйбәт хәл ителәчәгенә чын күңелдән ышанам.

*1992 елның феврале.*
*Переделкино.*

**ВӘЛИ БУЛАТОВ**

# ГОРЕФ-ГАДӘТ, ЙОЛАЛАРЫБЫЗ

***Мин бу язмаларымда 1900—1912 елларда Оренбург ягы татар авылларында балачагымда күреп үскән; урта хәлле гаиләләр тормышына хас гореф-гадәт, йолаларыбызны тасвирлыйм. Буыннар алмашына, егерменче йөздә булып узган иҗтимагый-сәяси, социаль тетрәнүләр ата-бабаларыбыз кичергән яшәеш тәртибенә, ышану-ырымнарына, әдәп-әхлак кагыйдәләренә дә байтак үзгәрешләр кертте. Аларның һәммәсен хуплавы кыен. Шуңа күрә яшьләргә үткәнне искә төшерү һич тә комачауламас, бәлки әле файдалы да булыр диеп уйлыйм.***

## Сүз салу

Шундый-шундый сүзләр, хәбәрләр әледән-әле йөреп кенә тора авылда:

— Фәләннәр теге фәләннәргә кызларын сорарга яучы җибәрмәкче булып «сүз салып» караганнар икән дә, юк, булмаган, тегеләр кире каккан.

— Фәләннәр фәләннәрнең кызына яучы җибәрәләр икән, «сүз салу»га уңай җавап алганнар, ди.

Димәк, улларын өйләндерергә ният иткәннәр үзләренә кулай дип санаган кешеләргә аларның кызларын сорарга яучы җибәрәчәкләрен арадашчы-димче аркылы әкрен генә ишеттерәләр, сиздерәләр. Арадашчы-димче серне кызның якыннарына, очрашканда, җаен табып әйтә. Менә шуны «сүз салу» диләр.

## Яучы

Егет ягы «сүз салу»га уңай җавап алгач, үз якыннарыннан берәүне, һәрхәлдә, сөйләшә белә торган кешене кызга яучы итеп җибәрә. Яучы исә кыз өенә тора салып, теләсә кайчан барып керми, арадашчы-димче аркылы сөйләшенеп билгеләнгән көнгә генә бара. Аны якты йөз, тәмле сүз белән каршы алалар. Аның килүенә, гадәттә, самавыр куелган, казан асылган.

Исәнлек-саулык сорашканнан соң, төп мәсьәлә буенча сөйләшүләр китә. Яучы үзенең кайдан һәм нигә килүен әйтә. Егетнең, кызның — булачак кияүнең, киленнең исемнәрен җиренә җиткереп, кыскартмыйча атый.

— Әйе, якын кардәшләр булырга исәп итеп йөрибез бит әле, кабул күрсәгез? — ди.

Шулайрак башланып киткән әңгәмә ярыйсы ук озакка сузыла. Әти кеше, тел төбе кызын бирергә булса да, кисеп әйтми. Яучының беренче килүендә үк кисеп әйтүне, яулык (вәгъдә бүләге — сөлге) биреп җибәрүне һич тә килештермиләр.

— Ярар, безне санга сугып зурлап килүегез өчен рәхмәт. Бу хакта агай-энеләр белән киңәшләшеп карарбыз, фәлән көнгә, рәхим итеп, тагын килерсез, шунда тагын сөйләшербез, — ди әти кеше.

Әйтелгән көнне шул ук яучы икенче кат килә. Аны якты йөз, тәмле сүз белән каршы алалар, бары белән сый-хөрмәт күрсәтәләр. Бу мәҗлестә киңәшләшергә кыз әтисе һәм яучы янында тагын бер-ике ир-ат катнашырга мөмкин. Сөйләшәләр, киңәшәләр... Тик, тыйнаклык йөзеннән, чишелеп үк бетми әти кеше.

— Кызыбыз яшь (уналтысы тулып унҗидесе киткән кыз яшь саналмый), әллә беразга кичектереп торабызмы бу зур эшне? Юкса, Сезне үзебезгә кулай кешеләр күрәбез күрүен, — ди ул.

---

Вәли БУЛАТОВ (1911) — *гомере буе туган ягында балалар укыткан мөгаллим. Оренбург өлкәсе Габдулла районы Яңа Якун авылында яши.*

Чыннан да, кайчакта берәр сәбәп белән кыз аклашуны (ярәшү) ярты елга, бер елга кичектереп тору хәлләре булгалый. Егет тә, кыз да бик матур итеп, әдәп саклап вәгъдә көнен көтәләр. Ата-ананың, олыларның карарына каршы килү кая ул! (Бу урында көчләп кияүгә бирү, көчләп өйләндерүләр турында сүз бармый, билгеле.) Инде аклашу кичектерелмәгән хәлдә, яучының икенче килүендә мәһәр салына. Һәм яулык (вәгъдә бүләге) бирү көне билгеләнә. Егет ягының кызга күпме мәһәр бирергә теләвен яучы алдан ук белеп тора. Һәм шуны кыз ягына җиткерә. Инде мәһәр турында ризалашу авырга китә икән, ул чакта егет әтисе бу киңәшмәгә чакырылырга мөмкин. Мәһәр, күбесенчә, кызга ике күлмәклек, ике яулык, шәл, берәр тышкы кием (җилән), кәлүш, эче-тышы белән юрганлык һәм бик шәп кенә сандык. (Кызның яшьтән үк үз кулы белән эшләгән әйберләре куела килгән сандыгы булса, егет ягы мәһәргә сандык салмаска да мөмкин. Тик бу әйбернең булу-булмавын мәһәр салганда кыз әтисе әйтергә тиеш.) Туйны сый-хөрмәтле итеп үткәрү өчен, хәл кадәренчә бал, ярты яки бер сарык түшкәсе, чәкчәк оны һәм бик тә чама белән акча салына. Инде килешенгәннән күбрәк китерәләр икән, рәхим итсеннәр, бик хуп!

Тәмам килешенеп, сөйләшенеп җиткәннән соң, мәһәр салулардан соң кыз әтисе бу очрашуда яучыга: «Фәлән көнгә рәхим итәрсез, аллага тапшырып яулык бирербез»,— ди.

Яучы өченче кат килүендә урамнан ярыйсы ук киңәеп атлый. Сынар балак та чыгарылган. Чөнки бит яулык бирергә вәгъдә ителгән. Эш ышанычлы. Баштагы ике килүендә ул әле кеше күзенә бик үк иркенләп ташланырга кыймый, балак та чыгарылмый. Булыр-булмаска балаклар чыгарып йөрү килешеп бетми, янәсе.

Инде бу юлы яучы килеп бераз сөйләшкәч, яулык, ягъни вәгъдә бүләге бирү тантанасына егетнең атасы да чакырыла. Хәзер мәҗлестә ике яктан бергә өч-дүрт ир-ат катнаша. Кыз анасы исә ире белән икенче өйдә яки чаршау эчендә киңәшбелешә итә. (Бу — яучы ир-ат булганда шулай.)

Менә инде бик тә җитди рәвештә, тантаналы төстә ике якның бергә-бергә гөрләшеп яшәүләрен, ике яшькә чиксез бәхет, керсез мәхәббәт теләп, кызны аклашу (ярәшү) билгесе бүләкләре бирелә. Баш яучыга бит яулыгы яки сөлге, биш бармаклы җон бияләй, кулъяулыгы һәм намазлык тапшырыла. Бит яулыгы баш яучыга, бияләй белән кулъяулыгы кияүгә, намазлык кияүнең әти-әнисенә дип исәп тотып бирелә.

Бүләкләр тапшырылгач, ягъни зур, җитди эш башкарылганнан соң, рәсми сөйләшүләр бетә. Мәҗлес икенче төс ала: җиңелчә сөйләшүләр, уен-көлке сүзләр китә. Табын яңартыла.

Кыз аклашып яулык алып кайтканда яучы (ир кеше) үзен мактанган, масайган кыяфәттә тота. Хәтта, аклашу билгесе бит яулыгын (сөлгене) әләм кебек итеп җилфердәтә-җилфердәтә кайталар. Күрегез, янәсе, эләктердекме менә дигән кызны!

## Колак сөенчесе

Егет үзенә кыз аклашу хәбәрен беренче булып китерүчегә сөенчегә акча бирә. Моны «колак сөенчесе» диләр.

## Аш китерү

«Колак сөенчесе» бирелгәннән соң бер-ике көн үтүгә үк, кияүнең сеңлесе яки апасы — һәрхәлдә кыз туганы аклашылган кызга аш китерә. Ап-ак тастымалларга пөхтә итеп төреп китерелгән төенчектә ашамлыклар ярыйсы ук мул. Анда коймак, чәкчәк, пешкән ит яки итле камыр ашы һәм кыр җиләк-җимешләре.

Аш китерүчегә, әлбәттә, яшь килен исеменнән бүләкнең затлырагын бирергә тырышалар. Нәфис итеп чигелгән алъяпкыч күкрәкчә бирәләр.

Аш китерүче биредә озакламый, аш-судан соң шул ук көнне кайтып китә.

## Якынаю ашлары

Кияү әтисен һәм аклашылган кыз әтисен баш кодалар диләр. Шушы баш кодалар арасында, алар бер үк авылныкы булсалар, кыз аклашуга биш-алты көн үтүгә ашка чакырышулар булып ала. Баш кода белән кодагыйны, ягъни кыз

əти-əнисен икесен генə башта егет ягы ашка чакыра. Аннан соң икенче баш кода белəн кодагыйны — егет əти-əнисен кыз ягы ашка ала. Бу чакырышуларда бүлəк бирешү-алышулар юк. Бер-береңне күрү, танышу өчен үткəрелгəн ашлар була инде болар.

## Мəһəр китерү

Мəһəр күп вакыт яучының икенче яки өченче килүендə салына. Шул чакта аның кайчанрак китерелəчəге дə əйтелə. Гадəттə кыз аклашуга унбиш-егерме көн үтүгə, кияүнең энесе яисə иптəш егете матур итеп җигелгəн атта кызга мəһəр китерə. Әйберлəрнең барысын да пөхтə итеп мəһəр сандыгына тутыралар. Ит, он, исеме өчен генə булса да бал (ансыз ярамый), борын кычытуын басарлык күчтəнəч кумəче кебек ризыклар мөмкин кадəр ару савытларга салып, пакь тастымалларга төреп китерергə тырышыла.

Мəһəр китерүче дə көтеп алынган кадерле кунак санала. Аңа сый-хөрмəт күрсəтəлəр. Җиңгəчəй (җиңгəй, җиңги) бүлəге биш бармаклы бияләй, чиккəн кулъяулыгы бирəлəр. Егет биредə озакламый, əйберлəрне тапшырып, аш-судан соң шул ук көнне кайтып китə.

## Туй килү

Кызны аклашудан ук ике якта да зур туйга хəзерлек башлана. Никах ашына атна-ун көн кала, зур туйга чакырып, кыз ягыннан егет ягына хат бирəлəр. Хатта баш кода белəн кодагыйның туйга килүлəрен һəм үзлəре белəн телəгəн кешелəрен «канат» итеп алып килүлəрен үтенəлəр. (Туйга гадəттə телдəн генə əйтеп чакыралар. Хат белəн чакырулар укымышлы гаилəлəр һəм өйлəнешүчелəр икесе бер үк авылда тормаучылар арасында була.)

Менə инде никах ашына бер көн кала кыз ягына туй килə. Туй көткəн йортның капка төбенə кунак каршыларга халык җыела. Артлы чанага җигелгəн беренче атта баш кода белəн кодагый, икенче, өченче атларда баш коданың якыннары — «канат» кодалар килə. Кызның əтисе йортына килеп җитеп, беренче, икенче, өченче атлардагылар туй каршылаучыларга кулъяулыкларга төйнəлгəн чəкчəк яки вак акча (бик сирəк) чөялəр. Иң арттан килүче күчтəнəч чанасындагы малай бүлəк ыргытмый, ул, күчтəнəчлəр салган сандык өстенə утырган килеш, атын куа-куа, тегелəрдəн калышмыйча ишегалдына уза.

Йортта мəш килəлəр — туй килде бит, туй!

Икенче көнне иртүк аш өлгерə. Чакырылган ирлəр никах ашына җыела. Ким дигəндə егерме-утыз кеше ике-өч табынга бүленеп, ап-ак киезлəр, кулдан тукылган келəмнəр җəелгəн, кырыйларына тар корама юрганнар сузылган сəкегə, идəнгə түгəрəклəнеп утыралар. Мулла никах укый. Никах укудан, алдым-бирдемнəн элек, кызның ризалыгын сорарга дигəн булып, мəҗлестəн ике кешене тышка чыгаралар. Чыгалар да болар бик тиз əйлəнеп тə керəлəр. Һəм ишектəн керə-керүгə үк: «Кыз риза-риза!» — дилəр бу кешекəйлəр. Ә чынлыкта исə ризалык сорарга дип чыгарылган əлеге шаһитлар аклашылган (ярəшелгəн) кызны күрмилəр дə, аның янына бармыйлар да. Бу алдашу гадəткə бик нык кереп киткəнлектəн, алай-болай сүз кузгатучылар, төпченүчелəр булмый.

Мəҗлестə никах укылганнан соң, табынга аш китергəнгə кадəр, бирнə бүлəклəре өлəшəлəр. Иң элек баш кодага бирнəгə күлмəклек, аннан «канат» булып килгəн кодаларга күлмəклек, сөлге, намазлык кебек нəрсəлəр бирəлəр. Егет əтисе һəм канат кодалар бүлəклəрне җанлы мал əйтеп алалар. Ягъни: «Киленгə бездəн бер сарык». «Киленгə бездəн бер каз». «Киленгə бездəн бер башмак», дилəр. Соңыннан биреләме юкмы: «Киленгə бездəн бер сыер», диеп ычкындыручылар да булгалый. Ераграк кардəшлəр (егет ягы кешелəре) бирнəлəрне котлап акча салып алалар. Беррəттəн кыз хəзерлəгəн сандык əйбəрлəрен, кияүгə дигəн бүлəклəрне дə табын халкы алдына күрсəтергə чыгаралар. Кияү өчен бүлəклəр: кулдан сугылган, чачаклы итəкле, изүе чуклы бəйлəвечле, киҗеле күлмəк, сөрмəле (буй-буй сызыклы) ыштан, сарык җоныннан бəйлəгəн озын чачаклы, озын ак шарф, оекбашлар, чолгаулар, кулъяулыклар.

Бирнəлəр тапшырылып, маллар əйтелеп, бүлəклəр күрсəтелеп беткəч, табынга аш китерəлəр. Иң элек агач табаклар белəн нечкə токмачлы аш бирелə. Савыт-саба

җитмәгәндә, бар табын халкы бер үк табактан ашый. Аштан соң һәр табынның икс-өч җирендә туралган ит куялар. Шунда ук кодаларның күчтәнәч казларын табынга бирәләр. Күчтәнәчләрнең кемнәрнеке икәнен әйтеп, һәр казның яртысын турыйлар һәм кунаклар итне авыз итәләр. (Гадәттә кодалар пар каз алып киләләр.) Аннан катык, корт, сөзмә, кызыл эремчек, кыр чиясе суы (компот), тура[1] кебек ашамлыкларның берничәсен китерәләр. Әни кеше бармак та яламыйча, гаиләдә көндәлек ашау-эчүне кысып килеп хәстәрләгән сары май була мондый зур аш мәҗлесләрендә. Табын кырыена самавырлар килеп утыра. Ләкин, чәй ясаганчы әле кодалар алып килгән иң кадерле туй күчтәнәче — җәлпәк савытка баллап катырылган чәкчәк бирелә табынга. Чәкчәкнең беразын матурлап кискәләп, бик тә тыйнаклык белән, кунаклар авыз итәләр. Һәм әлеге күчтәнәчне котлап савытларга акча салалар. Күчтәнәч күмәчләр куялар табынга. Күмәчләрне башта бөтен кое күрсәтәләр, аннан телемләп кисеп, кунаклар алдына тараталар. Бу күчтәнәчләрнең барысын да баш кода һәм канат кодалар бергә әзерләп алып киләләр. Чәкчәкне: «Туй чәкчәкләре бик шәп!» — дип мактарлык итәргә тырышалар. Чәй эчү башлана. Чәй янына мөмкин булганча әзерләнгән барлык сыйларны да куялар. Мәһәр балын һәр кунак авыз итәргә тиеш. Шунлыктан бу ризык, әзләп-әзләп кенә булса да, табынның берничә төшенә куела. «Йөз иту» өчен куелган бу ризыкны, «бал дисәң, бер кими, бармак тидерсәң, ике кими», дип кенә кабып чәй эчәләр. Хуҗа һәм аның якыннары табын халкын аягүрә басып сыйлыйлар, кыстыйлар. Алар һәммәсе дә бийләренә матур билбаулар, яки сөлгеләр бәйлиләр. Бу — туй сыйлауның бер шарты санала. Ягъни биләр буып кодалар сыйлау, туй кунакларын сыйлау була.

Мәҗлес тәмам. Ирләр тарала. Тик ике якның да иң якын кардәш кешеләре ашка икенче катка кала. Аларны тагын бер мәртәбә сыйлап озаталар.

Инде ашка чакырылган хатын-кызлар җыела.

Кунаклар җыелып бетеп мәҗлес башлануга, аклашылган кызны, киендерепясандырып, җиңгәчәйләр, апалар озатуында табын кунаклары катына кертәләр. Кыз, аларына чуплэмле, озын сарфиткәләр ябып, түгәрәкләнеп утырган барлык табын кунаклары белән ике куллап күрешеп чыга. Алдан бианасы (каенана) һәм киявенең башка якыннары белән күрешә[2]. Күрешкәндә бианасына, кодачаларга бүләкләр бирә бара. Бүләкләр: баш яулыгы, күкрәкчә, бияләйләр, кулъяулыклар. Болар «кыз күренеше» бүләкләре дип атала. Күрешүдән соң сандык әйберләре, кияүгә дигән бүләкләр күрсәтелә. Һәм бирнә бирү китә. Бирнәне кызның әтисе тарата. Гадәттә егет әнисенә — баш кодагыйга иң зур бирнә-күлмәклек, кодачаларга сөлге, баш яулыгы, намазлык, бияләйләр бирәләр. Бирнәләрне, катлап, егет әнисе һәм канат булып килгән кодачалар ирләре әйткән малларны кабат әйтеп алалар. Җанлы мал әйтмәгәннәр бүләкләрне акча салып алалар.

Хатын-кыз кунакларны сыйлау-хөрмәтләү тәртибе нәкъ ир-атларны сыйлагандагы күк бара. Күчтәнәчләрне табынга бирүләр, һәр күчтәнәчтән авыз иттерүләр, чәкчәкне котлаулар — барысы да ирләр аш мәҗлесендәге күк була. Хатын-кыз кунакларның да байтагы — ике якның туган-тумачасы ашка икенче катка кала, табын яңартыла.

## Куна алу

Кодалар, туй кунаклары туйда дүрт-биш көн торалар. Алар һәр көнне ашка йөриләр. Кызның кардәшләре исә кодаларны куна алып сыйлыйлар. Ашка чакырып кына калмыйлар, ә үзләрендә бер кич кундырып, мунчалар кертеп, сый-хөрмәт итәләр. Шуны куна алу диләр.

## Савым ашы

Туй китмәс борын бер кичне кыз ягында савым ашы уздыралар. Ашка кунакларны ирле-хатынлы парлап чакыралар. Ләкин, парлашып килсәләр дә, ир-атлар бер өйгә, хатын-кызлар икенче өйгә җыелалар. Савым ашына һәр пар күчтәнәч белән килә. Күчтәнәчләре: бөртекле чәй, кыр җиләк-җимешләре. Бүтән төрле күчтәнәч һич тә алып килмиләр. Йоласы шундый. Башка кунак ашларына караган-

[1]Тура — җир җиләген изеп әзерләнгән ашамлык.
[2]Кыз туй килгән көнне бианасы һәм кодачалар белән беренче чәй табынында ук күрешергә «күренеш» бүләкләре бирергә мөмкин. Алай иткәндә ул — никах ашына җыелган хатын-кызлар катына күрешергә керми.

да савым ашында кунаклар күбрәк була. Һәм аларның күпчелеге — яшь парлар. Сыйлау-сыйлану тәртибе дә монда бүтәнчәрәк.

Табындагы кунакларга башта ук чәй ясап бирәләр. Һәм менә савым чәе эчү башлана. Бер-ике самавыр табын янында гөжләп торса, аларга алмашка бер-икесе өйалдында кайнап утыра. Табында бүтән сыйларга караганда иң күп сый — кыпкызыл итеп пешерелгән чәй һәм кыр җиләк-җимешләре. Ашка килүчеләр дә күчтәнәчләрен табыннарга куялар.

Биредә мәҗлеснең башыннан ахырына кадәр һәр ике өйдә дә үен-көлке, мәзәкләр сөйләү, җор сүзләр әйтешү артканнан-арта бара. Менә инде чәйне, кымызны җырлап-җырлап бирәләр кунакларга. Җырлап чәй эчү китә. Берәү җырлап бетерүгә икенчесе башлый, парлашып та җырлап куялар. Күмәкләшеп (хор белән) өй тутырып җырлаулар юк. Күбрәк авылда танылган җырчылар җырлый. Һәр ике өйдә дә бик күп җырлар җырлана. Анда туйга бәйләнешлеләре дә бар.

Кода-кодагый, кодачаларга җырлау.

*Атлар килә, әй лә, олы җырлау.*
*Җиде микән, әллә сигезме?*
*Ни хөрмәтләр итим, әй кодалар,*
*Җаннарымдай күрәм мин сезне.*

*Сезнең өчен лә шул ак өемнең*
*Ишекләрен лә киң ачам.*
*Кодачалар безнең асыл заттан,*
*Кодачалар безнең оялчан.*

Мәҗлестә туйга бәйләнешсез җырлар да күп җырлана:

*Арыслан да киек әй иркендә,*
*Җөрер яланнары киң була,*
*Кешеләргә кеше әй тиң була,*
*Маллар тапмый гына ким була.*
*Җил юкта да җилбердидер*
*Безнең бакча таллары,*
*Бетә дә ул, табыла да ул*
*Фани дөнья маллары.*

Кода-кодагыйлар кара-каршы җырлаша:

*— Җир җиләге җимеш җирдә чук,*
*Сездәй күркәм затлар илдә юк,*
*Әй кода-кодагыйлар.*
*Атлар җиксәгез, пардан җигегез,*
*Чакырганны көтми килегез,*
*Әй кода-кодагыйлар.*
*— Күгәрченнәр гөрли гел бергә,*
*Гел гөрләшик бергә гомергә,*
*Әй кода-кодагыйлар.*
*— Җан эреде тәтлы сүзегезгә,*
*Рәхмәт сый-хөрмәтегезгә,*
*Әй кода-кодагыйлар.*

Мәҗлес дәвамында яшь ир-атлар бу өйдән теге хатын-кызлар җыелган өйгә үз парлары катына керeп-чыгып йөриләр. Савым ашында бу гаеп ителми. Бергәләп күңел ачулар — җырлау, кубызга, курайга, такмакка биюләр ярыйсы ук озакка сузыла. Уен-көлке өзелеп тормый.

*Ай гәдер гәдәни,*
*Вай гәдер гәдәни,*
*Гәдер-гәдер, гәдер-гәдер,*
*Гәдер-гәдер, гәдәни.*
*Арыш кетеркәсеме,*
*Бодай кетеркәсеме,*
*Кетер-кетер, кетер-кетер,*
*Кетер кетеркәсеме.*
*Ипи басасым да бар,*
*Казан асасым да бар,*
*Бөеркәемә таянып*
*Биеп аласым да бар...*

*Кара тавык чирләгән.*
*Кара тавык каз булмас,*
*Утын бетсә, яз булмас.*
*Бас-бас, шома бас,*
*Шома басарга кирәк,*
*Мәдинәкәй туенда*
*Күңел ачырга кирәк.*

*Әттә-тәтә, әттә-тә,*
*Сикәлтә дә микәлтә,*
*Җыры беткәч, ак тути*
*Такмак әйтә дә әйтә.*

Дус-ишләргә җырлаулар:

*Сакмар сулары гына ярында*
*Сандугачлар сайрый талында.*
*Авыр юллар җиңел була икән*
*Ир-егетләр булса янында...*

Кунакларның хуҗаларга, хуҗаларның кунакларга җырлавы:

*— Айдай якты йөзегез лә,*
*Ай, тәмле кымызыгыз,*
*Рәхмәт хөрмәтегезгә лә,*
*Гел бәхетле булыгыз.*
*— Җәйдем киндер басасын,*
*Безнең хәтер калса калсын,*
*Сезнең хәтер калмасын.*

Кыз бала турында җыр:

*Бик вак кына яфрак кына*
*Бакчада куак кына,*
*Кыз балага суз әйтмәгез,*
*Ул сезгә кунак кына.*
*Болыннар да гына ал чәчкә,*
*Кыз балакай матур бер чәчкә,*
*Шиңмәсен лә ие ул чәчкә*
*Эткәй йортларыннан киткәч тә.*

Кыз анасы, кызның олы туганнары җыры:

*Сайрый былбыл, сайрый ла былбыл,*
*Моңлана былбылкаем,*
*Сайрый ул, өзелеп лә сайрый —*
*Очырткан балакаен.*

*Яратамын йолдызларны,*
*Яратам моңсу айны,*
*Моңаермын инде мин дә*
*Сагынып балакайны.*

Савым чәе эчү мәҗлес ахырына кадәр бара. Уен-көлке, җырлау, такмак әйтүләр һаман дәвам итә:

*Урманнар да гына урманнар,*
*Урманнарда гына бураннар.*
*Утка-суга төшәрдәй чакларда*
*Йолып кала дуслар, туганнар...*

Идән тутырып күмәкләшеп биюләр әле гадәткә кермәгән, әмма такмак әйтеп, ялгыз биюләр бик җанлы бара:

*Төшәсең дә биергә,*
*Таянасың бөергә,*
*Туйда, туйда биергә*
*Бик килешә биемгә*[1].
*Җиңгәчәем, җиңгәчәй,*
*Синнән шикәр, миннән чәй,*
*Җиңгел булыр чәй эчкәч,*
*Биеп китәр каенигәч.*

*Анда читән алачык,*
*Монда читән келәттер,*
*Туйга килгәч парлашып,*
*Биергә дә кирәктер.*
*Канат кода килгәндер,*
*Кырпу бүрек кигәндер.*
*Сөйкемле сөяк кенә,*
*Өздерә биеп кенә.*

Төн урталары җитә (савым ашы көндез уздырылмый), мәҗлес һаман дәвам итә. Табыннарга туй күчтәнәчләре — чәкчәк, күмәчләр куела. Кунаклар баллап катырылган туй чәкчәген мактыйлар, авыз итәләр. Һәм аны котлап савытларга акча (вак акчалар) салалар. Күчтәнәч күмәчләрне, кемнәрнеке икәнен әйтеп, мактыйлар, авыз итәләр.

Инде кунаклар кайтырга сорый башлагач, табыннарга токмачлы аш, аш артыннан туралган ит, ит артыннан бар кадәренчә башка төрле ашамлыклар — катык, корт, чия суы китерәләр.

[1]Бием — каенана.

Уен-көлке өзелми инде ул, әмма ишегалларына, урамнарга чыгып бию, җырлаулар, шаулашулар юк. Күңел ачу, сыйланулар өй эчендә генә була.

Менә шушы күңелле итеп кыз ягында уздырыла торган бер аш-су мәҗлесен савым ашы диләр.

## Кияү килү, кияү ашы китерү

Кызларны күреп өйләнүләр юк диярлек. Болай үзе, яучылый башлагач, кыю, өлгер егетләр булачак кәләшләрен күрү җаен табалар. Күпчелек исә никах укылып, баштагы туй аш мәҗлесләре үткәч кенә очраша.

Менә кодалар туйдан кайтып китә. Инде кичкә кияү килә. Аны кызның энесе яки берәр кардәш малай ат белән алып килә. Малайга, ягъни каенешенә җизни кеше пәке бүләк итә. Кунакны егет-җилән, яшь ир-атлар каршылый. Кияү өйгә кергәндә әчке яклап ишекнең ике ягында ике бала тора. Болар — ишек бавы тотучылар. Ишек бавы тотучыларның берсе — кыюрагы такмаклый:

*Кер, җизнәкәй, тыш салкын,*
*«Ишек бавы» бер алтын,*
*Безнең апа мең алтын!*

Такмак бетәр-бетмәстән, яшь кияү балаларга вак акчалар биреп түргә уза. Аны каршылаучылар чыгып китә. Инде егет янына кызны кертәләр, озатучы җиңгәчәй, апалар алгы якта калалар. Кыз кул биреп кияве белән күрешә. Аннары алар икесе ике төштә намаз укып алалар. Аннан соң алдан әзерләнеп куелган табында икәүдән-икәү генә аш ашыйлар, сыйланалар. Иртәнгә чаклы монда кереп-чыгып йөрүчеләр булмый. Өй эче алдан ук җыештырылган, бизәлгән, чыбылдык-чаршаулар корылган, урын-җир җәелгән.

Тәрәзәләрнең эчтән пәрдәләре төшерелгән, тыштан капкачлары ябылган. Вакыт соң. Бу — кыз белән кияү күрешү йоласы инде.

Икенче көнне, яшь өйләнешүчеләр иртәнге мунчадан кайтып чәй эчүгә иртүк кияү ашы китерә башлыйлар. Һәр ике якның якыннары, туган-тумача, күршетирәләр, көмәйләр, дус кызлар өч-дүрт көн буе кияү ашы: төче коймак белән тәбә, төче коймак белән каз ите, коймак янына аз-азлап кына куелган чәкчәк яки берәр төрле җиләк-җимеш ташыйлар. Коймаксыз кияү ашы булмый. Теләлеп торган күршеләр, кызның көмәе, ахирәте әлеге тәмле-тәмле ризыклар белән бергә самавыр кайнатып та кертәләр. Андыйлар хакында: «Кияү ашын бик зурлап, самавырлар куеп керткән», дип сөйлиләр. Аш китерүчеләр ашамлыкларны табынга куялар. Яшь пар һәр ризыктан авыз итәргә тиеш. Шунда ук кияү ашы китерүчене чәй белән дә сыйлыйлар. Һәм кияү-килен бүләге бирәләр. Кыз ягыннан аш китерүчеләргә кияү алып килгән бүләкләр — исле сабын, хушбуй, иннек-кершән, көзге кебек нәрсәләрнең бер-икесен һәм бераз акча бирәләр. Кияү ягыннан аш китерүчеләргә чиккән алъяпкыч, биләй, кулъяулыгы, күкрәкчә кебек нәрсәләрнең бер-икесе һәм акча бирелә. Акча дигән нәрсәне инде, елына, кесәсенә карап, ике якка да кияү сала, күп чакта салынмый да кала. Бу гаеп ителми. Аш китерүчеләр күпкә киткән хәлләрдә кияүнең алып килгән әйберләре бетеп тә куйгалый, җитми кала. Анда инде өйдән тагын алып килергә туры килә. Чөнки бүләкләр кияү ашы китерүчеләргә генә түгел, якын җиңгәчәйләргә, каенигәчләргә, балдызларга да өләшенә. Беренче кич кияү түшәге җәюче җиңгәчәйгә, беренче иртәдә кияү мунчасы ягучыга шул ук әйберләрдән өлеш чыгарыла. Болай байлыктан, мал артып ятканлыктан түгел, билгеле. Йола булгач йола инде, мөмкин кадәр үтәргә кирәк.

Кәләшкә беренче килүендә дүрт кич куна кияү. Шул өч-дүрт көн эчендә бер аш мәҗлесендә ул — кызның әти-әнисе белән күрешә. Бабасына, әбисенә (кәләшенең әти-әнисен бабай, әби дип атый) шунда кияү күренеше бүләкләрен бирә. Бүләкләр — баш яулыгы, түбәтәй. Кыз белән кияү арасында да истәлек бүләкләре (йөзек, беләзек, кулбау, кулъяулык, түбәтәй кебек нәрсәләр) бирешү-алышу гадәте бар.

Бу — кияүнең кәләшкә беренче мәртәбә килүе бит әле. Моннан соң һәр атнаның пәнҗешәмбе көнендә чакырылып, икешәр кич кунып китә. Тора-бара атнага бер генә кич кунып китә башлый. Шул рәвешчә бабасы йортына килеп-китеп (кәләшкә йөрү) җәйгә кадәр, килен төшергәнче кунак булып йөри. Ә бит кыз бирү, ул өйләндерүләр, өйләнешү туйлары, гадәт буенча, көзнең соңгы аенда, кышка

кергәндә башлана. Яңа өйләнешүче яшьләрне сыйлау-хөрмәтләү, димәк, бары белән билгеле, шулай бик озак дәвам итә.

Өйләнешү туйларында төрле аш мәҗлесләре бик күп үткәрелә. Әмма бу аш тотулар азык-төлек ташып ятканлыктан түгел, билгеле. Аш тотучы хуҗа да, ашка килгән кунаклар да икмәкнең һәм бүтән ризыкларның кысынкы булуын, ничек хәстәрләнүен, кадерен яхшы беләләр. Бал, май, кымыз кебек ризыклар бик чамалы була табыннарда.

## Чәкчәк ашы

Кияү кәләшкә бер килеп киткәннән соң, кыз ягы чәкчәк ашы үткәрә. Бу ашка күрше-күлән, ике якның кардәш-ыру егетләре, малайлары чакырыла. Кунаклар җыелып беткәч, табынга токмачлы аш, аннан соң туралган ит бирәләр. Яшь кунаклар аш, ит ашыйлар, катык, сөзмә, эремчектән авыз итәләр. Чәй эчү алдыннан баллап катырылмаган чәкчәк яки коштеле китерәләр табынга. Яшь ягыннан кечерәк малайлар шаярта-шаярта чәкчәк ашыйлар. Чәкчәк бик мул була. Алай да савытта калдырыштан түгел, ашап бетерешле. Ә ашап бетергәнче, кыз чәкчәген котлап, табыннарга акча чәчәләр. Ягъни һәр яшь кунак ашъяулыкка тиеннәр ташлый. Бу акчалар ярәшелгән кызга була.

## Кичектерелгән туй

Никах ашы узгач, йола буенча, егет әти-әнисе кыз ягында туйда булып киткәннән соң, кызның әти-әнисе кияү ягына каршы туйга барырга тиеш. Ләкин, туй чыгымнарын әлегә күтәрә алмаганлыктан, бу бару күбесенчә кичектерелә. Каршы туйга кыз озатканнан соң бер-ике ел үткәч барсаң да ярый. Гаеп ителми.

## Кырга чыгу

Җәйнең бер матур көнендә кияү кәләшен алып китәргә килә. Бу көннәрдә яңа өйләнешүчеләрне аеруча хөрмәт итәләр. Кыз ягы кешеләре аларны ашка чакыралар, сый-хөрмәт күрсәтәләр. Ике-өч көн шулай үтә. Менә инде кыз иртәгә китәчәк. Нәкъ шушы көнне — һич тә элекке көннәрдә түгел — матур итеп жигелгән пар атта кияү белән кәләш һәм аларның иң якын иптәшләре ун-унбер кеше бергәләп кырга чыгалар. Тыелмаган җиргә, табигатьнең бер матур урынына барып туктыйлар. Чәчәкләр җыялар, ямь-яшел, хуш исле үсемлекләр белән арбаны бизиләр. Гармунда уйнау, уен-көлке, шаяру-шукланулар белән ял итәләр. Җиңелчә генә ашап алулар, кымыз эчүләр булгалый.

Кәләш белән кияүгә бер яки ике кеше җырлый:

*Ак дулкыннар уйный ди диңгездә,*
*Ак бәхетләр телим мин сезгә.*
*Пар аккошлар йөзә лә суларда,*
*Охшатамын сезне шуларга.*
*Ак дулкыннар уйный ди диңгездә,*
*Саф мәхәббәт телим мин сезгә.*
*Пар аккошлар кебек лә икегез,*
*Сүрелмәсен мәхәббәтегез.*

Җырга җыр ялганып кына тора:

*Өстеңдәге лә зәңгәр күлмәгең*
*Кояшларда гына уңмасын,*
*Кавышырга сезгә насыйп булды,*
*Аерым тору насыйп булмасын.*
*Кавыштыгыз изге лә сәгатьтә,*
*Күзегез лә күзләрдән китмәс,*

*Сез гүзәлкәйләрнең арасыннан*
*Дошман түгел, җилләр дә үтмәс.*

Ялгыз һәм ара-тирә кара-каршы биешкәндә болай такмак әйтеп торалар:

*Бас-бас чирәмгә*
*Бие-бие дигәндә.*
*Кече кода чибәр лә,*
*Кайсы кызны димләргә?!.*

Инде бу урыннан кузгалып, җырлаша-гөрләшә ат белән ялан юллары буйлап байтак җирләрне урый алар. Шулай итеп китәсе кызны туып-үскән, җиләк җыйган, печән җыйган кырлары, болыннары белән саубуллаштыралар. Бу — башка авылга килен булып төшәчәк кыз өчен саубуллашу исәпләнә. Ләкин, өйләнешүчеләр шушы бер үк авылныкы булсалар да, барыбер, кырга чыкмыйча калмыйлар. Гореф шундый.

Атта йөргәндә җырлаулар:

*Әрәмәләрдә йөрдем мин,*
*Борлегәннәр өзмәдем.*
*Бездән аерылгачтын да*
*Бик боекма, гүзәлем.*
*Сүзең йомшак, йөзең кояш,*
*Кашың туган ай гына,*
*Әллә энҗе сибелгәнме*
*Керфек араларына...*

## Килен төшерү

Килен төшерүләр җәйнең иң матур чагында, утау бетеп, печәнгә төшәр алдыннан бер-ике көн эчендә булып ала. Улларын өйләндергән ата-аналар үзара сүз куешып, килен төшерүне бер үк көнгә туры китерергә тырышалар. Шулай иткәндә күңелле дә, бергәләп кунак сыйлавы да җиңелгә килә дип исәплиләр.

Киленне, ким дигәндә, өч-дүрт җигүле ат белән төшерәләр. Һәр ат, һәр арба бизәлә: йөгәннәргә аллы-гөлле кулъяулыклар тагыла, дугаларга сөлгеләр урыйлар, арба артларына кулдан эшләнгән келәмнәр салындырып салалар. Иң алдан кыңгыраулы пар атта килен белән кияү һәм ат тотучы кияү егете, икенче, өченче атларда кыз озатучы кунаклар килә. Дүртенче булып килүче атта бүрек кадәр генә, ут борчасыдай ат тотучы малай. Әлеге ат арбасында кыз әйберләре тутырылган мәһәр сандык, мендәр-ястык, киез-юрган, көянтә-чиләкләр. Арба артына куелган тагын бер кечкенә сандык яки әрҗә. Монысында кыз озатучыларның күчтәнәчләре.

Биредә иң кызыгы шунда: капкадан кергәндә әйбәтләп төрелгән килен бүләге сөлгене, кияү үзләрен каршыларга җыелган кешеләр өстенә һавалатып җибәрә. Халык шау-гөр килә, бүләкне эләктерергә тырышалар. Шул арада пар ат ишек алдына үтеп, ишек төбенә килеп туктый һәм килен бусага алдына салынган мендәргә тимер хуттан бик җитез генә сикереп төшә. Аны шунда ук хатын-кызлар чолгап өйгә алып кереп китәләр. Яшь килен, гореф буенча, актан киенә, башындагы калфагы яки кама читле бүреге өстеннән челтәр шәл бөркәнгән яисә (бик сирәк очрый) баштанаяк ак челтәр ябынган була. Битен күрсәтми, тик аның сулкылдап елавын барыбер сизәләр. Еламаган киленнәр бик сирәк. Андыйларны: «Җыламый да бит печәт[1]!» — дип гаеп итүчеләр дә табыла, хәтта. Кияү дә мөмкин кадәр, гореф буенча, киенергә тырыша, әлбәттә: итәк очы чачаклы, изү бәйләвече чуклы киҗеле күлмәк (кәләш бүләге), күлмәк өстеннән камзул яки җилбәгәй җибәреп кыска җилән кияр.

Кыз озата килүче кунаклар да капка төбендәге халыкка, килеп каршылаучыларга, кулъяулыклар, ап-ак тастымалларга, кулъяулыгына төйнәлгән чәкчәк, уенчык туптай итеп төрелгән бияләйләр чөеп ишегалдына узалар. Дүртенче аттагы малай гына бүләк-фәлән ыргытмый-нитми ишегалдына керә.

Килен төшкән бу өйнең ишегалдында да халык тулы. Билләренә билбау, сөлгеләр бугән эшлекле кыяфәттәге агайлар дисеңме, җиңнәрен сызганган җиң-

[1]Печәт — чекерәеп тора, тартынмый.

гәчәйләр дисеңме, бала-чага, әби-бабайлар дисеңме — барысы да бар. Шау-гөр киләләр, килен бүләкләрен, кыз озата килүчеләр ыргыткан бүләкләрне һәм аларны алучы җитезләрне мактыйлар. Бит, килен төшкәндә бүләк алу сабан туйларында көрәшеп бүләк алу шикелләрәк санала. Сөлге эләктерүче кеше өлгер, җитез дип исәпләнә, авылга шәплеге ишетелә. Аннан соң, билгеле инде, заманына күрә шул кечкенә әйберләрнең дә бәһасы бар.

Кунаклар өйгә кереп беткәч, хатын-кызлар чаршау эчендә яшь киленне чәй белән сыйлыйлар. Чәйдән соң кыз озата килгән җиңгәчәйләр, апалар киленнең сандык әйберләрен биатай (каенатай) өе эченә элеп чыгалар. Киленгә каенсеңел тиешлеләргә чиккән алъяпкыч, күкрәкчә кебек нәрсәләр, җанагай (каенә) тиешләргә кулъяулыгы, перчатка кебек нәрсәләр бирәләр. Болар — яшь җиңгәчәй бүләкләре.

Кыз озата килүче кунаклар биредә ике-өч көн тора. Хуҗа килен төшү хөрмәтенә аш мәҗлесе үткәрә. Ашка йөрү, күңел ачулар була.

## Су юлы күрсәтү

Киенгән-ясанган, көянтә-чиләкле бер төркем кыз-кыркын, шаян, күңелле сүзләр сөйли-сөйли, киленне, төшеп чәй эчү белән, су юлы күрсәтергә чишмәгә алып баралар. Бу — килен башка авылдан яки шушы авылдан төшкән булса да, барыбер шулай ителә. Берсен дә су юлы күрсәтмичә калдырмыйлар. Гореф шулай. Кызлар су ала. Яшь килен бу юлы көянтә-чиләк күтәрми, су алып кайтмый. Ул әле — кунак.

## Килен ашы

Килен төшкәч, атна-ун көн үтүгә, шушы йортка егетнең туган-тумачасы яшь килен исеменә аш китерә. Моны килен ашы диләр. Килен ашы — өреп кенә пешерелгән майлы коймак, көлчә яки итле аш. Аш китерүче исә бик тиз, кайвакыт чәйләп тә тормыйча кайтып китә. Бүләк бирешү-алышулар булмый.

## Әлүү элеп керү

Яшь килен киявенең иң якын кардәшләре өенә беренче кат кергәндә буш кул белән түгел, ә бүләк итеп чөйгә сөлге элеп керә.

## Бәбәй ашы

Ана бәбәйдән котылгач, аның һәм яңа туган сабый исәнлегенә атап күршекүлән, туган-тумача, дус-ишләр аш китерәләр. Бәбәй ашы: көлчә, коймак. Аш китерүчеләр, әлбәттә, сабыйга исәнлек-саулык, бәхет тели, кулга алып иркенләп сөя, чын күңелдән котлый. Гадәттә монда озак тормый, кайтып китә.

## Бәбәй туе (исем туе)

Бала тууына атна-ун көн тулганда исем кушалар. Исем кушкандагы аш мәҗлесенә бәбәй туе, исем туе диләр. Ата-аналар баланы исемле итәргә ашыгалар. Баланы тизрәк атлы итү аны зурлау санала. Аннан соң кайберәүләр «Сабый атсыз озак торса, аны пәри алмаштыру ихтимал», — дип ышана.

Бәбәй туе зур аш мәҗлесе исәпләнә. Ата-ана сыйны, үз авызыннан өзеп булса да, мөмкин кадәр яхшы әзерләргә тырыша.

Мәҗлескә башта ирләр керә. Шунда балага исемне гадәттә мулла куша. Исем кушылгач, аш-судан элек табын халкы сабый яткан мендәргә (сабый өстенә) акча сала: баланы котлый. Аш-судан соң мәҗлес тәмамлана.

Инде хатын-кызлар җыела. Мәҗлес бик күңелле башлана: килгән бер кунак ачык йөз белән сабыйны кулына алып сөймичә калмый, һәрберсе сабыйга җылы сүз әйтергә тырыша, аны мактый, аңа озын гомер, бәхет тели. Шунда ук шаулап-гөрләп дөньяга яңа килүчене бүләкләү китә: өстенә исле май сибәләр, исле сабын, кулдан тегелгән күлмәк, кечкенә калфак, башлык, түбәтәй, ак биләү кебек әйберләр бирәләр. Шулай итеп, баланы котлау ирләр мәҗлесенә караганда күпкә күңелле, шау-шулы булып үтә. Тагын шунысы да бар: табынга аш китергәнче әни кеше бәбәй туе хөрмәтенә кендек әбисенә, олы яшьтәге берничә кешегә бүләкләр бирә. Табыннарга токмачлы аш, ит, катык, сөттән ясаган бүтән ризыклар бирәләр. Соңыннан чәй эчү. Чәй янында таба ашлары һәм кыр җиләк-җимешләре мул була.

## Каз өмәсе

Ап-ак карлар төшкәч, каз өмәләре башлана.

Каз тәбикмәге[1] белән иртәнге чәйне эчкәннән соң, өмәче кызлар сәке йөзлеге буена, эскәмияләргә тезелешеп утырып, каз йолкалар. Эш әйтелмәгән, килешенмәгән ярыш белән эшләнә. Кемнең ничек каз йолкуы, ничек тазартуы күз йомып торсаң да күренә монда. Шуңа күрә һәркем сынатмаска тырыша: тазарткан казлары күп тә булсын, ак шалкан кук тә булсын. Шырпылы итсәң, сине җыбыткы диюләре бар. Җитмәсә, эшнең иң кызган чагында, иртә дә түгел, соң да түгел, эш уртасында яшеренеп кенә егетләр килеп керә. Ләкин бу комачауламый, киресенчә, эшне кыздыра гына, күңеллелекне арттыра гына. Хуҗа көйле кеше икән, җырлаулар, биюләр дә булгалый. Кызлар басынкы тавыш белән берәм-берәм дә, парлашып та җырлап алалар. Бөтен өйне яңгыратып кумәкләшеп җырлаулар юк. Егетләр гармун алып керә алсалар (гармунны чабу астына яшереп кенә алып керәләр), биешүләр дә була. Шулай да монда көннең күп өлешен эш ала. Җыр, биюләр эш арасында, ара-тирә генә. Аның каравы, кызык, җор сүзләр әйтешү, шаяру, көлешүләр бетеп-нитеп тормый. Хуҗа көйле булса, кызларга егетләр белән сөйләшү, серләшү җае да табыла.

Кич. Инеш сукмагында егетләр чуала. Кызлар каз юарга төшә. Алар артыннан бер бала яки бер өмәче кыз өйдән инешкә кадәр сукмакка каз каурыйлары, каз йоннары чәчеп бара. Бу юрау, теләкләр шуны аңлата: киләсе елга казлар бәпкәне күп итеп чыгарып үстерсеннәр, каз котүенең бер очы капка төбендә, икенче очы инештә булсын. Сукмакның буеннан буена шушы каурыйлар, йоннар кебек тезелешсеннәр, янәсе. Казларны чалганда да күңелле ыгы-зыгы килеп шаяралар, юрыйлар: өмәче кызлар яңа суелган казларның муеннарын калкыта төшеп, чалу каның ераккарак сиптерергә тырышалар. Кан никадәр ераккарак сибелсә, киләсе елга казлар шул кадәр күп була, имеш.

Түшкәләрне юып кайтуга аш әзер, өмәчеләрне каз ите белән сыйлыйлар. Кайтып киткәндә һәр өмәчегә каз башы, бүтәкә, канат кебекләрне биреп җибәрәләр. Болары — өйдәгеләргә күчтәнәч.

## Кич утыру

Төннәр озайгач, кызлар, яшь киленнәр бер-берсенә кич утырырга йөрешәләр. Кич утырырга кул эше — бәйләү, чигү, эрләү белән киләләр. Һәм искиткеч күңелле итеп, кызыклы хәлләр, мәзәкләр сөйли-сөйли, төннәр буе дип әйтерлек эшләп утыралар. Менә эшләгән эшләрне чагыштырып караулар, мактаулар китә. Менә берәүнең чигүенә сокланалар, менә бер кыз көмәсенең Насыйбуллага дип бәйләгән биш бармаклы бияләен киеп карап Насыйбуллалар турында кызыклы сүзләр әйтә. Күтәрелеп көләләр, шаяралар... Китә Насыйбуллалар турында мәзәкләр сөйләү.

Хәтсез эш эшләгәч, киленнәр, олырак яшьтәге апалар кайтып китә. Кызлар исә күп вакыт кунарга кала. Бу — аулак өй түгел. Олылар, хуҗалар өйдә булырга да мөмкин. Алар күбесенчә түр якта яки икенче өйдә ял итә. Кич утыручыларга комачауламыйлар. Инде Хуҗалар каядыр киткән, йорт башы булып бер әби генә калган өйдә яшьләрнең кич утырулары тагын да кызыклырак, уен-көлкеле, җырлы-

---

[1] Әче камырдан пешерелгән белен.

такмаклы, шау-шулы була. Тәрәзә төбенә шыпырт кына егетләр килә. Алар ничек кенә шыпырт йөрмәсен, эчтәге кызлар бик тиз сизеп ала. Менә бер егет тәрәзә капкачын кысып кына ачып өй эчендәгеләрне күзәтә. Аны танып алган кыз тәрәзә аша егеткә көзге күрсәтә. Бу — синең өчен якты йөзем дигәне белдерә. Ә таныш булмаган, әлектән белмәгән-күрмәгән егеткә көзге күрсәтмиләр.

Җан тартмаганнарга да көзге күрсәтелми. Кечкенә көзге кызлар арасында кулдан кулга күчә. Ягъни күз күргән, үз иткән егетләренә бүтән кызлар да тәрәзәдән көзге ялтырата. Һәм өн чыгармыйча гына авыз, ирен, йөз-күз хәрәкәте белән сөйләшәләр. Кич утыручылар янына егетләр керү гадәте юк дип әйтерлек. Бу аулак өй түгел бит әле.

Мондый җыелып күңелле итеп утырулар, эш эшләүләр җырсыз гына үтми, билгеле. Бигрәк тә ялгыз әбидә яки берәр ирсез түтәйдә — ир-атсыз өйдә кич утырганда җырлашалар, эш аралаш такмак әйтәләр:

*Карлыгачкай кара, муены ала,*
*Һаваларга менеп юл ала,*
*Бәхетлекәй бала илдә кала,*
*Бәхетсезе китеп югала.*

*Житен матур үзенең җирендә,*
*Җикән матур ла үз күлендә,*
*Бәхете генә булган балалар*
*Җөри лә шул туган илендә.*

* * *

*Җәй дә яшел, кыш та яшел*
*Арыш басукайлары,*
*Былбыл тал тибрәткән кебек*
*Аяк басукайлары.*

*Елмаюы, күз карашы*
*Иркәлидер йөрәкне,*

*Аны гына сөя җаным,*
*Башка беркем кирәкми.*

*Бәйлим әле ак бияләй,*
*Буләк итсәм, киярсең,*
*Мәхәббәтең саф, нык булса,*
*Сүрелмичә сөярсең.*

* * *

*Аланда гына алсу чәчкә.*
*Чәчеләбез үсеп җиткәч тә.*
*Чәчелмәс тә идек, ай, без бер дә,*
*Шулай язылмаса тәкъдирдә.*
*Биек тауның гына башларында*
*Боланкайлар эзли пакъ җирне,*
*Тәкъдир каләмнәре бездә булса,*
*Без нишләтмәс идек тәкъдирне!*

* * *

*Ай яктысы бигрәк якты*
*Утырып мәрҗән тезәргә,*
*Күркәм сабырлыклар кирәк*
*Сагынганда түзәргә.*
*Ап-ак каен — ялгыз каен*
*Тирбәлә басуларда,*
*Мине тик син төшерәсең*
*Бер утка, бер суларга.*

* * *

*Тәрәзәгә килгәнсең,*
*Бүркең басып кигәнсең.*
*Басып кисәң дә танyйм —*
*Чыгарга хәйлә тапмыйм.*

*Ай ли, дусларым,*
*Апаларым, кызларым,*
*Тәрәзәдән ай карый,*
*Кайтып китсәк тә ярый.*

## Урнаш пешерү

Урнаш пешерү кышкы озын төннәрдә була. Бу эшне башлап йөрүче бер-ике кыз урнашны кайда пешерергә һәм аның өчен үзара салышып нәрсәләр җыярга кирәклеге турында иптәшләре белән сөйләшеп килешә.

Урнашка катнашучылар гадәттә шундый азык-төлек китерә: бераз ит, берәр коштабак он, күкәй, май, сөйләшенгән кадәр акча (күп вакыт акча җыелмый да кала яки бик аз гына җыела). Бу азыклар урнаш пешерү өчен билгеләнгән өйгә иртәдән төшкә чаклы китереп бетерелә. Кичкә табан урнашка катнашучылар үзләре киләләр. Һәм бергәләп пешерү-төшерү, сый әзерләүләр башлана. Аш-су әзерләгәндә үк өй эче шау-гөр килә: кызлар шаяра, көлешә, җырлаша.

Ут алынып бераз үтүгә ашлар әзер була, җыелган акчага алынган шикәр яки кәнфит тә табынга куела.

Монда да тәрәзә төбенә егетләр килмичә калмый. Килгәч-килгәч керергә инде! Керәләр, кызлар белән бергә пилмәнле аш — урнашның беренче сыен ашыйлар. Иң кызыгы да менә шунда, пилмән ашаганда: сынау-юрау пилмәннәре кемнәргә чыгар? Һич яшермичә, сыйланучылар ул пилмәннәрне күрсәтергә тиешләр. Ә табакта андый пилмәннәр байтак: бәхетлегә шау камырдан ясалган пилмән, ак эчлегә — он тутырып ясалганы, укымышлыга кәгазь, умартачыга, бай буласы кешегә агачтай каты, берничә борчак салып ясалган пилмәннәр. Ачы теллегә шау суган, кара эчлегә — шау борыч тутырып ясалган пилмән. Камыр пилмән дә, он пилмән дә, бүтәннәре дә берәм-берәм чыга, аларны күрсәтәләр. Тик суган, борыч пилмәннәр генә беркемгә дә «чыкмый». Беркемнең дә ачы телле, кара эчле буласы килми. Ләкин, кемнең күзе яшьләнә, шуңа «бәйләнәләр»: «Суган пилмән сиңа чыккан, сиңа, күрсәтмичә йоткансың!..» «Борыч пилмән сиңа чыккан, сиңа, күрсәтмичә йоткансың!»...

Урнашта шикәр, кәнфит булганда чәй дә эчкәлиләр.

Аннары берничә уен уйнап алалар. Такмакка яки, егетләр алып керә алса, гармунга биилəр. Җыр, биюләр була булуын. Тик, егетләргә яхшы чакта чыгып таярга кирәк. Алар бит качып-посып, олыларга сиздермичә генә керә.

Егетләр чыгып китә, кызлар кунарга кала. Һәм алып килгән кул эшләренә тотыналар. Уен-көлке дәвам итә. Йокларга яткач, бертын әкият сөйләү, табышмак әйтешүләр булып ала.

## Аулак өйдә

Кышын әти-әниләр башка авылга кунакка киткәндә, йортта күз-колак булып әби-бабайлар, бала-чага гына калганда, яшьләр, форсаттан файдаланып, аулак өй ясыйлар.

Ут алынгач, аулак өйгә килгән кызлар (аларны кунакка киткән кешенең — өй хуҗасының кызы чакыра) барысы да кул эшенә утыра. Эш, эш белән бергә уен-көлке, шаяру-шуклану, җырлашулар башлана. (Бу әле егетләр кергәнче.):

*Пар самавыр — сигез аяк*
*Кайный мичаллардында,*
*Күңел ачыйк әле, дуслар,*
*Бергә килгән чагында...*

* * *

*Агым суда агып килә*
*Яшел тал кәерысы,*
*Карлыгачка мисал килгән*
*Кашыңның аерысы.*
*Кигән күлмәккәең актыр,*
*Каптырма белән каптыр,*
*Ышанмасаң, фаллар ачтыр,*
*Минем сөюем хактыр.*

* * *

*Безнең дуслар ал кисен,*
*Безнең дуслар гөл кисен,*
*Безгә буласы яр түгел,*
*Соклансыгыз, күз тисен.*
*Альяпкычым кыскарак,*

*Кыскарак та кысмарак,*
*Эч серемне ала язды*
*Билләремнән кочкалап.*

Эчтә шулай кызлар җырлаша, шау-гөр килә, тышта тәрәзә төбенә килгән егетләр өйгә керү җаен көтә. Башта аулак өйгә бер-ике егет кенә керә ала. Чөнки, өй сакларга калган әби күрше-күлән, яки кардәш-ыру егетләренә генә керергә рөхсәт итә. Бер-икесе кергәч, ни буласы билгеле инде: тиздән өй эче егетләр, кызлар белән тулып куя. Уйнарга, биергә-җырларга да шул ук өй башы булып калучыдан рөхсәт сорала, рөхсәт алына.

Кул эшләре бер якка ташлана, менә китә уйнау, җырлау, менә китә кубызга яки курайга, гармунга биюләр. Такмак әйтүләр була да була инде.

*И нәвәли, нәвәли,*
*Әнкәсе ипи әвәли,*
*Кызы талкан болгата,*
*Чүлпыларын чыңлата.*
*Гармун ниләр дип әйтә?*
*Өзеп бие, дип әйтә.*
*Гәдер-гәдер, гәдер гет,*
*Өзеп бии бу егет...*

Уеннар күп була бирелә. Яратып, озак ук уйнала торганнары: «Арка чабышлы», «Йөзек алышлы». Әле егетләр килеп җитмәгәндә кызлар «Без-безле», шунда ук «Күркә», «Кадерле кодагый» яки «Кадерле кияү» кебек шаян уеннар да уйныйлар.

Тезелеп утырып кара-каршы җырлаулар.

Е г е т л ә р. *Бездә кызлар, ай, чибәрләр,*
*Алачадан кигәннәр,*
*Уйнамыйлар да көлмиләр,*
*Әллә нигә килгәннәр.*

К ы з л а р. *Тула оегың каралган,*
*Юдыр әнкәңә биреп.*
*Куктән төшеп килмәгәнсез,*
*Тормагыз бездән көлеп.*

Е г е т л ә р. *Бездә кызлар шул чаклы шул,*
*Акыллары тау чаклы,*
*Кич утырып сагыз чәйни*
*Төн уртасына чаклы.*

К ы з л а р. *Суслар элдем лә кабага,*
*Ясарга дип тәрәшле,*
*Ат тугарып җигә белми,*
*Үзе сайлый кәләшне.*

Е г е т л ә р. *Җилбер-җилбер җил исә шул,*
*Агач башларын кисә,*
*Апасы өчен кайгырмыйбыз,*
*Сеңелләре тагы усә.*

К ы з л а р. *Сатмаган, алмаган җегет —*
*Көн дә базарга барган,*
*Карт әбисенә ышанып*
*Урагы карга калган.*

Кайчакта мактау-макташу җырлары да монда кара-каршы җырлана.

Е г е т л ә р. *Исем китеп карап торам*
*Куктәге йолдызларга,*
*Алмалар ла матур була —*
*Җитми безнең кызларга.*

К ы з л а р. *Беләзеккәем уралган*
*Сәгать чылбырларына,*
*Нинди җырлар җырлыйм икән*
*Сәхрә былбылларына.*

Бигрәк тә шаян җырлар җырларга, такмаклар әйтергә, такмакка биергә яраталар. Монда:

*Чабатага чук такмыйлар,*
*Кия-кия чуклана,*
*Чибәр кызлар китә тора,*
*Чибәр егет, йоклама.*

*Агыла болыт, агыла,*
*Агылсын да авышсын,*
*Җебегәннәр калып торсын,*
*Ике уңган кавышсын.*

*Кул буенда куләгә җук —*
*Тирәкләр үсмәгәннәр.*
*Печәнне такыр чапмыйлар*
*Уңмаган, пешмәгәннәр.*

*Альяпкыч бавы салынкы,*
*Чишелеп китәр әле.*
*Артыннан тыр туза бара*
*Бәйләгән көлтәләре.*

Аулак өйдә, бер-береңнең зирәклеген, тапкырлыгын сынау өчен табышмак әйтешүләр була. Мәзәкләр, кыска-кыска мәзәк әкиятләр сөйләнә. Тезелешеп утыралар да табышмак әйтешәләр. Мәзәк сөйләүләр сүз арасында үзеннән-үзе килеп чыга. Әкиятне инде йокларга яткач сөйлиләр. Аулак өйгә җыелган кызлар барысы да кунарга кала. Егетләр кунмыйлар, үз вакытларын белеп, ут сүндермәс борын чыгып китәләр.

## Утырмага бару

Утырмага барулар кыш айларында башлана. Кызлар утырмага, бик зурдан купмыйча, күчтәнәч белән килә. Утырма кызы хөрмәтенә хуҗа хатын аш мәҗлесе үткәрә. Ашка фәкать кызлар һәм яшь киленнәр генә чакырыла. Алай да, яшеренеп кергән, битенә иннек-кершән сөрткән, кызларча киенгән-ясанган берәр шук егет булгалый мондый аш мәҗлесендә. Ул башка авылдан килгән утырма кызын якыннан күрергә, күзләргә теле һәм табында кунак кызы янәшәсендә «песи» булып утыра.

Сыйлау-сыйланулар, кызның күчтәнәчен авыз иттерүләр — барысы да олылар аш мәҗлесендәгечә.

Башка авылдан килгән утырма кызы унбиш көн, ай чамасы кунак була. Шушы авылныкы булса, атна-ун көн утырып китә. Кунакны бүтән кызлар ашка, чәйгә чакыралар, кич утырырга, кунарга йөртәләр. Утырма кызы бик күп кул эше белән килә. Көндез дә, кич утырып та сүс эрли, чигү чигә, бәйләм бәйли. Аны сынарга яраталар, шуңа күрә ул үзен тыйнак, әдәпле тотарга тырыша (бу турыда мәзәкләр дә бар), кием-салымы да мөмкин кадәр матур, җыйнак була. Әмма, олылар кунакка баргандагы кебек, утырма кызы да берәр киемне вакытлыча башка кешедән алмыйча калмый. Һич тә булмаса, беләзек, йөзек, чулпы, чәчкап, сырга кебек әйберләрне көмәсеннән, ахирәтеннән алып тора. Шунсыз мөмкин түгел — юклык куша. Күршеләр җибәрсә, кунакка барыр идек, дигән сүз шул заманнарда әйтелгән, ахрысы.

## Урам урау

Безнең егетләр арасында элек-электән үк урам урау, урамда йөрү гадәте була. Тик бу йола Октябрьдән соңгы елларда бара-бара үзгәрә һәм бетү дәрәҗәсенә җитә.

Язмы, көзме, җәйме, кышмы, җил-яңгырмы, кар-буранмы, барыбер һәркөн кичен караңгы төшкәч, егетләр гармун тартып, җырлар җырлап, урам буйлап йөриләр — урам урыйлар. Төркемдәге дүрт-биш егетнең берсе, күп дигәндә икесе гармунга кушылып җырлап бара.

*Атларымны җиктем, чыгып киттем,*
*Урарга дип лә басу түрләрен,*
*Турыгызда йөрдем, капкагызга килдем —*
*Үзеңне лә шул һаман күрмәдем.*

*Кышлау гөлләр чәчкә атайкән,*
*Ак беләген мендәр итеп*
*Җаныем йоклап ятайкән.*
*Мәдинәкәй туташ, ай каләм каш,*

*Урамнарга ла чакмый яланбаш.*
*Уйлары да авыр микән, җиңел микән?*
*Сызылып кынай киткән кара каш.*

*Кышлау гөлләр чәчкә атайкән,*
*Ак беләген мендәр итеп*
*Җаныем ялгыз ятайкән.*

Тәртмә, шаян җырлар җырларга да күп аптырап тормый егет халкы:

*икләмә, абзый, капкаңны,*
*Тибеп ачмабыз әле.*
*Яшермә, абзый, кызыңны,*
*Урлап качмабыз әле.*
*Абзый арбаң шыгыр-шыгыр,*
*Кабык мәллә, туз мәллә?*
*Айга-көнгә күрсәтмисең,*
*Синдә генә кыз мәллә?!*

Төркемгә тагын егетләр килеп кушыла. Төркем зурая. Ул чакта инде бер төштә тукталып, гармунга, такмакка биюләр, шау-гөр килүләр булып ала.

*Әйли чабата,*
*читек түгел аякта.*
*Бии белсәң чабата*
*Шап та шап шапылдата.*

*Әйли без әле,*
*Безгә бәйләнмә әле.*

*Бәйләнерсең, арырсың,*
*Мәсхәрәгә калырсың.*

*Әйли без әле,*
*Баскан саен өз әле.*
*Ярың күрми кичә түздең,*
*Бүгенгә дә түз әле.*

Янә гармунда сыздырып йөрүләр, янә тукталып-тукталып биешеп алулар дәвам итә.

## Ташу карау

Менә ташу айкала. Кичкә керсәң, су буе тулы халык. Анда да, монда да салам-солам өемнәренә ут төртеп агызалар, әй китә утлы салам өемнәре күксел төтен баганасы утыртып, тегендә картлар ел килешен юрау-сынау өчен ташуның ни дәрәҗәдә шәплеген, бозларның кузгалу-кузгалмауларын күзәтәләр. Яр буйлап яланаяклы малайлар чабыша. Ир уртасы агайлар да багор тотып су читенә баскан-нар, бүрәнә, такта-токта, агач-богачлар агып килмәсме, боз өстенә утырып куян куркаклар килмәсме? Күзәтәләр, көтәләр. Инешнең тугай ясап боргаланып аккан турында яшьләр уйный. Биредә уен да уен. Олы яшьтәге хатын-кызлар да шушы төштә, уен карыйлар, яшьләргә күз-колак булып торалар.

Ташу караганда кызларның яратып уйный торган уеннары: «Көтүчеле», «Алам-алам, алам, кош», «Хан юлы», «Ак тирәк» һәм башка шундый җитәкләшеп, йөгерешеп, хәрәкәт ясап уйный торган уеннар. Егетләр, малайлар исә зур чүпрәк туп тәгәрәтеп «Йомыркалы», «Акчалы» уеннар уйнарга яраталар. Кызлар, билгеле, мондый уеннарга якын да килми. Кыю егетләр кызлар уенына да катнашалар, кызлар белән бергә дә уйнап-уйнап алалар. Уеннар нигәдер кызлар уенына, малайлар уенына аерып йөртелә. Гармун булганда гармунчы тирәсенә җыелышып биилэр. Егетләр берәм-берәм чыгып бии, кызлардан исә биючеләр аз. Алар, кешеләр бик нык сорагач, кыстагач кына биеп алалар. Биючеләрне әй мактыйлар, әй мактыйлар, әмма кул чабып алкышламыйлар, ул гадәт юк.

Тик табигать кочагында күңел ачулар бик тиз үтеп китә. Ата-аналар кызларын, улларын бик аз вакытка гына чыгара — таралышалар.

## Киндер тукмаклау

Кар өстенә тутларга җәелгән кулда тукылган киндерләрне җыеп алуга байтак вакытлар үтеп китә, карлар бетә, ташу кайта, инде киндер тукмаклар чак та җитә.

Кызлар, яшь киленнәр бергә җыелып киндер тукмаклыйлар. Сугылганнан (тукылганнан) соң көндә тутлаган, ашалган киндерләрне сары гәрәбәдәй итеп юылган такталарга катлы-катлы итеп җәяләр дә, аның тирәсенә дүрт яки сигез кыз утыра. Алар, арадан берсе: «Башладык!» диюгә, көйгә салып, кулларындагы бәләкләр белән киндерне тукмакларга керешәләр. Оста тукмаклаучылар булганда, кирәк дүрт белән, кирәк сигез белән тукмаклау булсын, кичке саф, салкын һавада искиткеч матур ритмлы бер көй тарала. Аргы очтан ишетелгән дәртле киндер тукмаклау көенә бирге очта теттереп алып биергә була. Киндер тукмаклаучылар авылның әллә ничә җирендә — бер урындагылар аз гына тынып торган арада, аларга җавап кайтаргандай, икенче урындагылар тукмаклый башлый. Барыннан да уздырыйк дип, тегеләр туктар-туктамастан, өченче урындагылар матур иттереп тыпырдатып алып китәләр.

Киндер тукмаклаучыларны карарга бала-чага, хатын-кызлар җыела. Егетләр дә килгәли бирегә, тик алар бу эшкә бик сирәк катнашалар, шушы тирәдә чуалалар гына. Алай да, кызлар күрү, кызлар белән бер-ике сүз әйтешү бәхетенә ирешә алалар.

Тукмаклагач, бәләкләгәч, билгеле инде, киндер йомшара, ялтырый, күлмәк, алъяпкыч кебек нәрсәләр тегәргә әйбәтләнә. Бу эш шуның өчен эшләнә дә. Әмма монда яшь-җилкенчәкне бергә җыелып күңел ачу, аз булса да күңел күтәрү, бер-береңне күреп сөйләшүләр дә бик кызыктыра. Киндер тукмаклаулар фәкать кичен, кояш баер-баемас чакларда була.

## Карга боткасы

Язын таулар кардан ачыла башлагач, авыл малайлары унбиш-егерме көн эчендә үз хуҗалыкларындагы терлекләрне кырда көтәләр. Моны мал көтү диләр. Бу эш язгы чәчүгә чыгар чак җитүгә, көтүче яллагач туктала, шуннан соң әлеге малайлар карга боткасы пешерәләр. Үзләренчә, хезмәт бәйрәме ясыйлар.

Мал көтүче малайлар, үзара салышып, тары ярмасы, ит, казылык, йомырка җыя. Аның өстенә сыер, сарыкларын көтәрлек малайлары юк кешеләр мал көтүче бу балаларны бик теләп бүләклиләр: ит, казылык, күкәй кебек ризыклар бирәләр. Чөнки бу кешеләрнең терлекләрен дә шул малайлар көткән була.

Азык-төлекне атка төяп кырга алып чыгалар. Кар сулары агып яткан бер матур күл эчендә учак ягып, казан асып, малайлар үзләре итле тары боткасы, күкәй пешерәләр — аш-су әзерлиләр.

Ашамлыклар пешеп өлгергәч, балалар башта ботканы чумырып алып, боткалы кашыкны югары тотып «кар-кар» дип кычкыра-кычкыра ялан буйлап чабышып йөриләр. Аннан әйләнеп киләләр дә табынга утырып ашыйлар. Тагын «кар-кар» дип чабышалар... Көн җылы, кояшлы. Көтүче капчыклары аркадан төшә, ямаулы-йомаулы өске киемнәр салып, чабаталар чишелеп ташлана. Күлмәкчән, яланаяк көе йөгерешүләр, уйнаулар, әллә бик сирәк тигәнгә, искиткеч күңелле һәм бик тә рәхәт була.

Малайларның яратып уйный торган уеннары: «Түбәтәй алышлы», «Куянлы», «Чокыр туплы», «Таяк төкеш» һәм башкалар.

Буй җиткән һәм үсмер кызлар исә «карга боткасы»н шул көннәрдә авылда берәр өйдә пешерәләр. Кызлар үзара салышып җыйган азык-төлекнең беразын көн күтәрелүгә өлгертәләр. Беренче чәйдә сырлыкай[1], коймак-колчә һәм башка ашамлыклар булса, төшке, кичке табыннарда шул ашамлыклар янына иткә пешкән тары боткасы булмыйча калмый.

Иртәнге, төшке ашлардан соң, киенгән-ясанган, төзәнгән-бизәнгән кызлар шау-гөр килеп тауга уйнарга чыга. Анда алар йөгерешеп, җитәкләшеп такмаклы-сүзле уеннар уйныйлар. Язгы кояшлы көндә ямь-яшел тау битләрендә уйнаулар, бәйрәм ясау, ай күңелле була да соң инде!

Карга боткасы шушы көннәрдә авылның берничә җирендә (берничә өйдә) үткәрелә. Бу оч кызлары үзләре, теге оч кызлары үзләре узалдына бәйрәм ясыйлар — карга боткасы пешерәләр. Бу бәйрәмнең һәрберсендә кеше күп, бәйрәм кызык, күңелле була. Монда, күрәсез, егетләр юк. Алар кызлар белән дә, үзләре генә аерым да карга боткасы пешермиләр. Гадәткә кермәгән.

Кичке аштан соң инде кызлар уен корып тормыйлар, кайтып китәләр.

---

[1] Сырлыкай — өстен сырлап пешергән төче күмәч.

Карга боткасына кайбер кызлар катнаша алмый. Ярлылык аркасында бәйрәм казанына алар азык-төлек китерә алмыйлар шул!

## Орлык ашлыгы чыгару

Салам тубалын кулбашына бау белән асып игенче агай бодай чәчә. Артыннан өч-дүрт баласы ияргән. Агай тубалдан учына орлык алып як-якка селтәнгән саен, бодай орлыклары белән бергә ап-ак йомыркалар тәгәри. Балалар аларны йөгерешә-йөгерешә җыялар. Бу йола язгы чәчүгә беренче көн чыкканда башкарыла. Аны «орлык ашлыгы чыгару» диләр. Агай балаларына: «Безнең бодай бик уңар, аның һәр бөртеге шушы тавык йомыркасы зурлыгында булыр»,— ди. Балалар куанышa. Әниләренең орлык бодае эченә пешкән йомыркалар салып җибәрүе, бәлки, аларның башына килмидер дә әле.

## Чәчү бетереп кайту

Сабан ашлыгы чәчеп бетереп кайтучыларга капка артына яшеренеп торган кызлар чиләк-чиләк су сибәләр. Эш бетереп кайтучыларны манма итәләр. Ә игенчеләр исә моңа һич ачуланмый, көлешә, шаярышалар гына. Чөнки бу гореф-не үзләренчә: «Ашлыкларга менә шулай чиләкләп койгандай яңгыр яусын, ашлык уңсын, дигән теләк белән эшләнә», — дип аңларга күнеккәннәр.

Бу көнне эш бетереп кайтучы игенчеләргә — чәчүчеләргә өйдә аш-су бәйрәмчә әзерләнә.

## Сынамак сабан туе

Кар бетеп җир кибәр-кипмәстән үк, язгы чәчүгә чыкканчы сынамак сабан туе ясыйлар. Икенче төрле моны, тау сабан туе, бәләкәй сабан туе, дип тә атыйлар.

Сынамак сабан туена алдан әллә ни зур әзерлек күрелми. Быел килен төшкән кайбер йортлардан, яңа өй салган кешеләрдән бит яулыгы (сөлге), кулъяулыгы, бияләйләр, баш яулыгы кебек нәрсәләр һәм үзләре теләп биргәннәрдән йомырка җыялар да сабан туе үткәреп алалар. Бу сабан туена башка авыллардан көрәшчеләр, йөгерүчеләр, чабыш атлары килми. Шушы авыл батырлары гына көч сынаша, шушы авыл атларын гына узыштыралар. Үз авыл эчендәге көрәшчеләрне, йөгерекчеләрне, чабыш атларын сынап карыйлар. Ягъни, зур сабан туенда башка авыл батырлары белән бил алышырдай егетләребез бармы, башка авыл аргамакларын узардай чабышкы атларыбыз бармы, икенче якларга чыгып мәйдан тотарлык рәт бармы?

Бу — бәләкәй сабан туе. Ә матурлык, күңеллелек зур сабан туйларыннан бер дә ким түгел. Биек тау башындагы бәйрәм мәйданыннан болын, су, әрәмә, басуларның гүзәллеген якты иртә яз аенда бер күрү, күзәтү үзе генә дә ни тора! Уеннар тәртибе исә зур сабан туйдагыча бара.

Төп мәйданнан байтак еракта тагын бер төркем халык — яшь-җилкенчәк, бала-чага, хатын-кызлар. Бирeдә ярыш юк. Әкрен генә гармун уйныйлар. Гармунга егетләр биилләр. Бик тә кыстатып кына кызлардан да биючеләр булгалый. Бик кыюлары гына батырчылык итә бу кадәр күп кеше алдында биергә. Җырлаулар, җырлы-такмаклы, биюле уеннар уйнау юк. Йөгерешеп, хәрәкәт ясап уйный торган уеннар гына уйнала.

Авыл халкы бу көнне бәйрәм итә. Бала-чаганың өс-баш киеме юылган, ямалган. Олылар да ару киемнәрен кияләр. Халык эшкә бармый. Һәр өйдә, бары белән, бәйрәмчә аш-су әзерләнә. Башка авылдан килүче кунак-төшем булмаса да, шушы авыл кешеләре, сабан туеннан кайткач, бер-берсенә ашка барышалар.

## Зур сабан туе

Иртәгә сабан туе дигән көнне үк авылга бәйрәм төсе керә. Төштән соң бер төркем ыспай киенгән егетләр урам буйлап бүләк җыеп йөриләр. Төркемдәгеләрнең берсе аллы-гөлле бит яулыклары, кулъяулыклар эләнгән озын колга тоткан. Егетләр

быел килен төшкән йортларга туктала. Туктау бик аз вакытка гына. Чөнки иҗтиһадлылар сөлгенең менә дигәнен капка төбенә чыгарып торалар, яңа өй салучылар һәм нәзер[1] әйтүчеләр дә бик теләп сөлге, баш яулыгы, бияләй кебек куллан эшләнгән әйберләр бирәләр. Хәтсез йортлардан йомырка чыгаралар. Өй борынына кереп сорап йөрешле түгел. Байтак нәрсә җыела — иртәгә бүләкләр әзер.

Зур сабан туе көнне иртүк балалар күкәй җыя. Кулларында матур итеп тегелгән кечкенә капчык. Алар өй саен кереп йөри. Бу йола сабан туе күкәен җыю дип атала. Кечкенәләргә кардәш-ыру, дус-иш кешеләр генә буяулы йомырка, чуклы кәнфит, кызыл билле прәннек бирә, бүтәннәр сабан туе өчен сырлап пешерелгән йорт прәннеге бирәләр. И шат та инде сабыйлар!

Көтеп алган сабан туенда бар да ямьле күренсен дип тырыша кеше: бу көнгә ишегаллары, капка төпләре, урамнар себерелә. Балчык өйләр, читән алачыклар сылана, акшарлана. Таш коймаларның төшкән, таралган ташлары урынына алып куелган, иске читән коймалар яшел тал чыбык белән үреп ямалган. Хәтта өй түбәсе саламнары да элекке көннәрдәге кебек эленке-салынкы түгел, тузып тормый төсле күренә бүген — һәрнәрсә җыйнаклаштырылган.

Авыл тулы халык. Ел әйләнәсенең бүтән бер генә көнендә дә бу хәтле күп кеше йөргәне юк урамнарда. Өйдән чыгу белән күңелле, ачык йөзле кешеләр күренә: бадъянчуклар таккан, өрфия[2] тәңкәле муенсалар кигән үсмер кызлар, чуклы түбәтәйле, юылган, ямалган ак, күк киндер күлмәк кигән яланаяклы малайлар арлы-бирле йөгерә, йөрүдән бер дә туктап тормыйлар. Киҗеле чүпләмле, аллы-гөлле дебет чигешле алъяпкычлар бәйләгән, чабата киндерләрен төсләмичә кыстырып кына куйган — бик тә ыспай киенгән буй җиткән чибәр кызлар күп күзгә чалына бүген. Көн эссе булса да, балтыр нәзек күренмәсен өчен, ап-ак тула оек белән чабата кигән, түбәтәйләрен, киез эшләпәләрен кыңгыр салган, уксындай[3] буйлы матур егетләр үтеп-сүтеп тора. Кайберәүләр, бигрәк тә, олы яшьтәгеләр кунак каршылап, кунак озатып кайнаша. Ара-тирә җайдаклар — ат аягы кыздырып йөрүчеләр урам буйлап әре генә уза.

Сабантуй мәйданындагы ярышлар, уеннарны тасвирлап тормыйм — алар хәзер дә борынгыча дәвам итә.

Төп мәйданнан читтә, олылар күзеннән еракта — яшьләр төркеме (хатын-кызларның барысы да дип әйтерлек шушында). Монда егетләр, кызлар уйный. Ләкин, олылардан тартыныбрак уйныйлар. Йөгерешеп, җитәкләшеп уйный торган җырсыз-такмаксыз, биюсез уеннар уйнала. Гармунчы тирәсенә җыелып биюләр бар барын. Егетләр берәм-берәм чыгып биләр. Ә кызларның бик кыюлары гына биергә батырчылык итә.

Яшьләр сабан туеннан олылардан соң, кичегебрәк кайтырга яраталар. Сабан туйлары әлек-әлектән үк көтеп алына, зурлап үткәрелә, үткәннәре еллар буе сагынып сөйләнелә килә.

## Каршы уен

Башта ике күрше авыл яшьләре кайчан, кайда каршы уен уздырачаклары турында сүз алышып йөриләр. Һәм менә утау бетеп, печәнгә төшәр алдыннан, эшнең бер саекган чагында, очрашу өчен билгеләнгән көндә ике күрше авыл болыны тоташкан, матур гөл-чәчәкле җиргә уенга чыгалар. Әүвәл бу авыл егетләре белән теге авыл егетләре, бу авыл кызлары белән теге авыл кызлары кара-каршы киләләр, күрешәләр, беркадәр сөйләшеп танышалар. Аннары барысы да бер җиргә җыелалар. Уеннар башлана. Җитәкләшеп, кушып уйнала торган уеннар уйныйлар. Шау-гөр киләләр. Шунда ук чәчәкләр җыялар, аксыргаклардан камчылар үреп, шул камчылар белән бәрешеп уйныйлар, шаяралар. Моның бер төрле дә уйнау кагыйдәсе юк. Әмма бәрешеп, буталышып-буталышып уйнау, шаяру-шуклланулар эч катып көләрлек кызык була. Тагын кызлар үзалдына, егетләр үзалдына, аксыргаклар йолкышып, сынау-юрау уеннары уйнаулар бар. Парлы дигән уен озакка сузыла. Аны бик яратып уйныйлар. Каршы уенда бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүләр гадәткә кергән. Күченгәндә егетләр белән кызлар берга-

---

[1] Нәзер — шартлы вәгъдә.

[2] Өрфия тәңкә — бик юка калай тәңкә.

[3] Уксын күк буйлы — матур озын буйлы камышларны, арышларны уксындай диләр. Шуннан алып озын зифа буйлы кешеләргә карата да уксын күк буйлы сүзе кулланыла.

бергә сөйләшеп, серләшеп, пар-пар булып баралар. Ә төркемнән аерылып андамонда китүләр юк. Шулай инде: каршы уенның башыннан ахырына кадәр читкә сибелү-чәчелүләр һич юк, ярамый, гайбәтчеләр авызына эләгүең бар. Каршы уен яшьләр тырышлыгы белән оештырыла. Аның кайчан һәм кайда үткәреләчәген гайбәтчеләргә белдермәскә тырышалар.
Уенга күпчелек яшьләр чыга алмый кала: «Каршы уен аяк селкеп йөрү, эш калдыру гына ул»,— дип исәпли кайбер ата-ана.

## Бөкре[1] язу

Җиткән кызлар, егетләр нинди дә булса бер эш эшләп ятучылар янынннан исәнләшеп кенә: «Арымай эшләгез, сары май тешләгез!» — дип кенә үтеп китмиләр. Ә аларга (мәсәлән, печән җыючыларга) булышалар, ярдәмләшәләр. Бертын умырып алып эшләп ташлыйлар. Менә шуны, кыз кеше эшләшүне «кияү бөкрәсе язу», егет кеше эшләшүне «кәләш бөкрәсе язу» диләр. Ярдәмләшмичә үтеп китүче кызларга: «Ярдәмләшергә онытты͟ң, киявең бөкре булыр әле менә!» Ярдәмләшмәүче егетләргә: «Кәләшең бөкре булыр әле менә!» — дип шаярталар.

## Төртке боткасы

Кайбер кунаклар, үз кадерләрен үзләре җибәреп, кайтып китәр вакытлары җитсә дә, кайтмый яталар. Шундыйлар табынына тары боткасы пешереп китерәләр. Моны «төртке» боткасы диләр. Ягъни бу аш кунакның китәр вакыты җиткәнен сиздерү өчен, аңа ипләп кенә төрттерү өчен пешерелә. Кайчакта кайтып китәргә бик ашыгып торучы кадерле кунакларны да (уен-көлкене күтәрә белгәнен, билгеле) әлеге ризык белән сыйлыйлар. «Кунагыбыз китми ята, шуңа күрә төртке боткасы пешердек әле»,— дип шаярталар. Шаярырга бер әйбер кирәк бит.

## Кием котлату

Яңа кием кигәч, кечкенә балалар якын кешеләренә шул киемнәрен күрсәтергә баралар. Кардәшләре, туганнары киемне карап мактап, сабыйларга йомырка, шикәр-кәнфит бирәләр. Бу — кием котлату була.

## Уракка кул салу

— И, уракка төштегез дәмени!?
— Юк, кул гына салып кайттык әле. Бер-ике көннән төшәбез.
Уракка ныклап төшкәнче, үз җир башына барып, игенне бер кишәрлек урып кайту гадәте бар игенчеләрдә. Шуны уракка кул салу дип сөйлиләр.
Уракка кул салулар бигрәк тә игеннәр уңган елларда, күңел күтәренке чакларда була. Яхшырак киемнәрен киеп, мөмкин кадәр матурланып (кунакка баргандагы күк булмаса да), аты-туны барлар парлашып (ирле-хатынлы) җигүле ат белән, атсызлар җәяү барып, уракка кул салып кайталар. Башланган эш — башкарылган эш, ди халык. Һәм бу инде, каты эшкә тотынганчы, үзенә күрә күңел ачу, иркен кырда ирек ачып кайту санала.

## Башчагалау

— Киндер сугасыз икән ләбаса!?
— Юк, күрше, әле бары озатып, башчагалап кына куйдым. Иртәгә булмаса да, берсекөннәргә суга башлыйм.

---

[1] Бөкре — холыксыз, киребеткән.

Кулдан киндер тукыганда шулай, вакыт булу-булмауга карамастан, әшне башлап кую — киндерне аз гына тукып кую гадәте була. Шуны башчагалау дип әйтәләр.

## Көмәй[1] куешу

Сердәре килешкән, инде бер-берсен нык белгән ике яшьтәш кыз җан дуслар булырга, ягъни көмәйләр булырга сүз куешалар. Һәм бер-берсенә көмәй дип әйтешеп йөри башлыйлар. Ә кайбер кызлар бер-берсен күреп белеп танышканнан соң, көмәй куешу өчен махсус рәвештә чәйгә чакырышалар.

Менә сердәшеп йөргән ике яшьтәш кызның берсе, ата-ананың рөхсәте белән, икенчесен чәйгә чакыра. Чәй төбендә ике чибәр сөйләшә, сөйләшә... сөйләшеп сүзләре бетми. Сөйгәннәре, егетләр-кызлар турында иң тәмле әңгәмә бу. Шунда ук гомергә тату яшәргә, бер-берсенә көмәй дип әйтешергә сүз куешалар. Шулай итеп, алар дуслыкны ныгыталар, беркетәләр.

Тормышта күренгәнчә исә чәйгә чакырышып көмәй куешканнары да, чакырышмыйча гына көмәй куешканнары да гомер буйларына, сүзләрендә торып, җан дуслар булып яшиләр.

Көмәйләр җыры:

*И көмәем, көмәем лә,*
*Чуклы чәпчүр[2] кигәнең,*
*Пешкән алма, ятка калма,*
*Насыйп булсын сөйгәнең.*

*И көмәем, көмәем лә,*
*Килешә ак күлмәгең.*
*Алма, хөрмә, кайгы күрмә,*
*Насыйп булсын сөйгәнең.*

## Таң суы

Татлы йокыларын калдырып, миһербанлы аналар кызарып таң атканда чишмәдән янсо инештән су алып кайталар. Бераз җылымсалатып, шул суда сабыйларын коендыралар. Бу — балалар таза, чибәр, саф күңелле, физик яктан таза булып үссен, дигән теләк белән эшләнә. Чөнки таң суын аналар коннең тузаны-туфрагы төшмәгән, әле берниндә кер кунмаган пакь су итеп беләләр. Җыры да бар:

*Кулларыңда ал гөл мәллә?*
*Исләре аңкып тора,*
*Таң суында юганнардыр,*
*Йөзләрең балкып тора.*

Сабыйларны таң суында юындыру, коендырулар күбесенчә җәй айларында була.

## Кот кою

Бала нәрсәдән булса да куркып авырса, аңа кот кояла. Матур җәй айларында җыелган мәтрүшкә, шалфей, хуш исле гөлчәчәкләрне яңа кайнаган суга салалар, парлыйлар, пешерәләр дә, шул үсемлекләрнең буына сабыйны утырталар. Моны кот кою диләр.

---

[1] Көмәйләр — җан дуслар.

[2] Чәпчүр — аяк киеме.

## Ат дагасы

Ат дагасы үзенә бер башка матур әйбер санала. Күп нәрсәләрне ат дагасына чагыштырып мактыйлар: «Көмеш дага кебек, корыч дага сыман, акбүз юрга дагасымыни!» — диләр. Ул — яхшылык бәтие булып та йөри. Авырган балага кот кою өчен әзерләнгән кайнаган суга чәчәкләр белән бергә ат дагалары да салалар. Ягъни дага үзенең тылсымлы көче белән чирне куа, баланы сәламәтләндерә, имеш. Юлдан дага яки дага ватыгы тапканда да яхшыга юрала: табучыга тиздән берәр бәхет-шатлык килүен көтәләр.

## Көтү чыгу

Язын беренче мәртәбә көтү чыккан иртәдә елның елында шундый-шундый күренешләр кабатланмыйча калмый: хатын-кызлар көтү куарга күчтәнәч белән киләләр. Ягъни аларның һәрберсе көтүчегә ике-өч йомырка яисә бүтән төрле ашамлык китереп бирә. Беренче кат көтү чыккан көндә көтүчегә күчтәнәч китермәү мәнсезлек, саранлык санала. Гаҗәбрәге: күңелсезләнүләр, көрсенүләр була тагын бу иртәдә. Нигә? Чөнки көтүче авылда хәерчеләр кебек үк иң түбән, иң сансыз кеше исәпләнә. Хәтта аның көтүче дигән «түбән» исеме нәселдән нәселгә кала килә. «Аның бабасы көтүче булган бит!» — дип сөйлиләр кайберәүләр турында. Шуңа күрә көтүчене, аерыча көтүгә беренче кат ялланучыны кызганып күңелсезләнәләр. «Шул көнгә төшәргә тәкъдиреңдә язылган була күрмәсен!» — дип көрсенүләр, балавыз сыгып алучылар да була хәтта. Күп кенә кешеләр өчен, бигрәк тә көтүченең якыннарына күңелсез була язгы беренче көтү чыгу иртәсе. Билгеле, монда малларын исән-сау кышлатып чыгара алуларына сөенеп йөрүчеләр барлыгы да сизелә сизелүен. Һәркемгә мәгълүм, сөенү, көенүләр кайда да, кайчан да янәшә йөри бит инде бу дөньяда.

## Көмеш тәңкә

Өй салганда нигезгә, беренче бүрәнә астына көмеш тәңкә куеп калдыралар. Шулай иткәндә бу өй эче ашлы-сулы була, өй хуҗасы бай була, имеш.

♣♣♣




*«Чын белорус телен... татарлар саклап калган»,— дисәләр, ышанырсызмы? Шикләнергә ашыкмагыз, чөнки бу сүзләрдә хакыйкать юк түгел.*

*Беларусь җирендә татарлар XIV гасырдан бирле яшиләр. XVI йөзнең икенче яртысыннан башлап исә, нигездә, Туктамыш хан сугышчыларының варислары булган татарлар ана телен югалта башлыйлар. Күрәсең, шуны сизеп, алар милләт буларак үз-үзләрен саклап калу өчен дин мәсьәләсенә аеруча зур игътибар бирәләр. Шул дәвердә гарәп хәрефләре белән башлыча белорус телендә язылган китаплар («китабы») барлыкка килә. Кириллица белән чагыштырганда 46 гарәп хәрефенә нигезләнгән белорус татарларының теле баерак булган, ахрысы. Һәрхәлдә, үзенчәлекле әлифбага ия булган китаплар иске белорус телен бернинди үзгәрешсез диярлек бүгенге көнгә кадәр алып килгән. Шунысын да әйтергә кирәк: башта урыс патшалыгы, соңыннан большевиклар хакимияте астында яшәгәндә белорус теле бик кадерсезләнә, җитди тел булып саналмый, төрле яктан кысрыклауларга дучар ителә. Гарәп хәрефләре белән язылган китаплар исә, колонизаторлар игътибарыннан, күрәсең, читтә кала, чөнки андый китапларга каршы көрәш, нигездә, төркимөселман төбәкләрендә бара.*

*Ничек булса да, әлеге татар китаплары («китабы») белорус теле вә тарих белгечләре өчен чын мәгънәсендә алтын хәзинә булып тора. Шуның белән беррәттән, китапларда көнбатыш татарларының тарихи вакыйгалары, әкият-риваятьләре, төрле дини текстлары һ. б. зур урын алган. Белорус татарлары телендә сакланып калган татар сүзләре дә еш очрый: саф (ряд), иман, дуа (дога), хамаил (шамаил), минбар, мизар (мазар, ягъни каберлек), джума (җомга), курбан, байрам, рахмат, садага (садака), ахрат (ахирәт, побратим мәгънәсендә), малай, гальма (ашамлыкның бер төре), буза (эчемлек), баурсак, джэйма (җәймә, ягъни камыр җәймәсе) һ. б.*

*Бу санда укучылар игътибарына белорус татарлары китабыннан бер әкият тәкъдим итәбез.*

**Тәрҗемәчедән**

# ТАПКЫР ЕГЕТ

Укыйк әле изге китапның бер сүрәсен вә шуннан соң бер борынгы хикәятне тыңлыйк.

Борын-борын заманда, Ләхестанның[1] көнчыгыш җирләрендә яшәгән, ди, Салават исемле егет. Булдыклы, акыллы, тапкыр егет булган ул, ләкин ничек тырышса да, үзен һәм ата-аналарын ярлылыктан чыгара алмаган.

Ниһаять, бервакыт әйтә ул аларга:

— Газиз әтием, сөекле әнием! Күрәсез ки, мин сезгә таза тормыш кора алмадым. Өйдә сукыр бер тиен дә юк. Рөхсәт итсәгез, мин сезне берәр бай кешегә хезмәткә биреп, үзем бәхет эзләргә китәр идем. Алла боерса, баермын, соңыннан сезне үз яныма алырмын.

[1]Ләхестан — урта гасырларда татарлар Польшаны шулай атаганнар. Бирелә сүз Польшаның көнчыгыш, ягъни Беларусьның көнбатыш җирләре турында бара.

Егет рөхсәт ала һәм газиз ата-анасын бер байга алып килеп үтенә башлый:

— Бай әфәнде! Ике колым бар, ләкин аларны ашатырга бернинди чара калмады, чөнки ярлылыкка тәмам дучар булдым. Сатып алмассызмы? Колларым ачлыктан үлсә, тәңре мине кичермәс. Мин үзем ерак якларга сәфәр кылмакчымын, мал эшләмәкче, соңыннан колларымны кире алмакчымын...

— И улым,— ди бай,— нәрсәгә кирәк соң миңа әүкатеңдә булмаган бу картлар?

— Алла хакы өчен, бай әфәнде, ярдәм итче, алар сиңа тугрылык белән хезмәт итәчәк, теләсәң нинди әмереңне үтәячәкләр. Үтенеп, баш иеп сорыйм...

— Ярый, инде алайса... Йөрәгем таштан түгел ләбаса. Тик... бу ике картлач өчен нәрсә бирим икән соң сиңа, егет?

— Карт өчен — бер карт алаша да ярый, карчык өчен — бер иске толып бирерсең.

Бай шундый арзан бәягә бик риза булып, егетнең сораган хакын түли. Салават та канәгать — ни әйтсәң дә, ат белән толып иясе булды бит.

Карт алашага атлана да юлга чыга бу. Бер көн бара, ике көн... бер атна, ике атна... Юлда тәмам арыган бер җайдакны куып җитә. Егет аны сәламли, сораша башлый:

— Юлың бигрәк озын, ахрысы, атың да көчкә атлый, үзеңнең дә йөзең караңгы. Сер булмаса, кая барасың? — ди.

Юлчы ерак илдәге бер хөкемдар кальгасына[1] махсус хат илтергә бара икән.

— Алайса интекмә шулай, миңа гына бир хатыңны, мин нәкъ шушы калага юл тотам,— ди егет.

Йомышчы бик нык шатланып хатын юлчыга бирә дә, кире өенә кайтырга дип борыла.

Салават исә юлын дәвам итә.

Бервакыт ул әлеге хатны ачып, укып карарга була. Хатта: «Кальгага ошбу мәктүпне алып килгән адәмнең башын кисәргә һәм колгага кадап куярга»,— дип язылган икән.

«Ай-һай! — дип гаҗәпләнә егет.— Димәк, хатны укып, мин үземне дә, теге юлчыны да үлемнән коткарам булып чыга».

Аллага рәхмәт укып дога кыла да юлын дәвам итә Салават.

Көннәрнең берендә егет зур вә матур бер калага якынлаша. Кальганы биек, калын таш койма уратып алган. Корылманың тышкы ягында бихисап колгаларга кадап куелган кеше башлары күрә. Салават, батыр егет булса да, шушы тамашаны күреп, ирексездән көрсенеп куя. «Бирелә ниндидер сер бар. Бер көн булса да бу шәһәрдә куныш карыйм, серне белим әле»,— дип уйлый егет һәм зур тимер капкага таба юнәлә.

Кала эчендә фәкыйрь генә бер алачыкка сугыла егет.

Алачык ишеген бер карчык ача, егетнең йомышын сорый.

— Әбекәй, арыган юлчыга кунарга рөхсәт итче,— ди Салават.

Күптән түгел генә карчыкның бердәнбер улы үлгән булган икән. Мәрхүм угылына охшатамы, әллә ялгызлыктан интеккән буламы, хуҗабикә егетне бик теләп, куанып каршы ала, аңа кече бүлмәдә урын җәя, кичке ризык хәстәрли, ягымлы сөйләшә. Салават та хуҗабикәгә «әнкәй», дип эндәшә, рәхмәтләр укый.

Ятар алдыннан егет шундый сорау бирә:

— Әбекәй! Нигә бу шәһәр янында колгага кадалган кеше башлары эленеп тора?

— И угылым, белмисеңмени? Тыңла алайса, [redacted]сөй-ләп бирим,— ди карчык һәм егеткә гаҗәеп хикәятне бәян кыла.

Шәһәр хөкемдарының искиткеч матур һәм төрле дин-гыйлемнәргә ия булган бердәнбер кызы бар икән. Бихисап кенәз, король, башка югары дәрәҗәле затлар ул кызны үзләренә яучылап караганнар, байлыклар, алтын-көмешләрне арбалар, кәрванлап китереп өйгәннәр, әмма ләкин чибәркәй малга-дәрәҗәгә дә, рыцарь-алыпларның хәрби данына да кызыкмаган. Бары тик бер шарт белән кияүгә чыгарга риза икән: килгән егет хөкемдар кызының бөтен сорауларына дөрес җавап табарга тиеш. Әгәр дә ки егет патша кызы белән акыл ягыннан тиңләшә алмый икән, аны җәллад кулына бирәләр, ә җәлладның эше мәгълүм: корбанының башын гәүдәсеннән аерып, колгага утырту. Шулай итеп, кальга янында тагын бер шәһәрчек — кисек башлар шәһәрчеге барлыкка килгән.

---

[1]Кальга — крепость, замок.

Ошбу хикәятне тыңлагач, Салават гаҗәпләнә, тирән уйга бата. Аннары әйтә:

— И әбекәй, синең рөхсәтең белән, мин зур гыйлемгә ия булган ул чибәр кыз янына барып, бәхетемне сынап карар идем. Аллаһе тәгалә ярдәм итсә, хөкемдарның кияве дә булырмын әле. Барып чыкмаса инде, язмыш ихтыяры...

— Угылым, алла хакы өчен йөрмә, теге кызны котыртма, башыңны сакла, үтенеп сорыйм!

— Әбекәй, тыйма мине, мин инде, һичшиксез, барырга булдым. Кем үлемнән курка — шул бәхет кошын үзеннән куа.

— Алай булгач, тәңре үзенә ярдәм кылсын, җиңеп кайт, балам,— дип хәер-фатихасын бирә аңа карчык.

Салават, кала хөкемдарының мәһабәт Сараена барып, зур тимер капканы кага. Сакчылар, егетнең ниятен белгәч, аны Сарай хуҗасына озаталар.

— Бөек патша хәзрәтләре! — ди егет.— Мин кызыгыз белән фәлсәфә кылып, дин-гыйлемне сөйләп карамакчы идем. Рөхсәт итсәнче.

— Һай, бичара. Башыңнан колак кагасың киләмени? Бөтен сорауларга җавап тапмасаң, теге дөньяга юл тотачаксың лабаса.

— Хуп, мин риза. Кызыгызга да шулай әйтсәгезче.

Ниһаять, патша кызы тәвәккәл егетне үз янына чакырып ала. Хезмәтчеләр егетне кыз бүлмәсенә озатып, алтын кәнәфигә утырталар.

Бүлмәгә өлешчә генә кенгән патша кызы кергәч, мескен егет һушын югалтып егыла яза: кыз, чыннан да, шулкадәр чибәр, сөйкемле икән! Сөйләшергә генә түгел, тыныч кына карарга да мөмкин түгел бу оҗмах хурына! Ә кыз юри кыланамыни — йә бер ягы, йә икенче ягы белән боргалана, ак нәфис гәүдәсен, фәрештәдәй йөзен балкыта. Егетнең шундук авыз сулары янып кибә, акылы томанлана, ләкин ул тиз генә үз-үзен кулга ала, шундый хәләттә бер сорауга да җавап таба алмаячагын төшенеп:

— Йә, гүзәл ханым, кием әле. Йөзеңне дә капла, чөнки безнең дин шулай куша. Шуннан соң мине дин-гыйлемдә сынап карасаң да була,— ди.

— Ярар соң,— ди кыз һәм сорауларын яудыра башлый.

Егет исә алтын кәнәфидә утырган килеш тыңлый.

— Син нәрсә өстендә утырганыңны беләсеңме? — ди кыз.

— Үземнең ыштан өстендә утырам,— дип җавап бирә егет.

— Кылычсыз килеш кем кемне чаба ала?

— Диңгездә кылыч борынлы дәү балык бар. Шул балык кораб корсагына борынын майга керткән кебек кенә кертә...

— Кем үз каберендә кырык көн елап яткан?

— Юныс пәйгамбәребезне дәү балык йоткач, ул балык эчендә кырык көн елап яткан.

— Кем кабергә кермәс борын үлем газабын татыган?

— Әюп пәйгамбәр. Ул унсигез ел бик авыр чирләп яткан. Аны берьюлы ике мең корт ашаган, шуңа күрә Әюп пәйгамбәр кичергән коточкыч газап үлем газабыннан да дәһшәтлерәк булган.

— Маладис, егет! Ә хәзер миңа анадан тумаган дүрт җан иясен әйтеп кара.

— Беренчесе — бабабыз Адәм, икенчесе аның хатыны — Хава. Өченчесе — алла тарафыннан бар ителгән һәм оҗмахта Ибраһим өчен бернчә мең ел буена сакланган бәрән. Дүртенчесе — Мөхәммәт пәйгамбәрнең Салих кушаматлы дөясе.

— Кем, гөнаһсызны харап итеп, ялган сүз сөйләп акланган?

— Гөнаһсыз Йосыфны аның туган энеләре харап иткәннәр, ә өйгә кайткач, аталарына Йосыфны бүре ашады, дип ялган сөйләгәннәр.

— Мисырга килгән унике кеше ничек итеп алты мең кешегә әверелгән?

— Йакуб үзенең унбер улы белән Мисыр-йортка барып җиткән. Шул ук вакытта диярлек аның янына Йосыф кешеләре дә килгән, барлыгы алты мең инсан җыелган...

Кыз, төрле-төрле сораулар биреп, кичкә кадәр сынады Салаватны. Аннары әйтте:

— Хуп! Бүгенгә кайтып китәргә мөмкин. Иртәгә тагын кил, катлаулырак сорауләр бирермен.

— Шунысы өчен дә рәхмәт, якты йөзле ханым! Бәлки, иртәгә дә ходай миңа ярдәм кылыр,— ди егет тыныч кына.

Теге әбинең алачыгына кайта ул. Карчык исә и куана, и гаҗәпләнә:

— Балам, ничек исән-имин чыктың ул оядан? Сине көтә-көтә саргаеп үлә яздым лабаса.

— Бөтен сөальләргә җавап таптым, әбекәем.

Егет йокларга ятты, ләкин күзенә йокы кермәде, башында төрле уйлар чуалды.

Иртәгесен чираттагы сынау башланды. Кыз, чыннан да, катлаулырак сораулар әзерләп куйган икән.

— Нинди агачта унике ботак, һәр ботагында утыз яфрак бар, эче — кара, ә кайрысы — ак?

— Ул агач — ел дәвамындагы вакыт булыр. Һәрбер елның — унике ае, айның утыз көне бар. Агачның эче — кара төн, кайрысы — ак көн.

— Нинди кош йомырка салмавы сәбәпле үрчеми, ләкин кимеми дә?

— Ел эчендәге вакыт — ул кимеми дә, үрчеми дә.

— Нәрсә ул: аяк-куллары юк, ә ике тылсымлы теле бар?

— Алланың каләме. Ул каләм белән Коръәннең «Әлһәм-дәлилләһи» һәм башка өлешләре язылган.

— Берәүләр ялган сөйләп тә оҗмахка кергән, ә икенчеләр хакыйкать әйтеп тә җәһәннәмгә дучар булган. Кем алар?

— Ялган сөйләүче оҗмахлылар — Йосыфның мәкерле энеләре була. Алар Йосыфны коега ташлап калдырганнар, аталарына исә аны бүре ашады, дигәннәр. Соңыннан алар Алла алдында гафу үтенгәннәр һәм Аллаһе тәгалә боларны кичергән. Шулай итеп, ялганчылар оҗмахка элэгү бәхетенә ирешкәннәр. Хакыйкать сөйләп тә тәмугка эләгүчеләргә килгәндә, шуны әйтергә кирәктер: алар — христиан белән яһүд булырга тиеш. Чөнки христиан, яһүдне мыскыл итәргә теләп, аңа: «Сез — балбалны үпкән халык» — дигән. Яһүд үз чиратында христиан кешесенә: «Ә сез һаман да икона белән балбалларга табынасыз»,— дигән. Икесе дә дөресен әйткән. Үзләре тәмугка дучар булган.

— Йә, егет, әйтеп бирче, шайтанның исеме ничек?

— Иблис.

— Адәм атабыз теге дөньяда ничә ел яшәгән?

— Мең ел.

— Тәмуг уты кемне вакытыннан алда үзенә алган?

— Үзенең Һабил атлы энесен үтергән Кабилне.

.. Бу юлы да тапкыр егет бөтен сорауларга дөрес җавап таба. Ә патша кызы борчыла башлый, үзенә урын табалмыйча йөри, чишелмәслек табышмак-сорауларны уйлап интегә.

Менә өченче көннең иртәсе җитә. Егет тагын килеп, алтын кәнәфигә утыра. Патша кызы аны янә сыный башлый.

— Әйтче миңа, егеткәем, кем элек кеше булып, соңыннан төрле бөҗәккә һәм җанварларга әверелгән?

— Үрмәкүч, маймыл, каплан, шәүлегән, чырайсыз ябалак, мәче, тычкан, куян, карга, попугай, бөркет, күбәләк, бүре, фил һәм башка күп хайван, кошкорт — барысы да элек кеше булып йөргәннәр. Шуннан тыш, күктәге Зөһрә йолдызы да әүвәл кеше булып яшәгән.

— Ни сәбәпле соң алар кеше сыйфатларын югалткан?

— Ходай тарафыннан бирелгән җәза ул. Гайсә пәйгамбәрнең карамагында җитмеш кяфер кеше булган. Әлеге кяферләр Гайсәнең изгелегенә, авыру-имгәкләрне аякка бастыру сәләтенә ышанмаганга, дин-әхлак йолаларын үтәмәгәнгә, Гайсәдән мыскыллап көлгәнгә күрә Аллаһе тәгалә аларны төрле бөҗәк вә хайваннарга әйләндергән. Әйтик, ике егет бер кызга гашыйк булып бер-берсенә төрле киртәләр корып маташкан, кыз исә егетләрнең бәхәсен юри кыздырып торган, шуңа күрә ходай аны Каргага әйләндергән. Яисә шәүлегән тарихын алыйк. Иң әүвәл ул — бер кешенең чит ирләр белән мавыгучан Салита исемле хатыны булган. Ире рөхсәтеннән башка теләсә кая йөргәне өчен ходай аны куянга әйләндергән. Үрмәкүчнең элеккеге халәте кабердәге мәетләрне «чишендереп» кәсеп итүче кешедән гыйбарәт. Гаять чибәр, ләкин ирен санга да санамаган, җиңел холыклы, чит ирләр белән уйнашчылык иткән хатын күбәләк кыяфәтенә кергән. Кеше байлыгын таларга яраткан бер ир-атны ходай филгә әйләндергән. Алланы да санга сукмаган бер чамасыз горур хөкемдар бөркеткә әйләнгән...

Шул рәвештә егет җитмеш кяфернең бөтенесен дә элеккеге гөнаһларын вә хәзерге йөз-кыяфәтләрен әйтеп чыга.

Кыскасы, өченче көн дә егеткә уңыш китерә. Хәзер инде Салават үзе кызны сынап карамакчы:

— И-иһ, туташым! Үзеңне сынап карарга вакыт җитте түгелме? Йәле,

минем сорауга җавап табып кара. Табалмасаң — миңа кәләш булырсың, карышсаң — нәфис башың «колгалар каласына» эләгер, килештекме?

— Ярый,— дип ризалаша кыз.— Чыннан да, бу эшкә нокта куярга кирәк. Йә минем, йә синең өстенлек булырга тиеш.

— Алайса тыңла. Бер егет әнисен җилкәсенә күтәргән, үзе әтисенең иннәренә атланган, шул килеш юлга чыккан. Юлда ана Газраил очраган, ләкин мәрхәмәтле хода егетне үлемнән коткарган. Мин нәрсә һәм кем турында сөйләдем?

Кыз бер уйлый, ике уйлый, өч уйлый, төрле ысуллар ярдәмендә табышмакны чишәргә тырыша, ләкин ничек тә булдыра алмый. Ниһаять, әйтә ул егеткә:

— Ай, маладис! Синең кебек галим вә булдыклы егетне очратканым юк иде әле. Уздырдың мине, хак. Алай да иртәнгә чаклы сабыр итик әле, яме? Иртә белән дә җавап табалмасам — мин синең ихтыярыңда.

Егет хуҗабикә өенә кайтып китә. Кыз исә тирән кайгыга батып кала. Йөрәге гарьлектән әрни аның. Тегесен-бусын уйлагач, кыз бер мәкерлек кылырга тәвәккәлли.

Кичен ул гади күлмәк киеп, танымаслык буянып, йөз-кыяфәтен үзгәртеп, исерткеч һәм тәмле-тәмле ризыклар алып, егет торган алачыкка юнәлә. Килеп җитә, ишек кага.

— Ни кирәк? — дип сорый карчык.

— Әбием, өйгә керергә рөхсәт итегезче,— дип ягымлы, тәүфыйклы кылана кыз.

— Кер әйдә, кер, балам.

Кыз рәхмәтләр укып, туп-туры егет бүлмәсенә үтә.

Егет бу кызны күргәч сорый:

— Сәлам, кызгынай — йөзең алтынай. Ни йомышың бар?

Кыз оялчан елмая, кара толымлы башын аска ия дә әкрен генә әйтә:

— Әй, егет, мин сина гашыйк булдым бит. Бөтен шәһәр халкы синең турында, синең динле, гыйлемле, төскә матур булуыңны мактап сөйли, патша кызы белән акыл сынашуда җиңүеңә соклана. Патша кызын да бик гүзәл, хур кызы диләр...

— Хе! Тапкансың!.. Аның кебек кызлар дөнья тулы! — ди егет.

Бу сүзләр кызның күңеленә нык тия, күрәсең, ул ябык изүле күлмәген вә чуклы яулыгын тиз генә сала, егетнең киң җилкәсенә ак кулын куя, назлы карашы белән егетне иркәли.

Каф тавы хәтле жыелган төкереген көчкә-көчкә йотып, акылдан шашкан егет кызны кочагына ала. Кыз исә исерткеч эчемлек, татлы ризыклар чыгара. Төне буе алар эчә-ашый, серләшә, үбешә, яратыша. Кирәк вакытны сайлап, кыз сорый:

— Батырым, бер соаль бирсәм, ни әйтерсең?

— Сора, иркәм, мең сора...

— Син теге патша кызына биргән табышмакны ничек уйлап чыгардың икән?

— Әнисен җилкәгә күтәреп, үзе әтисенең иңнәренә атланган егет — мин ул. Ярлылыкка төшкәч, әни өчен иске толып, әти өчен — карт алашаны алдым. Юлда бер сәфәрче миңа хат бирде. Анда, кальгага ошбу мәктүпне алып килүченең башын кисәргә, диелгән иде...

Егетнең хикәясен тыңлаганда кыз эчтән бик куана. Таң атар алдыннан гына өенә кайтып, Салаватны каршы алырга әзерләнә башлый.

Егет исә уянгач һәм айныгач, вакыйганы искә төшерә, кызның чынында кем икәнлегенә төшенә.

— Һәй, бетте башым! — дип сукрана ул, һәм Аллага ялварып, белгән догаларын укый башлый. Аллаһе тәгаләнең ярдәме тигәндер, күрәсең, чөнки шул вакытта Салават үз ятагы түшәгендә алтын йөзекне шәйләп ала. Балдакның кыйммәтле ташы да бар, ташында — патша кызының исеме язылган. Шул мәлдә егетнең күңеле күтәрелә: димәк, яшәргә була әле, аллага шөкер!

Йөзекне кесәсенә тыга да Салават, хөкемдар Сараена бара. Патша кызы, әлбәттә, табышмакны чишеп әйтә, атасына җиңү турында хәбәр җибәрә. Егетне патша янына алып китәләр. Шунда Салават әйтә:

— Мөхтәрәм падишаһ! Сезгә бер сүзем бар иде. Әйтергә рөхсәт итегезче.

— Нинди сүз әйтә алыр инде ул үлем алдыннан? — диешә патша яраннары.— Йә елар, йә берәр ялган уйлап чыгарыр.

— Сөйлә, егет! — ди шунда хөкемдар.— Кызым белән өч көн акыл саттың, бәлки, миңа да берәр кызыклы нәрсә әйтерсең.

— Падишаһым-солтаным, — дип башлый сүзен егет.— Бүген төнлә кызыгызның пулатыннан бер тылсымлы күгәрчен очып киткән. Ул очканда җиргә зөбәрҗәт-энҗеләр коелган. Ахырда күгәрчен мин куна торган йортка очып керде, шунда мин аны ак канатларыннан тоттым да теләгәнчә аның белән уйнадым. Аннары күгәрчен кулымнан ычкынып китте. Бармак арасында кошның бер каурые гына торып калды.

— Йә, егет, күрсәт әле теге каурыйны!

Салават йөзекне күрсәтте. Йөзекне таныгач, патша ачуланды, кызын сүгә башлады:

— Аһ, каһәр суккан кыз! Ялганчы бала! Йөзегең ничек бу малайга эләкте? — дип сорый кызыннан.

— Бу минеке түгел ләбаса! — дип аклана кыз.

— Алайса үзеңнекен алып килеп күрсәт! Тиз арада китермәсәң, бу малайны ирекле кылырмын, ә сине... сине... күз күрер!.. Бар!

Курыккан кыз патша пулатыннан йөгереп чыкты да, туп-туры алтын остасына йөгерде.

— Алтынчыгым, мәрхәмәтлем! Синең бөек оста икәнлегеңне күптән беләмен. Зинһар өчен, миңа бер сәгать эчендә яңа алтын йөзек ясап бирче. Атсыз бармагыма сыйсын, йөзекнең кашы зөбәрҗәт булсын, калынлыгы — минем керфек, киңлеге минем каш кеби булсын. Шуны башкарып чыга алсаң, теләсәң нинди хак түләрмен, теләсәң нинди теләгеңне үтәрмен!

— Эшләрмен,— диде алтынчы һәм, чыннан да, бер сәгать эчендә патша кызына әлеге йөзекне ясап та бирде. Зөбәрҗәт ташка кызның исеме дә язылган иде.

Кыз йөзекне атасы пулатына алып килде. Патша үзе дә, кенәз вәзирләре дә, төрле яраннары белән хезмәтчеләре дә ике йөзекне чагыштырып карадылар һәм шундый нәтиҗәгә килделәр: әйе, икесе дә — патша кызыныкы, әмма йөзекләрнең берсе — искерәк, икенчесе — өр-яңа...

Эшнең асылын аңлаган патша кызына болай диде:

— Бу егет сиңа ир булыр, балам. Аның кебек тапкыр, гыйлем, вә акыллы кеше безнең якларда юктыр. Амин.

Сарайдагы кешеләр куанды. Дөресен әйткәндә, патша кызы инде үзе дә егетне ошата башлаган иде. Бигрәк тә теге төннән соң...

Патша сараенда зур туй мәҗлесе ясадылар. Ул җиде көн, җиде төн дәвам итте. Тәмле ризыклар, эчемлекләр белән мең казан, мең чүлмәк тулган иде. Кияү белән кәләш исә йокы бүлмәсенә кергәч тә, гадәт буенча, озак вакыт акыл сынашып, табышмак әйтешеп утырдылар.

Шуннан соң берникадәр вакыт узгач, Салават газиз ата-аналарын чакыртып язма хәбәр сала. Карт белән карчык Салаватның шулкадәр биек дәрәҗәгә мөнүенә чиксез шатланалар, хатны хуҗаларына күрсәтәләр. Хуҗа әфәнде, билгеле, аларга шундук ирек бирә, юлга бәхет теләп озата...

Хөкемдар вафат булгач, шәһәр аның бердәнбер кияве Салават кулына күчә. Салават, Аллаһы тәгалә ярдәме белән, халыкка гадел хакимият кылып, бик озак яшәгән, ди...

*Белорусчадан* **Фаяз ФӘИЗ** *тәрҗемәсе.*

*(«Бәйрәм» журналы, Минск, 1991, 1 сан).*

# ӘДӘБИ МИРАС

*Татарстанның бәйсезлеген ныгыту өчен көрәш бара. Бу көрәштән әдәбият та читтә кала алмый. Бүгенге язучылар гына түгел, үткәндәгеләр дә, Татарстандагылар гына түгел, аннан еракта яшәүчеләр дә Татар иленең ирекле яшәвен таләп аваз сала, хәтта исемсез каһарманнарыбыз да еллар, гасырлар катламы аша халкының бәхетен яклап телгә килә.*

*Анкара шәһәрендә яшәгән, милли-мәдәни мирасыбызны җыюга бөтен көчен, сәләтен биреп тырышкан инженер Мәхмүт Таһир үзе җыйган мирастан ике әсәрне журналыбыз игътибарына тәкъдим итеп җибәргән. Аларның беренчесе — «Балта әкияте», икенчесе — Ләбиб Каранның «Сөембикә һәм татар бәйсезлеге» мәкаләсе.*

*«Балта әкияте»н мөһаҗир язучыбыз Гаяз Исхакый Алманиядә тупланган Милли Мәркәзләр мәҗлесендә сөйләгән нотыгында фикеренә дәлил итеп китергән, нотыкны тыңлап утырган милләттәшебез М. Кәрими исә аны кәгазьгә төшергән.*

*Ләбиб Каран — табиб, Алманиядә һәм Төркиядә яшәгән. Кайда яшәсә дә, Гаяз Исхакыйның уң кулы булып, ул юлбашчылык иткән барлык эшләрдә катнашырга тырышкан.*

*Ләбиб Каран арабызда юк, әмма аның «Сөембикә һәм татар бәйсезлеге» дигән мәкаләсе укучылар өчен исә әле бүген дә әһәмиятен югалтмаган. Мәхмүт Таһир да шушы көннәрдә арабыздан китте, шуңа күрә ул әзерләгән бу язмаларны безгә Сәгыйдә Арсланбәк — мәшһүр Садрый Максудиның оныгы, Анкарадагы Төрки мәдәниятләрне өйрәнү институты хезмәткәре җибәрде. Тарихи ватанына мәхәббәт саклаган, тырышлыкларыбызга куәт өстәгән ерактагы, әмма безнең өчен якын булган газиз милләттәшләребезгә рәхмәтләребезне белдереп, киләчәктә дә журналыбыз битләрендә очрашулар теләп калабыз.*

**Тәүфикъ ӘЙДИ.**

## Балта әкияте

(Халкыбызның Казан егылганнан соң чыгарган бер әкияте булса кирәк)

Безнең халык инде ике мең еллар урманлы-сулы җирләрдә яшәп килә. Бездә йортларны күбесенчә чыршы, нарат агачларыннан салалар. Ул бай урманнар, вакытында кирәк кадәрле агач үстереп, халыкның кирәгенә җитештереп торганнар. Халкыбыз да бик саклык белән генә, кирәк кадәрлесен генә кискән. Урманнар моңа бер дә ачуланмаганнар.

Бервакыт бу урманнарның башына көтмәгәндә зур бәла туган. Әллә нинди усал бер балта чыккан да тыныч яшәгән урманнарны кирәккә дә, кирәкмәгәнгә дә кисә башлаган... Карт имән бу хәлне күреп, корылтай туплаган. Идел, Кама, Агыйдел, Сакмар, Дим, Урал, Иртеш, Миас сулары буендагы урманнардан юкә, нарат, чыршы, миләш, өрәңге, шомырт, тал, тирәк, каен, усак вә башка агачлардан бик күп вәкилләр килеп, зур корылтай уздырылган. Бу вәкилләр барысы да башларына килгән бәланe белгәнчә сөйләгәннәр. Әмма төп мәсьәләне җыючы, йомгаклаучы табылмаган.

Рәис ак каенга карап:

— Син инде безнең арада изге агач, күпне күргән һәр авылда торасың, тәҗрибәң дә зур. Бәлки син берәр нәрсә әйтерсең? — дигән.

Каен бик салмак кына сүз башлап:

— Җәмәгать, бу мәсьәләдә гаеп үзебездә дә бар,— дип әйтүгә, барлык вәкилләр ачуланып каенга ташланганнар. Каен исә:

— Җәмәгать, безнең арада да сап булучы агачлар бар. Балта сабы булудан сакланырга кирәк,— дип сүзен бетергән.

Корылтай: «Моннан соң бер агач та балтага сап булмасын»,— дигән карар чыгарган.

Әмма җансызлар арасында, ни эшлисең соң, бүген дә андый балта саплары табылып тора.

## Ләбиб Каран

# Сөембикә һәм татар бәйсезлеге

Казан ханлыгының урыслар тарафыннан басып алынуына һәм татар бәйсезлегенең югалуына быел 15 октябрьдә инде дүрт йөз ел[1] тула. Бу караңгы көнне искә алганда, бу ачы истәлекне чын күңелдән кичергәндә, Казанның соңгы ханнарыннан булган Сөембикәне искә төшермәскә мөмкин түгел. Чөнки ул татар бәйсезлегенең бер символыдыр. Ул Казан илендә хан булып торганда, Казан каласы урыслар кулына төшмәячәк иде. Моны Мәскәү кенәзе Иван Грозный да шулай белә иде. Ул да аны татар бәйсезлегенең соңгы бер терәге дип аңлый иде. Шуның өчен Иван Грозный Казан иленә каршы ачкан хаксыз һәм сәбәпсез бер сугышын туктатыр өчен һәм Казан ханлыгы берлә Мәскәү кенәзлегенең татулыкта яшәүләренең иң беренче шарты кебек иттереп Сөембикә ханның үзенә тапшырылуын теләгән иде. Татулыкка сусаган һәм сәбәпсез сугышлардан бизгән татар илчеләре Иван Грозныйның бу хәйләсенә алданып, ике өлкә арасында татулык вә тынычлык бәясенә сөекле ханнарын билә фида итәргә күнгәннәр иде.

Ләкин Иван Грозныйның максаты, татарлар аңлаганча, сугышны бөтенләйгә туктатып, ике өлкә арасында озын бер тынычлык, өзлексез бер татулык яшәтү түгел, тик Казан иленең иң ныклы бер терәвен егып, ул ханлыкны тизрәк җимерү вә ул илне басып алу иде. Чыннан да, Казан ханлыгының татулык илчеләре бу тынычлык сатулашуында бик нык алдандылар. Сөембикә хан китү белән башларына нинди зур бәлаләрнең килеп басачагын алдан төшенә алмадылар. Сөембикә хан киткәч тә Казан ханлыгы тәхете буш калачак иде. Иван Грозныйның бөтен шайтанлыгы, иблислеге менә шул хан сайлау эшендә уртага чыгачак иде.

Чынлап та, соңгы заманнарда Казан ханлыгының тәхетенә бер хан сайлау эше үзе генә дә бу ханлык бәйсезлегенең какшавына сәбәп булган төп мәсьәләләрнең берсе хәленә килгән иде. Чөнки хан сайлауда чыккан талашлар, мирзаларның, бәкләрнең төрле партияләргә аерылып аяусыз тартышулары, хан нәселеннән килгән кайбер ханзадәләрнең урыслар кулында Мәскәүдә яшәүләре, бу йөздән кайбер партияләрнең бу ханзадәләрне тәхеткә чыгару юлында Мәскәү кенәзләренең ярдәмнәренә таяну кебек бик зарарлы юлга кереп китүләре, урыс кенәзләренең Казан иле эчке эшләренә катнашуларына юл ача иде. Бу исә Казан ханлыгының бәйсезлеген бик зәгыйфьләтә, хан сайлау уңае белән Мәскәү кенәзләренең Казан ханлыгы эшләренә борын тыгуларына сәбәп була иде.

Сөембикә Казан өлкәсенә килен булып килү белән бу начар хан сайлау гадәтен бетерү өчен тырышты. Урысларның, бигрәк тә Мәскәү кенәзләренең Казан ханлыгы эшләренә катнашуларына юл ачкан сәбәпләрне юк итәр өчен чабаланды. Иң соңында Сафа Гәрәй хан берлә бергә төшенеп, моның бер чарасыны таптылар. Казан халкын, Казанның мирза һәм бәкләрен төрле партияләргә аерган, аларны бер-берсенә дошман итеп, дошманнарыннан дуслык эзләргә көчләгән бу хан сайлау эшен бетереп, ханның беренче улының варис булуы өчен карачылар җыелышында бер төзек ясап чыгарттылар. Бу төзек Мәскәү кенәзләренең, урыс дипломатларының Казан ханлыгы эшләренә борын тыгуларына ачылган юлны каплап, бикләп куйды. Бу эшне эшләүче, эшләтүче Сөембикә иде. Иван Грозный моны бик яхшы белә иде.

Сөембикәнең зур акылы, сизгер күңеле, чиксез зирәклеге, бигрәк тә татарларны һәрвакыт урыслардан югары күргән милли горуры бу төзекне ясаткан иде. Ул бу төзек берлә татар бәйсезлеген җил-яңгырдан саклаган, иң зур бер милли дошманының өлкә эшләренә катнашуын тыйган иде. Ул үзе бу төзекнең иң зур, иң көчле һәм иң аңлы бер сакчысы иде. Менә Иван Грозный тагын Казан ханлыгының эчке эшләренә борын тыгар өчен шул зур сакчыны, Казан бәйсезлегенең бу куәтле

[1]Мәкалә 1952 елда язылган.

тербвен алып ташлауны, үзенең яшерен эмәлләренең барлыкка чыгуы өчен бик кирәкле тапты. Казан ханлыгын җимерү эшен ашыктырыр өчен Сөембикәне тозакка төшерүне беренче планга алды. Казан татарларының тынычлык вә татулыкка бик мохтаҗ булуларын сизеп, бу тынычлык вә татулыкка ирешүнең беренче шарты Сөембикә хан берлә улы Үтәмеш Гәрәй бала ханны үзенә тапшырылуы булганында бик нык аяк терәде.

Партиячелек гаугалары берлә күзләре пәрдәләнгән кайбер мирзалар, Сөембикәнең Казаннан аерылуында үзләренең файдаларын сизгән кайбер эш башындагы бәкләр Иван Грозный берлә татулык сатулашуында ханнарын фида итәргә разый булдылар. Казан иле халкының ризалыгын сорамыйча, Сөембикә хан берлә углы Үтәмеш Гәрәй ханны Иван Грозныйга бирергә кул куйдылар. Һәм дә бу хаин илчеләр бу ике ханны урысларга тапшыру көнен һәм урынын да билгеләп, сүзләшеп кайттылар.

Сөембикә ханның Казаннан аерылуы һәм дә урысларга тапшырылуы татар тарихының иң ачы, иң авыр һәм иң фаҗигале вакыйгасыдыр. Казан халкы үзләренең сөекле ханнарын урысларга бирмәс өчен, өлкәләренең шәфкатьле әнкәсеннән аерылмас өчен күз яшьләрен түгеп, хан сарае янына җыйналдылар. Ханнарын алып китәргә килгән кораллы көчкә каршы торып, урам ташларын куптарып аларга бәрделәр һәм яраладылар. Хан сараендагы һәм бөтен Казан шәһәрендәге хатын-кызлар чәчләрен йолкып елаштылар. Кораллы көч белән халык арасында канлы сугышлар булды. Кораллы көч җиңде вә ханнарын сарайдан алып киттеләр.

Сөембикә хан юлда бара ятканда, үзенең үлгән ире Сафа Гәрәй ханның каберен зыярат итәргә теләде. Аның бу соңгы теләген кабул итеп, урыс субас вә солдатлары каравында, зиратка җибәрделәр. Сөембикә хан Сафа Гәрәйнең кабер-енә бару белән башындагы алтын калфагын җиргә атып бәрде дә кабер өстенә капланып һәм аны кочаклап еларга тотынды. Һәм елый, һәм сөйли иде: «Әй сөекле ханым Сафа Гәрәй! Ач кабереңне, яныңа мин килдем! Синең сөекле бикәңне дошманың урысларга бирәләр. Мине аларга бирмәсәнә, яныңа алсана?!» — дип ялварулары бөтен тыңлаучыларның йөрәкләрен тетрәтте. Хәтта аны алырга килгән урыс субайларын да елатты. Күз яшьләре бөтен кабернең өстен чылатты. Сөембикәнең елый-елый күз яшьләре түкәнде. Сафа Гәрәй ханга ялвара-ялвара тавышы калмады. Иң соңында һушы китеп егылды. Аны һушсыз бер хәлдә урысларның бер көймәсенә кертеп куйдылар.

Бу көймә Казан иленнән аерылып Мәскәүгә таба кузгалып киткәндә Сөембикә хан бераз айныган иде. Казанны соңгы тапкыр күрергә теләп, көймәнең өстенә чыкты. Сөекле Сөембикәбезнең аннан Казан каласына карап сөйләгән сүзләре әлегә чаклы татарларның хәтерләрендә һәм йөрәкләрендә сакланып килә. Бәйсезлек гашыйгы сөекле ханыбызның бу соңгы сүзләре йөз еллар буенча татарларның йөрәкләрен сызлатып торадыр. Ул сүзләр бөтен татарларга мәңге бәйсез гыйшкы урынлаштырган бик кыйбатлы бер дәрес булып калды.

Аның сөйләгән бу кыйбатлы сүзләре тарихларда шулай язылып калган: «Әй Казан, сөекле кала! Инде башыңнан таҗың төште. Син хәзер бер тол булып калдың. Син инде үз-үзеңә хуҗа түгел, бер кол булдың. Син бер башсыз арыслан кебексең, беттең инде. Һәр өлкә бер акыллы патша белән башкарыла, көчле чирүләр белән саклана. Синдә хәзер болар булмагач, кем генә булса да килеп, синнән ханлыкны тартып алыр. Әй Казан, канлы, кыйгылы кала! Иске матур көннәреңне уйлап, син дә минем белән бергә ела! Кайда калды инде синең ханлык бәйрәмнәрең? Кайда инде ул шатланган балаларың? Кайда ул үзенең барлыгы белән горурланган түрә һәм мирзаларың? Кайда ул синең көләч йөзле, нурлы бикәчләрең? Кая китте ул сөенечле тавышлары берлә илгә шатлык тутырган матур туташларың? Инде ул сөенечле тавышлар югалды. Аларның урынында елашулар, ыңгырашулар гына калды. Синдә бал аккан елгалар, чишмәләр бар иде. Инде алардан синең балаларыңның күз яшьләре һәм каннары ага һәм агачак!»

Бу сүзләрнең барысының да чын булганын безләр һәм бөтен кайгылы милләтебез дүрт йөз ел буенча сынадык, күрдек, ишеттек һәм аңладык. Бөтен татар халкы урыска шушы дүрт йөз еллык тоткынлык заманында сөекле Сөембикәләренең ил һәм өлкә сөйгесе ашлаган шул ачы сүзләрен онытмадылар. Сөембикә хан бер татар өлкәсенең тынычлыгы, татулыкта яшәве, иреге һәм бәйсезлеге өчен бирелгән бер корбандыр. Шуның өчен ул безнең каршыбызда бер бәйсезлек символыдыр. Аның Казандагы манарасы татар бәйсезлегенең бер сыны-һәйкәле рәвешендә яшәп киләдер. Аны күргән һәр татарның йөрәгендә бәйсезлек гыйшкы уяна. Ул манара бөтен бер халыкның тарихын җанландыра. Ул ирекле һәм үзгә яшәгән көннәребезне искә төшергән, киләчәгебезгә, Идел-Урал өчен өмет биргән бер кыйбладыр. Чөнки ул татар бәйсезлеге каһарманы Сөембикәбезнең мәңгелек бер истәлегедер.

# ЙӨРӘКТӘГЕ ТЫНГЫСЫЗЛЫК

ЯЗУЧЫ ГАЗИЗ КАШАПОВНЫҢ ТУУЫНА — 50 ЕЛ



1992 елның 21 августында аңа 50 яшь тулган булыр иде. Бу бәйрәмен бик көткән иде ул. Юбилеена якынлашып килгәндә, ягъни 49 яшь тулуга, дөньяны, гаиләсен, туганнарын, дусларын, чәчәккә бөреләнгән иҗатын калдырып китеп барды Газизҗан. Язмыштан узмыш юк, диләр. Шулай булса да, ир уртасы кешенең, талант иясенең йөрәге тибүдән мәңгегә туктавына ышанасы килми. Аның оптимистик рухта язылган, яшәүгә, тормышка мәдхия җырлаган шигырьләре, хикәя, повесть һәм романнары укучылар күңелендә дәвам итә. Әмма үлем — котылгысыз, табигый. Аның шулай икәнен Газиз дә аңлый иде. Әмма тәкъдир сәгатенең кайчан сугасын белмәде, болары инде, өлкәннәр әйтмешли, бер Алланың үзенә генә мәгълүм булгандыр...

Узган елның 30 августы көнне авыр хәбәр килде. Яр Чаллыга ашыктым. Дүрт бүлмәле фатирының залында дустым, йокымсыраган шикелле итеп кенә, күзләрен бөтенләйгә йомган. Чиста йөз (ул җан бирер алдыннан гына кырынып-юынган була), пөхтә таралган чәчләр...

Эш бүлмәсенә үттем. Ул 20 августта, шифаханәгә керер алдыннан, соңгы шигырен тәмамлап калдыра. Менә ул.

## Туган көнемә — 21 августка

Алтынланган агач яфраклары,
Тынып калган урман.
Миләшләргә сары сагыш сауган,
Алма пешеп тулган.
Һәр фасылның үз вакыты — вакыт,
Артыгы юк аның.
Кырык тугыз тапкыр дүртәр
фасыл
Тумышымнан алып...
Юк.
Туктатып булмыйдыр ул, бәлки,
Гомер агышларын.
Минем әле яңа үрләр яулап
Алга барышларым.
Тормыш үзе катлаулыдан болай.
Ачы да соң язмыш!
Тик барыбер каршы алам әле
Тагын илле язны.
Әйтсеннәр соң көнче жирдәшләрем
«Туксан тугызлы» дип.

Әрнүләре, рәнҗүләре белән
Бу дөнья кызык бит...
Миләшләргә сары сагыш сауган,
Алма пешеп тулган.
Алтынланган агач яфраклары,
Тынып калган урман.

*18—20 август, 1991 ел.*

Әйе, Газиз Кашапов өчен урман гына түгел, бөтен җиһан тынып калды. Кем уйлаган — дөнья белән бәхилләшү дәвалану гимнастикасы ясаганда булыр дип... Йөрәк өчен бик авыр заманда яшибез шул.

Газизҗан җөмһүриятебезнең Аксубай районы, Яңа Үзи авылында туа. Кечкенәдән әти-әнисез калып, әбисе тәрбиясендә үсә. Туган авылында җидееллык, Иске Ибрайда урта мәктәп тәмамлагач, ике ел колхозда бухгалтер ярдәмчесе, аннары тракторчы һәм клуб мөдире булып эшли. 1962 елның көзендә Совет Армиясе сафларына алынып, башта курсант, соңыннан гаскәри частьта механик булып хезмәт итә. Благовещенск шәһәрендә хәрби училище тәмамлый. 1969 елда хезмәт вазифаларын үтәгән чакта җәрәхәтләнеп, госпитальләрдә бик озак дәвалана, ә инде 1971 елда хәрби эштән бөтенләйгә китәргә мәҗбүр була.

Безне аның белән Казан дәүләт университеты дуслаштырды. 1973 елда бергә татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга кердек. Соңыннан гаиләләр белән даими аралаштык, туганлаштык диярлек.

Газиз Кашапов язучы, шагыйрь генә түгел, көчле публицист та иде. Ул Әлмәт шәһәрендә чыга торган «Хезмәт байрагы» газетасы һәм КамАЗ радиотапшырулар редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Социалистик Татарстан» газетасының Түбән Кама, Алабуга, Мамадыш, Тукай районнарындагы үз хәбәрчесе булды. Аннары язучыларның Яр Чаллы оешмасын житәкләде. Гомумән, Газиз журналистиканы чын күңелдән яратты. Моннан өч ел элек ул Татарстан язучылар съездында татар публицистикасы турында ялкынлы чыгыш ясады һәм шул мөнбәрдән төшүгә аңа көчле инфаркт булды. Шуннан соң да ул бер роман, ике повесть бастырып чыгарды, иҗат эшчәнлеген дәвам итте. Бигрәк тә якташы, танылган шагыйребез Хәсән Туфанга багышланган «Киек каз юлы» дигән романы өчен бик күп фактик материал туплады. Г. Кашапов Туфан эзләре буйлап күп йөрде, олы шагыйрь эшләгән Пермь өлкәсендәге Лысьва шәһәрендә мемориаль такта куюны һәм аны тантаналы төстә ачтыруны оештырды. Туфан утырган төрмәгә барып, аның «шәхси дело»сын тапты, шуның кесәсеннән «халык дошманы»ның сирәк рәсемен алып кайтты. Хәсән ага сөргендә булган Новосибирск өлкәсендәге авылны эзләп табып, аны белгән кешеләр белән очрашты, шагыйрь яшәгән землянка урынында төн кунды... Әмма Г. Кашапов бу романының бер кисәген генә тәмамлый алды. 1991 ел башында ул Ташкент якларында булып, элек туган төбәкләрендә яшәгән Сиражетдин мулланың көндәлеген табып алып кайткач, тагын бер романлык материал бар, дип шатланып сөйләгән иде.

Газиз Кашапов «Сәмум җиле» дип исемләнгән автобиографик повесть белән үзен прозаик итеп таныткан иде. Аннан соң ул «Солдат иртә ир була», «Җир җылысы», «Убырут», «Гомернең утлы өлеше», «Лачын кошка күкләр кадерле», «Язмышыңа ышан», «Гыйфрит» кебек әсәрләр иҗат итте, 5 китап чыгарды. Басылмаган күп кенә шигырьләре, хикәяләре һәм поэмалары калды.

Газиз Кашаповны райондашлары, авылдашлары да тирән хөрмәт иткән икән. Мәрхүмне җирләгән вакытта бу бигрәк тә ачык күренде. Яңа Үзи авылы кешеләре матәм митингасы вакытында язучының музей-йортын булдыру һәм аңа һәйкәл-бюст кую турында карар кабул иттеләр. Бу тәкъдим халык депутатларының Аксубай район советы рәисе М. Хәлитов тарафыннан хупланды. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Чөнки Г. Кашапов туган халкының азатлыгы өчен жан атып йөрде, Идел-йорт, Акбусай яклары мохитенең мәсхәрә ителүенә түзеп тора алмады.

Газиз Кашапов-Үзиле, 1991 елның 21 февралендә язылган васыяте нигезендә, үзе теләгән төбәктә җирләнде. Аның: «Минe мөмкин булса, туган авылым Яңа Үзигә алып кайтып, Югары як зиратына, әбием, туганнан-туган абыем Афзал янынарак күмәрсез. Теләгем шул...» — дигән сүзләре җиренә житкереп үтәлде.

Моңсу булды Газизҗанны озату. Җитмәсә, гүр иясе булып дүрт тәүлек үткән көннәрдә Казан телевидениесе «Шигърият» программасында Г. Кашаповның язмасын бирде. Бу тапшыруны, исән чактагы Газизнең чыгышын гаиләсе, туганнары, дуслары, авылдашлары үкси-үкси карадылар.

Сүземне йомгаклар алдыннан, хәрби коралны каләмгә алыштырган язучы Газиз Кашапов хатлары турында берничә сүз әйтү кирәктер. Алар барысы да сакланмаган, әлбәттә. Булганнарыннан иҗат эшенә караган, шәхеснең үз-үзенә ничек таләпчән булуын һәм ныклы характерын чагылдырган хатларны сайлап аласы килде. Хатлар, нигездә, Переделкино, Малеевка, Голицыно иҗат йортларыннан, Яр Чаллы шәһәреннән юлланган. Кыскасы, Газизҗанның хатларын укыгач, аның якты образы күңелләребездә тагын бер тапкыр яңарыр, диган өметтә калам мин.

**Тәлгать НӘҖМИЕВ,**
«Саба таңнары» газетасы мөхәррире,
Татарстан җөмһүриятенең атказанган
мәдәният хезмәткәре.

* * *

16 март, 1984 ел.
Переделкино.

Исәнме, Тәлгать дус!

Тагын олактым бит әле мин. Бу юлы инде чын иҗат йортына. Дөрес, ике көнемне соңга калып әрәм иттем итүен, әмма килү белән ярыйсы гына эшләп алдым. Менә бүген әле әллә ни майтарып булмый, эш нишләптер тәрәлеп тора. Моннан романны йомарлап кайтырга исәп бар. Ничек булып чыгар. Мондагы шартлар, уңайлыклар Дубултыдагыдан кимрәк булса да, сынатырга исәп юк.

Өйгә кайткач та, монда килгәч тә сәламәтлеккә туеп булмый әле, Тәлгать дус. Давление дигәннәре бөгештерә генә, быел, кем әйтмешли, үләсе елым бугай. Дөрес, инвалидлыкка комиссия узып йөрдем, әмма бит моның белән генә сәламәтлек рәтләнми. Хәл юк, бөтен нәрсә, бигрәк тә йөрәк дигәнең кылтыр-кылтыр килеп тора, башның тоташ авыртуларын әйтмим дә инде, чөнки син аны әйтүдән болай да туеп беткән. Әмма, бер карасаң, мин бик үк начар, чуттан чыккан кеше түгел бит әле. СССР Язучылар союзы члены булгач та, аннары Чаллыга кайтып юклы-барлы газет эшенә керергә тиешменме мин? Кемнәрнеңдер мыскыллы карашларын күрмәс өчен генә, ялгыз йөрүләрнең тәмен татып, дуңгыз көтүе көтәргә туры килер, ахрысы. Ә бит аннары синең кебек биографлар: «Аның язарга мөмкинлеге, сәләте бар иде, әмма язмады ул, җанына тынычлык тапмады»,— дип килер буыннарга сөйләп-язып калдырырлар, валлаһи дип әйтәм.

Син гаепләмә инде, Тәлгать, чөнки, язып булса да эчне бушатасы килә. Арынасы килә җанны тыгызлап торган нәрсәләрдән. Алла боерса, исән-сау очрашсак, сөйләшер идек анысы. Ул көннәр әллә килә, әллә юк әле. Алай-болай шушы иҗат юлында әрәм булып калсам, начар сүзләр белән искә алма инде...

Минем хатны һәм китапны алгач та Чаллыга хат язгансыңдыр, бәлки, мин аны алып өлгермәдем. Кайткач укырмын инде.

Хуш, сау бул, кабат сәламнәр белән Газиз.

27 март, 1984 ел.
Чаллыяр.

Тәлгать!

Хатыңны, газетаны алдым. Рәхмәт хәбәрләрең өчен.

Хәзер съездда ясаячак доклад (очерк һәм публицистика) белән чиләнеп утырам. Менә яза башладым инде. Болай башлана: «Безне икейөзле булырга, һава торышына, кояшның күренү-күренмәвенә, болытларның куемы-сыекмы икәнлегенә карап хамелеон шикелле төс алмаштырырга өйрәттеләр...»

Башлар ни күрер?

Тагын дошман арттырып кайтырмынмы инде?

Гомумән, бу жанр бездә үги генә түгел, үксез үк булырга охшый...

Мена үзгәртеп корулар инде ничә ел бара. Ә ачы хакыйкатькә бәргән публицистик чыгышлар юк, юк бит... Нибары бернича кеше...

Әле мена «Казан утлары» кичәсен уздырырга хәстәрләнәбез.

Өйдә иминлек әлегә.

Ихтирам белән Газизжан.

18 ноябрь, 1989 ел.
Чаллыяр шәһәре.

Тәлгать дустым!

Хатларыңны алган идем, бу хакта телефоннан әйттем, әмма нишләптер хат язасы килмичә торган чак булды. Аннары машинкамның көе китте, атна буе шуның белән интектем.

Әлегә үземнең хәлләр — сөбханалла. Алга таба диярга дә була инде. Көн саен бик һәйбәтләп җәяү йөреп кайтам. Хәзер инде 10 чакрымга җиткердем. Аннары тагын бер сәгать чамасы күнегүләр ясыйм. Ашауны да бик яман тәртиптә тотам. Шулай итеп, терелергә, яңадан да тормышка басарга һәм дус-ишләрем белән бергә атларга исәплим. Өметләрем нык, теләгем дә бик көчле, иншалла, бәлки әле кабул булыр.

Яза торган повестымны төгәлләдем. «Елан агуы» дигән исем таптым. Ул — мәхәббәт турында. Гаҗәеп көчле бер сөюнең тарихы. Соңыннан шунысы кызганыч: Сәяр исемле хатынны буар елан чагып үтерә. Нишләмәк кирәк, мин аны бүтәнчәрәк бетәр дип уйлаган идем дә, әсәрнең агышы, вакыйгалар шуңа китереп терәде һәм мин инде моңа каршы килә алмадым... Болай ничава гына килеп чыкты кебек. Әле мена бүген генә Казанга җибәрдем, машинкада бастырырга. Шуннан соң «Идел»гә бирермен дип торам.

«Җилләр улы» дигән поэманы Уфага җибәргән идем. Рафаэль Сафин укып, бик матур фикерләр язган. Шулай ук Мостай Кәримгә дә укыган һәм ул да хуплады дип язган.

Казанга, Харрас Әюповка җибәргән идем. Бик нык бирелеп укып чыктым, әмма Х. Туфанның биографиясен күбрәк сөйлисең, үзеңнең фикер йөртүең азрак бугай, дигән.

Нәшриятта шигырь китабын, күпме вәгъдәләр биреп тә, планга кертмәгәннәр.

50 яшькә «Язмышыңа ышан»ны карап чыгып, тулыландырып һәм өстәмәләр кертеп, аның дәвамын тәшкил иткән «Һәркемнең үз йолдызы»н һәм, бәлки, «Елан агуын» бирермен дигән фикергә килдем. Моның өчен тагын өч-дүрт ай бик нык җигелеп эшләргә кирәк була инде... Ә бит «Туфан»га керешермен дигән идем...

Ярый, дустым, минем аһ-зарым бетмәс. Хәзергә хуш-сау булып тор. Лемарага да терелү насыйп булсын. Аңа ачлык игълан итү кирәктер дим. Шулай дәвалану турында бик күп язалар. Бутейконы да өйрәтәсе иде дә бит. Ярый, бәлки очрашырбыз әле...

Ихтирам белән Газизжан.

30 гыйнвар, 1990 ел.
Малеевка.

Әссәламегаләйкум, Тәлгать дустым!

Үзебезнең мөселман ягы — Руза тирәсендәге кара урманнан кайнар сәламнәрем Саба якларына барып ирешсен әле.

Мена инде ике атнадан артык монда килеп җиткәнемә. Бераз эшләгән дә булдым, беразрак дигәнем — мена бүген 65 нче битне яздым. Туфан турындагы әсәр. Әлегә мин аны «Киек каз юлы» дип атап торам. Киләчәктә ничегрәк килеп чыгар. Байтак кына вакыт материал муллыгына күмелеп үтә. Шул комачаулый, кайсын язарга да белмим, калдырырга да жәл, тегесен куйсам, монысы кызганыч. Ничава, язарга кирәк акрын гына.

Төп максат, билгеле инде, сәламәтлекне ныгыту. Иртән бер сәгать чамасы гимнастика, аннары берәр сәгать эшлим, аннары массаж, аннары ашау, аннары тагын бер сәгать ярым чамасы шапылдатып алган көннәр дә булгалый. Аннары ике сәгать буе урман һавасын сулап йөрим. Килгәннән бирле 8 километрдан

ким йөргәнем юк әле. Бер-ике көн хәтта 12 не куаладым. Менә бүген кәеф ярыйсы гына әле, йөз дә чытык түгел. «Бүген Тәлгатьтән хат килер әле»,— дип йөрдем. Төшке ашка барганда карасам — икәү яталар. Бер атна элек Мәхмүт агай Хәсәнов килгән иде. «О, сине онытмыйлар!» — дип куйды. «Мә, мин әйтәм, бу конвертның исен иснә, синең Саба ягы исе киләме»,— дидем. Көлештек. Ул инде ике инфаркт кичергән, ну бирешми. Әле кичә әфлисуннар белән чәй эчтек. «Ачысы»ннан да бераз авыз иттек.

Иртәгә-берсекөнгә Башкортстаннан Рафаэль Сафин агай килергә тиеш. Ул минем дус кеше бит. Аннары Әхсән Баян да килеп җитәр, ди Мәхмүт агай. Менә шулай итеп ятабыз әле. Димәк, мин монда, хәзерге хәлдә яши алсам, синең туган көннәр тирәсендә генә кайтып җитәрмендер. Хәзер, билгеле инде, тиз генә барып булмас, ләкин бит без аны, алла теләсә, җәйге җылы көннәрдә дә искә төшереп бәйрәм итә алабыз. Шулаймы?

Газизҗан.

17 декабрь 1990 ел.
Малеевка.

Тәлгать!

Менә кичәгенәк килеп җиттем. Чаллы-Мәскәү поезды ул бик әшәке, ташландык бер поезд икән. Җыен бич, җыен марҗа алып сатарлар белән тулган. Шуңа карамастан, борчылмаска тырышып килдем...

Казан шифаханәсендәге профессор кереп чыкты китәр алдыннан гына, кунып китте. Илдус Әнвәрович, бик әйбәт кеше. Без аның белән дуслашып та киттек. Киләчәктә, исән булсам, бер әйбер язарлык биографиясе бар.

Синең Туфан ага турындагы әйбереңне килгәч тә тагын бер мәртәбә бик җентекләп укып чыктым. Молодец. Күз бар икән синдә. Акрын гына каләм тибрәтә башласаң да ярыйдыр, минемчә. Әйтик, истәлекләр, аннары зурракларын да язарга мөмкин. Язмыйча булмый ул. Газетага язу саналмый диярлек. Әмма язу дисциплинасын өйрәнү кирәк. Әйтик, үзеңнең җаныңны тетрәндергән бер вакыйганы аласың һәм шуны фантазияң белән тулыландырып, ярамаган җирләрен төшереп, кирәк төшенә үзеңнән өстәп хикәя язып карыйсың. Түлке, чур, газетага яза торган штамплар тулы телеңне онытасың һәм авылда әбиенәниең сөйли торган чын тел белән язасың... Аннары миңа җибәрерсең. Күзең бар, фикерең бар... Давай... Хәерле сәгатьтә...

Авылда өй салырга исәп кылуымны беләсең инде. Бүрәнәсен кистерәсе генә. Кайбер нәрсәләрен Чаллыдан да табармын, бәлкем. Шулай итәм әле, аллаһы боерса. Аннары шунда китеп кенә язармын. Мондагы марҗаларга карап күз ямен җибәргәнче, үземнең туган җиремә, аның урманнарына, кырларына, болыннарына карармын...

Романны машинкага берерлек итеп кайтасы иде. Өстәвенә, тагын да бер дәфтәр табып кайттым. Шуның нигезендә байтак кына нәрсәләргә үзгәреш кертергә туры киләчәк. Бу инде чынлык. Хәсән абыйлар авылына килгән беренче мулла, Шиһабетдин хәзрәтнең шәкерте, 1898 елдан алып 1926 гача көндәлек язган. Шуның күчермәсен бирделәр. Әллә ниләр килеп чыга бит ул, эзләргә генә кирәк...

Аны да күчереп аласы бар... Кыскасы, Чаллыдагы эшләмәгән өч айлык эшне бер айда эшләргә кирәк.

Хуш иттек.

Газизҗан.

5 май, 1991 ел.
Голицыно.

Тәлгать!

Белмим, син миңа ни әйтерсең, әмма ләкин бел, дустым: мин бу килүемдә икенче повестьны язып бетереп, нокта куйдым.

Беренчесе — «Дисбат яки Кояшлы тау итәгендә» дигән әсәр сиңа бераз таныш инде. Сөйләүләр буенча. Мин аны монда килгәч яңадан башладым. Хәлләр бар анда, син караламадай укып чыксаң да шәп булыр иде. Кинәшләрең булыр сыман...

Шуннан, 30 апрель көнендә үк, икенче әйбергә керештем. Бусы бераз җиңелрәк иде. Чөнки моның хатлары-көндәлекләре бар. Алар бергә тупланган. Миңа аларны үземнең участок врачы — бер хатын бирде. Аны инде эшләргә язучы кулы кирәк, хат саен мәгънәле вакыйга, сүз, фикер, характер сыйфатлары һәм тагын бик күп нәрсәләр өстәргә кирәк иде. Алланың биргән илһамы һәм көче белән бүген иртән анысын да тәгәлләдем.

Дөрес, соңгы өч көндә инде минем кәефләр бик начар, теге күкрәк бакасы гел үзен сиздерә башлады. Чатный, «ата». Хәтта бер-ике көн йөрергә чыкмадым, гимнастикаларны да эшләмәдем... Өченче көн ачыгырга керешкән идем, бүген иртән, 44 сәгатьтән соң, авыз ачтым. Хәлләр әйбәтләнебрәк китте.

Аллаһы боерса, 9 ында кич китәм, әти мәрхүмнең фронтовик иптәшләре белән көндез очрашканнан соң. Унысы Казанда булам. Каршы алучы юк, ләкин ничек тә булса китәрмен әле. Миңа инде чемодан күтәрергә ярамый, шул гына...

Кыскасы, минем хәлдәге кешегә 260—270 бит әйбер язу — уен эш түгел. Ничек булгандыр, моны һич кенә дә аңлый алмыйм. Болар мактану түгел, һич тә түгел. Адәми затның мөмкинлекләре, теләгән очракта ниләргә сәләтле булуын гына сиңа язуым...

Барыгызга да рәхмәт. Тугрылыклы дус булганың өчен сиңа рәхмәт. Һәрвакыт мөлаем, ачык йөзле Лемарага рәхмәт. Ниязга һәм Гөлназга бәхетле язмыш язсын.

Һәрвакыт сине якын күреп, ихтирам иткән дустың Газизҗан.

Әссәламегаләйкүм, Тәлгать ахирәт!

Ур-р-р-а-а-а! «Киек каз юлы»ның беренче китап караламасын бетердем, тәки ерып чыктым бит, дустым, чыктым...

Соңгы көннәрдә отыры бер үҗәтлек белән эшләдем. Ә бүген исә, бүген исә иртәдән, сәгать биштән үк торып утырган идем, ашау-эчүсез диярлек, чәй эчтем инде, эшләдем дә эшләдем. Чигәләр кыса, күзләрдән утлар күренә башлады, әмма дә туктап булмый. Менә әле генә нокта куйдым да, беравык хәл алгач, шул олы шатлыкны сиңа язарга булдым.

Ә бит ходай бар, бар ул, дустым. Мин ышанам аның барлыгына. Көтмәгәндә килеп чыккан афәт җиле изге хыялларны җир астына алып китмәгән икән. Аннары... егылган җирдән торгызып утыртып роман хәтле роман яздырган икән, нишләп булмасын ди ул?

Хәзер, моннан кайткач та, беравык тын алу белән үк караламаны эшкәртергә керешәм һәм эшкәрткән берсен машинкага биреп барачакмын. Шулай итеп, Яңа елга хәтле әсәрне бастырып алып, «Казан утлары»на илтеп саласы, ә икенче нөсхәсен дусларга җибәрә башларга кирәк булыр.

Әлегә хуш, сау бул.

Кочып, Газизҗан дустың.

# САГЫНУЛАРЫ БИНИҺАЯ

*Яшел чирәм эчләренә*
*Былбыл баласы качкан.*
*Сагынуларым биниһая —*
*Җирдән күкләргә ашкан...*



Халыкның бу илаһи, матур сүзләрен җан тетрәткеч сагышлы бер көйгә җырлый ул. Җирдән күкләргә ашкан сагышны җырчы кемнән, кайдан, кайчан алган? Менә шул хакта язарга, шул җырчы турында сөйләргә җыенам. Әйе, ул җырлаган җырлар сагыштан тора. Сүзләре, көе, моңы, тавышы — барысы да сагыштан тора. Сөйгәненңе, дустыңны, яшьлегеңне, туган җиреңне, якын кешеләреңне, үткәнеңне, киләчәкне сагыну... Әйе, әйе, хәтта киләчәкне сагыну! Әдәм баласы киләчәген дә сагына булса кирәк. Бу сагыну бәхетле яшәргә омтылып, килер көнеңне өметләнеп көтү, киләчәгеңә ышану, ахрысы. Сагынуның биниһая күп төсмерләре бар. Барсы да аның җырына, моңына сыйган. Ул чын мәгънәсендә сагыш җырчысы. Кем ул дисезме? Моң сөючеләрнең яраткан җырчысы — Рафаэль Ильясов. Шөкер, бүген инде сүз иреге килде, сагыш һәм моң сүзеннән курыкмыйбыз. Юкса бит моннан бер-ике дистә еллар элек сагышлы, моңлы көйләрне, сагыну сүзләре кергән җырларны, шигырьләрне кайбер музыка белгечләре, тәнкыйтьчеләр яратмыйлар иде, андый җырлардан уттан курыккан кебек курыкалар иде. Концертларда андый җырларны җырлатмаска тырышалар иде. Янәсе, сагыну кешенең күңел төшенкелеген чагылдыра, совет кешесе андый булмаска тиеш, янәсе, сагыныр өчен безнең илдә сәбәпләр юк. Ягъни, сагынырга нигез юк, без сагынмаска тиеш, чөнки без бәхетле илдә яшибез, сагынуның, моңның безгә кирәге юк. Җырчылар бәхет турында җырларга тиешләр. Менә шулай куелган иде җырлар язмышы. Ә бәхет дигәнебез хәзер дә хыял гына. Төптән уйлап карасаң, сагыну, сагыш хисе — татар халкының күңелен тоташ биләп алган халәт ул. Безнең халык сагынмыйча яши алмый. Аның яшәве сагынудан тора. Чөнки халкыбыз дөнья буйлап таралган, туып-үскән иленнән еракларга китеп яшәргә мәҗбүр ителгән. Күпләр туган җиреннән, нигезеннән аерылган, ата-анасыннан, туганнарыннан, якыннарыннан, дусларыннан, сөйгән ярларыннан аерылган, «агач яфраклары кебек сибелгән». Рафаэль Ильясов — халкыбызның шул олуг сагышын җырлаучы җырчы.

Сагыш — мәхәббәт юлдашы диләр. Аның җырларында мәхәббәт назлы, татлы, ярсулы, тирән сагыштан тора. «Әйткән идең», «Оныталмасам нишләрмен», «Йөрәк сере», «Өметемне өзмә генә» кебек мәхәббәт җырлары аның башкаруында тыңлаучы күңелен саф, керсез килеш сакланган мәхәббәт хисләре белән иркәли.

Рафаэль Ильясовның күкрәк түреннән тигез агылып чыккан йомшак, тумыштан килгән табигый тавышындагы сагыш төсмерләрен сүз белән аңлатып булмыйдыр шикелле. Тыңлыйсың, тыңлыйсың да, гаҗәпкә каласың: нинди көче, нинди кодрәте бар икән ул тавышның? Нинди назы, нинди тылсымы бар икән? Ул күңеленңе, җаныңны, бөтен халәтеңне биләп ала, тормыш ваклык-

ларын оныттыра, күңелне биеклеккә, югарыга ашкындыра. Татлы хыял диңгезендә йөзгәндәй, татлы кичерешләргә биреләсең, шул татлы җыр дөньясында яшисең. Рафаэль кешене үзенең тавышы белән әнә шулай тылсымлый. Ул җырлаган көйләрнең җаны бар, рухы бар. Тыңлаучының бәгыренә үтеп керә, хисләрен нечкәртә, күңелен сафландыра. Сез Рафаэль Ильясов башкаруында «Яшьлегемә кире кайтыр идем», «Олы юлның тузаны», «Шахта», «Галиябану», «Күн авылы көе», «Яшьлегем тургае», «Юксындырсаң, нишләрмен», «Әйткән идең» кебек җырларны игътибар белән кабат тыңлап карасагыз, чынлап та бу җырларның җаныгызны сафландыруын тоярсыз. Ул башкарган җырларның берсенә генә — «Юксындырсаң, нишләрмен» җырына гына тукталыйк әле. Марс Макаровның Хәсән Туфан шигыренә язган бу җыры беренче карашка гади генә көй кебек. Халык көйләре стилендә язылган. Рафаэль башкаруында ул көй киң колачлы, киң яңгырашлы, тирән мәгънәле җырга әверелә. Халкыбызның борынгы көйләренә хас кителмәгән бормалары белән үзенчәлекле, шул ук вакытта ул хәзерге заман җырларыбызга хас киеренке хәрәкәтчән, ярсулы агымда. Бу җыр күңелдә шундый үзәк өзгеч киеренке сагыш уята, аны тыңлаганда сулыш алмаска тырышасың, сулыш алсаң, җырның иң гүзәл аһәңен ишетми калырсың кебек.

Синсез үтә, тиңсез үтә,
Иртәләрем, кичләрем.
Аена түзәм, елына түзәм,
Мәңгесенә нишләрем?..

«Аена түзәм, елына түзәм»... Җыр шушы урында кёше күңелен югарыга, биеклеккә аштыргандай көчәеп җанны тетрәтә. Әлеге җыр уңаеннан, Хәсән ага белән Рафаэль Ильясов арасында булган бер сөйләшүне искә төшерик әле. Хәсән ага үзенең юбилее алдыннан радиокомитетка килә. Эшләпәсен салып, куе чал чәчләрен артка җилпи дә җайлап кына сүз башлый:

— Син, Рафаэль туганым, минем бәйрәмдә катнашмый калма инде, минем сүзләргә язылган бер-ике җырны җырла инде, яме,— ди. Шундый олы затның, «инде» дип кенә, тыйнак кына үтенүен кире кагарга базмыйча, Рафаэль болай ди:

— Мактаулы исемнәр алган җырчылар, шөһрәт казанган артистлар җырласа, Сезнең бәйрәмегез күңеллерәк үтәр иде, Хәсән абый.

Хәсән ага сабыр гына:

— Юк, Рафаэль туганым, син нәкъ минем күңелем теләгәнчә җырлыйсың, миңа шул кирәк иде,— ди.

Рафаэль Ильясов бу юбилей концертында катнаша һәм Хәсән аганың сүзләренә язылган җырларны башкара. Ә инде «Юксындырсаң, нишләрмен» җыры юбилей концертының иң югары ноктасына җиткән моң булып, залны тетрәтә.

Җырчы репертуарында композиторларыбыз әсәрләре һәрвакыт зур урын алып тора. Юк, ул ноталардан өйрәнеп җырлаучы гына түгел, һәр әсәрне йөрәге аша үткәрә, җырны яңабаштан тудырган кебек нотага җан өрә, җырның иң асыл мәгънәсен ача. Нәтиҗәдә, ул үзе генә ачкан, үзе генә сурәтләгән үзенчә җыр тудыра. Әсәр яңа яңгыраш ала, яңа тормыш белән яңгырый. Композиторларыбыздан ул аерата М. Мозаффаров, С. Садыйкова, Р. Яхин, Б. Гайсин; яшьләрдән Р. Хәсәнов, М. Макаров, И. Закиров җырларын яратып башкара.

Хәзер аның Сара апа Садыйкова белән булган озак елларга сузылган иҗат дуслыгы турында берничә сүз. Сара апаның бик күп җырларын беренче тапкыр Рафаэль Ильясов сәхнәләрдә җырлады, радио аша яңгыратты. «Онытa алмасам, нишләрмен», «Арча кичләре», «Татарстан минем Республикам», «Балкый Шеморза утлары», «Йөрәк сере» кебек җырларны ул тыңлаучының йөрәгенә уеп салгандай итеп башкарды. Сара апа белән бергәләп, ул озак еллар дәвамында сәхнәләрдә чыгышлар ясады. Сара апа иҗат концертларында катнашып, Татарстанның бик күп районнары, авыллары буйлап һәм илебезнең бик күп төбәкләрендә гастрольләрдә йөрде. Шул көннәрне искә төшереп, сагынып сөйли ул: «... һәр җырны кайнар алкышларга күмеп, кабат-кабат җырлаталар иде. Сара апа мөлдерәп торган күзләре белән безгә шундый итеп карый, ул күзләрдән никадәр моң, никадәр шатлык сирпи, аның дөньяда яшәвенең бөтен мәгънәсе җырларында икәнлеге күзләрендә чагыла иде».

* * *

Рафаэль Ильясов беркайчан да артык кычкырып, «тавыш күрсәтим әле» дигәндәй җырламый. Әкрен генә, табигый тавышы белән, тавышының «түмен белеп» җырлый. Әлбәттә, хәзер инде микрофоннар заманы. Аның әкрен генә, җайлап кына җырлавын кирәк чакта микрофоннар көчәйтә дә ала. Юк, ул тавыш белән уйнамый, кеше тавышының нәфисләгән саклый. Күренекле композиторыбыз Җәүдәт ага Фәйзинең кеше тавышының нәфислеге турында әйткән сүзләре иске төшә: «Кеше тавышы музыканың башка яңгырашларыннан үзенең җанлы һәм нәфис булуы белән беренче урында тора. Кешенең җан көзгесе булган җыр иң элек кеше тавышы аша безнең күңелләргә барып керә бит. Әлбәттә, ул тавыш, көчен күрсәтер өчен түгел, ә җырның эчтәлеген дөрес һәм матур итеп ача белер өчен кулланыла. Италиянең бер профессоры үзенең укучысына: «Нигә сез болай кычкырасыз?.. Сез җырлагыз!... Онытмагыз шуны, паровоз да бик каты кычкыра, ләкин аны берәүнең дә тыңлыйсы килми»,— дигән. Очрый бит әле шундый үзенең көчле тавышына гашыйк булып, башын югалткан җырчылар...»

Рафаэльнең халык көйләрен башкару осталыгы турында аерым сөйләргә, бу осталыкның төрле якларына, төрле нечкәлекләренә, үзенчәлекләренә тукталырга кирәктер. Халык көйләрен ул халыкның үзе җырлаган кебек гадилек белән, әмма үз моңы белән баетып, кирәк кадәр генә, тиешле урыннарда гына матур бормалар (мелизмнар) кертеп, көйләргә яңа бизәкләр өстәп башкара. Бу җәһәттән «Алмагачлары» көен җырлавын искә төшерик. Үзе күптәнге һәм бик күп җырчылар тарафыннан җырланган көй ул. Казан татарларының урам көенә әверелгән, әйтергә кирәк, хәтта бераз таушалган көй. Рафаэль башкаруында көй бөтенләй яңа сулыш алып, яңа рух белән яңгырый. Үзе тирән мәгънәле, үзе бераз шаян характерда, дәртле, заманча. Җыр тыңлаучыны уятып җибәрә, елмайта, күңелләренә шатлык өсти. Ә борынгы озын көйләрне башкарганда Рафаэль халкыбызның авыр язмышы турында тирән уйландырырлык итеп, йөрәк ачысы белән җырлый. Халкыбызның гасырлар буена изелеп килүе, хокуксызлыгы Р. Ильясов башкарган борынгы көйләрдә югары эмоциональ кодрәт белән яңгырый. Менә без башкорт халкының атаклы «Сандугач» җырын тыңлыйбыз.

Кайда гына сайрый сандугач?..

Кайда сайрый сандугач? Кайда?.. Халыкның бәхете, өмете кайда?.. Җыр әнә шул сорауларга җавап эзләгәндәй яңгырый. Бу җырны бик күп башкорт һәм татар җырчылары җырлады. Рафаэль аларның берсен дә кабатламый, үзе яңа сандугач табып, үзенчә сайрата.

Борынгы озын көйләрне яратып башкаруы белән бергә, ул сугыш елларында һәм сугыштан соңгы елларда чыккан, хәзер инде онытылып бара торган көйләрне җырлап, аларны халкыбыз күңеленә кабат кайтара. «Өй артында шомыртым», «Рәйхан», «Озату», «Шахта», «Сарман», «Болын», «Бәгърем», «Өнсә», «Кошларга» кебек җырлар, яңадан тугандай, бүгенге көннәр яме булып яши башладылар. Халкыбызның күренекле җырчылары Р. Ваһапов, З. Басыйрова, Ф. Кудашева, Г. Рәхимкулов, Р. Тимерхановалар иҗатын дәвам итеп, әлеге җырларны бүгенге яшь буынга тапшыру бик изге эш.

Чын җырчы гомер буена җырларга өйрәнә. Рафаэль дә әлеге күренекле өлкән җырчыларыбыздан, шулай ук бүгенге мәшһүр җырчыларыбыз И. Шакиров, Ә. Афзаловалардан чын халыкчан моң белән башкару алымнарын өйрәнә. Күренекле опера җырчылары Ф. Насретдинов, А. Аббасов, З. Хисмәтуллиналардан да ул үзенә кирәк нечкәлекләрне өйрәнә. Башкалардан өйрәнә, әмма ләкин аларны кабатламый. Үзенчә җырлый. Җырчыны җырчы иткән бик күп сыйфатларның берсе — җырчының бер кемгә дә охшамаган үз тавышы булуы. Андый җырчыны тыңлаганда башка бер җырчы белән дә бутамыйсың. Рафаэль дә шундый. Күктә йолдызлар бихисап күп. Һәр йолдызның үз урыны, үз нуры. Безнең җырчыларыбыз да күп. Алар һәркайсы халык күңеленә үз нурын сирпи.

Үз нурың белән балку өчен, әлбәттә, җырчының югары музыкаль белемгә ия булырга тиеш икәнен истә тотарга кирәк. Рафаэль Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый. Дөрес, ул оркестр музыканты әзерли торган факультетта укый. Гобойчы булып чыга ул һәм Пермь опера театрына эшкә җибәрелә, оркестр музыканты булып эшли башлый. Ә аңа хәтле узган сукмаклары турында, әйдәгез, үзеннән сөйләтик.

«...1954 елның сентябрь ае. Казан музыка училищесына кереп йөргән көннәр бүгенгедәй хәтеремдә. Менә кабул итү имтиханнары бара. Икенче каттагы зур гына бүлмәгә музыкаль сәләтебезне тикшерү өчен берәм-берәм чакырып алалар да кайсыбызны җырлатып, кайсыбызны берәр инструментта уйнатып карыйлар. Ә укырга керергә теләүчеләр бик күп иде. Ниһаять, миңа да чират җитте. Бүлмә ишеген ачып кердем дә, каушап, югалып калдым. Бер сүз әйтә алмыйм. Бүлмә уртасында миңа таныш булмаган, әмма бик матур ялтырап торган кара төстәге бер нәрсә (соңыннан белдем — рояль икән ул) янына бастырып, җырлатып карадылар. «Кара урман»ны җырладым. Җырлап туктагач, бүмәдәге абый-апалар үзара русча сөйләшеп алдылар. Шуннан соң арадан бер озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, матур киенгән абый миңа якынрак килде дә елмаеп: «Җырчы буласың киләмени?» — дип сорау бирде. «И бала, бала! Без сине әле җырчы булырга укыта алмыйбыз. Син бик яшь бит әле. Нибары 14 яшьтә дисең. Җырчы булырга укыту өчен кимендә сиңа 18 яшь тулган булырга тиеш», — диде. Бу абый училищеның директоры Ильяс абый Әүхәдиев булган икән.

Шулай итеп, җырчы булам дигән хыялларым челпәрәмә килде. Елавын еламадым, шулай да тамагыма төер килеп тыгылды. Кичергән кичерешләремне тоепмы, кыяфәтемә, ярлы өс-башыма игътибар итепме, күңелләрендә кызгану хисе уянды, ахрысы, тагын русча сөйләшеп алдылар. Бармакларымны, тешләремне караганнан соң, шул ук абый болай ди: «Әгәр училищеда бик укыйсың килсә, сиңа башка бүлеккә керергә тәкъдим итәбез. Менә бу абыеңда укырсың», дип, урта яшьләрдәге бер укытучы абый белән таныштырды. Әлбәттә, риза булдым. Шулай итеп мин, Мәскәүдә укып белем алган, Бөек Ватан сугышы кырларында утны-суны кичеп кайткан, инде чәчләренә чал йөгергән гобойчы Мөбарәк Батталов классында укый башладым».

Халкыбызның борынгыдан килгән уен коралы курайга тартым йомшак тавышлы, мөлаем аһәңле инструментны яратып китә Рафаэль. Гобойдан аерылмыйча, училищены, аннары консерваторияне тәмамлый. Халкыбыз көйләрен гобойда чын халыкчан моң белән бик матур башкара. Гобойчы булып калырга да мөмкин булыр иде аңа. Әмма күңелендәге моң байлыгы кайнап, ярсып тора һәм ул Казанга кайтып җырлый башлый.

* * *

Сагыш һәм моң җырчысы дип сүз башлаган идек. Сагыш турында сөйләшик, моң турында бер-ике сүз әйтик. Сагыш белән моң икесе дә бербересенә үрелгән, бер-берсен тулыландыра торган рухи кыйммәтләр. Алар күбрәк төрки халыкларга, бигрәк тә татар-башкорт халкына хас кыйммәтләр дияргә була. Чөнки башка милләтләрдә моң төшенчәсе ботенләй юк та шикелле. Моң ул безнең татарның җанында, канында. Шулай булгач, ул аның җырында яңгырый торган илаһи бер серле гүзәллек, серле аһәң, татарны татар иткән аһәң, милли сыйфат. Моннан егерме, утыз еллар элек сагышны кысрыклаган кебек моңны да җырдан, гомумән, сәнгатьтән кысрыклыйлар иде. Хәсрәт музыка белгечләре, зур-зур мактаулы исемнәр алган композиторларыбыз да моңга каршы «сугыш ачканнар» иде. Әле дә хәтеремдә, Татарстан композиторларының бер конференциясе булган иде. Әлбәттә инде, татар музыкасы турында сүз рус телендә барды. А. Леман, Я. Гиршман кебек «үзебезнең» музыка белгечләребез акыл сатты. «Что такое мон?» — диләр. «Не надо нам мона!» — диләр. Татар җырларының җанын алырга чакырган шикелле, аның моңын алып ташларга чакыралар. Имеш, музыка интернациональ булырга тиеш. Имеш, татар җырын рус та, башка милләт кешесе дә тыңларга, җырлый алырга тиеш. Бу фикерне кайбер татар композиторлары да, белгечләребез дә яклап чыктылар. Әмма җаннарында татар моңы тибрәнгән, халыкчан рухта иҗат итүче композиторларыбыз бу моңкортлыкка каршы чыктылар. М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, Р. Яхин, С. Садыйкова кебек чын милли йөзле композиторларыбыз гасырлардан килгән асыл аһәңнәребезне, моңнарыбызны үз иҗатларында саклап калдылар, күңел түрләрендәге моңнарын халкыбызга бүләк иттеләр. Халыкчан моң белән җырлаучы җырчыларыбыз Р. Ваһапов, З. Басыйрова, Ф. Кудашева, И. Шакиров, Ә. Афзалова, Ф. Сөләймановалар халкыбызның гүзәл моңнарына тугры калдылар. Казның мамыгын йолкып таш-

лаган сыман, җырларыбызның моңын кыркып ташларга ирек бирмәделәр. Моң сагында нык тордылар.

Р. Ильясов та халкыбызның моңына шулай тугры булып, репертуарын һәрвакыт моңлы, халыкчан җырлардан төзи. Ул үз-үзенә бер вакытта да хыянәт итми, музыка дөньясындагы, сәхнәләрдәге төрле агымнарга, тиз үзгәрә торган модаларга иярми, җил кая таба иссә, шул якка ава торган кайбер артистлардан үзенең тотрыклылыгы белән аерылып тора. Килешле тегелгән затлы костюмыннан алып, бөтен килеш-килбәте, бөтен хәрәкәте, үз-үзен тотышы халык күңеленә якын. Шулай булмыйча, Р. Ильясов бит авыл баласы. Татарстанның Чүпрәле районы, Түбән Чәке авылында туып үсә ул. 9 балалы гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килә. Аңа 11 яшь тулганда әнисе үлеп китә. Сугыштан соңгы авыр елларда ятимлектә үскән баланың күңеле тулы моң була. Авыл баласы авыр эш эшләп үсә. Рафаэль дә, ат җигеп, салам, печән ташырга, борчак чабарга, башка күп эшләр башкарырга өлгерә. Гомере буена җитәрлек моң, сагыш ала ул туган авылыннан.

Р. Ильясов еш кына мине үзенең концертларында катнашырга чакыра. Еш кына Чүпрәле районына барабыз. Чүпрәледә аны инде аерата яраталар. Рафаэлебез, Чүпрәлегә кайтканда, поездда ук Чүпрәле ягында яшәүче якташлары кебек мишәрчәләтеп сөйли башлый. Артист дуслары көлешеп: «Кара әле, Рафаэль дус, син дә мишәр икәнсең бит! Мишәрчә сиптерә башладың!» — диләр. Һәм ул шаяртып җырлап та җибәрә:

Безнең район Дырҗаной,
Бездә әпәй ырҗаной!..

Дырҗаной дигәне — Чүпрәле инде. Чүпрәлесен шулкадәр ярата ул, ел саен диярлек концертлар белән кайта. Болай гына, туган ягын сагынып кайтулары да еш аның. Үз уллары итеп, якташыбыз дип хөрмәтлиләр, Рафаэль кайткан дип, бөтен Чүпрәле кузгала. Бөтен районга бәйрәм төсе керә. Олысы, кечесе, яше, карты — бөтенесе концертка килә. Залда әле күк күкрәгәндәй көчле алкышлар, әле шаулашып көлгән тавышлар яңгырый. Яки зал тынлыкка чума, күз яшьләрен сөртеп алучылар да күренә. Өч сәгатькә якын сузылган концертта бер генә битараф кеше дә булмый. Район, авыл җитәкчеләре, укытучылар, колхозчылар, бер-бер артлы сәхнәгә менеп рәхмәтләрен әйтәләр.

* * *

30 елга якын җырлап, Рафаэльнең кыяфәте, килеш-килбәте кебек үк, аның тавышы да үзенең сафлыгын, матурлыгын җуймый. Күренекле нәфис сүз остасы Фәйзи ага Юсупов: «Бал бозылмый, артист картаймый», — ди торган иде. Бу сүз, әлбәттә, артистның талантлысы, җырчының яхшы тавышлысы турында әйтелә. Ильясовның да тавышы үзгәрми. Яшь вакытында ничек ягымлы, йомшак аһәңле булса, хәзер дә шундый. Яшь вакытында нинди төсмерләр белән яңгыраса, хәзер дә шул төсмерләрен саклый. Ә бит тавыш дигән нәрсә дә картая. Гадәттә, еллар узу белән җырчының тавышы карлыга төшә, тупаслана башлый. Көйнең иң әһәмиятле бормаларын алу җырчы өчен авырлаша. Ни гаҗәп, бу кайберәүләргә кагылмый.

1989 елны Р. Ильясов «Яшьлегемә кире кайтыр идем» дигән программасы белән күрше өлкәләрдә дә концертлар куйды. Ульяновск шәһәрендәге концертларында мин дә катнашкан идем. Ульяновск шәһәрендә Чүпрәле, Буа, Апас якларыннан күчеп килгән татарлар бик күп яши. Алар үзләренең якташлары Рафаэль Ильясов концертларына бик яратып йөрделәр. Тамашачылар аны сәхнәдән чыгармыйлар. Сәхнәгә үтенеч язулары ява. Рафаэль халык үтенгәч сораган һәр җырны диярлек башкара. Аннары көлемсерәп залга дәшә:

— Армадыгызмыни әле? Әллә бүген таң атканчы утырырга булдыкмы? — Зал гөр килеп, көлешә-көлешә кул чаба. «Утырабыз! Тагын җырла!» — дип кычкыра.

— Әллә татарның бөтен җырын җырлап бетерергә кирәкме? — ди Рафаэль елмаеп. — Татар халкындагы бөтен җырны да җырлап бетерергә җыенсак, бу залдан без берничә айсыз чыгып китә алмабыз бит! Әйдәгез, концертны исән-имин төгәлләп, бу залдан таралышыйк!

Көчле алкышлар астында баянчыга соңгы җырны башларга ымлый. Соңгы дип җырлаганнары соңгы булмый, тагы җырлаталар. Ә баянчы белән ул үзен

сәхнәдә шундый күркәм тота, аңа иң якын иҗат дусты, таянычы итеп хөрмәт белән карый. Сәхнә түрендә алар бер сулыш белән сулаучы җанга әйләнәләр. Баянчы белән ул инде күз карашлары аша гына да аңлаша. Баянчы аның тавышын нәкъ кирәк урында гына көчәйтеп, тулыландырып, матур аһәңнәр өстәп, бизәкләп, баетып уйный.

Р. Ильясовның яраткан баянчыларыннан Рәгъде Халитов турында берничә сүз. Әгерҗедә туып, Әгерҗе сәхнәләрендә кечкенәдән тальян гармун уйнап үскән. Казанга килеп югары музыкаль белем алган. Рафаэль Ильясов белән Рәгъде Халитов 30 елга якын бергәләп сәхнәдән төшмәделәр, илебезнең күпме төбәкләрендә, күпме шәһәр, авылларында концертлар бирделәр. Шулай бергә-бергә матур, зур иҗат юлы үттеләр. Бүген инде Рәгъде Халитов — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгать фәннәре кандидаты. Халкыбызның дистәләрчә уен коралларын өйрәнеп, шул турыда фәнни хезмәт язган галим. Казан педагогия институтының музыка факультеты деканы, бик күп музыкантлар, баянчылар укытып, өзерләп чыгарган тәҗрибәле укытучы.

Соңгы елларда Р. Ильясов сәхнәләрдә шундый ук сәләтле баянчы Алмаз Имаев белән чыгышлар ясый. Төгәлрәк әйткәндә, 1968 елны ук, Алмаз Имаевны үзенә аккомпаниатор итеп чакыра. Опера театры оештырган Урал шәһәрләре буйлап барган зур концертларда катнашып, алар халкыбызның танылган опера җырчылары З. Хисмәтуллина, Ф. Насретдинов, Р. Билаловалар белән бергәләп чыгышлар ясап, өч елга якын гастрольләрдә йөриләр. Әле музыка факультетының икенче курс студенты гына булуына карамастан, А. Имаев зур артистлар белән тамашачылар алдында чынығу үтә. Еллар узгач, Р. Ильясов яңадан Алмаз Имаевка мөрәҗәгать итә. Алмаз Имаев — Рәгъде Халитовның шәкерте.

Р. Ильясов сәхнәләрдә дә, радио аша җырлаганда да баянга кушылып җырларга ярата. Халкыбыз күңеленә иң якын уен коралы булган баянга тугрылыклы. Шуның өчен халык күңеленә якын да. Җырчы турында сүз йөрткәндә, аның тавышы, башкару осталыгының бик күп матур үзенчәлекләре турында тәфсилләп сөйләргә мөмкин булыр иде, әмма яхшы җырчы турында барсын да язып бетерү мөмкин түгел. Җыр сөючеләр Р. Ильясовны заманыбызның күренекле җырчысы дип таныйлар. Хөкүмәтебез дә аның хезмәтләрен югары бәяләде. Аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе», «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исемнәр бирелде. Әлбәттә, бу мактаулы исемнәргә ул җиңел генә ирешмәде. Бу исемнәрне алу өчен күпме җырлар җырланган, күпме юллар үтелгән. Ә юллар — гастрольләр дигән сүз. Авыр, бик авыр артист хезмәте. Елдан-ел авырая бара ул. Чөнки тормышыбыз елдан-елга авырлаша. Бигрәк тә юллар йөрү кыенлаша бара. Юллар безнең илдә адәм баласының тәненә сызылган канлы җәрәхәт кебек, җир өстенә сузылган төзәлмәс яралар сыман. Чакыр-чокырлы, сазлы-баткаклы. Кышларын юньләп ягылмый торган, җәйләрен чебен тулган бернинди уңайлыклары булмаган кунакханәләрдә, кунакханә әләкмәсә, төрле фатирларда кунып йөрүләр...

Гастрольләрдән ул арып-талып, әмма дәртләнеп, рухланып, яңа иҗат планнары белән кайта. Кая гына бармасын, үзен сагынып каршы алган тамашачылар белән очрашу бәхетеннән канатланып кайта.

— Безнең халкыбызның сәнгатькә мөнәсәбәте һәркайда соклангыч. Җырыбыз-моңыбыз яши, шулай булгач, милләтебез дә яшәячәк,— ди ул киләчәккә ышаныч белән.— Бигрәк тә Уфа, Ижау, Ташкент, Ульяновск, Мәскәү шәһәрләрендәге тамашачыларыбызның күңелендә милли рух сүнмәгән, бу шәһәрләрдә гастрольләрдә йөреп кайткач, яңадан җиң сызганып сәнгатькә хезмәт итәсе килә.

* * *

Р. Ильясов, җырчы буларак, халкыбыз өчен бик кадерле иҗат кешесе. Тагын шуның өстенә Татарстан радиокомитетының музыкаль тапшырулары белән җитәкчелек итүе, музыкаль редакциянең өлкән редакторы булып эшләве — Р. Ильясовның тагын бер зур хезмәте. Ике зур эшне берьюлы башкарып, ул халкыбызга ике кеше буларак хезмәт итә төсле. Бу аның киң колачлы сәнгать эшлеклесе икәнен раслап тора. Аның радиога музыкаль тапшыруларның өлкән редакторы булып килүе очраклы хәл түгел. 1964 елны аны радиога махсус чакыралар. Танылган музыка белгече, үзе дә озак еллар радиода

музыкаль тапшыруларның өлкән редакторы булып эшләгән Маһинур Җиһаншина егетнең музыкаль әзерлеге яхшы булуын, татарча матур итеп яза белүен күреп ала һәм аны бу җаваплы эшкә тәкъдим итә. Һәм ялгышмый, Р. Ильясов менә утыз елга якын бу авыр һәм мактаулы хезмәтне намус белән башкара. Радио аша яңгыраган йөзләгән концерт программаларын төзү, ул концертларда башкарылган меңләгән җырларның туына, магнитофон тасмасына язылуына җитәкчелек итү, җырчыларның репетицияләрен оештыру, яңа әсәрләрне тикшереп кабул итү, моның өчен художество советы утырышларын үткәрү, фондта саклана торган язмалар турында кайгырту һ. б. дистәләгән шундый эшләр радиода санап бетергесез.

Концерт программаларын төрлеләндереп, көнгә берничә концерт оештырырга кирәк. Соңгы елларда «Музыкаль Татарстан», «Музыкаль очрашулар», «Музыкаль сәхифәләр», «Музыкаль почта», «Радио тыңлаучыларның сораулары буенча концерт», «Таныш моңнар» кебек концертларны радио тыңлаучылар бик яратып көтеп алалар. Бигрәк тә «Таныш моңнар» тапшыруы популяр булып китте.

Музыка редакциясенә көн саен берничә дистә хат килә. Р. Ильясов бер генә хатны да игътибарсыз калдырмый. Ул хатлар кайлардан гына җибәрелми! Анда теге яки бу җырны тапшыруны сорап язганнары, теге яки бу җырчының җырлавын сорап, теге яки бу композитор иҗаты белән кызыксынып язганнары да күп.

Атнаның һәр шимбәсендә көндез халык көйләреннән торган зур программалы концерт тапшырыла. Р. Ильясов бу тапшыру турында болай ди:

— Халкыбыз җәүһәрләрен — халык көйләрен даими яңгыратып торырга кирәк. Халкыбызның үз хәзинәсе үзенә булсын, онытыла, югала күрмәсен. Халкыбыз моңнарын яшьләребезнең күңеленә җиткезеп, аларны халкыбызның милли байлыгы җирлегендә тәрбияләргә кирәк. Әле күптән түгел генә Татарстан радиосы кулы-аягы белән Мәскәүгә бәйле иде. Атналык программаны Үзәк радиога җибәреп торуыбызны таләп итәләр һәм һәр шимбә көнне тапшырыла торган халык көйләре программасына бәйләнәләр иде. Нигә, имеш, һәр шимбәдә яңгырый бу татар халык көйләре?! Нәрсәгә кирәк инде ул көйләр?! Бу милләтебезнең иреген кысарга тырышуның бер формасы иде. Шөкер, хәзер Мәскәү таләпләренә исебез китми, милли моңнарыбызны рәхәтләнеп яңгыратабыз.

* * *

Заман үзгәрә, җырлар үзгәрә. Үзгәрә генә түгел, җырлар искерә. Бик кызганыч, ләкин нишләмәк кирәк, заманасында бик шәп яңгыраган, бик матур җырлар да искерә. Әлбәттә, беренче чиратта җырның сүзләре искерә. Сүз иске тоелгач, музыкасы да иске булып ишетелә башлый. Сүзләре искергән җырлар белән нишләргә? Радиодагы редакторларны бу мәсьәлә бик уйландыра. Искерде дип җырны фондтан алып ташларга ярамый. Әле берничә ел элек кенә без яратып, зур горурлык хисе белән җырлаган «Татарстан минем республикам» дигән җыр (С. Садыйкова музыкасы, Н. Дәүли сүзләре) бүгенге сәясәткә ярамый башлады:

> Татарстан минем Республикам,
> Россиянең матур җирендә.
> Ленин аңа үзе исем кушкан
> Бәхет теләп, гомер-гомергә.

Бу сүзләр безнең сәясәткә каршы килә. Без бүген Россия җирендә түгел, әборынгы Болгар бабаларыбыздан мирас булып калган үз җиребездә — үз Татарстаныбызда яшәвебезне исбат итеп, мөстәкыйльлек өчен көрәшәбез. Әйтергә кирәк, бу җырның сүзләре турында радио тыңлаучылар үзләре үк хатлар язалар һәм бу матур музыканы бу сүзләр белән яңгыратмаска кирәк, дип тәкъдим итәләр. Радио тыңлаучылар сәяси яктан сизгер. Редакторлардан да сәяси сизгерлек сорала. Рафаэль бүген күп мәсьәләләрдә уйлана, сүзләре бүгенге сәясәткә каршы килә торган матур-матур музыкаль әсәрләрнең язмышлары өчен борчыла, хәл итү чараларын эзли. Бу мәсьәләдә радио инде художестволы тапшыруларның баш редакторы, шагыйрь Әхмәт Рәшитов җитәкчелеген-

дә эш башлап та җибәрде. Музыкалары матур, ләкин сүзләре искергән кайбер җырларга, бигрәк тә С. Сәйдәшев, А. Ключарев кебек композиторларыбызның музыка хәзинәбезгә классик җырлар булып кергән, халык күңелендә зур мәхәббәт белән яшәгән онытылмас әсәрләренең сүзләрен яңадан язу кирәк булыр, мөгаен. Бу эшкә талантлы яшь шагыйрьләрне тартырга, ул җырларга яңа эчтәлекле яңа сүзләр язарга, яңа яңгыраш бирергә кирәк булыр.

Музыкаль оештыру эшенең тагын бер тармагы — Р. Ильясовның яшь башкаручылар белән эшләве. Бу эш аерата зур игътибар, саклык һәм кешелеклелек сорый. «Эфирда һәр башкаручының үз тавышы, үз урыны бар»,— ди Р. Ильясов яшь җырчылар турында сүз чыккач.

Соңгы дистә елда халык арасында нык танылган җырчылардан Х. Тимергалиева, З. Сәхәбиева, А. Фәйзрахманов, Г. Сафиуллина, З. Шәрифуллина, И. Биктаһиров, В. Ганиева, К. Хәйретдинова, З. Хәйретдинов, Г. Фәрукшин, Ф. Сәләховлар һәм шулай ук, нигездә, радио аша халык күңеленә юл салдылар. Аларны эфирга хөерле юл теләп, Рафаэль абыйлары озатты.

Көнкүрештә Р. Ильясов гаҗәп дәрәҗәдә гади, тыйнак, кешеләр белән үзен кече күңелле итеп тота, җәйлап сөйләшә, кешенең хәленә керә белә. Олыны олы, кечене кече итә. Гаилә җанлы кеше. Гаиләсен хөрмәт итә. Хатыны Светлана үз эшен яратып башкаручы врач. Кызы Айгөл, улы Алмаз әле укып йөриләр.

Без еш кына «халык өчен хезмәт итәбез» диярга яратабыз. Безнең Тукаебыз: «Әйдә, халыкка хезмәткә!» — дигән. Р. Ильясов әнә шулай, Тукаебыз әйткәнчә, халкыбызга хезмәт итеп, киеренке эшчәнлек белән яши, иҗат итә, үзенең күпсанлы шәкертләрен тәрбияли.

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА.**

Китап күзәтү

# ҮР АРТЫНДА ҮРЛӘР

— Зәки, мин синең фән докторы булуыңа да, полковник дәрәҗәсенә ирешүеңә дә артык аптырамыйм. Синдәй булдыклы, тырыш һәм кыю кеше өчен әллә ни гаҗәпләнерлек эш түгел болар. Әмма мине таң калдырган бер ягың бар: утыз-кырык ел урыс арасында булып, ходайның бирмеш көнендә шул халык телендә сөйләшеп яшәгән кеше татар телен ничек шулай бөтен нечкәлекләре белән белә ала икән?! Мин — гомерем буе Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшләгән кеше — синең әсәрләреңне тел төзеклеге ягыннан сынап укыйм, ләкин чатаклыкларга сирәк юлыгам...

Болар — фронтовик шагыйрь Мөхмүт Хөсәен сүзләре һәм алар, әйтергә кирәк, нәкъ минем авызымнан тартып алынган диярсең. Чыннан да, гаҗәп бит! Зәки Зәйнуллин әсәрләрен укыганда, аның теленең образлылыгына, сыгылмалылыгына, шаянлыгына-шуклыгына, халыкчанлыгына кем генә сокланмый икән? Әйтерсең, кеше гомере буе бары тик татар мохитендә генә яшәгән дә, фәкать язучылык эше белән генә мәшгуль булган!

Аның үзе туып-үскән Башкортстанда яшәүче татарларның җирле сүзләрен әсәр тукымасына табигый нәкышләп урнаштыра баруы үзе бер эстетик ләззәт бирә. Ул «капшый-капшый» димәс, «сөрмәнә-сөрмәнә» дияр, «базмый» урынына «базнат итү» дип җибәрер, «курка»ны — «шыртлый», «ана бурзай»ны — «инә бурзай», «мәктәп почмагы»н — «мәктәп мөеше», «ниге»не — «ния» дип әйтер... Әйе, язучының теле — аның күңел көзгесе. Ул шуның ярдәмендә тулысы белән үзен ачып сала — укучы исә аны йә кабул итә, яки кире кага. Зәки Зәйнуллинны сүз сәнгате остасы итеп танымыйча мөмкин түгел. Мин, туган телебез белән ләззәтләнергә теләсәм, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Бәширов, Н. Исәнбәт, М. Мәһдиев, Х. Сарьян әсәрләрен алып укыйм. Боларга соңгы елларда З. Зәйнуллин өстәлде. Мин генә шулай уйламыймдыр. Бу инде кулына иҗат каләме алган кеше өчен аз нәрсә түгел.

Татар халкының элек-электән килгән данлыклы, олы мәдәни үзәкләре булган. Шуларның берсе — Эстәрле. Шәһәрне хәтерләткән базарлы бу зур авылның иң олы мактанычы, әлбәттә, аның мәдрәсәсе. Әнә башкорт карты Яңгыл да нәрсә ди: «авылыгыз менән укымышлы халык һаналаһыгыз». Мәдрәсәнең үткән гасырдагы мөдәррисе Нигъмәтулла Тукаевны авторның зурлап искә алуы да юкка түгел. Мәгърифәт утын бу авыл кешеләренең йөрәгендә мәңге шундый затлы мөдәррисләр кабызып калдырган.

Татар галәмендә генә түгел, Көнчыгыш илләрендә дә милли-азатлык хәрәкәтендә иң күренекле теоретик һәм гамәли эшлеклеләрдән хисапланган шәхесләрнең берсе Мирсәет Солтангалиев та шушы авылның мәдрәсәсенең тәрбиясен күргән гали зат. Әмма, билгеле булганча, Солтангалиевка инанган юлыннан ахырга кадәр бару насыйп булмый. Канэчкеч Сталин үзенең иң беренче корбаны итеп шушы М. Солтангалиевны сайлый һәм аны юк итә. Әмма, мул сулы чишмәнең бер урынын томаласаң, ул икенче урыннан чолтерәп ага башлый. Шуның кебек, сиксәненче елларның икенче яртысында милләтебезгә чын азатлык яулау өчен көрәшне яңадан тергезеп, үрләтеп җибәрүчеләрнең берсе шушы тәбәк каһарманы Зәки Зәйнуллин булды. Латвия башкаласы Ригада ул татар җәмгыяте оештырып, латышларның гаделлек өчен көрәшен хуплау сәясәте алып барды. Аның Латвия телевидениесеннән ясаган чыгышы бик күпләрне сискәндереп җибәрде. «Бу җөмһүрияттә бары тик латыш теле генә дәүләт теле булырга тиеш!» дигән карашы исә урыс теллеләрне аңа каршы аякландырды. Ләкин шуннан башка ул биредәге татарларның мәнфәгатен яклый алмый иде. Миңа бу кешенең Ригада никадәр олы абруйга ия булуын үз күзләрем белән күрергә,

андагы байтак миллəттəшлəр белəн очрашып сөйлəшергə туры килде. Кем белəн генə сөйлəшсəм дə, андагы татар үзеге җитəкчесенə ихлас хөрмəт сиздем. Армия полковнигы өчен бу шактый хөтəр иде. Лəкин иманына турылыклы əлеге шəхес башкача эшли алмагандыр. «Полковникны озату» əсəрен «Идел» журналында укыган һəркем күңелендə аның героена карата ихтирам барлыкка килə.

З. Зəйнуллинның Татарстан мəркəзе Казанга кайтуы да эзсез калмады. Дөресрəге, ул биредəге милли хəрəкəткə көч өстəп җибəрде, вакыйгаларның тизлəнүенə сəбəпче булды. Ш. Мəрҗани җəмгыяте президенты булараК, эшчəнлеген шулкадəр кыю җəелдереп җибəрде ки, моңа кадəр халыкны җитəклəп барган кайбер əһеллəр дə аңардан шөллəп калды. Милли Мəҗлес оештыру корылтаен чакырудагы тырышлыгы өчен аңа халкыбыз берəр вакыт үзенең олы рəхмəтен əйтер əле. (Дөрес, Милли Мəҗлес президенты итеп үзен сайлауларына ризалык бирмəвенə мин, аңа əйтмичə генə, бераз үпкəлəп тə йөргəн идем, лəкин ул вакыттагы шартларда шулай кирəк булгандыр дигəн уй күңелне йомшартты тагын.)

Халкыбызның икенче бер асыл заты Фəүзия Бəйрəмова Татарстанда Рəсəй президентын сайлауга каршы ачлык игълан иткəч, З. Зəйнуллинның унлаган зыялы белəн бергə шушы акциягə кушылуы үзе генə дə күп нəрсə турында сөйли.

Мондый киң колачлы, абруйлы оештыручы, көрəшче, халыкны əйдəп баручы ничек тəрбиялəнə? Зəки абыйны күрə-белə башлаганнан бирле миңа шушы сорау тынгылык бирми. Моңа күпмедер җавапны мин аның «Сугыш алды малайлары» дигəн китабын укыгач таптым. Бу җыентыкны төшкил иткəн повестьларның икесе дə («Сугыш алды малайлары», «Зират күперен чыккач») чын хəл-əхвəллəргə, авторның үз күргəннəренə нигезлəнə. Хəер, аның миңа укырга туры килгəн һəр əсəре диярлек шулай. Моны аңлап та була: мəгънəле тормыш юлы үткəн бу кешенең үз тəҗрибəсендə булганнарны башкаларга җиткерердəй күңел байлыгы шулкадəр күп, əле без алга таба да аларны уку бəхетенə ирешербез.

Аның бер əсəрдəн икенчесенə күчə бара торган бер герое бар, ул — Зиннур Булатов. Зиннурның прототибы автор үзе. Аның əтисе «писарь» Лотфулла абзый балаларына «байлык җыегыз, үзегезне кайгыртыгыз» дими, бəлки күңеллəренə «ил мəнфəгате турында уйлагыз» дигəн гамь сала. З. Зəйнуллинның, кайда гына булса да, халык, миллəт мəнфəгатьлəренə өстенлек бирүе əнə шуннан килə.

Укучы күз алдыннан сугышка кадəрге һəм аннан соң булган авыр елларның бөтен кырыслыгы аша узган, сиңең белəн минем кебек, гап-гади гаилəлəрдə туып-үскəн малайлар язмышы үтə. Татар ир-егете өстенə төшкəн авырлыктан аларның иңнəре сыгыла. Лəкин сыкранмыйча түзə белү, алга куелган максаттан тайпылмау кебек сыйфатлар аларны тормыш дулкыннары өстендə батырмыйча тотып тора. Яшь-яшь малайларның бүре аулау вакытында алган психологик-ихтыяри чыныгулары аларга гомер буе кирəк була.

Азу тешлəрен ыржайтып, өскə ташланырга торган бүрелəрне Зиннур Булатовларга тормышта соңыннанрак та еш очратырга туры килə. Əмма теге вакытта нигезе салынган холык ныклыгы һəрвакыт ярдəм итə. Аның əтисе исə халык зирəклегенə ия булган гаять акыллы əкият картын хəтерлəтə башлый. Бəхтияр тавы дип аталган текə биеклектəн чаңгы белəн шуып төшəргə куркып калганлыгын сөйлəп биргəч, аның үз улына биргəн киңəшенə генə игътибар итик: «Ул тауның син төүдə башына менмə, иң астан башла. Башта түбəннəн генə шу. Аннан соң əзерəк өскəрəк мен. Шул биеклектəн үзең өйрəнгəнче шу да шу. Ныклап шуа башлагач, тагын өскəрəк мен...» Зəки бу киңəшне үрлəрнең телəсə кайсын буйсындырганда да онытмый. Укучыларга ирешкəн беренче əсəрлəреннəн берсенең «Үрлəр аша» дип аталуы да юкка гына булмагандыр. Əйе, тормыш үрлəре текə, мəкерле, алдаучан. Аларны үз ихтыярыңа буйсындыру З. Зəйнуллиндай йөрəге белəн халык бəгыренə тоташкан кешелəргə генə мөмкиндер.

З. Зəйнуллин калəменə хас бер үзенчəлек шунда: ул теге яки бу вакыйгадан ясалырга мөмкин булган нəтиҗəне укучыга көчлəп такмый. Киресенчə, фактны бирə дə, уйлану өчен мəүзуг тəкъдим итə. Мəсəлəн, Иркутск хəрби авиация училищесына кергəн меңлəгəн курсантларның, өйдəн киеп килгəн киемнəрен салдырып, аларны хəрби формага алыштыру күренешен генə алыйк. Командир егетлəрнең барысын бер сафка тезеп куя да, өсбашлары иң теткəлəнгəн малайларны бармагы белəн күрсəтə-күрсəтə, иң беренче итеп кием алыштырырга тиешле төркемгə туплый. Хикмəтле хəл, алама киемле бу төркемне тулысы бе-

лән диярлек татар-башкортлар тәшкил иткән булып чыга. Югыйсә, командир биредә бары бер бизмән белән генә эш итә — фәкыйрьлек. Күрәбез, илдән җыелган ничә мең курсант арасында иң фәкыйре татарлар белән башкортлар икән. Укучы моннан үзе тиешле нәтиҗәсен ясап куя. Шуңа охшаш гыйбрәтле мисалларны авторның әсәрләреннән күпләп китерергә мөмкин.

Язучы каләменең икенче көчле ягы — милләтнең рухын, күңел төпкелләрендә яткан бик нечкә фикерләү һәм хис итү хасиятләрен үзенә даими сурәтләү чарасы итеп алуында, урынлы куллана белүендә. Тапкыр сүзләр, мәзәкләр, җырлар аның әсәрләренең тукымасын бизәп кенә калмыйлар, ныклы җирлеген дә тәшкил итәләр. Дөрес, әле автор аерым фактлар белән артыграк мавыга, әсәргә килеп кергән теге яки бу кеше образының үткәндәгеләрен инәсеннән җебенә кадәр сөйләп бетерергә омтылып, озын сүзлелеккә дә бирелеп алгалый. Андый күренешләр ыспай кибәннән тартелеп торган урынсыз «кабыргалар» кебек тоела башлый. Болар — сәнгатьлелек гармониясенә зыян китерә торган нәрсәләр. Таныпбелү ягыннан, дөрес, алары да кирәксез әйбер түгел. Шулай да, язучы үзенең сүз сәнгате белән эш итүен онытмаска тиеш. Шул ук чигенешләрне башка яклары белән әйләндереп куюю кайчакта күпкә отышлырак булыр иде. Язучы урыны белән повесть жанры үзенчәлекләрен дә онытып җибәргәли. Болай дигәндә, калэм әһелләрен һич тә нинди дә булса кыса белән чикләргә теләмим. Китапта (корректорларның күреп җиткермәве булырга тиеш) «казакъка тартым» урынына «казакъка тартып» (16 бит), «рубль штука» дип әйтәсен «руль штука» (129 бит) итеп язу кебек хаталар да очрап тора. Автор берничә урында «эссе кан эчеп» дигән җөмлә куллана, ләкин «җылы кан эчеп» дию уңышлырак булыр иде. Кан, ни әйтсәң дә, эссе үк булмый бит (93 бит). Менә бу җөмләне дә аңламый гаҗизләнәсең: «Аннары, сарыкны гәүдәгә иң зур баласын күтәреп, үткән юлларын адаштыра-адаштыра өннәренә алып кайтып китте (75 бит). Ахыр чиктә болар китапның сыйфатын төшерә, димәк, алга таба игътибарлы булырга кирәк.

Шунысы куанычлы, халык яратып укый торган язучыларыбыз сафына тагын бер исем — Зәки Зәйнуллин өстәлде. Бүген — укучы документальлеккә йөз белән борылган заманда — аның пәйда булуы табигыйдер. Инде хәзер чынбарлыкны тагы да сәнгатьлерәк, димәк, үтемлерәк итеп тасвирлау осталыгына ирешүдә үр арты үрләр яулап аласы бар.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

# Марсель Сәлимов

## БИГРӘК ШӘП ИЛЕБЕЗ!

САТИРИК ХИКӘЯ

Мин килгәндә райком алдында биш-алты кеше бөтерелә иде. Озын чәчле, битләрен йон баскан ир-узаманнар кулларындагы транспарантны селкә-селкә нәрсәдер кычкыра. Сүзләрен аңлап булмый, иллә мәгәр язулары әллә кайдан ук аермачык күренеп тора: «Коммунистларны кырыгыз!»

— Ишеккә якын бармагыз, райком сургучланган,— дип миңа каршы төште милиционер.

— Эшләпәм калган иде бит әле...

— Юк, юк, ярамый! Президент указын җиренә җиткереп үтәргә кирәк.— Милиционер баштанаяк миңа күз йөгертеп чыкты да:— Әй, абзый,— диде.— Эшләпә нәрсә ул хәзерге заманда?! Башыңны сакла.

Ул да булмады, сакаллы әзмәверләр, йодрыкларын болгап, миңа табан атлады. Эшләпә кайгысы китте. Баш исән чакта тизрәк моннан ычкынуың хәерле.

— Үлем партократларга! — дип, артымнан акырып калды сакалбайлар...

Бу мәхшәрне Шомабаев абзый каршыдагы райсовет тәрәзәсеннән карап торган икән. Ул мине үзенә чакырып алды.

— Дә-ә, энем, хәлең хөрт хәзер.

Шомабаев абзый озак еллар райком секретаре урынында утырды. Институтны тәмамлап, зоотехник булып эшләгән җирдән райкомга инструктор итеп ул алдырган иде мине. Ризалыгымны да сорап тормады. «Партия органнарына нәкъ синең кебек перспективалы яшьләр кирәк»,— дип кенә әйтте. Ләкин Шомабаев абзый белән озак эшләргә насыйп булмады. Дөньялар үзгәреп, власть партия кулыннан ычкына башлагач, райкомны ташлап, райсоветка күчте ул.

— Ярый әле вакытында китеп өлгердем,— диде Шомабаев, шатлыгын яшермичә.— Йөрер идем әтү синең сымак фетнәчеләр рәтендә.

— Мин фетнәче түгел!

— Йә, ярый, ачуланма. Шаярып кына әйтүем.— Шомабаев дусларча аркамнан сөеп куйды.— Шулай да киләчәк тормышың хакында җитди уйларга кирәк. Кайда барасың хәзер? Кем сине эшкә ала? Син бит партократ!

Мин, нәрсә әйтергә белми, җилкәмне җыердым.

— Ярар, борчылма,— диде элекке хуҗам, мәрхәмәтле елмаеп. — Шомабаев абзаң исән чакта ким-хур булмассың. Мин сиңа файдалы

---

Марсель СӘЛИМОВ (1949) — *Башкортстанда яшәүче язучы-сатирик. Уфада һәм Мәскәүдә чыккан китаплар («Тәгәрмәчле чана», «Күгәрчен сөте» һ.б.) авторы. «Һәнәк» журналы баш мөхәррире.*

бер киңәш бирәм. Син, энем, хәзер Демократик консерваторлар партиясенә бар. Аның җитәкчесе Олпат Кылтапович. Синең кадәр райкомда эшләп киткән иде. Бик таләпчән, принципиаль кеше. Синең кебек тәҗрибәле аппаратчыны читкә типмәс.

Шомабаевның киңәшен тотып, мин яңа партия хуҗасына юл тоттым. Олпат Кылтапович дигәннәре чынлап та бик таләпчән булып чыкты.

— Сәяси биографияңдә кара таплар юкмы? — дип сорады, күрешкәч тә.

— Юк шикелле.

Минем җавабым аны канәгатьләндермәде. Шуңа күрә соңгы вакытта бөтен кешегә дә бирелә торган бердәнбер демократик сорауны чәпәде:

— 19 августта нәрсә эшләдең?

— Мин фетнәче түгел! — дидем, тегенең тел төбен аңлап.

Әмма ул төпченүен белде:

— Конкретно итеп әйткәндә?

— Конкрет әйткәндә, баз казыдым.

— Кемгә? — диде ул, кинәт сагаеп.— Коммунистларгамы, демократларгамы?

— Берсенә дә түгел. Бәрәңге салырга баз казыдым. Фетнә мәлендә ялда идем.

— Тукта, бу ничек була инде? Илебезнең барча прогрессив карашлы патриотлары Ак йортны саклады, демократияне яклады. Ә син баз казып яткансың. Фетнәчеләр җиңсә, подпольега качырга җыенгансыңдыр, бәлки. Кем белә, әллә син шуның өчен баз казыгансың... Ю-ук, мондый шикле биография белән безнең партия аппаратына эшкә алу мөмкин түгел. Син инде, энем, эш сорап, бүтән партияләргә мөрәҗәгать итеп кара.— Ул миңа Консерватив демократлар партиясенең адресын бирде.

Көчкә эзләп таптым бу оешма резиденциясен. Кала читендәге ташландык йорт подвалында булып чыкты. Андагы партия лидерының сораганын да көтеп тормыйча:

— Мин фетнәче түгел! — дидем.

Тик аның моңа исе китмәде.

— Ничава, булырсың әле,— дип кенә куйды.— Күпме утырдың?

— Кайда?

— Төрмәдә!

— Мин төрмәдә утырмадым, райкомда утырдым.

— Хыянәтче! — дип кизәнде ул миңа, ачуланып.— Яхшы чакта үкчәңне күтәр?

Азак аңладым: бу оешмада консерва заводы житештергән әйберләрне партияләп чәлдерүчеләр әгъза булып тора икән. Шуңа күрә алар үз «эш»ләрен подпольеда, ягъни идән астындагы подвалда алып баралар.

Район үзәгендәге сәяси мохиткә кул селтәп, туган авылыма юл алдым. Колхоз рәисе белән без яхшы танышлар — мине райкомга алганчы бергә эшләгән идек. Шуңа күрә тартынып-нитеп тормый туп-туры үзенә кердем.

— Менә,— мин әйтәм,— теге вакытта син җибәрергә теләмәгән зоотехник үзе кайтып төште. Элекке камытны кияргә әзермен.

Иске дустым икеләнеп калды.

— Кайтуың әйбәт лә ул, тик...

— Нәрсә, әллә колхозда эш юкмы?

— Эш бар ла ул, тик... Оппозиция көчле бездә. Ә син, ни дисәң дә, райкомда эшләгән кеше — партократ.

Менә гаҗәп! Әллә миннән шикләнә инде?

— Яхшы белгеч икәнеңне беләм. Тик башкаларның шикләнүе ихтимал. Фетнәчеләрне канат астына ала, дип миңа гаеп ташлаулары бар.

— Котың очмасын,— дидем аңа, ачуым килеп.— Мин фетнәче түгел. Янаев белән бер колхозда эшләмәдем, синең белән эшләдем. Павлов белән дә бергә төшереп утырганым булмады. Синең белән генә...

— Шулаен шулай. Тик барыбер махсус комитет карарыннан башка сине эшкә ала алмыйм.

— Анысы нинди комитет тагы?

— Элекке коммунистларның демократик яктан тотрыклы булу-булмавын ачыклаучы...

— Баш катты бит бу комитетлардан!

— Тс-с... Антидемократик сүз сөйләмә.— Рәис дустым телефон аппаратына ишарә ясады.— Берәрсенең тыңлап торуы бар. Хәзер демократия бит...

— Ә теге комитетыгызның хуҗасы кем соң?

— Бутаушев әфәнде. Син аны беләсең.

— Комбайн белән иген урлаганы өчен партиядән куылган Артавыл бригадирымыни?

— Нәкъ үзе. Тик ул хәзер бригадир түгел.

— Ә кем?

— Артавыл Азат халык фиркасенең генеральный секретаре.

— Оһо!

— Президент коммунистлар партиясен япкач, Бутаушев әфәнде парторг бүлмәсен сургычлап куйды. Хәзер бәләкәй генә урынга тәгаенләнгән кеше дә мотлак аның иләге аша үтәргә тиеш. Шулай булгач, дускаем, зинһар, мине гафу ит инде...

Рәис яныннан чыккач, Бутаушев әфәндене эзләп киттем. Ул үзенең коттеджында бразилия кофесы эчеп, япон телевизоры карап утыра иде.

— Демократиягә кабер казучыларга коммунистик сәлам! — дип, мыскыллап каршы алды ул мине.

— Кабер түгел, баз... ягъни бәрәңге ямы казучы мин. Фетнәче түгел...

— Ярар, ярар, акланма. Судта акланырсың.

— Судка барып җитәрлек гаебем юк.

— Коммунистлар бөтенесе дә гаепле, бөтенесе дә җинаятьче. Лениннан башлап! Әйе, хәтта ул да! Шуңа күрә клубтан Ленин сурәтен алып ташлап, аның урынына Рим папасыныкын элеп куйдык. Ә папа астына хәрефләр белән Коръән сүрәсен яздык.

— Нигә алай иттегез?

— Чөнки без яңача фикерлибез. Үзебезнең авыл исемен дә яңа фикер нигезендә үзгәрттек. Беләсеңме, ул хәзер ничек атала? Санкт-Артавылбург! Ленинградны Санкт-Петербургка алмаштыру хөрмәтенә шулай яңарттык.

— Бу яңарыш нәрсә бирә инде сезгә?

— Санкт-Петербургка яуган чит ил ярдәменнән безгә дә, бәлки, акмаса да тамып куяр. Шундый өмет белән Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар истәлегенә утыртылган бакчага Ак йортны саклаучылар исемен бирдек. Менә шулай, энем, җинүче демократиягә хөрмәтебез зур безнең. Ә бу хөрмәт җимешләрен тиздән үзебезнең партия әгъзаларына бүлеп бирәчәкбез.

— Нәрсә бүләргә итәсез соң?

— Колхозны! Аны бүлеп, таратып бетергәч, тарихта беренче булып авылыбызга президент сайлаячакбыз. Минемчә, бу урынга миннән дә лаеклы кандидатура юк. Шулай бит?

— Шулай шул,— дигән булдым мин, аны ирештереп.— Сине Артавылга гына түгел, Аргентинага да президент итеп куярга мөмкин.

— Аргентина? Кайда ул авыл?

— Һи, шуны да белмисеңме?! Хәер, президент буласы кешегә аның ни кирәге бар! Советникларың белсә, шул җиткән.

— Ә син минем советнигым буласыңмы?

— Юк! — дип кырт кистем мин.— Андый эшкә башым җитми.

Бәй, шулай дими, нәрсә әйтим... Инде менә шундый генсекларның «акыллы җитәкчелеге астында» эшлисе генә калды! Тәүбә-тәүбә, мондый президентның советнигы булып утырганчы, эшсез йөрүең мең артык!..

Шундый уйлар белән мин туган авылымнан чыгып киттем. Хезмәт биржасына барып, эшсез кеше дәрәҗәсендә регистрацияләнергә булдым.

Биржага керсәм, үз күзләремә үзем ышанмый торам: элекке райком секретаре колачын җәеп каршы алмасынмы!

— Рәхим ит, хөрмәтле эшсез әфәнде! — диде дә мине үзе артыннан ияртте.

Райкомны япкач, яңа оештырылган хезмәт биржасына директор булып урнашкан икән ул. Элек бергә эшләгән иптәшләрен, давыл вакытында чебешләрне канат астына алган тавык шикелле, үз янына җыйган.

— Син генә калган идең.— Ул мине бик зур өстәл янына алып килде.— Менә синең яңа эш урының.

— Нәрсә эшләргә тиешмен соң мин? — дип сорадым аңардан кыяр-кыймас кына.

— Үзең белгән эшне башкар: кәгазьләр актар, телефоннан сөйләш,— диде иске һәм яңа шефым эшлекле кыяфәттә.— Тагы шуны исеңдә тот: хәзер синең хезмәт хакың ике тапкыр артык булачак.

Бигрәк шәп илдә яшибез дә инде. Нәрсә генә юк бездә! Эшсезләргә ярдәм итү өчен ачылган хезмәт биржаларына тиклем бар хәтта. Эшсезләр ишәйгән саен, биржалар күбәя. Биржалар күбәйгән саен, эшсезләр кими. Чөнки алар биржага эшкә урнаша. Болай барса, безнең илдә беркайчан да эшсезлек булмаячак!

Мин, шуны уйлап, совет кешесенә генә хас горурлык белән үземнең яңа эш урыныма утырдым.

♣♣♣

# ТАРИХЫБЫЗ ХАТИРӘЛӘРЕ

Безнең эрага кадәр 100—75 меңьеллыклар — Идел буена һәм бүгенге Татарстан җиренә беренче борынгы кешеләрнең килеп яши башлавы.

Безнең эрага кадәр IX—III йөзләр — Көнчыгыш Европада һәм Идел-Кама буйларында иң атаклы археологик мәдәниятләрдән булган Ананьино культурасы дәвере, борынгы төркиләрнең матди һәм рухи мәдәнияте белән бәйле булган әһәмиятле тарихи заман.

375 ел — дөньядагы иң зур төрки кабиләләрнең — сөннәрнең (гуннарның) берләшеп, Идел буеннан Рейн елгасына кадәрге җирләрне биләгән куәтле империясе төзелү. Аның иң кодрәтле патшасы АТТИЛА 434—453 елларда тәхеттә утыра.

552—745 еллар — Төрки каханлыгы яшәгән заман. VII йөз башыннан икегә бүленеп, Көнчыгыш Төрки каханлыгы халкының зур өлешен борынгы татар(«Утыз татар», «Тугыз татар») кабиләләре тәшкил итә.

632—642 еллар — Азов диңгезе буенда Кубрат хан җитәкчелегендә Бөек Болгар дәүләте яшәгән дәвер.

650—965 еллар — Түбән Идел һәм Төньяк Каспий буйларында Хәзәр каханлыгы заманы.

VIII-X йөзләр — Көнбатыш Себердә борынгы татар кабиләләре җитәкчелегендә Кимәк каханлыгы яшәгән заман.

IX йөз ахыры-X йөз башы — Идел-Кама буйларында Болгар мәмләкәте оешу.

922 (һиҗри белән 310) ел — Болгар илендә Алмас патша җитәкчелегендә рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү.

1236 ел — Болгар мәмләкәтенең мангул гаскәрләре тарафыннан басып алынуы.

1243 ел башы — татарның бөек дәүләте Алтын Урда (Җучи олысы) төзелү. Бу дәүләтнең иң атаклы ханнары: Бату (1243—1255), Бәркә (1256—1266), Үзбәк (1312—1342), Җанибәк (1342—1357), Туктамыш (1380—1398), Олы Мөхәммәт (1422, 1424—1438).

Алтын Урданың кодрәтле әмирләре Нугай, Мамай, Идегәй (1352—1419 елларда яши).

1380 ел, 8 сентябрь — Алтын Урда белән Урыс дәүләте арасында Куликово сугышы.

1420—1430 еллар — Нугай Урдасы оешу.

1430—1440 еллар — Алтын Урданың таркалуы.

1429—1598 еллар — Себер ханлыгы яшәгән заман.

1434—1502 еллар — Олы Урда (Бөек Урда) яшәгән дәвер.

1443—1783 еллар — Кырым ханлыгы яшәгән чор.

1452—1681 — Касыйм ханлыгы яшәгән заман.

1459—1556 — Әстерхан ханлыгы яшәгән дәвер.

1445 елның 1 (14) октябре — Казан ханлыгы оешу. Аның иң атаклы ханнары: Мөхмүт (1445—1465), Ибраһим (1467—1479), Мөхәммәтәмин (1487—1497, 1502—1518, Сафагәрәй (1524—1549). Зирәк ханбикәләре Нурсолтан һәм Сөембикә, бөек карачылары Булат һәм Нургали Шириннәр, олуг сәет һәм шагыйрь Колшәриф.

1506 елның 22 мае (5 июне) — 50 меңлек татар гаскәренең 100 меңлек урыс гаскәрен тар-мар итүе.

1551 елның 11 (24) августы — Сөембикәне улы Үтәмешгәрәй хан белән Мәскәүгә әсирлеккә алып китү.

1552 елның 2 (15) октябре — Казан ханлыгының Явыз Иван илбасарлары тарафыннан яулап алынуы, татар халкына каршы геноцид (милли юк ителү) башлануы.

1558. Сөембикәнең туганы, Нугай Урдасы бие Гали Әкрам җитәкчелегендә Казан ханлыгын тергезүнең уңышсызлыкка очравы.

1615—1619. Җангали җитәкчелегендә татарның милли азатлык көрәше.

1670—1671. Татарларның Степан Разин күтәрелешендә азатлык өчен көрәшүе.

1708. Казан губернасы төзелү.

1774. 12 (25) июль. Пугачевның Казанны алуы.

1804. Казан университеты ачылу.

1886. 13 (26). IV. — 1913. 2 (15). IV. Татар халкының даһи шагыйре Г. Тукай яшәгән вакыт.

1905—1907. Татарда милли азатлык хәрәкәтенең яңа зур күтәрелеш еллары. Бу хәрәкәтне өзерләүчеләр һәм аңа җитәкчелек итүчеләр: Исмәгыйль Гаспралы (1851—1914), Габдерәшит Ибраһимов (Рәшит казый, 1850—1944), Галимҗан Баруди (1857—1921), Риза Фәхретдин (Риза казый, 1859—1936), Габдулла Бубый (1871—1922), Муса Биги (1875—1949), Йосыф Акчура (1876—1935), Гаяз Исхакый (1878—1954), Садрый Максуди (1879—1957). Шушы дәвердә Бөтен Русия мөселман корылтайлары үткәрелү.

1905—1914. «Иттифак әл-Мөслимин» яшәгән еллар.

1917. Татарда милли азатлык хәрәкәтенең яңа баскычы, Бөтен Русия мөселманнарының яңа корылтайлары үткәрелү (Мәскәү, 1—11 май, Казан, 21—31 июль).

1917. Декабрь. Уфа шәһәрендә Милләт Мәҗлесе үткәрелеп, «Идел-Урал штаты» төзелү (1918 елда большевиклар тарафыннан таркатыла).

1920. 27 май. Татарстан АССР төзелү.

1990. 30 август. Татарстан Җөмһүриятенең (Татарстан ССР) суверенлыгы игълан ителү.

1992. 21 март. Татарстан Республикасының бәйсез дәүләт булып яшәве кирәклеген раслап, җөмһүриятебездә бөтенхалык референдумын үткәрү.

1992. 19—21 июнь. Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессы үткәрелү.

# РӘСӘЙ ИМПЕРИЯСЕ ТАРИХЫННАН

Милләтара мөнәсәбәтләргә багышлап, «Правда» газетасы (3. IV. 1989) уздырган «түгәрәк өстәл» тирәсендәге әңгәмәләрнең берсендә СССРның халык рәссамы Илья Глазунов алдын-артын уйламый гына «Русия — колонияләре булмаган бердәнбер ил» дип ычкындырган иде. Хәер, моңа беркем дә гаҗәпләнмәде. Чөнки андый фикерләр бүген генә тумаган, җәмгыятебездә алар шактый киң таралган, аны «барлык заманнар һәм халыклар» юлбашчысы хакимлек иткән чорларда да шулай диләр иде. Хәзер дә бик төпченеп тормыйлар.

Төрле төстәге «ямаулыклардан» торган географик картага күз салыйк: союздаш республикалар, автономияле республикалар, автономияле өлкәләр, милли округлар — элекке Русия империясе кыйпылчыклары. Барысы да статус буенча, барысы да дәрәҗә буенча. Беренче сортлы, икенче сортлы һ. б. Бу республикаларның кайберләре Союзга чыннан да үзләре теләп кушылгандыр, бәлки, икенчеләрен «үгетләргә» туры килгән, өченчеләре — Балтик буе илләре Сталин белән Гитлер арасындагы килешүнең җәнҗаллы беркетмәсе нәтиҗәсендә «кергән», дүртенчеләре...

Тарих яңгыравыклы сүзләр ярата. Русия тарихында «колония», «яулап алу», «экспансия» кебек төшенчәләрне табу кыен. Анда «яңа җирләрне үзләштерү», «кушу», «кушылу», «үтенече буенча», «составына кергән» кебек тегъбирләргә өстенлек бирелә.

Русия империясенең яулап алулары Совет тарих энциклопедиясе мәгълүматлары буенча түбәндәгечә бара:

1364 — Коми җирләре Мәскәү князьлегенә бәйлелеккә эләгә.

1478 — Карелия Россия составына «керә».

1552 — Казан ханлыгы яулап алына.

1557 — Адыгея, Башкортстанның күп өлеше, Удмуртия тулысы белән Россия дәүләте составына кертелә.

1630 — Бурятия һәм Якутия Россия составына кертелә.

1654 — Переяславль радасы Украинаның яңадан Россиягә кушылуы турында карар кабул итә.

1721 — Эстония, шулай ук Видземе, Ништадта төзелгән тынычлык килешүе буенча, Россия империясе составына кушыла, ә Речь Посполитая бүленгәннән соң, Латвия территориясенең калган өлеше дә Россиягә кертелә.

1731 — Казагыстанның «үзе теләп» Россиягә кушылуы башлана.

1756 — алтайлыларның «үтенечен канәгатьләндерү йөзеннән» Таулы Алтай Россия составына керә.

1771 — Калмык ханлыгы яшәүдән туктый, ул Әстерхан губернасы составына кертелә.

1774 — Төньяк Осетия, Олы һәм Кече Кабарда Россия кулына төшә.

1783 — Кырым Россия составына алына.

1792—1793 — Яссы килешүеннән һәм Речь Посполитаяның икенче тапкыр бүленүеннән соң, Молдавиянең сулъяк ярдагы җирләре, ә 1812 елда Бессарабия Россия өлешенә тия.

1771—1795 — Речь Посполитая бүленгәч, Белоруссия җирләре Россия өлешендә кала.

1801 — Көнчыгыш Грузияне һәм Көньяк Осетияне Россиягә кушу үткәрелә.

1805 — Карабах ханының яклау сорап мөрәҗәгать итүе нәтиҗәсендә Таулы Карабахны Россиягә кушалар.

1810 — Ингушлар «үзләре теләп» рус дәүләтенә керә.

1810 — Абхазия Россиягә кушыла.

1826 — 1828 — Көнчыгыш Әрмәнстанны Россиягә кушу тәмамлана.

1863 — 1864 — Көнбатыш Грузияне кушу үткәрелә.

1863 — Төньяк Кыргызстан Россия составына керә.

XIX гасырның 60 еллары — Казагыстан җирләрен Россиягә кушу тәмамлана.

1865—1873 — Коканд, Бохара һәм Хива ханлыклары (хәзерге Үзбәкстан) яулап алына.

1873 — Хивага каршы походтан соң Каракалпакстан Россия протекторатына эләгә.

1876 — Россиягә Көньяк Кыргызстан һәм Таҗикстанны кушу тәгәлләнә.

1877—1878 — Рус-төрек сугышыннан соң Аҗарстанны Россиягә кушалар.

1885 — Бөтен Төрекманстан диярлек Россия империясе составына кертелә.

1914 — Тува ягы Россия протекторатына әверелә.

Болары 1917 елда большевиклар хакимияте урнашканчы булган «казанышлар». Аннан соңгылары барыбызга да мәгълүм.

Тарихның И. Глазунов һәм аның фикердәшләре танырга теләмәгән сәхифәләре менә шундый.

Материалны **Әхмәт РӘШИТ** әзерләде.

# КҮЧЕНҮЛӘРДӘ ҮЗГӘРЕШ

Халык саны табигый үрчү һәм читтән күчеп килү (механик үсеш) хисабына арта. Табигый үрчү республика халкының милли составына, гореф-гадәтләренә һәм гаиләләрнең матди хәленә бәйләнгән һәм ул, гадәттә, кыска вакыт эчендә кискен үзгәрми. Механик үсеш исә мәгълүм сәяси һәм икътисади максатлар куйган хакимият тарафыннан шактый дәрәҗәдә идарә ителә. Табигый һәм механик үсеш республика халкының тулаем санын гына түгел, аның аерым өлешләре нисбәтен һәм сыйфатын да үзгәртергә мөмкин. Моның нәтиҗәләре тиз арада яшәешнең барлык даирәләренә җитди йогынты ясавы ихтимал. Шушы җәһәттән тикшергәндә, 1991 ел Татарстанга нинди яңалыклар алып килде соң?

Республикабыз халкының механик үсешен чагылдырган түбәндәге таблицадан 1991 елда Татарстанга 98 мең кеше күчеп килүен һәм аннан 87 мең кешенең күчеп китүен күрәбез. Менә шушы ике санның аермасы җөмһүриятебездә төпләнеп калучыларның микъдарын билгеләр. Минус билгеле саннар исә шул милләтләрнең республикабызда кимүен — күчеп китүчеләрнең килүчеләрдән артыграк булуын раслый.

Мәгълүм ки, тоталитар режим чәчәк аткан заманда Союз җитәкчелеге һәм КПСС юлбашчылары СССР милләтләрен механик аралаштыру, урыстан башка халыкларны тарихи ватаннарында да азчылыкка калдыру, аларны зәгыйфьләндерү, туган телләрен һәм мәдәниятләрен кысрыклау сәясәте алып барды. Республикаларның төп милләтен читкә тарату, алар урынына урысларны һәм кайбер бүтән ят милләтләрне күчереп китерү эзлекле рәвештә тормышка ашырылды.

Совет империясенең таркалуы бу хәвефле хәрәкәткә дә чик куйды. Татарстан халкының механик үсешен күрсәткән таблица мәгълүматлары — шуңа бик ачык дәлил. Аннан күренгәнчә, хәзер татарларның Татарстанга тупланы башланган — бер ел эчендә тарихи ватаннарына кайтып урнашкан милләттәшләребез саны 9402 кешегә җиткән.

Милли аң үскән дәвердә һәр милләт үз иленә, үз җөмһүриятенә тартыла — Татарстанда кайбер азчылык халыкларның саны кимүен бары тик шуның белән генә аңлатырга мөмкин.

1991 елда Татарстанда урысларның да гомуми саны арткан. Бу — республикабызда тормыш дәрәҗәсенең матди яктан тирә-яктагы күп кенә төбәкләрдәгедән югарырак булуы, татар халкының башка милләтләргә дустанә мөнәсәбәте нәтиҗәсе.


Башка илләрдә һәм халыкларда, гадәттә, кешенең тарихи ватаны һәм туган җире бер ил була. Татар бу яктан фаҗигале язмыш корбаны. Әмма редакцияләргә килгән үтенеч хатларыннан, Татарстанга җибәрелгән аерым вәкилләрнең гозерләреннән беләбез: фаҗигале язмышын үзгәртеп, җөмһүриятебезгә күчеп кайтырга омтылган милләттәшләребез йөз меңләгән. Аларны ташкын кебек Татарстанга агылудан тарихи ватанында торакка мохтаҗлык, кулай эш табу кыенлыклары гына тыеп тора. Республикабыздан нахак хөкем ителеп яки башка мәкерле алымнар белән кысрыклап читкә тибәрелгән милләттәшләребезнең һәм аларның нәселләренең тарихи ватанында яшәргә хакы бар. Ләкин әле бүгенгә кадәр аларны ата-баба нигезенә кайтару өчен махсус законнар кабул ителмәгән, тиешле бюджет аерып бирелмәгән. Сибелгән, чәчелгән татарның үз иленә җыйналыр көне җитте. Былтырның хисабы бу эшнең башлануын раслый. Иртәгә шушы хәрәкәт тагын да көчәер дип ышанасы килә.

## РЕСПУБЛИКАБЫЗ СТАТИСТИКА ИДАРӘСЕНЕҢ ТАТАРСТАНДА 1991 ЕЛДА ХАЛЫК САНЫНЫҢ КҮЧЕП КИЛҮ-КИТҮ ХИСАБЫНА ҮЗГӘРҮЕ ХАКЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАРЫ*

| милләте | килде | китте | калды |
|---|---|---|---|
| Барысы | 98266 | 87304 | 10962 |
| татар | 55114 | 45712 | 9402 |
| урыс | 31948 | 29937 | 2011 |
| чуваш | 4804 | 4794 | 10 |
| украин | 1079 | 992 | 87 |
| башкорт | 989 | 841 | 148 |
| мари | 969 | 711 | 258 |
| удмурт | 849 | 768 | 81 |
| мордва | 806 | 851 | —45 |
| үзбәк | 323 | 383 | —60 |
| әзербайҗан | 244 | 351 | —107 |
| белорус | 142 | 279 | —137 |
| казакъ | 111 | 111 | 0 |
| әрмән | 91 | 87 | 4 |
| грузин | 73 | 105 | —32 |
| төрекмән | 72 | 116 | —44 |
| немец | 65 | 120 | —55 |
| молдаван | 58 | 40 | 18 |
| яһүд | 52 | 569 | —517 |
| кыргыз | 35 | 59 | —24 |
| таҗик | 26 | 39 | —13 |
| латыш | 19 | 6 | 13 |
| литвалы | 7 | 10 | —3 |
| эстон | 1 | 0 | 1 |
| бүтәннәр | 389 | 423 | —34 |

*Махсус контингент исәпкә керми

# Равил Вәлиевкә 50 яшь



Равил Вәли улы Вәлиев 1942 елның 20 августында Татарстанның Арча районы Яңа Кенәр авылында туа. Ул дөньяга килгәнче үк әтисе сугышка китә һәм анда батырларча һәлак була. Өч бала белән тол калган әнисе тәрбиясендә үскән Равил ул еллардагы авыл нужасын бик яшьли җилкәсенә күтәрә, белем алырга да вакыт таба. Яңа Кенәр урта мәктәбен тәмамлагач, Арча мәгариф училищесында укый, үз авылларында укытучы булып эшли. 1961—64 елларда хәрби хезмәттә була. Аннан соң Казан дәүләт университетын тәмамлап, Казан телевидениесендә редактор булып эшли.

1970 елда Р. Вәлиев Чаллы каласына күченә. «Кама таңнары» исемле газетаның редактор урынбасары булып эшли. Шул ук вакытта әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә. Тиздән аның очерклары, хикәяләре республика газета-журналлары битендә күренә. «Шәһәр булсын бүләгем», «Таяну ноктасы» һәм башка китаплары дөнья күрә.

Р. Вәлиев — 1978 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Ул бүген «Аргамак» журналы редакциясендә бүлек редакторы булып эшли.

50 яше тулу уңае белән каләмдәшебезне кайнар котлыйбыз һәм аңа яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез!

# УЙМАК УЙЛАР

*(Кеше булу турында)*

Вакыт, хезмәт, намус, белем, үз-үзеңә хуҗа булу, кешедәге физик, акыл һәм әхлакый көч — менә ул барлык байлыкларның иҗатчысы.

К. УШИНСКИЙ

Яхшылык кылу хакында сөйләнү — бу әле яхшылык кылдым дигән сүз түгел, уй-фикерләрдә гадел булу — эштә гадел булырга тырышуның күләгәсе бары.

АРИСТОТЕЛЬ

Әгәр кешегә хезмәт итми икән, акыл дигән нәрсә куркыныч әверелә.

СОФОКЛ

Иң элек яхшылыкка өйрән, аннары зирәклеккә, чөнки беренчесеннән башка икенчесен үзләштерү мөмкин түгел.

СЕНЕКА

Хәтта үз-үзең белән ялгыз калганда да начарлык турында уйлау һәм гамәл кылудан сак бул. Башкаларга карый үз-үзеңнән ныграк оялу кыйммәт.

ДЕМОКРИТ

Зур әхлак юк икән, андый җирдә зур шәхесләрнең булуы да шикле.

Р. РОЛЛАН

Җәмгыятьтә яшисең икән, җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел.

В. ЛЕНИН

Кеше җәмгыять өчен яратылган. Ялгыз яшәр өчен аңа сәләт тә, кыюлык та бирелмәгән.

У. БЛЭКСТОУН

Кешене табигать тудырган, ләкин җәмгыять аны үстерә һәм камилләштерә.

В. БЕЛИНСКИЙ

Кешеләр арасында кайнашып кына кеше үз-үзен танып белергә сәләтле.

И. ГЕТЕ

Бүтәннәрдән башка да яшим, дип уйлаган бер ялгышса, миннән башка яши алмыйлар, дип масаючы икеләтә ялгыша.

Ф. ЛАРОШФУКО

Җирдәге бөтен матурлыклар — кояштан, тормыштагы бөтен яхшылыклар — кешедән.

М. ПРИШВИН

Һәрбер кеше — китапка тиң, аны укый белергә генә кирәк.

У. ЧЭННИНГ

Бик тиз генә аңлаешлы кеше, гадәттә, кызыксыз була.

М. ГОРЬКИЙ

Кешеләр беркайчан да тоташтан яхшы яисә тоташтан начар гына була алмый.

Ф. ЛАРОШФУКО

Кешенең кайсы да булса сыйфатын бәяләр өчен, әлеге сыйфатның күпмедер өлеше үзеңдә дә булу зарур.

В. ШЕКСПИР

Үз-үзен өйрәнмәгән кеше башкалар хакында беркайчан да ныклы фикер туплый алмас.

Н. ЧЕРНЫШЕВСКИЙ

Яхшы кеше дигән исем яхшылык эшләүгә карап түгел, начарлык эшли белмәү сәләтенә карап билгеләнә.

В. КЛЮЧЕВСКИЙ

Әгәр эчке матурлык белән яктыртылмаса, бернинди тышкы матурлык та тулы була алмый.

В. ГЮГО

Үзеңне хезмәттән азат итү — җинаятькә тиң.

Л. ТОЛСТОЙ

## ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫНА ҺӘМ ДӘҮЛӘТЛӘРЕНӘ, БЕРЛӘШКӘН МИЛЛӘТЛӘР ОЕШМАСЫНА БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ

# МӨРӘҖӘГАТЕ

19 июнь, 1992 ел — Казан шәһәре

Без, Бөтендөнья татар конгрессында катнашучылар, ата-бабаларыбызның борынгы җирендә беренче мәртәбә җыелучылар, күп гасырлык тарихыбыз, тел, мәдәният, йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез һәм дин уртаклыклыгы нәтиҗәсендә берләшүчеләр, тавышыбыз күп миллионлы татар халкының язмышына битараф булмаган һәр кешенең йөрәгенә һәм аңына барып җитәр дип өметләнеп, сезгә мөрәҗәгать итәбез.

Суверен Татарстан Республикасына исем биргән халык алдындагы бар җаваплылыкны тоеп, шулай ук якындагы һәм ерактагы чит илләрдә яшәүче барлык милләт һәм халыкларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен хөрмәт итеп;

бөтен Җир йөзендә тынычлык һәм татулыкны ныгытырга теләп, сәяси һәм иҗтимагый мәсьәләләрне хәл итүдә көч куллануны кире кагып;

халыкара хокук һәм кеше хокукларының Гомуми Декларациясе кагыйдәләренә омтылуыбызны раслап;

Татарстанны Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы договорлар нигезендә коручы суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты дип игълан иткән шушы елның 21 мартында уздырылган референдум нәтиҗәләренә таянып, без барлык илләрдән, Берләшкән Милләтләр Оешмасыннан Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын, мөстәкыйльлеген тануны сорыйбыз.

Халыкара форумда катнашучылар, татар халкының язмышын, аның бүгенгесен һәм киләчәген кайгыртып, дөнья бердәмлегенең игътибарын, татар мәнфәгатьләренә юнәлтеп, татар халкының улларын һәм кызларын, ватандашларыбызны, кайда яшәүләренә карамастан, милли яңарышның милли-мәдәни тарафына, Татарстан Республикасы дәүләтчелегенең демократик юллар белән урнашуы һәм үсеше хакындагы фикерләр тирәсенә тупланырга чакырабыз.

## ЮГАРЫ СОВЕТ СЕССИЯСЕ

6—11 июль көннәрендә Татарстан Югары Советының унынчы сессиясе үзенең эшен дәвам итте. Анда республикабызда халыкны социаль яклау буенча Югары Совет карарын гамәлгә ашыруның барышы турында, дәүләтнең яшьләр сәясәте турында Закон проектын тикшерү, телләр турындагы Закон проектын икенче укылышта тикшерү, Югары Советның Халык мәгарифе, фән һәм тәрбия даими комиссиясенең эше турында, дәүләт милкен һәм коммуналь милекне хосусыйлаштыруның Дәүләт программасы проекты турында һәм башка мәсьәләләр каралды.

Сессиядә кызу бәхәс һәм фикер алышулардан соң, «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында»гы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү турында» карар кабул ителде, кайбер статьяларның (маддәләрнең) гамәлгә кертелү вакыты билгеләнде.

Унынчы сессиядә республикабызның хокук саклау органнарын Татарстан юрисдикциясенә күчерү турындагы мәсьәлә каралды. Югары Совет киләчәктә республикабыз судларын, юстиция һәм хокук саклау органнарын Татарстан юрисдикциясенә күчерү турында карар кабул итте.

Бу җыенда Татарстанның тышкы икътисади элемтәләр министрлыгы булдырылды. Аның министры итеп Мәскәүдәге Татарстан вәкиллеге җитәкчесе булып эшләгән Шәүкәт Рәүф улы Арсланов расланды.

## ТУГАННАР УРТАК ТЕЛ ТАБА

Узган елның августында Уфа шәһәрендә Татарстан Республикасы белән Башкортстан Республикасы арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелган иде. Аннары бу килешүне һәр ике республиканың Югары Советлары ратификацияләде.

Әлеге килешүнең ратификация грамоталары белән алмашу һәм тугандаш ике республика хөкүмәтләре арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул кую өчен быелның 17 июлендә Казанга Башкортстан Республикасы Югары Советы Рәисе М. Г. Рәхимов җитәкчелегендәге Башкортстан Республикасының рәсми делегациясе килде.

Кремльдә ике республика арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы килешүнең ратификация грамоталарын алмашу һәм Татарстан белән Башкортстан җөмһүриятләре арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул кую тантанасы булды. Тантанада Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев һәм Башкортстан Югары Советы Рәисе М. Г. Рәхимов чыгыш ясадылар.

## СӨЙЛӘШҮЛӘР ДӘВАМ ИТӘ

2 июльдә Казанда Татарстан Республикасы Вице-президенты В. Лихачев җитәкчелегендә Татарстан Республикасы һәм Россия Югары Советы рәисе урынбасары Ю. Яров җитәкчелегендәге Россия Федерациясе делегацияләренең консультатив сөйләшүләре булды.

Бу очрашуда Татарстан белән Россия арасындагы килешүне әзерләү буенча сөйләшүләр алып бару механизмын эшләү максаты куелды. Эксперт группалары дәрәҗәсендә эшне дәвам итәргә кирәклеге турында карар кабул ителде. Ә ул группалар дәүләт-хокук, икътисади һәм социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча төзеләчәк. Әлеге группалар әзерләгән документлар проектын карау шушы елның июль ахырында Мәскәүдә һәр ике якның вәкаләтле делегацияләре составында уздырылды.

Делегация җитәкчеләре сөйләшүләр барышында өч мөһим принциптан чыгып эш иттеләр: Россиянең территориаль бөтенлеге, Татарстанның мөстәкыйльлеге һәм Татарстанның Россия белән союзы.

Әңгәмәләр һәр ике якның үзара аңлашуы, дуслык һәм ачыктан-ачык аңлашу шартларында барды.

Эш комиссияләренең җитәкчеләре Россия Федерациясе дәүләт власте федераль органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт власте органнары эш комиссияләренең очрашу йомгаклары турында уртак коммюнике кабул ителде.

## УНИВЕРСИТЕТТА — ЯҢА ФАКУЛЬТЕТ

Казан дәүләт университетында соңгы елларда экология факультеты, журналистика, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетлары ачылган иде. Шуларга быел экономика факультеты өстәлде. Ул заман өчен бик кирәкле һөнәр ияләрен — менеджментлар әзерләп чыгарачак. Быел яңа факультетка 30 кеше кабул ителәчәк.

Университетның рус филологиясе факультетында яңа ачылачак романо-герман бүлеге дә игътибардан читтә калмас. Бу бүлектә, нигездә, совет немецлары укыячак.

## РӘХМӘТ СҮЗЕ

Мәгълүм ки, 19—21 июнь көннәрендә республикабызда Бөтендөнья татар конгрессы булып узган иде. Шул уңайдан Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев һәм Югары Совет Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин матбугатта рәхмәт сүзе белән чыктылар. Анда Конгрессның дөньяда һәм БДБ дәүләтләрендә җөмһүриятебез турында, хезмәт сөючән һәм кунакчыл халкыбыз турында объектив җәмәгатьчелек фикере булдыруга булышлык итүе турында әйтелә. «Конгресста кабул ителгән документлар — Бөтендөнья татар конгрессының Резолюциясе, Берләшкән Милләтләр Оешмасына Мөрәҗәгате дөньяда аңлау һәм яклау табачагына, татар халкын, аның телен һәм мәдәниятен яңарту хакына тарихи гаделлекне торгызуга булышлык итәчәгенә ышанабыз»,— диелә рәхмәт сүзендә.

## «МӘГАРИФ»: ҖИТМЕШ ЕЛДАН СОҢ КАЙТУ

Халкыбызның китапка булган ихтыяҗын үтәү әлегә кадәр бердәнбер нәшриятка йөкләнгән иде. Ниһаять, милләт таләбен искә алып, Татарстан хөкүмәте Казанда тагын бер дәүләт нәшрияты ачарга карар кылды.

«Мәгариф» дип исемләнгән бу басмаханә татар баласы яшәгән барча төбәкләр өчен уку әсбаплары һәм матур әдәбият китаплары нәшер итү вазифасын үз өстенә ала. Яңа китап нәшриятының директоры итеп журналыбызның редколлегия әгъзасы, язучы Салих Маннапов (Мөдәррис Харис улы Вәлиев) тәгаенләнде. Нәшрият советында күренекле галимнәр, язучылар һәм дин әһелләре бар.

Тарихтагы якты эзе моннан җитмеш ел элек өзелгән (Г. Тукайның барлык китаплары диярлек шунда нәшер ителгән) «Мәгариф» басмаханәсе традицияләрен дәвам итү — әлеге коллективның максаты әнә шундый.

## ЭШЛЕКЛЕ ОЧРАШУЛАР

9—11 июльдә Татарстан Республикасы Вице-президенты В. Н. Лихачев Киевтә рәсми визит белән булды. Ул Украина Президенты Л. М. Кравчукка Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиевнең махсус хатын тапшырды.

Украина җитәкчеләре белән очрашулар һәм сөйләшүләр вакытында Татарстан белән Украина арасында төзелгән ике яклы хөкүмәтара килешү нигезендә икътисади, сәүдә һәм мәдәни элемтәләрне үстерү мәсьәләләре тикшерелде. Хезмәттәшлек турында тулы масштаблы дәүләтара килешүне әзерли башлау өчен экспертларның эш группаларын булдырырга карар кылынды.

Татарстан җитәкчелеге исеменнән В. Н. Лихачев Украина Президенты Л. М. Кравчукка һәм Премьер-министры В. Ф. Фокинга рәсми визит белән безнең республикага килергә чакыруны тапшырды.

* * *

14 июльдә Татарстан Югары Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Халыкара хәвеф» комиссиясеннән бәйсез экспертлар группасын кабул итте.

Массачусетс университетының (АКШ) халыкара хокук профессоры, доктор Херст Ханнум, Лондонда чыга торган «Үзәк Азия күзәтүе» журналы мөхәррире, доктор Мари Б. Броксап, Һиндстанның Җаваһарлал Неру исемендәге университет профессоры Сух. Д. Муни һәм Англиянең Оксфорд университетыннан сәяси фәннәр кандидаты Стефан Салливан көч куллануга каршы чыгучы, этник группалы низагларны сөйләшүләр юлы белән хәл итү ягында торучы халыкара оешма кушуы буенча Казанга килделәр. Алар Татарстандагы хәл турында доклад әзерләү һәм тарату максатын күздә тоталар.

Очрашу барышында Ф. Мөхәммәтшин кунакларга җөмһүриятебездәге сәяси һәм икътисади хәл турында, Татарстанның дәүләт суверенитетын гамәлгә ашыру проблемалары һәм Россия белән үзара мөнәсәбәтләр турында сөйләде, экспертларның сорауларына җаваплар бирде. Ул Татарстанның барлык проблемаларны хәл иткәндә сөйләшүләр юлын гына тануын билгеләп үтте.

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

10 июльдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда Бөтендөнья татар конгрессы, Халыкара Язучылар берлекләре бердәмлегенең оештыру съезды йомгаклары, Татарстан әдәбият фондының бүгенгесе һәм киләчәге, республикабызда иҗат берлекләре турында закон әзерләү, язучыларга матди ярдәм күрсәтү, яшьләрне тәрҗемәчелек буенча Төркиягә укырга җибәрү һәм башка мәсьәләләр каралды.

## ЯҢА ОЕШМАНЫҢ БЕРЕНЧЕ ҖЫЕНЫ

Мәскәүдә Халыкара Язучылар берлекләре башкарма комитетының беренче утырышы булды. Анда яңа оешманы регистрацияләү, әдәби фонд, «Советский писатель» нәшрияты, бердәмлекнең үз гәзитен һәм журналын булдыру кебек мәсьәләләр каралды. Россия Федерациясе Президенты Б. Н. Ельцинга һәм Югары Советы Рәисе Р. И. Хасбулатовка язучыларны социаль яклау турында мөрәҗәгатьләр кабул ителде.

Утырышта Халыкара Язучылар берлекләре рәистәше Р. Мөхәммәдиев һәм башкарма комитеты әгъзасы З. Мансуров катнашты.

## ЯШЬ АВТОРЛАР СЕМИНАРЫ

Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультанты Р. Мингалим, язучылар И. Юзеев һәм Р. Кәрами республикабызның Яңа Чишмә районында яшь авторлар семинары һәм әдәбият сөючеләр белән очрашулар үткәреп кайттылар.

* * *

«Әдәби җомга» атналык гәзитенең 2 сынау саны басылып чыкты.

## АРАЛАР ЯКЫНАЯ

Әстерхан өлкәсендә татар сәнгате атналыгы булып узды. Казан артистлары, язучылары, җыр һәм бию сәнгатенең күренекле әһелләре Әстерханның үзендә генә тукталып калмадылар. Төбәктәге татар авылларына — Киләче, Ташлы Яр, Яңа Болгарга мәдәни сәяхәт кылдылар, андагы эшчеләр, терлекчеләр һәм ашлчә үстерүчеләр, балыкчылар белән очраштылар. Татарстан кунакларын һәр җирдә ипи-тоз, якты йөз белән каршылап, аларның чыгышларын йотлыгып тыңладылар.

## ЗУР БҮЛӘКЛӘР

БМО яклавында эшли торган Бөтендөнья рыцарьлар конфедерациясе турында без инде байтактан ишетеп беләбез. Кеше хокуклары өчен, гуманизм һәм гаделлек принциплары, халыклар һәм илләр арасында тигезлек өчен көрәшкә зур өлеш керткән кешеләр бу конфедерациянең бүләкләре белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев һәм Татарстан Җөмһүрияте Премьер-министрының беренче урынбасары, Татарстан Фәннәр Академиясе президенты Мансур Хәсәнов үзләренең соңгы елларадагы эшчәнлекләре өчен шушы конфедерация бүләкләренә лаек дип табылдылар.

## ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ КӨННӘРЕ

Идел буендагы халыкара лагерьда татар яшьләре көннәрен уздыру матур гадәт булып әверелде. Ул «Азатлык» татар яшьләре берлеге, «Ядкарь» клубы, Татарстан яшьләр оешмалары советы тарафыннан өченче тапкыр үткәрелә. Анда Кырымнан, Казагыстаннан, Төмән, Омск, Чита һәм башка өлкәләрдән, Урал һәм Идел буе республикаларыннан күпсанлы кунаклар катнашты.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1993 ЕЛДА

Татарстан Министрлар Кабинеты, Язучылар берлеге һәм редакциянең хезмәт коллективы тарафыннан чыгарыла торган «Казан утлары» — айлык әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал. Татар телендәге бүтән әдәби басмалар арасында зур күләмле романнарны һәм повестьларны даими рәвештә бары без генә нәшер итәбез. 1993 елда дөнья күрәчәк әсәрләр арасында Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Шайтан каласы», Миргазиян Юнысның «Без — коллар»ы, Әмирхан Еники, Ибраһим Сәлахов, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев һәм башка әдипләребезнең яңа романнары һәм повестьлары бар. Журналыбыз битләрендә барлык әдәби жанрлар да лаеклы урынын алачак. Гамил Афзал, Нажар Нәжми, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Мөдәррис Әгъләм һәм бүтән күренекле шагыйрьләребезнең шигырьләре һәм поэмалары, Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев һәм бүтән драматургларыбызның яңа пьесалары, туган телебезгә, сәнгатебезгә, тарихыбызга багышланган, Татарстаныбызның үткәнен һәм бүгенгесен яктырткан материаллар да сан саен тәкъдим ителәчәк. Габдулла Батталның «Казан татарлары», Алексей Литвинның «Милләтчеләр эше», Нурихан Фәттахның «Борынгы атамалар сере» әсәрләре, Миркасыйм Госмановның, Әбрар Кәримуллинның һәм бүтән галимнәребезнең тикшеренүләре, әдәби мирасыбыз, танылган җәмәгать эшлеклеләребезнең үткен мәсьәләләргә кагылган чыгышлары, укучыларыбызның кызыклы хатлары — болар барысы да замандашларыбыз рухи ихтыяҗын канәгатьләндерүгә хезмәт итәр.

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Журналыбызга Татарстанда, БДБ җөмһүриятләрендә һәм ерак чит илләрдә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. «Казан утлары» вакытлы матбугат каталогларында 73210 индексы белән теркәлгән, аңа язылу бәясе бер айга — 20 сум, 6 айга — 120 сум.

Журналыбызның бер саны үзкыйммәте хәзер 45 сум чамасы, сез түләгән акча, шунлыктан, чыгымның бер өлешен капларга гына җитәр, калган зуррак өлешен Татарстан хөкүмәте тотырыр дип ышанабыз.

Журналга язылуны Элемтә һәм информация дәүләт предприятиесе җирле элемтә бүлекләре ярдәмендә уздырачак. «Казан утлары»на үзегез эшләгән оешмалар аркылы ярты елга тулаем яки аерым айларга кредитка (әҗәткә) язылуны рәсмиләштерергә мөмкин булачак. 1993 елның беренче яртысында журналыбызны алдырырга теләсәгез, быелның август-сентябрь айларында язылып өлгерергә тырышыгыз!

Татарстаннан читтә яшәүче укучыларыбыз игътибарына!

Вакытлы матбугатка язылу бәяләренең еш-еш үзгәреп торуы, бу үзгәрешләрне БДБ республикалары каталогына тиз арада кертү мөмкин булмавы аркасында, «Казан утлары»на 1992 елның икенче яртысына өстәмә язылу да редакциябезгә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында кыенлыклар тудырды. Шушы уңайдан редакциягә тугрылыклы укучыларыбыздан бик күп хатлар, телеграммалар килде, гозерләрен әйтеп, телефоннан шалтыратулар булды. Шул мөрәҗәгатьләрдән соң без журналыбызның күпсанлы укучыларга никадәр кирәкле, кыйммәтле басма булуына тагын бер кат ышандык. Журналны киләчәктә дә даими алдырып тору өчен бик күп көч түккән меңнәрчә укучыларыбызга без ихлас рәхмәтләребезне белдерәбез. Өстәмә язылуның БДБ дәүләтләрендә барган икътисади үзгәртеп кору нәтиҗәсендә өзелүен истә тотып, «Казан утлары»на 1992 ел өчен былтыр ук тулаем язылган Татарстаннан читтә яшәүче укучыларыбызга без, Республикабыз Министрлар Кабинеты матди ярдәмендә, журналыбызның барлык унике санын да җибәрергә тырышачакбыз. «Казан утлары»ның якты нурлары болганчык елларда да милләттәшләребез күңеленә сүнми-сүрелми барып җитсен!

# Мөдәррис Әгъләм

## Сабантуй

*Сабантуйларда да алга карый халык,*
*Көрәштерә башлый нәниләрдән алып.*

Сөлгеләр тотыла, һәр авыл
Батырын күзәтә, билгеле...
Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:
— Бирмә биленне!
— Бирмә-ә-ә...

Дошманнар таптаса җиреңне,
Сорамый: «Син батыр идеңме?»
Мәйдан күк кысыла бар халык:
— Бирмә илеңне!
— Бирмә!

**Тышлыкның беренче битендә:** Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә Каенлыкта (Казан) үткәрелгән сабантуй бәйрәме. Мәйданда — татарча көрәш.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы, Г. Исхакый исемендәге бүләк иясе Рабит Батулла.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәтләре

## КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Башка күп кенә газета-журналлар кебек, матди ярдәм алу өчен, без дә **Редакция фонды** оештырдык. Татарстанда, Россиядә, БДБ дәүләтләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итәбез. Безгә ярдәм итәргә теләүчеләр булса, хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

**420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет № 700161998/2345114 МФО 265005. Для Фонда редакции.**

Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# QAZAN UTLARI
# ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)